
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

3.1999





Әмирхан Еники

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1999

# 3

(917)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Айдар ХӘЛИМ. Татар вакыты. *Кечкенә роман* ..... 5
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Моңым кайтыр басу ягыннан. *Шигырьләр* ..... 43
Рәдиф ГАТАШ. Синең аша—җанкавемнәр эндәшә... *Шигырьләр* ..... 68
Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ. Нигез. *Повесть* ..... 76
Нәҗибә САФИНА. Җанавылда туып үскән без. *Шигырьләр. (Зөлфәт кереш сүзе белән)* ..... 109
Барлас КАМАЛОВ. Пар канатлар талмасын. *(Тәрҗемәче М. Харисовка 60 яшь)* ..... 113
Җәүдәт ИЛЬЯСОВ. Тынлык манарасы. *Хикәят* ..... 114
Луиза ЯНСУАР. Яз төсендә зәңгәр әкият. *Шигырьләр* ..... 146

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ 90 ЯШЬ

Олуг әдибебез бар! *(Аның турында замандашлары, каләмдәшләре)* ..... 48
Әмирхан ЕНИКИ. Шаяру. *Хикәя* ..... 55

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Наис ГАМБӘР. Туксанынчы еллар әдәбияты. *(Анкетага җаваплар)* ..... 149
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Сүзләр, сүзләр ..... 154

ФӘН ҺӘМ ДИН

Аллер ТИМЕРГАЛИН. Пәйгамбәр ..... 159

ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Аның шигърияте озак балкыр әле ..... 170
Шамил МАННАПОВ. Шагыйрь салган күпер ..... 174

ФӘН

Рәшит ГАЛЛӘМОВ. Тарихчы үткән юл *(Салам Алишевка 70 яшь тулу уңаеннан)* ..... 179

Безнең календарь ..... 187
Укучы сүзе ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190
Тышлыктагы сурәтләр ..... 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": Роман А. ХАЛИМА "Татарское время", повесть А. МУТАЛЛАПОВА "Фундамент", предисловие Б.КАМАЛОВА к 60 летию переводчика М. Харисова и рассказ-быль Дж. ИЛЪЯСОВА "Башня тишины" ; стихи И. ГИЛЯЗОВА, Р. ГАТАША, Н. САФИНОЙ (с предисловием Зульфата), Л. ЯНСУАР.
"К 90 - летию А. Еники": современники о творчестве А. Еники и рассказ юбиляра "Шутка".
"Литературная критика": "Татарская литература 90 - х годов" размышления Н. Гамбара; статья Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ "Слова, слова..."
"Наука и религия": статья А. ТИМЕРГАЛИНА "Пророк".
"К 80 - летию А. Давыдова": - статьи К. МИННЕБАЕВА и Ш. МАННАПОВА.
"Наука": "Историку С. Алишеву 70 лет". Статья Р. Галлямова.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
Слово читателя.
На наших обложках: картина художника Р. Имашева "Портрет девушки"; писатель Адлер Тимергалин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": A. KHALIM'S novel "The Tartar's time"; A. MUTALLAPOV'S story "The foundation"; commemorating the 60th annyversary of translator M. Kharisov the preface of B. CAMALOV, the story of D. ILYASOV "The tower of quiet";the verses of I. GILAZOV, R. GATASH, N. SAFINA (with the preface of ZULFAT), L. YANSUAR.
"Commemorating the 90th Anniversary of Yeniky": contemporaries about the creative works of Yeniky; the story of YENIKY "The joke".
" Literary criticism ": "The Tartar literature of 90 years"reflection of N GAMBAR; L. SHAKIRZANOVA'S article "The words, words..."
"Science and religion": A.TIMERGALIN'S article "The prophet".
"Commemorating the 80th Anniversary of A. Davidov": the articles of K. Minnebaev and Sh. Mannapov.
"Science": "Historian S. Alishev is 70". R. GALLAMOV'S article.
Our calendar.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the picture of artist R. Imashev "The portrait of the girl; the writer Adler Timergalin.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.02.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9019 Заказ 3-95
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

---

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.



Айдар Хәлим

# ТАТАР ВАКЫТЫ

КЕЧКЕНӘ РОМАН

## Иртәнге намаз үткәч

—Һәйбәт кешеләр иде, мәрхүмкәйләр...

Мөдәррис өстәл читенә сеңешеп чәй эчеп азапланган әтисенә югарыдан гасаби караш ыргытты. Гүяки әле генә уянган, уянса да саташып уянган һәм һаман да ки саташуын дәвам иткән картның мәңге ерык авызыннан бүген беренче кош булып очып чыккан бу сүзләр аның үзен дә уятып-айнытып җибәргәндәй итте.

—Кемнәр?—диде ул чөкердәп кенә аккан җылымса суда табак-савытларын чайкаштырып.—Кемнәр?

—Кемнәр булсын инде... Коммунистлар...

"Акылдан яза бугай бу".

Көндәлек гадәтеннән чыгып, эшенә бүген дә бераз соңлый төшкән Мөдәррис әтисен беренче тапкыр күргән сыман, күзеннән кичерде. Уң яңагы ирене-ние белән умырып алынган, ясалма тешләре казнасы-ние белән ыржаеп тышка чыккан карт, башын сулга янтайткан да, "Бу кадәр акыллы сүзләрне мин әйттем микән?" дигәндәй, дөньяга гел елмаеп караган авызы белән һавадан кош тотып утыра...

"Чынлап та акылдан язган. Бу вакыйганы көне-сәгате белән хәтердә калдырырга кирәк".

Тукта, ничәнче ел соң әле бу? Югыйсә, аны, йөгрек татар малаен, Соломон Марковичлар очсыз тауар артыннан Рәсәйнең төрле почмакларына чаптырып, зиһенен чуалтып бетерәләр. Ум за разум заходит. Ничәнче гасырда яшәгәнеңне онытмасаң, шунысы да бик җиткән. Чынлап та, ничәнче елда яши икән ул? Мөдәррис үзе язган йөзләгән кәпитәнсәләрдәге датаны күз алдына китерергә тырыша. Әһә, мең дә тугыз йөз дә туксан сигезенче ел бугай. Нинди ай? Тышта кыш инде, кыш. Декабрь түгелме? Юк, күптән түгел яңа елны отмечали. Январь. Әйе, январь. Ничәнче көн, атнаның нинди көне? Боларын Мөдәррис белми иде. Сәгать ничә икән соң әле? Ул сәгатькә караган кебек әтисен күздән үткәзде. Картка исә вакыт бөтенләй кирәкми икән, гүяки ул анардан тәмам ваз кичкән. Әйе, көннәр-төннәр буе өйдә томаланып яткан кешегә сәгать-вакытның нинди әһәмияте бар? Ул майлы бармакларыннан саклана биреп, күлмәк җиңнәрен өскәрәк ышыргандай

итте. Кул беләзегендәге башсыз-күзсез япун сәгате—вакытның электрон җан иясе тугызынчы унбиш минутны күрсәтә икән ләбаса.

Бер кешегә артык иркен, ике кешегә чамасыз кысан, өч кешегә борылырлык та урыны калмаган кухнэдә, Мөдәрриснең әле һаман чапылдап тәлинкә-мазар юып азапلануын исәпкә алмаганда, киеренке, ниндидер ташландык мәҗүсилек, кяфер татарлыгы, кыскасы, фиргавен тынлыгы хөкем сөрә иде. Илтифат биреп тыңласаң, бүлмәнең ис-кос белән исереп кызган һавасында дүрт тарафтагы диварлар, өстәл һәм әтисе утырган өстәл, урындыклар, киштәләрнең дымлы, шома такталары буйлап йөгереш-кән, юынгыч, бихисап савыт-саба, чынаяк, кашык-калак, чәнечкеләрнең елтыр өслекләреннән шуып төшкән, бүлмә аша аркылыга сузылган кер бавында атынганнан соң, ниһаять, ычкынып китеп, гөжләп янган газ мөшкәләренә төшеп, черт-черт куырылган эре таракан, симез кыргаяк яуларының фаҗигале шәйләре шәйләнә. Бирегә күченеп килгәннән алып менә шундый зоопаркта яши алар. Ярый әле, карт аларны не видит. Дару сиптереп, көйдереп тә карадылар югыйсә. Зөмәрәсенә әйтсә, анысы кырт кисә: "Таракан агулыйм дип, үземнең агуланасым юк!—ди ул.—Беренче каттан безне йә югарыга күчер, йә моннан бөтенләй алып кит!"

Бу Ходай Тәгалә җанварлары турында тагын да бер тапкыр эссе сөйләшү кузгалып киткәч, хатыны:

—Минем тараканнарымда синең ни эшең бар?!—дип җикеренде.—Атналар-айлар буе әллә кибет, әллә жегет юлында тырай тибәсең дә, таракан да таракан диеп минем измәмне изәсең! Үрчетеп куйган тараканнарың бардыр? Кагылма, тимә минем тараканнарыма!..

Әйе, шулай, "минем тараканнарым" диде ул. Мөдәрриснең моңа кадәр жир йөзендә әле беркемнең дә бу кадәр аслы шакшы малларны "минем тараканнарым" дип атаганын, тараканнарны да "минеке—синеке"нә бүлешкәнен ишеткәне юк иде. Дөресен әйткәндә, әлбәттә, анықылар алар. Таракан, һәрхәлдә, хатын-кыз юрисдикциясендә үрчи торган мал бит инде. Бәлки ярсып кына әйткәндер бу сүзләрне Зөмәрә. "Юньле ир булсаң, әтиеңнән аерып алып чыгарыең!" дип тә өстәп куйды ул шул әйткәләштә. Менә бит!

Их, Мөдәрриснең китәр җиркәйләре булсамы! Әтисенә кайнар коммунистик сәламнәр җибәреп, социалистик ярышта тагын да зуррак җиңүләр яулавын теләп, җир йөзенең аргы якларына ычкыныр иде! Моның өчен бит бакс кирәк, бакс! Дөрес, бер тапкыр әтисенә фатирны алыштыру турында сүз тишеп карады ул. Йоннары шундук кабарды тегенең: "Әниең гүр иясе булган нигездән кубарырга итәсеңме?!" , имеш.

Монда, әти фатирында яшәүнең тагын бер нечкәлеге бар бит әле: барысы да диярлек бушка! Әйе, кем белән яшәгәнеңне белеп яшә, Мөдәррис Мотаһарович Чанборисов! Бөек Ватан сугышы ветераны, Бөек Ватан сугышы инвалиды, беренче дәрәҗәдәге льготник малае син! Бихисап орден-медальләр кавалерының улы син! Телефон хакы, фатир хакы—яртылаш кына. Анысын да карт түли. Җитмәсә, малае да үсеп килә. Тукта, ничәнчедә укып маташкан була әле ул, Вадим? Өченчедә бугай. Әнисе белән бергә иртәнге сәгать җидедә мәктәпкә чыгып олага ул. Шулай да карт пинсәсенең күпме икәнлеген әйтеп бармый. Яшерә, старый хрыч. Белә Мөдәррис, бер миллионнан да ким түгел. Үзе карунның каруны тагын. Ашау ялына нибары ике йөз мең генә ычкына. А-е-на! Нәрсә инде ул деноминизациягә күчергәч? Ике йөз! Юньле чәйнең әчмухасы да иске акча белән егерме мең торганда, бар син, попробуй, ике йөз сум яңа акчага җан асрап кара! Шуңа күрә Зөмәрә, менә бер ел булыр инде, картны каты паекка утыртты. Калдык-постыкта тота инде шунда. Анысы да шүрәле салкыны. Моңа нәрсә әйтәсең? Ни дисәң дә, хатын-кыз шул. Күңелләре йомшак. "Акчасының калган сигез йөз меңенә ашамлыкны үзе сатып алсын да, үзе әзерләп ашасын!"—ди ул. Килешә аның белән Мөдәррис. Йә, әйтегез, нинди эше бар аның? Кырын ятып,

шул радиосын, ниндидер бәсәреп беткән җыр язмаларын тыңлаудан башка? Менә ни өчен карт әле дә, каткан ипиен кичәгедән калган, инде кискенләнеп, төелгән пыяланы хәтерләткән салкын чәйдә җебетеп ашап утыра. Кая ди ул куян каны кебек куе кызыл төстәге сөтле чәйләр, буы чыгып торган, хуш исләре белән калак сөягеннән үк суырып алган итле сумса, бәлеш, гөбәдияләр!

Шулай да ана бу кеше бик тә сәер күренә бүген. Сәясәтнең ни икәнен үзе генә белеп, тавыш-тынсыз, гомере буе, аю кебек, өненнән чыкмый яшәп яткан әтисе нишләп әле таң тишегеннән коммунистларны мактап утыра?! Соңгы айларда бик тә суырылды үзе. Бәлки озак та тормас.

—Чәй агызыйммы?

Әйе, “ясыйммы?” димәде ул, “агызыйммы?—диде.

—Юк, алтын кисәгем.

Монысы инде Мөдәррискә балачактан таныш: бары тик балаларына гына шулай иркәләп “алтын кисәгем” дип эндәшә ул.

Тырпайган кыска кара чәчле, тар мангайлы Мөдәррис картның бу сүзләренә, кул сәгатенә күз ташлады, аннан ачуы килеп, гадәтенчә, аскы ирене белән өске иренен шундый көчле итеп кымтыды ки, гүя өске ирен шундук ашалды, юкка чыкты, ә менә аскы ирене, танавына кереш сыман тартылып, кушылды һәм аның кәбестә суы сыман аксыл чырае йорт куяныныкы кебек бербөтен танаудан гына торып калды. Кыз-кыркынның эскәкләгән кашына охшаган нечкә кара мыегы белән һавада шомырт кара сызык сызып, коридорга үтте һәм ашык-пошык киенә башлады.

—Мин пош-шол!

—Хуш, алтын кисәгем.

Үзбелдекле келә зеңгелдәп куйды—ишек, бөтен өйне урыныннан кузгатып, шап ябылды. Малаеның саубуллашуы шушы иде.

Карт, гадәтенчә, урыныннан кузгалмыйча, озак кына тынсыз утырды. Кайбер көннәрне төшкә кадәр шулай уйланып утыра ул. Комачаулаучы, салым таләп итүче юк. Уйлый гына бит ул. Бу бит аның балалары кайтып, тынычлыкны бозганчы, үзе теләгәнчә яшәп алу хөррияте. Менә шулай, малаеның кәефенә туры килсә, алар, ике Казан татары, ата һәм ул, икәүдән икәү генә, атнага бер тапкыр булса да үз телләрендә сукалаштырып алалар. Анысына да рәхмәт укый Мотаһар. Кеше балалары бөтенләй сөйләшми диләр. Мөдәррисе өйгә маржа китереп, канны бозмады. Татар кызына—Бондюг кызына өйләнде. Әй, куандылар ул чакта Мотаһар белән Зөлхәбирә! Шулай да, Казан уртасында яшәп, татарча сөйләшүгә зарыга, сусый, коргаксый иде Мотаһар. Килене, әйтүләренчә, ниндидер мәктәптә—литсий диләрме шунда—татар сәнгате буенча сабаклар бирә, имеш. Әмма килененең Мөдәррис белән дә, Мотаһар белән дә татарча сөйләшү түгел, ялгышып, ипилек-тозлык та ычкындырганы юк. Алар әрепләшкәндә дә, урысча гына әрепләшәләр шикелле. Урысча әрләшүнең ни тәме дә, ни яме?! Аңламый, һич кенә дә аешмый Мотаһар: мәктәп кадәр мәктәптә, татарча белмәгән адәм татар сәнгате турында ничек итеп сабак бирә икән? Урыс телендә түгелдер бит инде?! Җитмәсә, Казанда! Килененең аңа бер вакытта да авыз тутырып, “Әти!” йә булмаса, “Папа!” дип тә эндәшкәне юк. Ул ана чүплектә үскән күплектә генә мөрәҗәгать итә: “Идите кушать”. Кем тәрбиясе? Әнисенекеме? Әтисене-кеме? Имеш, әтисе гаиләне Зөмәрәгә дүрт яшь чакта ук ташлап киткән. Зөмәрә ягыннан туйга төп кода булып үги әтисе Николай Иваныч килгән иде. Аерылышканнан соң ике атна да үтми, әнисе шул урыска кияүгә чыккан икән. Уртак кызлары да бар. Анысы Бирәнике исемле. Казанда төзелеш институтында укый диләр. Монда килгәләп йөри ул, шилма. Озын колактан ишетеп, Зөлхәбирәсе сөйләгән иде: әтисе киткәндә Зөмәрә бер генә кәлимә дә урысча белмәгән, имеш. Николай Иваныч аны “Говори по-русски!”—дип көн саен каеш

белән ярган, имеш. Бала шул заманнан алып туган телен йоткан, имеш. Булыр, булыр. Шулай булмыйча. Кәк же, иначе? Дәүләт теле бит ул, иң кирәк тел. Кодагые килгәли, болай ачык кына нәмәстәкәй, әмма бик гасаби күренә. Ә менә Николай Иванычның туйдан соң бу өйгә аяк та басканы юк. Вадимнарының бәби туена да килмәде. Ничек кенә булмасын, килененнән канәгать Мотаһар. Каты бәрелгәне, почмаклатып сүккәне, тавыш чыгарганы юк. Килгән елларында өс киемнәрен дә юа-чайкаштыра иде. Аннан әллә нәрсә булды, үзгәрде дә куйды.

Сәгать ничә икән?

Карт, яхшы ат кебек, колакларын шомрайтты. Залдагы сәгать, әлбәттә, сукмый иде.

## Өйлә намазы алдыннан

Мотаһарның һич кенә дә урыныннан күтәреләсе килмәде. "Коммунистлар һәйбәтләр иде шул...—Ул урындыгында шыгырдап куйды.—Алар барда тәртип иде. Чөнки алар нечкә иде..."

Яшь чагында ничек кенә кодаласалар да, Мотаһар партиягә кермәде. Ул алар кебек яхшы була алмам дип уйлый иде. Соңыннан аңлашылуынча, алар да ялганлаганнар икән. Әмма ялганласалар да, ач-ялангач калдырсалар да, шундый итеп ялганлый, юата белә иде алар—яшиселәр килә иде! Болары, бүгенге домкрат дигәннәре, көне-төне ниткәндер сәтсиәл гаделлек турында чүбек чәйни—ә яшисе килми. Чүбек чәйниләр дә атышалар, чүбек чәйниләр дә үтерешәләр. Коммунистлар өчен урлап булмаган әйберләр бар иде. Болары өчен урлап булмаган нәрсә калмады. Капитализм һәркайда да урлашып кына оеша икән, имеш. Фәлсәфәләрен кара, ничегрәк, ә? Телиләр икән, шушы йортта яшәүчеләрне куып чыгарып, шушы урамны, шушы трамвайларны кесәгә салалар да куялар. Аллаһы әкбәр! Буталып бетте дөньясы: ачтан казан астырма, туктан камыр бастырма. Коммунистлар заманында кеше үтерү иң сирәк, иң олуг җинаять иде. Хәзер кеше үтерүне чебен үтерү урынына да күрмиләр. Киресенчә, чебеннәрне сәтсиәл яклау, кеше үтергән кешеләрне сәтсиәл аклау буенча закуннар кабул итәләр, гөнаһ шомлыклары. Шуңа күрә, кеше үтергән—котыла, чебен үтергән—тотыла. Һәм утыртыла. Вҗәтке бирә алмаса, әлбәттә. Акча янчыгы булмаса, әлбәттә. Картәтисе әйтмешли, биргәнгә—бираешь, бирмәгәнгә—сираешь. Коммунистлар заманында урам себерүче дә, пркарул да, тимер юлчы да, трамвай кондукторы да фурмы-фуражкада иде. Бар, тәртип бозып кара! Фурмыдагы кеше тәртип боза аламыни? Фурмыда булмаган кеше дә юк иде бит, менәтерәк! Фурмы кешене калтыратып тота. Ә боларның сугыш эшләре министрын да гражданский кәчтүндә диләр.

Мотаһарның күңел чәйнүге актарылып кайный, астындагы урындыгы шыгырдап ыңгыраша башлады.

Ә син коммунистларның җырларын, тамаша-бәйрәмнәрен кара! Куып кертеп җырлата һәм җылата иделәр. "Бстабай, страна, агрумная..."—Карт күңеленнән генә көйләп куйды.—Партионный тәртип шундый булырга тиеш тә! Әнә, Ватан сугышындагы җиңүебезне ел саен, җитмәсә, һәр биш ел саен зур итеп бәйрәм итә идек. Фатирлар, машиналар, бүләкләр, медальләр, истәлекле значоклар ала идек. Ә боларның?—Мотаһар лач итеп идәнгә төкереп куйды. Юк, бу мәсьәләгә кагыласы да килми аның!..

Коммунистларның гаиләгә мөнәсәбәтләрен генә ал син. Ничек сакладылар алар ир белән хатын арасын! Ике моржадан төтен чыгаручылар, зиначылар аягы астында келәмнәр дөрләп яна иде, министрлар, янаралларның башлары оча иде! Ә боларның? Тьфу, чурту мәтри!.. Коммунистларның киналары, театрлары, мәктәпләре, балалар бакчалары, җәйге ял лагерьлары! И-их сөйлисең бармы! Ә гаилә төзү, бала үстерү җиңел түгел. Мотаһар белән Зөлхәбирәгә Ходай Тәгалә икене генә насыйп итте, әмма аларның

икесенең мәшәкате, борчылулары унга торырлык булды. Олы кызлары, Фәрдүнә, яшьтән үк бер егет аламасыннан тапалып, йөккә калды. Ярый, Зөлхәбирәгә рәхмәт, Бишбалтага алып барып, бәрәнге парында көмәнен төшертеп кайтты. Аннан нииндидер урыска чыгып матащты. Бер заразный кампаниягә эләгеп, берме-икеме ел утырып та чыкты. Аннан уйнаштан бала тапты. Килгәне дә юк. Хәер, былтыр килеп, мал даулап, өйнең астын-өскә әйләндереп киткән иде. Андый баланның килгәненнән килмәгәне яхшырак. Әйтерсең, тома сукыр Мотаһар урын өстендә түгел, ә рудникта алтын чыгарып ята!.. Ә бит Мотаһар да, Зөлхәбирә дә балаларына бары тик изгелек кенә теләделәр, тәрбияле итәргә тырыштылар. Нишләп, нишләп соң барысы да болай котелмәгәнчә килеп чыкты? Кем гаепле? Юк, үзендә бер генә дә гаеп тапмый Мотаһар!

Зөлхәбирәсе исенә төшкәч, картның күнеле йомшарды. Авыр туфраккайлары жинел була күрсен мәрхүмәнең. Сабын комбинатында эшләгәндә бер юлы аягын һәм кулын сындырып, янбалитлыкка чыккан иде ул. Моннан биш ел элек берсе тома сукыр, икенчесе чатан һәм кулсыз карт белән карчык, нокталы өтер кебек култыклашып, мунчага барган иделәр. Әмма карт, бу каһәрле мунчадан өтерен югалтып, ялгыз нокта булып кайтты. Дөресрәге, мунчаның йөк машинасы китереп куйды аларны. Машина әржәсендә Зөлхәбирәнең өстенә ак тукыма ябылган гәүдәсе иде. Тагын да шул сабын житте Зөлхәбирәнең башына. Хатын-кызлар катына килеп кергәч тә... кулына тас һәм башка кирәк-яракларын тоткан Зөлхәбирәсе...—Карт ирексездән шыншып куйды.—Сабын күбегендә таеп егыла, бизәкле ташка башы белән төшеп, шундук... шундук жан тәслим кыла... Менә шуннан алып ялгыз нокта булып яши ул. Әгәр алар әле утызынчы еллар уртасында Париж Коммунасы урамындагы йортларыннан куып чыгарылмаган булсалар, нәсел килене Зөлхәбирәнең гомере дә коммуналь мунча иданендә өзелмәгән булыр иде, бәлки...

Зөлхәбирә ташлап киткәннән соң бөтенләй авырлашты аның дөньясы. Тәмам азындылар, имансызлар. Өс-башын үзе юып кигән була. Яңа кием сатып алмый. Нигә аңа кием? Кием калыбы, күргәзмә фурмысы түгел бит ул. Килененә ай саен сайрап торган ике йөз меңлекне бирә, килене аны чатнатып санап ала. Кая куялар бу кадәр акчаны? Ике йөз меңгә ипине дә йөз буханка, майны да унбиш кила алырга мөмкин бит! Житмәсә, Ельцин тагын яңа акча уйлап тапты. Өч кенә нульне алып ыргыталар, имеш. Тагын алдыйлар. Динәминәтсия диләрме шунда. Алма син ул өч нульне! Кагылма! Тагын өстә өчне! Без күпме кан койдык ул нульләрне яулар өчен? Ә өстәлдә өч нуль белән дә, өч нульсез килеш тә майсыз тары боламыгы. Таң белән чыгып сызалар да, кичләтеп кенә кайталар. Мөдәррисенең кайтмый калган көннәре дә күп була. Кайчакта унар-унбишәр көн кайтмый. Йөриме? Кайда йөри? Йөресә, Өйрәледә бер кич, Боткалыда ике кич куныл йөриме? Ничек яши алар? Яраталармы бер-берсен? Улы белән килененең бер кайчан да шат көлешкәнен, бер-берсенә иркә сүз әйтешкәннәрен ишеткәне юк. Шулай да кайвакыт бүлмәләреннән кызу-кызу сөйләшкәннәрен абайлаганы бар. Андый чакларда бүлмәсен ябып куя, радиосын, кассеталарын жибәрә Мотаһар. Улының кайда эшләгәнен һаман да юньле-рәтле белми ул. Кәмирсәнт диләр бугай. Сәүдәгәр, димәк. Аның картатасы Казанның бер дигән сәү-дәгәре, бүгенге тел белән әйтсәк, кәмирсәнте иде. Димәк, оныгы бабасы юлыннан киткән? Сәүдәгәр булгач, аңарда акча букча белән йөрергә тиеш бит! Бар, тот капчыгынны. Ул үзе, акча таләп итеп, ай саен әтисен буа. Киле-неннән яшереп, Мөдәррисенә тагын да ике йөз меңне тамызмаса, тегесе аны кан дошманы күрә. Ул хәзер яңа акча белән ике йөз меңне чәлдерергә чамалый, мәлгунь! Бәй, һаман да шул нульләрдә, инде әтисен алдый! Дөнья бер, тормыш бер, акча бер—ә санау ике төрле, вәт әкәмәт, ә? Бирмәячәк аларга өч нульне Мотаһар, ул шул нульләр хакына күзләрен югалтты!

Аның улы мафиуз булып эшләмидер бит? Берәр хәерченең ялчысы,

хәтта тән сакчысы булып чапмыймы ул Рәсәй буйлап? Хәзер бит бәдрәф юучының да тән сакчысы бар диләр.

Картның тәне тартышып куйды.

Мафиуз булса, үз өендәгеләрен таламасын ул. Киресенчә, өенә алып кайтсын. Ә өйдә бар җиһаз Мотаһарныкы. Улы бүген йөргән машина да Мотаһарга ваянкамат биргән маядан—"Запарай"дан башланды. Фатир—бушка, телефон—бушка. Рәхәт бит дөньялар! Мафиуз булса, әнә, картәти-сенең Париж Коммунасы урамындагы ике катлы кибет бинасын кайтарып алсын. Акыллы кешеләр шулай итә бит. Сораштырып тора Мотаһар: аларның газиз бинасында әле булса "Хуҗалык тауарлары" кибете сату итеп ята.

Өстәвенә, бердәнбер балаларын да юньле-рәтле тәрбияли алмыйлар. Аһ, ул Вадим! Җәһәннәм кисәве! Исемен каян тапканнар диген. Киңәшләшү-нитү юк. Менә сиңа оның дисәң дә, оның! Эсникерснең эсникерсе!—Карт кайвакыт телерекламадагы үзе аңламаган сүзләрне сүгенү сүзләре итеп куллана иде.—Чупа-чупс! Үткәндә-сүткәндә этмичә-төрмичә үтәлми ул. Мәктәптән кайтып та керә, телевизор карарга комачаулый дип сикереп менеп, ярыйсы гына йөреп яткан кәккүкле сәгатьне туктата. Зөлхәбирә бар чакта алай ук узынмый иде әле. Сәгатьне генә чалышайтамы ул? Юк, урыныннан кузгатып, бөтен дөньяны чалышайта, тормышны кузгата ул, башкисәр. Төзек булып та йөретелмәгән сәгать—туктатылган тормыш бит ул. Җинаять! Сәгатең ватылып, вакытың буталса, тормышың да бутала, мин сиңа әйтим. Менә ни өчен көнгә чыкса шул сәгатьне турайтып, кире урынына җайлаштырып, хәрәкәткә җибәрү белән мәшгуль Мотаһар. Ә ул сукыр кешегә җиңел түгел. Күзлеләргә кәккүкле стена сәгате кирәкми, әлбәттә. Аларның һәркайсының сәгатьләре беләзекләрендә. Вакытлары бик якында, үзләре белән булгач, әтиләре ерагая; хәлен белергә вакытлары җитми; кермиләр дә, чыкмыйлар да. Теге башкисәр генә керә. Керә дә, мендәр-ястыкларны идәнгә ыргытып, ауный да башлый. Бар, әйтеп кара. Җавабы бер генә: "Дурак!" Татар мәктәпләре хәзер бихисап, баланы татар мәктәбенә бирегез дип еландай телләрен чыгарып инәлде Мотаһар. Юк, тыңламадылар. Җитмәсә, кесәгә кереп, акчаны да шылдыргалый, шилма. Шундый бер хәлдән соң ишегенә шартлатып йозак куйдырды Мотаһар.

Икенчеләрен табу турында уйлап та карамый шикелле алар. Киленен төскә-башка бик чибәр диләр югыйсә. Нигә бала үстерергә яратмый икән бүгенге хатыннар? Ач-ялангач та түгелләр. Электр яктысы комачаулыймы? Ач-ялангач халык чыра яктысында унарны—һәм ниндиләрне!—үстергән дә бит. Әнә, әниләре Мәрфуга абыстай гомерендә унтугыз тапкыр гына корсак күтәргән. Тугыз айга тапкырлап кара әле син аны. 171 ай, ундүрт ел була түгелме? Димәк, унсигездән соң егерме алты ел гомеренең ундүрт елын көмән күтәреп кенә үткәргән. Әтиләре Хафизның кибетен тартып алып, өйләреннән дә куып чыгаргач, алты балалы гаилә Бишбалтадагы туганнарына барып сыенды. Шул шартларда да тагын өч бала тапты әле ул. Сабир энекәшләрен, төпчекне, тудыра алмый өч көн газапланды. Ниһаять сабыйны кендек әбиләре бау белән тартып алганнар...

Картның жылыйсы килеп китте. Кулыннан килсә, ул туйганчы, үксеп-үксеп елаган булыр иде. Юк, аның сукыр күзләренә яшь типми дә, куып та җитми. Их, бер генә тапкыр куып җитсен иде аны күз яшьләре!..

Урындыгы тагын да шыгырдап куйды. Гасыр давыллары юшкын булып утырган сәлбер бугазыннан яшелле-күкле аһәңнәр ничектер иңрәп, төнге шәүләгән тавышы сыман куркыныч аваз өзелеп чыкты:

—Һәйбәт кешеләр иде, мәрхүмкәйләр!..

Гүяки бүлмәдә тагын да кемдер бар иде. Гүяки шул кемдер аңардан сорады:

—Кемнәр?

—Үз-зем беләм!—дип кычкырып җибәрде үз-үзе белән сөйләшкән

карт һәм шалт итеп өстәлгә йодрыгы белән сукты.—Сорашмагыз, үзем беләм!..

Күнел чәйнүге кайнап, тәмам актарылып чыккан иде шул Мотаһарның. Кинәт анын су буена барасы, агымсуларга карап, аккан суларны тынлап күнелен тынычландырасы килде. Яшь чагында, якты дөньяны үз күзләре белән күргән заманнарда, ул кайгыларын агымсуларга бушатырга ярата иде. Хәзер анысын да эшли алмый. Акчага ничә генә нуль өстәсәләр дә мөмкин түгел бу. Хәер, бүгенге Казанда, тынчу сулар патшалыгында, шарылдап аккан суларны каян табасын? Ярый әле, Мотаһарнын беркем дә тартып алалмый торган өч байлыгы бар: көне—үзенеке; артык чая, бай булмаса да, фикере—үзенеке; сәгате булмаса да, вакыты—үзенеке.

Бер урында утырып та тәкатьсезләнә ул. Бер бүлмәдән икенче бүлмәгә күчену анын өчен кыйтгадан кыйтгага күчену, олуг бер сәяхәткә тиң. Фатирындагы бүлмәләр төрле булган кебек, икенчесенә күченеп утыргач, аңа бөтенләй икенче уйлар-фикерләр килә. Менә ул буыннарындагы тоз утырымнарын, ырматизларын шыгырдатып, урыныннан күтәрелде, бераз артка чигенде, каршы якны куллары белән сәрмәп, күкрәге белән диварга елышты һәм артыннан авыр гер өстерәгәндәй, аякларын алмаштилмәш алыштырып, тезләрендә сак кына сиртмәләнеп, залга таба юнәлде. Дөресрәге—шуышты. Әйе, бүлмәдән бүлмәгә үтү анын өчен барлык малтуарын, мөлкәтен, һавасын, жирен иңенә төяп күченүгә тиңләшә иде. Гүя ул, бер каргалган, атсыз-арбасыз мөһәжир, Әфганстаннан Рәсәйгә контрабанда белән яшерен мөлкәт үткәрә. Гүя анын сәяхәтен күктән, анын шаукымлы, галибанә нурларда уйнап торган үзәгеннән, ниндидер азат, якты караш, жете зәңгәр күзләр күзәтә бара. Бу караш аны юата да, сискәндерә дә иде. Әйе, анын өчен кухнә, ванна бүлмәләре, зал һәм үз хөжрәсе—карт бүлмәсен шулай атый—барысы да үзенә генә хас исекосы, жиһазы, жылысы-суыгы, каны-жаны һәм һава басымы булган аерым яшәү божрасын хасыйл итә. Бер бүлмәнең яшәү божрасыннан икенчесенә күчкәндә ул гүяки шушы божрадагы чынбарлыкны гына түгел, ә бәлки аякларына тагылган гер кебек авыр язмышын, иске йөк арбасы кебек чалшайган, калтайган, сынган-сыналган, катырак жил иссә дә таралып китәргә торган гәүдәсен дә өстерәп керә. Әнә сез анын кайчандыр озын, нарат бастырык кебек туры гәүдәсен каплаган сәләмә, бәлки Гагарин галәмгә менгән көннәрдә сатып алынган һәм күп тапкырлар эре атлатып ямалган өс киеменә—сәдәф-каптырмасыз калуы аркасында гаурәт изүе ачык йөргән, аннан исә кайчандыр актан-ак, хәзер исә озак юылмау нәтижәсендә билгесез бер төскә кергән эчке ыштаны да күренеп торган чалбарына, шул ук йөк арбасы кебек канатлы иңнәреннән тезләренә кадәр салынып төшкән бәйләм кофтасына игътибар итегез. Әнә сез анын кайчандыр бик көчле, тотса тимер өзгән, хәзер инде хәлсез генә дивардан шуышкан кул чукларына, кайчандыр куәтле йодрык булып укмашкан бармаклар тәлгәшенә, кул чугынын беләккә әверелә башлаган төшенә игътибар итегез. Ничектер беләзексез, туры таяк рәвешендә тоташкан алар. Гадәттә мондый буынсыз тоташу сабый чактан ук авыр эштә изелгән, көненнән алда тәртә арасына жигелгән кешеләрдә очрый. Көзге янгырларда диварга ләпәшкән сары усак яфрагын жил билгеле бер ритм белән калтыратып шудырткан кебек кенә шудырта бу беләзексез беләкләр анын уч төбен. Әйтерсен, ул уч төпләре белән бетон—диварга тавыш-тынсыз хат яза. Үзе белемсез булса да, күп нәрсәләрне белә ул. Кешелеккә гыйбрәт итеп язасы серләре күп анын. Зал ишегенә житәрәк анын картайган тын юлларын француз ислемаенын килененнән көндәлек мирас булып кала торган затлы, ифрат та газаплы һәм нәзакәтле исе буып алды. Бу үкенечле хуш исләрне ул гүяки ишетә дә, күрә дә иде. Алар гүяки картны ят тормыш божрасына алып кереп яшәртә. Әмма ул яшәрүдән курыккан күрәзәче-шаман кебек, кисәк кенә борылды, сул кулы белән ишек янагына тотынып, уны белән ишекнең үзен эчкә этәреп, аяк дигәннәрен ванна бүлмәсенә күчерде. Ислемай исен биредә

тәмәке исе алыштырды. Нигә тартадыр инде Мөдәррисе ванна бүлмәсендә? Моны корчаңгы атлар өчен газ камерасы итәргә мөмкин!..

Улы утны сүндереп китәргә оныткан иде. Ванна көзгесендә әвәлдә картның шәрә башы, чалыш авызы шәйләнде, аннан бу баш, бу авыз аркылы-торкылы бауларга килене элеп киткән керләргә кереп адашты. Кер исе аны көтмәгәндә генә сабый чагына кайтарды. Әйе, бала чагыннан ук җилдә тутлаган кер исен, бауларга кер элгән хатын-кызларны күзәтеп торырга ярата иде ул. Мотаһар керләрне аерым бер сагыну, аерым бер юксыну белән исни, капшый, сыйпый башлады. Әйтерсең, аңа кемдер пышылдый иде... "Татар хатыннары кием-салымның эчен тышка әйләндереп, җөйле ягын тышта калдырып, чайкаганда да шул уңайга чайкап, ә маржалар исә әйләндереп-нитеп тормыйча, тышкы ягы белән юалар да, шул килеш эләләр. Җөйләре эчтә кала. Ни өчен? Җөйле ягын тышка каратып элгәндә кояш нуры киемнең сабын да алып бетмәгән керен ашый... Эчкә каратып элгән хәлдә кояш киемнең төсен-буяуларын ашый..." Ышанасызмы, нәкъ илле елдан соң аңа әнисе, газизләрдән газиз әнкәсе пышылдый иде!.. Биредәге керләр тышкы ягы, җөйләре эчтә калдырылып эленгән иде. "Киленебез пашпорты буенча гына безнеке икән, җаны белән маржа икән,—дип сөйләнеп алды карт.—Маржа икән!.."

Мотаһар абзыйның пеләш башы ниһаять керләрдән арынды һәм аның кыяфәте саргылт, дымлы һава аша саркылып, ачылганнан-ачыла барды, көзгегә үк килеп төртелде. Ул сул кулы белән ванна эчен капшады, анда бер нәрсә дә юклыгына ышангач, билен турайтты һәм кранны эзләп табып, борып та җибәрде!.. Аннан шарлап һәм җырлап, үксеп һәм гыжгылдап су ташкыны бәреп чыкты. Су агымында нинди сер, нинди ләззәт! Краннан аккан су—ул, әлбәттә, өтермә, тоткынлыктан килгән су, әмма барыбер, табигать баласы буларак, үз холкын тәмам югалтып бетерми һәм бикле торбада да җырларга тырышып маташа. Су гаугасы колның да кайгысын баса, авыруның да авыр уйларын агызып алып китә. Ә ул алып киткән кайгылар, уйлар соңыннан кая була, агымсу алар белән нишли икән? Капма-каршы уйлар, кешеләр кебек, бер-берсенә каршы фетнә күтәрмиләрме? Чәнти бармак кына сыярлык торбадан ваннага аккан су аның өчен гәлсәр агымсулар, бәллүр чишмәләр, чиксез дәрья, океаннар иде. Мотаһарның сул теш казнасы көзгедә ыржаеп куйды—бу аның елмаюы иде. Карт башын бераз янтайтып, су тавышын тыңлый, кайнап ташыган күңелен агымсуларга бушата иде...

...Әтисе Хафиз Казанның черегән бае булмаса да, төшеп калганнарыннан да түгел иде. "Онытмагыз, без атаклы Җан Барыслар нәселеннән!—дип күкрәк кагарга ярата иде әтисе кәефле чакларында.—Җаны Барыска "оф" өстәп, аны урыс кына имгәтте. Без—Җанбарыслар! Явыз Иван инде Казанга кергәч, иң соңгы Алып булып калдыра безнең бабабыз изге шәһәрне! Мамадышка чигенеп, ике ай буе сугыша ул урыс белән. "Кама-лышта калганда сез дә иң соңыннан чыгыгыз,—бала Җан Барыслар!" Бар, чыгарсың монда иң соңгы булып! Иң Беренче булып качабыз! Мотаһарның хәтерендә, 1929 елда—аңа дүрт яшь иде инде—яңа хакимият әтисенең кибетен тартып алды, гаиләне йортыннан куып чыгарды. Париж Коммунасы урамындагы кибетләренә күптән түгел барып та кайтты әле ул. Дөресрәге, күршесе Сәфәргали бер ярты аракы ялына алып барып кайтты. Андагы "Хуҗалык тауарлары" чыштым-пыштым гына булса да сату итеп яткан була. Бинаның диварларын очлы ак таягы белән тукылдатып та, сабый чакларын эзләгәндәй, сыйпап та, иснәп тә карады—бар, шактый нык әле ул таш пулат! Ә менә семәрле сәндерәсе Печән Базарына чыгып торган йортлары инде юк икән. Их, Мотаһар бераз гына яшьрәк булса, таза булса!.. Кайтарып алган булыр иде ул кибет бинасын. Ә Мөдәррисенә, эт ялкавына, кирәкми. Шул да булдымы мафиуз, шул да булдымы сәүдәгәр—мәми авыз!..

Гаиләләрен сөргенгә кумадылар кууын. Берсеннән берсе бәләкәй алты баланы җитәкләп, Бишбалтадагы бертуган энесенә барып елышты

әтисе. Хәзерге күзлектән караганда, гайрәт белән шом кушылган әкәмәт еллар иде алар. Гүяки адәм баласы жир йөзенә бары тик дошман эзләп табарга һәм аны мотлакан юк итәр өчен генә туа. Әвәле япун самурайлары, аннан фин империалистлары белән куркыттылар. Аннан Гитлер һәм аның ялчыларына күчтеләр. Япуннар дигәннән. Әйе, бөтен дөньясы, бәрәңге күзәнәгенә кадәр япушкаларга нәфрәт белән дыңгычлап тутырылган иде. Мөселман өйләрендәге изге шамаиллар, носари почмаклардагы изге Мәрьям аналар чүплеккә ыргытылып, алар урынына кызыл йолдызлы буденновкадагы кызыләрмиснең мылтык очтыгы пучык күзле япушканың эченнән сары эчәгеләрен агызып торган сурәтләре менеп атланды. Казан бистәләре, Бишбалтаның зәңгәр чәчкәдәге бәрәңге бакчалары өстеннән Сталин бөркетләре—самолетлар очып үткәндә бала-чага, аларны дошманнар дип уйлап, бәрәңге арасына кереп кача:

—Япушкалар! Япушкалар!..

Мотаһарның хәтерендә, шулай бер тапкыр самолетлар үткәндә, энесе Заһир бәрәңге арасыннан туңкаеп, күккә эчендәге һавасын шартлатмасынмы:

—Менә сезгә, япушкалар! Менә сезгә!..

Империалистларны тизрәк тар-мар итү теләге унбиш яшьлек Мотаһарны хәрби комиссариатка алып килде. Бик тә әфисәр булырга теләгән иде ул. Тәртәләрен кире бордылар: ышанычсыз кеше баласы икән ул. Әтисе төзелә башлаган мотор заводында йөкче булып эшли иде. Дегеткә акчам житми дип, ул арбасының күчәрләрен сыер мае белән майлый иде. "Өстең бөтен, тамагың тук булыр, ичмаса",—дип әтисе аны ФЗӨгә урнаштырды. 22 заводта тимер шомартучы булып эшли генә башлаган иде—сугыш башланды. Монысы инде чын-чынлап Мотаһарның сугышы иде. Унжидесе чак тулган егетне фронтка алып киттеләр. Алып та киттеләр, Иваново өлкәсенең Гороховец лагерьларында ике көнлек хәрби әзерлеген пулеметчы булып башлап, минометчы булып тәмамлаган-нан соң, мылтык түтәсен көпшәсеннән аера алырлык хәлгә житкән Мотаһарны һәм аның кебек иреннән ана сөте дә кипмәгән өч йөз селәгәй малайны сугышка да ыргыттылар. Авыр минометлар ротасына эләкте ул. Һәр расчетта дүртәр сугышчы. Минометның көпшәсе белән прицелы егерме, көпшә куела торган тактасы уналты, көпчәкләре белән лафеты егерме, дүрт авыр мина салынган әржәсе тагын да егерме кила тарткан мөлкәтне жилкәләрегезгә йөкләгез дә, әйдәгез, Мотаһарлар һәм Митрофаннар, егерме чакрымлык марш-бросокка!.. Ah, ашатты сугыш лаеш шулпасын, ашатты дигәч тә ашатты!.. Бигрәк тә беренче елларның беренче айлары. Чын сугышка Калинин тирәсендә керде ул. Җинелчә яраланып, Руза шәһәрендә госпитальдә ятып чыкты. Аннан Великие Луки—Старая Русса _ Новгород сызыгында Ленинградны саклауда катнашты. Шул Великие Луки сазлыкларында күзсез калды да инде ул. Дөресрәге, батальон командиры капитан Непейпивоның жүләрлеге аркасында күзсез калды. 1944 елның 26 феврале иртәсе иде. Ленинград камалышын өзгәннән соң Великие Луки—Новгород сазлыкларында бүленеп калган фашист гаскәрләрен тәмам тар-мар итү максатында һөҗүмгә күчәр алдыннан гына бу ахмак Непейпиво, Ленинград камалышын берүзе өзгәндәй, әтәчләнеп һәм югары командование алдында ярамсакланып алырга булды, күрәсең. Көтмәгәндә генә, фашистларга уч төбедәй күренеп, леркелдәп яткан мүкле сазлыкта үзенең күзәтү пунктын алыштырырга карар итте. Бу бурыч нәкъ Мотаһарлар расчетына төште. Башка һичбер мәшәкате булмагандай, бу "сирәк" операция белән Непейпиво үзе житәкчелек итәргә тиеш иде. Фашист снайперлары соңгы көннәрдә биредә уңышны болай да мул урдылар: унике сугышчыны сазлыкка манчыдылар, мәлгуньнәр. Алар шулкадәр узынды ки, безнекеләрнең маңгай агына, күз чокырына гына чәкетә башладылар.

Иске күзәтү пунктыннан өч йөз метр чамасы астарак, уң канатка күчеп, алар эшкә тотынды. Саклануның нәрсә икәнен дә белмәгән

Непейпиво гәүдәсен таяк сыман катырып, күрсәтмәләр бирә, гадәтенчә, җикеренә-сүгенә, үзенә урын таба алмагандай, йөренә башлады. Шулчак әллә нәрсә булды: күз алдында мүк өермәләре күтәреп, сазлык буйлап ут шарлары тәгәри башлады. Фашистлар бу юлы минометтан утка тота иде. Уң ботыннан нәрсәдер әче итеп чеметеп алган Мотаһар сазлыкка капланып төште. Бар тирә-якны ыңгырашу авазлары басты. Якында гына тагын шартлау яңгырады. Дулкын аны сазлыктан күтәрде, гүя үз-үзенә хуҗа булалмыйча, бөтенләй яраланмаган, исән-сау кешедәй, аягына басты һәм кулындагы бердәнбер коралы—көрәге белән селтәнә-селтәнә, һава ярып кычкыра, унга-сулга йөгерә башлады:

—А-а-а-а-а!..

Яраланудан тыш, ул контузия дә алган иде. Соңыннан аңлавынча, сугыш яланында контузия алу—исәнгерәү генә түгел, вакытлыча акылдан язу булып исәпләнә икән. Әгәр дәвалану шартлары җитмәсә һәм зиһене кире кайтмаса, контузия авырлардан исәпләнә һәм адәм баласы гомерлеккә алмашынган хәлдә кала икән... Тилергән карашы белән ул тирә-юньне күзеннән кичерде: тегендә һәм монда сугышчан дуслары аунап ята... Үлү шушы микән? Ничек инде? Әле генә исән егетләрнең җаннары кая киткән?! Ә ул үзе исәнме? Тәне үзенекеме? Җаны үзендәме? Тукта, ни күрә? Непейпивоның гәүдәсе бер җирдә, теле чыккан башы икенче җирдә аунап ята! "Командирны саклау, аны уттан каплау, гәүдәсен дошман ягында ташлап калдырмау—совет солдатының изге бурычы",—дип дөрес сендереп өлгергәннәр иде аңа. Уңын-сулын аешып та бетмәгән, ут-ялкын гарасатында үзенең нәрсә эшләгәнен дә белмәгән Мотаһар, ике дә уйлап тормыйча, уң кулына командирының башын бөдрә чәчләреннән эләктереп, кансырап яткан гәүдәсен иңенә салып, бозлы яшькелт сазлыкта чыптыртый-чыптыртый алга өстерәде. Күпме өстерәгәнен хәтерләми: нәрсәдер башына китереп сукты, күз аллары яктырып караңгыланды һәм ул тагын да сазлыкка ауды...

Госпитальдә генә аңына килде ул. Яшел сазлыкта бер тәүлеккә якын яткан икән командирының башы белән гәүдәсе арасында. Снайпер ядрәсе аның теш казнасын, сул як битен актарып чыгарган һәм сул күзен алып очырган иде...

Җиде ай да унике көн дәваланды ул Дим буендагы Шафран госпиталендә. Зиһене әйләнеп кайткач, тән ярасы бер газапласа, җан ярасы ике газаплады аны. Капитан Непейпивоның кисек башы төшләренә керер йөдәтте. Гүя ул баш анардан тел, зиһен һәм күз таләп итә иде.

—Бер күземне сиңа бирдем бит инде,—ди Мотаһар аңа төшендә.—Сиңа тагын ни кирәк?

—Икенче күзеңне дә бир,—ди теге имансызланып.—Миңа икенчесе дә кирәк.

—Нигә сиңа күз?—дип төпченә Мотаһар.—Син бит болай да башсыз.

—Мин башсыз булсам да, теге батырлыгым өчен үлгәннән соң "Дан" ордены бирделәр,—ди Непейпиво.—Орденнарымны күрер өчен кирәк миңа синең күзләрең.

Вәт әкәмәт!

Кисекбаш әле дә төшенә кергәли Мотаһарның. Һаман да котыла алмый ул бу газаптан. Табыштылар микән Непейпивоның башы белән гәүдәсе? Кавыштылар микән? Кавышып җирләнделәр микән? Әллә һаман да җирләнмичә ятамы аның сөякләре Новгород сазлыкларында?

Соңыннан ул Непейпивоның бу "каһарманлыгы" өчен икенче дәрәҗә "Дан" ордены, ә Мотаһарлар расчетының "Ленинградны саклаган өчен" медаленә тәкъдим ителүләре турында ишеткән иде.

Әйе, Мотаһарның "Дан"ы да, чурты да юк. Икенче дәрәҗә "Бөек Ватан сугышы" орденын да Җиңүнең кырык еллыгында гына алды ул. Хәер, аны сугыш елларында чакырылган һәркемгә дә бирделәр. Мотаһардан ике яшь кенә бәләкәй, егерме җиденче елгы, Җиңүне Мәскәү янындагы хәрби часть пешекчесе булып каршылаган күршесе Сәфәргалигә

дә эләкте ул. “Мин—ветеран!” дип кенә җиффәрә ул. Сазлык ерып, башсыз калган командирларын өстерәгәндә күзсез калган сугышчыларга бирелгән барлык рәхәтлекләр белән файдалана. Тәнендә җәрәхәтсез урыны калмаган, җитмәсә газиз күзләреннән дә мәхрүм Мотаһар да, сугышта тырналу бәхетенә ирешә алмаган Сәфәргали дә бертигез булып чыктылар. Исән әле Сәфәргали. Ходай Тәгалә озын гомер тәкъдир итсен үзенә. Исән генә дисезме? Аракының лаканына төшәр иде, әгәренки андый лаканны ишек төбенә китереп куйсалар. Башы авырткан саен Мотаһардан пенсион даулый, явыз.

Брежнев заманнарында орден-медальне капчыклап таратканда, кем әйтмешли, көне өчен түгел, дене өчен, болай гына, ачуы кабарып кына, үзенә “Ленинградны саклаган өчен” медале тиешлеге турында Оборона министрына хат яздырткан иде. Биш-алты ел буе аны архивтан ачыкладылар: тиеш икән шул. Менә хәзер инде биш-алты ел буе шул медальне тапшыра алмыйлар. Бөек Җиңүнең илле еллыгы да үтеп китте, әмма Идел буе районы хәрби комиссариаты ана әле булса ни “Ленинградны саклаган өчен”, ни маршал Жуков медален такмый! Шалтыраттырып та, хат яздырып та карады. “Өегезгә килеп тапшырабыз”,—имеш. Нигә чакыртмыйлар? Бик теләсә, таягын мичәүләп, ул анда үзе дә бара ала, әмма гарьлеге бирми картның, гарьлеге! Кем әйтмешли, барның маягы тия, юкның таягы тия. Ярар, килсәләр килерләр, килмәсәләр, чукыныплар китсеннәр шул медальләре белән!.. Ырадиудан диктор Хамматов әйтүенчә, Мотаһар кебек егерме бишенче елгы фронтовиклар Казанда нибары 32 кеше генә калган ди. Ай-һай кырылды шул аның елдашлары, чалгы астындагы үлән кебек кырылдылар. Мотаһар кебек тантанага үзе килә алмаган янбалитлар бер мең чамасы икән Казанда. Карт бармакларын бөгеп саный башлады. Май, июнь, июль, август... Йә, Хода, киләбез дип шалтыратканнарына тугыз ай тула түгелме? Мондый түзем өчен Мотаһарга өченче медаль дә тиеш түгел микән? Их, коммунистлар булса, машиналарда ялт иттереп кенә килеп алган, медален дә тапшырган, чәен-мәен дә эчергән, бүләген дә биргән, телевизордан да күрсәткән булырлар иде!..

Нигә Жуков кадәр Жуков хөрмәтенә медаль генә ясатты икән бу Ельцин? Шул коммунистларны яратмаганнан микән? Карт электр шаукымы суккандай дертләп куйды. Ул бит безнең Кутузов! Дошманны Иделгә кадәр китереп, сугышны дүрт елга сузып, дошманның бер солдаты исәбенә үзебезнең ун солдатны үтертеп булса да, Берлинны нәкъ беренче майга, бу тантаналы вазыйфаны Рокоссовский, Конев армияләренә тәтеттермичә, үз фронты гаскәрләре белән генә алып, сугышның сәтсиәлистик ярышында җиңеп чыккан бердәнбер пәлкәвәдис бит ул! Их, булса иде бүген Жуков! Рәсәй домкратларын җиң очы белән генә себереп төшергән булыр иде ул тарих өстәленнән.

Карт тирән итеп уфырып куйды. Яшьлеге булмады инде аның. Купшы киенеп, кызлар белән дә типтереп калалмады. Ул заманнарда милитсиясе хәтта матур киенсәң дә дукәмәтне тикшерә, ыштыраф сала иде. Фронттан кайтканда уң күзе ярыйсы һәйбәт күрә иде Мотаһарның. Ирләр җитмәгәнлектән, янбалит булса да, аны әлеге дә баягы сабын комбинатына әпирәтер итеп алдылар. 1962 елда әнисен, бер елдан соң әтисен дә җирләгәннән соң, шактый соңлап өйләнде ул. Сайланып торырга форсаты да булмады. Ярый, Зөлхәбирәсе юньле хатын булып чыкты. Тәүдә Фәрдүнәләре, аннан Мөдәррисләре туды. Моннан нәкъ утыз ел элек тома сукыр калды. “Сугышта яраланган уң күзегезне сабын селтесе киптергән”, диделәр аңа табиплар тыныч кына, артык берни булмагандай. Гүя ул хәзер күнел күзе белән мангаендагы тере күзен күрә иде: әнә ул зәңгәр чыпчык чәчәге кебек сула, аннан ул сөяк сыман катып, кипкән зәңгәр бөртек—зәңгәр нокта гына торып кала!..

Мотаһар айнып киткәндәй, баскан урынында таптанып куйды. Юк, суны, дәүләтнеке булса да, бу кадәр әләф-тәләф итәргә ярамый. Су өчен түләнгән булса да ярамый. Ул коргаксыган куллары белән бакадай

салкын- айган кранны борды. Аннан юеш диварда капшанды. Көзге булырга тиеш монда. Их, бер генә тапкыр үзенне көзгедә күрәсе иде. Нииндирәк икән ул хәзер? Ямьсездер, адәм үләте, хатын-кыз игътибар да итмәслек бер үләксәдер инде. Бар көзге, бар монда. Менә ул. Ул көзгене күрмәсә дә, көзге аны күрә иде. Бармаклары белән ертык иреннәннән бүлтәеп чыккан тешләрен, аннан юньләп кырылмаган сакал-мыегын, аннан морза-ларча киеренке һәм үркәчле борынын, аннан оч-очлары агарып, җәяләнеп төшкән кашларын, аннан пеләш башында Хо Ши Мин сакалы шикелле сирәк кенә калган чәч ишаратын салкын су белән сыпырды. Аңа рәхәт булып китте. Ул канәгатьлек белән елмайгандай итте. Иң мөһиме—исән. Иң зур матурлык—исәнлек түгелмени? Әнә, туганнары мур кырган шикелле кырылдылар да беттеләр. Кырык җиденче елгы ачлыкта Урта Азиягә чыгып олаккан сеңлесе Зәйнәп, Рәхимҗан энесе генә исәннәр. Тугыз баладан.

Кемдер кыңгырауга басмыйча, хуҗаларча каты, иркен итеп ишекне дөбердәтте. Аяк табаннарын песи йомшагында тирбәтеп, капшана-капшана, карт ишек катына килде. Ишек ярыгы аша тыштан карнның исерткеч сафлыгы керә иде. Тагын кактылар. Мотаһар тавышын хатын-кызларча нечкәртеп—мондый очракларда ул шулай итә—урынында сиртмә сыман тирбәлеп эндәште:

—Ыхту тамы?

—Мотаһар абзый, мин әле бу,—диде тыштагы.—Шәфәргали күршең.

Сәфәргали бу. Менә ике ел инде, тешен сугып сындырганнан соң, аның авызы "с" авазын иҗат итә алмый. Ул "ш" рәвешендә сызгырып чыга.

—Ышту тибә нады?—Сәфәргалинең нинди йомыш белән йөргәнен бик яхшы белгән Мотаһар күршесе белән мотлак урысча гына сөйләште. Шулай иткәндә ышанычлырак чыгар, тегесе, өметен өзеп, тизрәк китәр кебек тоела иде.

—Нәршә кирәк дип... Күптән күрешкән дә юк...

—Зәчем мине бидаться с табуй? Нинады мине это. Эскажи, диньгә нады.

—Кирәк иде шул, Мотаһар абзый.—Сәфәргали исә киресенчә, Мотаһарның милли кылларында уйнарга тырышып саф татар шәенә сыдыра иде.—Үтермә, быр-рат!.. Башкынаемда керәшен малайлары утын кишә...

—Вәт керәшен и прәси. Ысначалы дулг атдай.

—Икешен бергә кайтарырмын. Февраль пеншияшеннән.

—Бирмим, дигәч, бирмим.—Мотаһар күршесен үчекли башлады.—Әнә, "Ватан сугышы" орденын сат!

—Һы,—диде ишек артындагы тавыш.—Миңа бит бер яртылык кына!.. Әгәр теләшәң, теге кибетеңә тагын алып барам.

—Яхшы чакта аухади. Ни аухадишь, хәзер милитсия пазаву!

—Швинья!—диде түземе беткән Сәфәргали ишектән китә башлап.—Акчаңны барыбер кабереңә алып китә алмассың әле. Шбулыч!..

Талыйлар. Урамга чыкмагач, ишек катына килеп, көпә-көндез талыйлар.

Аккан сулардан йөрәгенә бераз гына булса да сихәт алган Мотаһар шушы кичтеки генә сихәтен дә ишек артындагы эттән ашатып, залга өстерәлде. Көненә-сәгатенә, кәефе-мәнфәгатьләренә карап, ул бу күптән таныш, дистә еллар буе тапталган, мең-миллион тапкыр йөрелгән аралыктан төрле рәвештә—кирәксә, песи кебек мамыкка басып, кирәксә, аю кебек лапылдап, кирәксә, тирәк мамыгы кебек тавыш-тынсыз әвәрелеп, кирәксә, буаз сыер кебек өстерәлеп, кирәксә, усак яфрагы кебек лепер-лепер килеп үтә ала. Хәзер ул чынлап та өстерәлде һәм аның сәбәбе каналья Сәфәргали иде. Зал ишегеннән үткәч тә колак салды: йөреми дә, сукмый да иде аның асылмалы асыл сәгате. Шулай көн саен турайтып, урынына куеп җәфалана ул сәгатьне. Оныгы Вадим... Юк, исенә дә төшерәсе килми ул башкисәрне. Ике телле сәгатьне бер телсез, үзен һәм барысын телсез-илсез итә, мәлгунь. Ата-бабаның каты кулы кирәк тә бит. Әнә шул

шайтан телевизорын карар өчен генә телсез итә бит ул дөньяны. Әгәр кулыннан килсә, Мотаһар телевизорларны бөтен дөнья буйлап лом белән кыйратып чыгар иде. Шуның аркасында җене котыра, дөньясы чалшая картның. Аның дөньясы гына чалышаямы? Нигә әйтми икән бу хакта малайга әти-әнисе? Ай-яй, зур нәрсә бит ул сәгать дигәнең! Дөньяда барлык бөек эшләр сәгатьтән башлана. Заман күзе бит ул. Аралар аргамагы. Гомер язмачысы. Сәгатьне турайту, дөрес көйләү һәм телләрне дөрес вакытка күчереп, даими йөрергә мәҗбүр итү сукыр Мотаһар өчен бер бөек җаза һәм бөек йолага әйләнгән: кәккүкле сәгать суккан саен аның йөрәгендә өзелгән җепләр ялгана да, гүяки күзләре ачыла, сәгать туктау белән—ул җепләр янадан өзелә, күзләре янадан ябыла. Әйтерсен салкын карбазга убыла һәм күрми башлый. "Әллә хәзер үк җибәрим микән?" Килененең ислемай исләре таралып та бетмәгән бүлмә уртасында карт туктап калды. Сәгатьне җибәрү өчен анык вакытны белергә кирәк иде. Ә анык вакытны белү өчен Мотаһар кемгәдер әҗәткә керергә тиеш иде. Үзең Вакытсыз булгач, кешедән Вакыт сорашу үзе үк Вакыт урлашу түгелме? Аннан Вакытны ваклап та бетерделәр. Мотаһар ишетеп белә: гади генә сәгатьтән әллә ниткән президент сәгатьләре, командир сәгатьләре, академик сәгатьләр, пилот, штурман сәгатьләре ясап бетерделәр. Соң аларның Вакытлары бер үк түгел микәнни?! Очучылар вакыты тизрәк чаба мәллә?

Җир йөзенең иң бай банкларына закладка салынган, алтын бәрабәренә тимер сандыкларда сакланган нәфис сәгать коллекцияләре бар диләр. Дөньяның иң маһир сәгать осталары ясаган ди аларны. Шул нәфис, матур булганнары өчен коллыкка төшкәнме соң алар? Сәгатьләре бар—ә Вакытлары юк. Сәгать белән вакытлары аерым яши. Булсын бер уртак Вакыт! Мотаһар диварындагы сәгать ил сәгате белән бер булсын! Монда шул җепне өзәләр. Шуңа күрә халык йоклый, бер Вакытта уяна алмый. Менә никадәр нечкәргән иде ялгызак картның күңеле! Әнә шул җәфалардан качу максатында ул үзе өчен тулы бер кануннар теркәмәсен булдырган иде. Әгәр күзләре күргән булса, ул шул Вакытны үзенең кул сәгатеннән генә белгән булыр иде. Чарадан бичара карт теләр-теләмәс кенә итеп үз бүлмәсенә сиртмәләнде. Тәмәке исе һәм ислемайдан арына барып, үз бөҗрасы—үз кыйтгасы һавасында йөзгән күкерт, нииндидер иприт-люизитләрне тәмәйткән, озак кузгатылмаган, куерып әчегән катламнарны ерып, эчкә үтте. Аның мондагы зәңгәр күге—пәрәвез челтәрләре белән челтәрләнгән, күптән юеш чүпрәк, акшар күрмәгән соры түшәм, мондагы кара җире, туган туфрагы исә—бетон өстенә түшәлеп, буяулары купкан, муртаеп беткән линолиум иде. Бу мәҗүси исләрдән котылу өчен почмакларга елышсаң, һаваны кузгатсаң, анда катламнар тагын да зәһәрләнеп куерган иде. Үзенә күптән таныш, өйрәнелгән, йөрәккә якын бу исләрдән Мотаһар карт иркенләп тын алды. Бу аның яшәү кыйтгасы—Ватаны иде. Унда, урындык өсләренә килде—китте ыргытылган юрган-япмалар, мендәрләр, анда-монда аунап яткан чүпрәк-чапрак, бер почмактан икенче почмакка сузылган баудагы эчке һәм тышкы кием сәләмәләре арасыннан сукмак табып, ул һаман да җыештырылмый яткан урын өстенә килеп ауды.

Өч бүлмәле фатирның инде ничә ел идәне себерелмәгән, бердәнбер тәрәзәле, анысы да ябыштырылмаган, ярыкларыннан җилләр курай уйнаган бүлмәсе-хөҗрәсе кайчандыр алар яшәп азапланган сабын комбинаты барагындагы бүлмәне хәтерләтә иде. Их, бу тәрәзәдән бер генә тапкыр булса да Айны, Кояшны күрәсе иде! Айның йөзен һаман да сабый чагындагы кебек янгырлар юа микән? Җәйге янгырлар шундый ук яшел кояшлы микән?

Күз алдына Зөлхәбирәсе килде. Ул аңа "Нигә өйләнмисең, карткаем? Нигә болай җәфаланасың?"—дип ялвара иде. Әйе, Зөлхәбирәсе исән чакта өсте бөтен, тамагы тук, җаны сөекле булды. Ул ташлап киткәч, сөйкемсез сөяккә әйләнде дә куйды. Бала үстерүнең бөтен мәгънәсе шул микәнни? Аның хәлендә һәм аның яшендә хатынсыз яшәү—икеләтә үлемгә хөкем ителү икән: әсир бүген атылам, иртәгә атылам дип салкын базда мәрмәр

шомартуын дәвам итә, ә баз хуҗалары үлем карарын җиренә җиткерүне махсус сузалар. Моны кичерергә башкага Ходай язмасын. Газапның да газабы мондый ялгызлык. Үлем авыр, мондый ялгызлык үлемнән дә авыр. Көндезләрен түзә лә ул, ә менә төннәрен!.. Их, төннәрен!.. Ул үзе белән янәшәгә ниндидер җылы тән, хатын-кыз тәне, җылы җан—хатын-кыз җаны тели. Җылый, үтенеп ялвара, күкләрнең гөмбәзен кага. Юк. Җавап юк. Мотаһар бит әле, житмеш өченче яшькә чыгып барса да, исемлектән сызып ыргытылганнардан түгел. Ыргытылса, ана медаль кадәр медаль бирерләр идеме? Дәрте бар, дәрманы житәрлек. Андагы дәрт, андагы дәрманмы?! Төннәрен җенесе котыра, җенесе талый аны. Башкалар ничек кенәләр итеп моны күрмиләр, ничек кенәләр итеп сизмиләр икән? Урам буйлап, эт кебек иснәшеп, хатын эзләп йөри алмый бит инде ул, адәм тәганәсе! Кайчакта Мотаһарга җир йөзендә бары ул гына күргәндәй, башкалар тома сукыр булгандай тоела... Андый сәгатьләрендә ул татар дөньясын гына түгел, бөтен кешелекне сукырлыкта гаепли башлый...

Аның иң яратмаган мизгеле—таң аткан мизгел. Нервылары уйный. Кычына, кашына башлый. Ник туганына үкенә, кимсенә. Башкалар күрә—ул күрә алмый. Башкалар йөри—ул йөри алмый. Башкалар көзгегә карый—ул карый алмый. Башкалар сөя, сөелә—ул сөя дә, сөелә дә алмый. Нәрсә хакына бирде ул тазалыгын-саулыгын? Ватан хакынамы? Кая ул Ватан? Сөюе хакынамы? Кая ул сөю? Балалары хакынамы—кая ул балалар? Их, күрергә иде, ничекләр генә киенә икән хәзер хатын-кыз? Элеккечә әдәпле, матур, ир-атны кызыксындырып, чит-ят дөнья кебек, сихри ымсындырып киенәләр микән? Әллә барлыктан, муллыктан узындылармы? Моннан берничә ел элек урамда бер ирнең бер хатынга "Нигә чалбар киясең сылу гәүдәнне ямьсезләп, кукәй үсәр бит!" дигәнен хәтерли ул. Әллә хәзер хатын-кыз чынлап та чалбар кияме? Бик ямьсез, бик пырдымсыздыр бит инде ул?

Шулай ярым уяу ята-ята да, таң аткач кына йокыга тала. Йокыдан уянганда кан тамырлары инде бушанган, хәлсезләнгән була. Тормышка битарафлык биләп ала аны. Шулай бер ярсыган чагында улына эч серләрен ачып та карады Мотаһар. Тәүдә аның учына мул гына акча сонды. Аннан сак кына: "Берәр юньле генә ак әби апкайтабыз мәллә, югыйсә?—диде.—Сезгә авырлыгым да төшмәс иде". Малай нәрсә, малай акчаларны шатырдатып кесәсенә йомдырды да, аннан шаркылдап көлеп, әтисенә тондырды: "Өйдәш булып чыгып китәсең икән, ун ягың кыйбла! Куанырбыз гына!"

Җылы почмаксыз да калсынмы ул? Әнә, Һади Такташ урамыннан бер хатынкай балга төшкән чебен кебек ябышты аңа. Телефонын да белеп алган. Вакытын да сәгатеннән алда төгәл әйтеп тора. Алдан шалтырата да, килеп тә җитә. Теле телгә йокмый пумала башның. Анысы да акча даулый, мин сиңа әйтим. Нишләп бу хатын-кыз туры карасаң да өйләндерергә генә тора?! Бер мәлне, ул чыгып киткәннән соң, акча янчыгын актарып караса, бушаткан, каһәрең!.. Юлны япты аңа Мотаһар. Былтыр, хатын-кызны бик тә тансыклаган, шундый да җирсегән, коргаксыган мәлендә бер оятсызлык та кылды ул. Оятсызлык дип инде, кучәрең кызганда... Бәлки бер хилафлык кынадыр шунда. Хилафлык дип инде, канын кайнаганда... Мөселман кешегә, бигрәк тә аның яшендә, килешеп үк бетмәгән кечкенә эш кисәге, ярамагандайрак адым, якты шәйтан вәсвәсәсе китереп чыгарган нәмәстә инде шунда. Ир кешегә гафу ителә торган кети-кети, ягъни мәсәлән. Ярый әле, балаларга сизелмәде. Бәлки сеңлесе оялып, апасына әйтмәгәндер. Әйе, килененең урыс үги әтисеннән туган сеңлесе Бирәникә килгәләп йөри аларга. Атламнарыннан, тын алышларыннан тоя Мотаһар, тутырган тавык кебек шактый йомры булырга тиеш ул, гөнаһ шомлыгы. Вәт, менә-терәк шул Бирәникә, студин кызкай, тегеләр эштә чакта, керләрен юарга килде бит, әй. Күңеле бик тә болганып торган Мотаһар, аны-моны уйлап тормады, оекчан килеш, төлке табаннарында гына шуышып килде, ванна бүлмәсендә, эчке күлмәктән генә онытылып кер юып азапланган Бирәникәне—әйе, и, Ходаем, бир бодаен, арыш катыш булса да!—

шүрәленекедәй "йомшак" куллары белән кочып та алды. Кочып та алды, кыз чырулап кычкырып та җибәрде—һәм Мотаһарның болай да чалыш яңагында утлар да уйнатты. Мина шартладымыни! Шундый чибәр кыз да ир кешегә кул күтәрер икән, ә?!

—Сез нәрсә эшлисез?—диде Бирәникә кер юу машинасын туктатып.

—Бер генә яраттыр!—дип инәлде тәмам югалып калган Мотаһар.—Бер генә тапкыр!—Ул кесәләрендә карманды.—Акча бирәм!!!

—Чыгып китегез! Минә апа гына кайтсын әле!..

Мотаһарга төлкедән аюга әйләнүдән һәм үз бүлмәсенә сөйрәлүдән башка чара калмады. Бернничә көн буе кайткандай тоелды аңа. Туктап ял да иткәләде бугай. Ярый әле, тавыш-тын чыкмады. Акыллы икән шулай да, пумала баш. Хәзер дә килгәли Бирәникә. Шулай да апасы-җизнәсе өйдә чакта гына килә.

Сәгать ничә икән? Ул яткан җиреннән үрелеп, каршысындагы өстәлдә капшана башлады. Биредә аның рухият келәте: тырнаклары җиткән бармаклар сукырлар җәмгыятеннән бирелә торган магнитлы ленталар, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Илһам Шакиров һәм тагын әллә кемнәрнең аерым язылган язмалары, ниндидер үткәргечләр, магнитофоннар өстеннән үтте дә, радиоалгычтагы тиешле басмакка басты. Казан һәрвакыттагыча такмак әйтә иде. "Юкка җырламый бу туктаусыз,—дип уйлап куйды карт.—Җыларга җырлый бу". Ниһаять радио такмактан туктады.

—Казан сөйли. Белдерүләр, игъланнар, һава торышын тапшырабыз...

—Нәрсәгә кирәк миңа синең җылак һава торышың!—Карт кычкырып җибәрде һәм радиоалгычны шарт сүндерде.—Миңа синең Вакытың гына кирәк! Ә синең Вакытың юк!..

Вакыт мәсьәләсендә радиога әҗәткә керү аңа уңайлырак иде шул. Югыйсә, радиоалгыч артында шул ук сукырлар җәмгыяте бүләк иткән япун сәгате дә бар. Тәүлекнең теләсә нинди секундында япун кызы саф урыс телендә шартлатып әйтеп тора:

—Ике сәгать утыз җиде минут!.. Ике сәгать утыз сигез минут!..

Әмма япуннан әҗәткә Вакыт алыр өчен Мотаһарга карт сөякләрен шыгырдатып урыныннан торырга кирәк. Аның һич кенә дә торасы килми. Ярый әле туган Казанының Вакыты булмаса да, коммунистлардан калган радио ишараты бар. Череп чыккан, отыры Казан кешесе буларак, ул сәясәтне сөйми, сәясәткә керми, хәтта аңардан уттан курыккан кебек курка иде; сәясәт дигән йогышлы авыруны Иван бабай аның зиһененнән сыргавыл белән куып чыгарган; һәм син аны сәясәткә куып та кертә алмыйсың; син аңа, Казан татарына, ипекәй бир дә, кәнсирт бир. Шуңа күрә аның өстәлендә яңа, соңгы заманда таракан кебек үрчегән көйче-җырчы-көрәзәче Сорхантай, Чурмантай, Кормантайларның язмалары да тулып ята... Сәясәткә кермәсә дә, Мотаһарның колагына сәясәт үзе керә. Ачып куелган радиодан ул Татарстан җөмһүриятенең мөстәкыйльлеге декларациясе, Шамил Басаевның халыкара үтерүче булуы, Ельцинның җиде ел буе Украинага сәфәргә бара алмавы, Мөслим, Актаныштагы бәрәңге, Арчадагы гектарыннан алтмыш центнерлык иген уңышлары турындагы хәбәрләрне дә шушы радиодан тыңларга мәҗбүр булды ул. Ышанмый ул аларның берсенә дә. Вакыйгаларга бәя дә бирми. Бәя бирергә хакы юк аның. Бәяне үз күзләре белән күргәннәр генә бирә ала. Әмма бирмиләр. Чөнки булмаганын беләләр. Күреп беләләр.

—Әйдә, сөйлә булмаса...

Көйсез кияү кебек көйсезләнеп, ул янадан басмакка басты.

Казанның Вакытны әйтергә әле һаман Вакыты юк иде. Диктор Гадилә Нургали үзенә генә хас йомшак, ягымлы, фетнәсе котырган җаннарны да тынычландыра торган тавышы белән Ураза гаете турында сөйли иде. Мөселманнарны өйлә намазына чакырып, моңлы азан тавышы яңгырады. Иртәгә гает икән ләбаса! Ниндидер дәһшәтле көч Мотаһарны урыныннан кубарып торгызды. Ул шау тирдә иде. Башыннан ми ярымшарларын яктыртып шаукым узды: әгәр хәзер УЛ ҮЗЕ ДӘ намазга басса? Уразасын да тотмаган килешме? Тәһарәтен дә алмаган килешме? Таза киемен дә

кимәгән, юньле-рәтле кырынмаган да, юынмаган да килешме? Намазлыгы да юк бит аның ичмасам!.. Ә нәрсә укыячак сон ул өйлә намазында? Әтиәнисеннән күңеленә сеңеп калган "шарабан таһура" догалары гына җитәме аңа? Картта ике көч сугыша, кормәкләшеп көрәшә башлады. Беренчесе "Намазлыгыңа бас, карт убыр!" ди. Икенчесе: "Баса күрмә! Тилерден мәллә!—ди.—Син бу йөкне тартып бара алмыйсың, ул сиңа кирәкми дә!" Беренче көч каяндыр йөрәк астыннан утлы төен булып томырылып чыкты, бугазына кадалып, тынын буды. Иманга кил, Адәм Тәганәсе! Кабер якасында булса да, бер Аллаһуга инан! Шунда гына гөнаһларың ярлыканыр, шунда гына мәҗүсиләнеп саргайган йөзеңә алсулык, иман нуры калкыр, кипкән күкрәгеңә галәми кодрәт кайтыр! Үзенең көчсезлегеннән үзе үрсәләнеп һәм үчекләнеп, урынында елан сыман бөтерелә, өши, гәүдәсен кая куярга белмәгәндәй, бәргәләнә, дерелди башлады. Еларга җиткән картның ясалма теш казналары бер-берсенә бәрелеп шакылдый, чалшайган иреннәре калтырана, куллары исә элмәккә бау эзләгәндәй, тирә-юнендә капшана иде... Иманга кил, Адәм тәганәсе!.. Килер иде дә бит... Иде дә бит... Аның Вакыты юк! Сәгате йөрми!..

—Казанда Мәскәү вакыты белән унбер сәгать утыз минут!..

Вакыт турындагы Казан игъланы гүя аны элмәктән төшерде. Кофтасының җиңе белән ул маңгаендагы салкын тирләрне сөртеп алды. Айныды Мотаһар. Бугаздан теге каһәр суккан төер дә китте. Котылды, бугай. Коткарды Казан, коткарды. Аны Мәскәү Вакыты коткарды. Әле дә шул Мәскәү бар. Мотаһар инде үзенең элекке халәтенә кайтты. Тукта, бүген ничәсе соң әле алай булгач? Егерме сигезенче гыйнвар була бит? Аһ, аның бит бүген генә эшләнәсе эшләре күпме? Көязләнеп, сыргаланып торыр чакмы?! Карт яшьләрчә дәрт белән идәнгә дүрт аякланды, башыгәүдәсе белән карават астына үрмәләп, үзе генә белгән яшерен келәтеннән нindидер кәрзиннәр, әрҗәләр, каплар арасыннан моңарчы басылып яткан тагын да әллә нинди исләр кузгатып, олтанлы пималарын эзләп тапты, кулын куныччларына тыгып, табан астына төшәлгән киезләрне чеметеп кенә күтәрде һәм капшап карады—Мөдәррисчә әйткәндә, бакслар урынында иде. Карават астыннан чыгып, аягына басты, пималарны киде һәм уңайлылар микән дип урынында тыпырдады. Табан астындагы миллионнар киез итекләрнең үз олтаны кебек кып итеп торалар иде...

Нindидер әһәмиятле әйбер эзләгән, хәлиткеч хәбәр көткән кебек, ул радио алдында туктап калды. Казан, Вакытын онытып, Чурмантайларның нindидер шырды-бырды көйләрен тапшыруга күчкән иде.

—Чурту!..

Мотаһар радионы шарт басты. Бүлмә, тамагы тыгылгандай, тынып калды. Куллары белән сәрмәләп, ул япун сәгатен эзләп тапты, тиешле сәйләнгә кагылуга япун кызының мөлаем тавышы яңгырады:

—Унбер сәгать илле ике минут!..

—Менә, ичмасам, сәгать! Япушка тек япушка!..

Бер-берсенә сер өләшкәндәй, аягын аякка елыштырып һәм леперДәп, ниһаять, залга юнәлеш алды. Ул үзендә кипкән усак яфрагыдай җинеллек тойды. Лепер-лепер. Ул инде—залда. Лепер-лепер. Ул инде почмактагы өстәл каршында. Бер кулына урындык, икенче кулына шул ук өстәлдән нindидер кәгазь кисәге ышырып алып, тагын да лепер-лепер. Ул инде улы белән килене йоклый торган бүлмә диварындагы асылмалы сәгать каршында иде. Урындыкны өйрәнгән алымнар белән диварга терәп урнаштырды, бөтен авырлыгын салып, ныклыгын сынап карады, тәрбиясе белән бик тә пөхтә, бик тә чиста кеше буларак, кәгазь кисәген урындык йомшагына салды һәм аякларын алмаш-тилмәш китереп, өстенә егетләрчә менеп басты, шәрә, сөякләнеп, тиреләре купыраеп, сары бала йоннары басып киткән куллары белән диварны астан өскә капшап менеп, сәгатьне эзләп тапты:

—И-һи-һи, алтын кисәгем!..

Ул балалары һәм Вакыт хуҗасы—асылмалы сәгатькә генә шулай назлап эндәшә.

Дивар буйлап Вакытсыз Вакытның Хуҗасын—сәгатен тапкан картка киез итек табаннарыннан җылы килә иде.

—И-һи-һи, —дип кабатлады ул.—Мине көтә бит ул...

Теге хәтәр елларда он-ипи хакына ун тапкыр закладка салынган һәм ун тапкыр үз оясына кайткан сәгать бит ул. Гомумән, йөри бит ул. Тырышып ята бит ул. Чалшайтсалар гына йөрми. Картның бугазыннан мал суйгандагы сыман хырылдау авазлары бөселде. Сәгатьнең перламутр тышчасына кагылу белән аның суынган куллары җылынды, бит алмаларына алсулык йөгерде, йөзенә илһам нуры калыкты...

—И-һи-һи, алтын кисәгем...

Үз йортында аны тирәннән аңлаган, кайгы-зарларының барысын да түкми-чәчми җыеп барган бердәнбер җан иясе—сәгатьне ул туктаусыз сыйпый, ярата, иркәли, назлый, кәнфит көткән сабый сыман тынычлан-дыра, башыннан, як-ягыннан, бәллүр пыяла белән капланган йөзеннән сөя, һәчтүк итә, үзе генә белгән ниндидер ымлыклар, догалар белән сихерли иде. Ике куллап кочаклап, карт сәгатькә яңагы белән сенеште. Бу сәгатьтә аның өчен Сәгать белән Вакыт аерылмаган, Сәгать белән Вакыт бердәм гомер сөрә иде. Сәгать гүя аның гына иркә, нәзәкатьле кулын, тынын, ихтыярын тоеп тын тора. Кем, нинди көчләр сине беренче тапкыр урыныннан кузгатты? Кемнәр бүген даими бимазалый сине? Йөрергә, Вакытыңны күрсәтергә ирек бирми? Оныгы Вадиммы? Ул гынамы? Берничә дистә ел элек, юк, юк, гасыр башында... Берничә гасыр элек башланмадымы бу Вакытсызлык бимазасы? Әллә Вакытны үзе дә чалшайттымы югыйсә? Карт бу сорауларга җавап бирә алмаслык дәрәҗәдә дулкынланган һәм каушаган иде...

Әйе, алман иленең атаклы "Густав Беккер" фирмасыннан моннан ике йөз дә егерме ел элек дөньяга чыккан сәгатьнең тышчасы—корпусы таш кебек каты самшит агачыннан эшләнгән булса да, ефәктән йомшаграк, атластан сыгылмалырак, аның сакал-мыек баскан, йөз сулары сулган битеннән байтакка үзерәк, яшьрәк һәм җылырак иде. Гүя аның иманы шул сәгать эчендә иде. 1902 елда Мәкәрҗә ярминкәсе үткәргән аукционда хакын унике сәүдәгәрдән артыграк биреп сатып алган аны дәү әтисе. Үктәбер кыйралышыннан соң әтисенең бертуган абыйсы Зариф гаиләсенең күңелен күрә бу күкеле могҗиза, ул үлгәч, васыять буенча, Мотаһарның әтисенә күчә.

Их, күрсәгез иде сез ул сәгатьнең матурлыгын!..

Татар остасының куллары белән ясалган кебек, татарча бизәкле, татарча матур татар сәгате иде ул!..

Мотаһар сәгатьнең бәллүр пыяласын кул яссуы белән сыйпап сөртте—алтын путал белән йөгертеп язылган рум саннарын, ак чынаяк циферблатны, кояшта ялкынланган алтын телләрне күрдегезме? Аның тәрәзә пыяласы картаймый да, сүрәнләнми дә, күрдегезме? Ул һәр сәгать саен яртыда бер тапкыр, сәгать тулганда сәгать санынча суга. Суга гынамы? Ул җанга тылсым булып ята, тынычландыра. Көмеш боҗралы авазлар өйнең бүлмәлә-рендә кайтавазлар тудырып, кире әйләнеп кайта, уйларны агымсулар кебек әллә кайларга алып китә... Суккан чакта аның чынаяк өстендәге кечкенә капусы ачыла, аннан агачтан кырып ясалган бәләкәй генә кәккүк килеп чыга да, сәгатьнең җиз аһәңнәрендә тирбәлеп, моңлана:

—Кәк-күк!.. Кәк-күк!...

Мотаһарга сәгатьне нәкъ уникедә суктырырга кирәк иде. Аның исәбенчә, уникегә җитәргә биш минут чамасы калгандыр. Өлгерергә кирәк. Вакыт алга китсә китсен, тик артка гына калмасын. Ул уң кулы белән тәүдә сәгать, аннан минут телләрен эзләп тапты. Сәгать теле сигезгә җитәрәк туктаган иде. Димәк, телләрне нәкъ уникедә кавыштыру өчен минут телен дүрт тапкыр уратырга тиеш. Менә телләр, ниһаять, уникегә җитәрәк бер-берсен табыштылар. Тик кавышырлармы? Аларның һәркайсының үз теле бар бит! Әлегә ике телле телсез сәгать бит ул!..

Мотаһар маятникны этәреп җибәрде. Сәгать йөреп тә китте. Карт чыпчык чәчәгенең зәңгәр төрткеседәй кипкән күзләре белән күрергә теләгән

шикелле аңа укталды. Аннан колагын куеп тыңлады. Сәгать янбалит кебек сулга аксый иде. Тәҗрибәсе буенча ул сәгатьне бераз гына унга янтайтты. Аксау хәзер унга таба көчәйде. Янадан бераз гына сулга күчергәндәй итте. Тагын тыңлады. Сәгать тыныч ритм белән текелди иде. Нәкъ шул чакта бөтен йортка җан кертеп сугып җибәрмәсенме дә, кәккүк моңнарында коендырмасынмы!

—Даң!.. Кәк-күк!.. Доң!.. Кәк-күк!..

Карт елый иде. Сәгать аның тәңресе иде. Ниндидер хәлсез мөңгерәү авазлары чыгарып, ул тәнресенә табынган мәҗүси сыман табына һәм елый иде. Мондый халәттә сукыр күздән дә яшь чыга, диләр. Чынлап та кысыр күзәнәктән саркыган тамыр тамчысы булып аның күз чокырларыннан ике тамчы яшь тәгәрәде.

Ул берничә минутка урынында катып калды. Бу минутта бөтен җир шарында аңардан да бәхетлерәк кеше булмагандыр, бәлки. Куанычтан дәрте ташып киткән карт бисмилласыз-нисез идәнгә ничек сикереп төшкә-нен сизми дә калды. Лепер-лепер килеп, урындыкны һәм кәгазь кисәген янадан үз урыннарына китереп куйды һәм тышкы ишек катына титаклады.

Ашыга-ашыга киенде ул. Сул култыгы астыннан бер уч мамыгы бүселеп чыккан, якасы кыршылып, кайракланып беткән иске драп пәлтәсен, кайчандыр ак төстә булган куян бүреген күз чокырларына кадәр батырып киде, колакчыннарын төшереп бәйләде, сул кулына кибеткә йөри торган тукыма капчыгын, уң кулына "җитәкчесен"—сукырларга бирелә торган очлым таякны ул шулай атый—алды һәм ишек яңагына килеп колагын куйды: "Сәфәргали көтеп тормасын тагын". Тавыш-тын ишетелмәгәч, суырылып кына ишектән чыкты...

## Тәравих намазы алдыннан

Гафу итегез: Мотаһар абзый, бер караганда, күрмәве белән күпләрдән бәхетлерәк иде.

Әйе, әгәр Мотаһар абзый күргән булса, акшары купкан, тырналган, почта әрҗәләре җимерелгән, һәр карыш дошман әлифбаның кәкре хәрефләре, оятсыз авыз иҗатының әшәке сүзләре белән чуарланган, идәне тәмәке төпчекләре, төкерек-какырык, чүп-чар белән тулган подъездны күзеннән кичереп кенә дә йөрәге суккан булыр иде. Хрущев заманнарында төзелгән, шырпы кабыдай кысан, түшәме башка тиеп торган, акылсызлар йорты сыман сарыга буялган биш катлы йортны тыштан күрә алмавы белән бәхетле иде ул. Әнә, Мотаһарның беренче каттагы фатирының тышка караган өч тәрәзәсе. Аларга эленгән челтәр-чыбылдыклар йорт куяннарына гына түгел, шакал-бүреләргә дә чыдарлык итеп әлүминдәй ак металлдан ясалган читлек челтәрен хәтерләтә. Бу йортта бала үстермиләр, үтерәләр генә шикелле. Имчәк баласы елаганы ишетелгәне юк. Болай да сазламык җирдә тилереп үскән тирәкләр йортның эченә кояшны бөтенләй үткәрми. Бөек Ватан сугышы ветераны Мотаһар Чанборисов бирегә кояш нурын Президентның үзенә шикаять язып кына китертә ала. Андый нур, әлбәттә, социаль ташлама, ягъни мәсәлән, льгота дип аталачак. Җитешсезлек тудыра белсәң, сасы һаваны да ташлама ясап кына иснәтергә мөмкин бит. Бүген беренче мәртәбә тышка чыккан карт саф һаваны күкрәк тутырып сулады. Белми, аһ, белми ветеран: нәкъ әнә шул үзебез тудырган кытлык-дефицит нәтиҗәсендә таракан, кыргаяк кәнүшнәенә әйләнгән бит инде аның фатиры. Мондагы бөҗәкләрне килене дару сибеп кенә түгел, кәрәчин сибеп яндырса да бетәрлек түгелен белми иде шул ул...

Тышта, гыйнвар азаклары торуга карамастан, бик җепшеткән шикелле. Тирә-юньдә тын иде. Кеше адымы, сөйләшкән авазлар да колакка чалынмый. Бары тик аның ак очлым таягы гына вакыт-вакыт карлы асфальт катысында зеңгелдәп куя, мондый чакта таягы астыннан җирдә җим эзләп азапланган күгәрченнәр гөргелдәп һавага күтәрелә. Таяк тагын да зеңгелдәп,

юл читендәге бетон күтәрмәгә орынгач, ул кисәк кенә унга—Әспирәт урамына борылды.

Элегрәк бу урам, карт уйлавынча, Жданов атлы бер бик тә һәйбәт кеше исемен йөртә иде. Татарстан мөстәкыйльлек алгач, аны Әспирәткә әйләндерделәр. Мотаһар абзый аны Ждановтан да һәйбәтрәк татар кешеседер дип уйлый. Әзмени татарда хәзер атасыз-инәсез исемнәр. Моряклар, Термослар, Ориентирлар, Бинокльләр. Үзенең оныгы Вадим Мөдәррисовичкә генә игътибар итсен. Бәхетенә каршы, карт Эсперантоның моннан өч мең ел элек фәләстиннәр тарафыннан кыйратылганнан соң, җир шарына таралып, телләрен онытканнар яһүдиләр өчен унтугызынчы гасыр азагында ләх яһүде Людвиг Заменгоф тарафыннан уйлап чыгарылган ясалма яһүд теленең атамасы икәнлеген белми иде.

Урамга чыкса, аның колагы гүяки күзгә әверелә. Алай гына да түгел, бөтен тәне, борыны, теле, тоемлау чаралары—барысы да күз бурычын үтәүгә хезмәт итә. Үз кайгысы үзенә хәттин ашкан булса да, үткән-сүткәннәрнең сүзләренә колак сала, үзенчә бәя бирә. Әнә, ике хатынкай тагын да бәяләр күтәрелү турында гәп сатып, бар тирә-якны агулап үтеп киттеләр. Карт бу хәбәрдән шыбыр тиргә төште. Күпмегә күтәрелде икән? Нәрсәләргә? Әнә чажлатып каршыга машина килә бугай. Бакасын кычкырта, тамагы коргыры. Үт, үт. Зеңгелдек таяк тыртуардан жилдертә, энекәем. Әнә, төшке һаваны бары тик пычрак авазлар белән чәчкәләп, бер төркем ирләр узды. Фу, аракы исе! Иванайлар. Сүгенүләреннән аңлашыла. Тагын машина. Тагын бакасын кычкырта. Нигә кычкырта? Хәбәрләр, хәбәрләр. Ниндидер Якушкин үлгән. Өстәвенә, тагын ниндидер Сашка Вредныйны чәнечкәннәр. Туучылар кая? Хәбәрләр нинди генә булса да, картның кәефе күтәренке иде—өендә күкеле сәгате суга, ул үзе исә бик зур йомыш белән дәүләт кантурына китеп бара!..

Кинәт ул ике аягы белән дә чупылдап сулы чокырга төште. Шайтан алгыры! Аяк табаннарына шундук салкын дым типте. Юкка тыңламаган бая Казан радиосыннан һава торышын. Акчалары суланып куйса?! Хәер, алар су үтми торган чәй кәгазенә төрелгәннәр төрелүен. "Яра-а-ар,—дип тынычландырды карт үзен.—Тоз түгел—эремәс, агач түгел—черемәс". Шулай да ашыгырга кирәк. Таягын кары эрегән как асфальтта зеңгелдәтеп, ул адымын ешайтты, аннан сиртмәләнеп, йөгерекли башлады. Чаж-чож. Чаж-чож. Машина бакалары. Тукта, Мотаһар. Әспирәт урамына килеп житкәнсең түгелме? Көпчәк тавышлары басылуга, иңдәшләренең аяк тавышларыннан юнәлеш алып, ул шул ук йөгерек алкымда урамны кисә башлады. Зеңк-зеңк. Урамның уртасына житте бугай. Зеңк-зеңк. Менә аның таягы юл читендәге таш күтәрмәгә бәрелеп зеңләде. Кешеләрнең сөйләшүеннән аңлашылды, ул нәкъ кибет каршына килеп чыккан иде. Әмәт Тавы ягына борылган гына иде, аңа эндәштеләр:

—Исәнме, Мотаһар абзый!

—Исәнме.—Карт галәтенчә тавышын нечкәртте.—Кем әле бу?

—Зәйни булабыз. Кая барасың?

—Барам әле шунда.

—Туктап та тормыйсың, ызначит. Безне санга да сукмыйсың, ә? Без бит, Мотаһар абзыкайгынам, икебез дә бер профсоюздан—сукырлардан, ызначит.

—Анысы ниткән пырафсоюз тагын?

—Сукырлар профсоюзы, диюем...

Зәйни белән ул кайчандыр сабын комбинатында эшләп алган иде. Караклыгы өстендә тотылып, өстәвенә каравылчыга тән җәрәхәте дә салганы өчен аны биш елга манчыганнар иде. Зонада чифир, динатур, җыен химикат эчеп агуланып, сукыраюын да белә иде Мотаһар.

—Син бит әле күрәсең!—дип ырылдады ул, сөйләшәсе килмәгәч.—Сукырлар пырафсоюзы, имеш!..

—Стакан тотарлык кына!—Зәйни шаркылдап көлде. Аңа кушылып башкалар да көлеште. Ул, күрәсең, гоп-компаниясендә иде.—Әнә, "Салон

модной обуви" кибетенең рекламасыннан "м" хәрефе егылып төшкән. "Дом одной обуви"! Ха-ха-ха! Эре хәрефләрне, юньле кешеләрне күрәм мин... Димәк, кеше бер генә аяк киемендә йөрергә тиеш. Ха-ха-ха! Хәзер бер киез итегеңне салдырабыз, ызначит!..

—Син нәрсә сөйлисең?!

Карт чын-чынлап шөбһәгә төште. Салдырыр да бу имансыз. Аның битен юмаган.

—Нәрсә ул "модный"дагы "м" хәрефе!—дип өстәде икенчесе.—Менә безнең Горкида икенче ел инде "Салон мебели"дәге "м" хәрефе янмый. Әллә фәхешханә ачканнар!..

Барысы да буылып көлештеләр. Үз кайгысы үзенә җиткән Мотаһар мондагы кинаяләрнең мәгънәсен дә аңламады, көлмәде дә. Ул Әмәт Тавы ягына борылды.

—Әйдә, безнең белән берәр йөз грамм!—Зәйни аны тагын туктатты.

—Эчмим бит мин.

—Шушы эт тормышында да эчмичә түзәсеңме?

—Үзебез эт булгач. Эчмим мин. Иртәгә ураза гаете дә...

—Шулаймыни? Әйдә, ураза хакына!—Зәйни картны җилтерәтә башлады.—Ураза гаете хак-кына не откаж-жи!..

—Бәйләнмә бабайга,—диде бер боерулы тавыш.—Исән күзеңнән язасың килмәсә, бабайны илтеп куй.

—Һи-и-и, илтеп куймый диме! "Бас, кызым, Әпипә, син басмасаң, мин басам..."—Зәйни такмаклап бии-бии килде дә, Мотаһарга чат ябышты.— Илтеп тә куям, каршы да алам! Безнең урамда иң бай пенсионер бит ул, шулаймы, Мотаһар абзый?..

—Юк, юк, кирәкми...—Карт аңа сырты белән борылды.—Мин ни... Саф һава суларга гына... Мин ни... Кибеткә генә...—Аннан хәйләләп, сүзне икенчегә борырга тырышты.—Хакларны тагын кыйммәтләнгән диләр. Ишеттегезме, егетләр?

—Аракыга юк. Ипи-сөткә шактый күтәрелгән бугай,—диде Зәйни картның капканына кабып.—Әнә, урамнарда көндез дә яна ел иллюминациясе яна. Январь азагында! Ха-ха-ха! Чыгымнарны нәрсә беләндер капларга кирәк бит...

Ниһаять, бу тигәнәкләрдән көч-хәл белән арына алды Мотаһар. Көндезге Казан урамнарында яндырылган ут гөрләвекләрен күрсә, ул Татарстанын танымас иде. Эссе мунчада чабып, үлеккә җан кертергә тырышу белән бер иде бу утлар. Хакларның кыйммәтләнүе аның буыннарына ком булып утырды. Чокыр-чакырларда абына-сөртенә, тирләп-пешеп, ул Әмәт Тавына менеп җитте. Очлым таягын Саклык кассасының мәрмәр идәнендә зеңгелдәтеп кергәндә ул шыбыр суда иде. Тынычрак почмак кирәк иде аңа. Дивар буйлап капшанып килеп, таныш эскәмиясен тапты, аңа лап итеп утырды. Як-якка карангалап, тирә-юньне колагы аша күрергә тырышты. Пималарын салып, аягындагы оекларын рәтләп кигән булып маташты. Киез табаннар астындагы ике төргәк акчаны елт иттереп кесәсенә шылдырган картка игътибар итүче дә булмады. Хәер, залда кеше-фәлән юк та иде шикелле.

Ул үзенә кирәк өченче тәрәзә каршысына килде. Тирә-ягына тагын колак салды.

—Әлфия, кызым, синме бу?

—Әйе, бабай.

—Исәнме.

—Саумы, бабай.

Карт тагын колакларын шомрайтып алды.

—Хаклар тагын кыйммәтләнгән диләр. Ишеттеңме?

—Юк, бер дә аны-моны ишетмәдем, бабай.

Саклык кассасы кебек акча оешмасында да бу хәбәрнең расланмавын миенә җай гына сеңдергән карт бер мизгелгә сүзсез калды.

—Салырга дип килдеңме?

Якында аяк тавышлары колакка чалынмый иде.

—Әйе шул.

—Процентлыгамы?

—Әйе шул.

—Бездә калдырасынмы?

—Әйе шул.

Әй, унган да инде, ачык та инде ул Әлфия! Аның белән очрашканнан соң яшәгәнлегенә куанасың, акчаны да гел генә салып торасы килә!

—Күпме?

Мотаһар ишетмәсеннәр дигәндәй тәрәзә авызына пышылдады:

—Дүрт кисәк.

—Дүрт мең, димәк—диде Әлфия саксыз гына.

—Тс-с!..

Нульләрне алып ташлап та өлгергәннәр икән. Ну, шилма булып чыкты бу Чубайыс дигәннәре. Картның йөрәге урталай ярылды: аңа миллионнар якынрак һәм кадерлерәк иде. Шулай да миллионер булып күренмәс өчен ул аларны "кисәк" дип кенә атый. Әлфия исә бабасын күптән белә. Гайдар реформасыннан соң биредә картның утыз ике мең сум акчасы утырып янды. Аларга заманында үкертеп дүрт "Жигули" алып калырга мөмкин иде. Ничек кенә булмасын, карт маясын тулыландырды, хәтта бераз арттырып та җибәрде. Биредәге саклык кассасында аның утыз биш миллион, янача утыз биш мең сум акчасы ята. Әмма чүмәләсен һаман да очларга җыенмый карт. Ташуын гына белә. Кирәкләре чыкса дип, акчаларының өч миллионын гади саклык кенәгәсендә тота, калганнарын кыйммәтле кәгазьләргә алыштырып, мондагы сейфта, аерым конвертларда саклый. Һәр миллион аңа елына кимендә утыз процент чумара китерә. Әгәр ул акчаларын хәзер үк алса, аның илле миллионга якын акчасы бар!

—Монда култамгагызны салыгыз.

Әлфия картның кулына ручка сонып, аны кәгазьнең тиешле урынына төрттерде.

—Эһ-һем.

Карт меңәр сумлык дүрт облигацияне әүвәле санады, аннан сыйпап, иснәп, форматларының берлеген чамалап карады.

—Менә монда.

—Эһ-һем.

Мотаһар, ниһаять, имзасын армаклап, кәгазьләрне тагын бер мәртәбә санады һәм кызга кире сузды.

—Рәхмәт, кызым.

—Үзенә рәхмәт, бабай.

Культурный кешеләр белән сөйләшү нинди күнелле! Картның уалы аркасы тигезләнгәндәй итте.

—Урынына куя күр инде, кызым.

—Әлбәттә, бабай.

Мондый житди эшләрдән соң карт Әлфия белән бераз уйнаклап алырга да ярата.

—Әлфия, теге ни... Кияүгә чыкмадыңмы әле?

—Юк, алучы табылмый бит, бабай.—Кыз ак тешләренең җәүһәре белән тирә-юньне яктыртып көлде.—Хәзер бит аның егетләре дә юк, булганнары кызлар күзли белми! Син дә алмыйсың!..

"Чыгасыңмы?! Бүген үк алам!"—дип чак-чак кына әйтми кала карт.

—Кит аннан! Синең кебек чибәрләргә дә кияү табылмагач,—ди ул, ниһаять, телен тешләп.

—Чибәр икәнлегемне каян беләсез?

—Тавышыңнан күрәм.—Ул ата каз кебек урынында биеп алды.—Мондый ачык кызлар ямьсез булмый.

—Рәхмәт. Ә сез өйләнмәдегезме соң?

—Юк әле, Әлфия,—диде карт, тәрәзәгә пышылдап кына. Аннан тирән итеп уфырды.—Кирәк иде дә бит... Бик тә кирәк иде. Көннәре ярый,

төннәре авыр, төннәре... Исән бул.

—Исән бул, бабай. Тагын кил.

—Килми диме, Әлфия!.. Килми диме!

Карт кулындагы капчыгын, таягын җайлаштыргандай итеп, урынында бераз чайкалып торды да, саклык банкыннан чыкты. Кәефе күтәренке булса да, җаны бик пошаман иде. Әйе, бик тә газаплый иде аны бу мәсьәлә. Бер-бер хәл булган очракта—инде озак яшәргә, үз малларының кадерен үзенә күрергә язсын!—кемгә калыр бу дәүләтләр?! Балаларынамы? Юк, беркайчан да балаларына васыять итмәячәк ул аларны. Чересә, чересеннәр, тик аларга түгел. Әмма кемгә? Балалар бакчасына васыять итәргәме? Авызыннан җил алсын. Шул уйнаштан туганнарга акча ди тагын. Әнә берсе үз өендә "Дәү әти" дип тә әйтә белми. "Дүрәк!" кенә ди. Бәлки сукырлар җәмгыятенәдер, картлар йортынадыр? Тотсыннар капчыкларын! Анда чын сукыр калдымыни хәзер? Барысы мәшинникләр, алкашлар, Зәйни кебек динатур эчеп сукырайгач та күрә торган сукырлар. Тиенен дә тәтетмәячәк. Ата-инәләрен дә балалары карасын. Тукта, бәлки Казан керәмәлендәге Колшәриф мәчете төзелешенәдер? Ай-һай! Мәскәү кадәр Мәскәү Казан керәмәле эчендә мәчет төзетә димени? Бәлки туганнан туган балаларына калдырыргадыр? Кая соң алар? Килеп тә күренмиләр, сабакылар. Тукта, бәлки Татарстан, Рәсәй хөкүмәтенең үзенә—Туган Илгә, Ватанга васыять итәргәдер? Зурлап, телевизордан күрсәтеп, Иске бистәдәге татар зиратына күмәрләр иде. Тукай янына! Мәтам мәрсиясенә Президентыбыз үзе кул куяр иде. Юк, аларның берсе дә Мотаһар күнелендәге Ватанга туры килми. Менә бер елга якын инде Жуков медален дә тапшыра алмаган Ватан нинди Ватан була инде ул? Бармы соң аның Ватаны? Матур күренәм, тарихка керәм дип, кан коеп алган акчаларын шул тиленәргә калдырамы соң? Үз акылында әле ул! Төкерә ул аларның тарихларына. Бөек Ватан сугышы—менә ул тарих иде ичмасам! Бөек Сталин—менә ул тарих! Коммунистлар—менә ул тарих! Кая соң алар? Барысын гаеплиләр. Күп корбан биргәннәр, имеш. Бирсеннәр. Җиңү корбансыз буламы? Бәлки хатынына һәм үзенә алтыннар белән язып, кабер ташлары эшләтеп куяргадыр? Ә нигә? Үлгәч, гәүдәбезне барыбер корт ашый.

Ятсыннар әле, дип тынычландырды карт үзен. Акча ипи сорамый. Көне килер, васыяте дә язылыр. Бәлки Әлфиягә өйләнергәдер? Кая ди, чыгамыни ул аңа! Үзеңне тәрбияләргә, акчаны үзеңнән кызганмаска, яхшы ашарга кирәк. Югыйсә, боларның суык чәендә, майсыз тары боткасында аяк та сузарга мөмкин. Тамакка яхшы ашарга кирәк! Кызганмаска кирәк!

Бу фикере житди иде аның. Карт адымнарын ешайтты. Васыять дигән нәрсәне яздыру бик авыр хезмәт иде аңа. Моның өчен икенче бер кешегә сер саклау әҗәтенә керергә, чишелергә кирәк. Аны язарлык кеше, серне сакларлык кеше бармы аның тирәсендә? Юк. Аннары, бүгеннән васыять язу—үз-үзен бүгеннән үк кабергә тыгу дигән сүз түгелме?

Әле генә евроремонт үткәрелгән бинаның чынаяк идәнендә таягының угы белән цукылдап, ул ашамлык кибетенә килеп керде. Һавадагы азык-төлек, аеруча әчкелтем ипи исе ашказанының тегермән ташын дөбердәтеп әйләндерде. Ул ач иде. Бәрелә-сугыла, капшанып, шүрлектән арыш ипие, әрҗәдән берәр кап сөт һәм катык алып, касса каршына килде.

—Ипи-сөтнең хакы тагын күтәрелдемени?

—Говорите по-русски.

—Хлип скульке?

—Ике мең алты йөз,—диде касса машинасында җуылдап утырган кыз урысчалатып.—Тизрәк булыгыз.

—Малака?

—Ике мең сигез йөз.

—Күтәрелгән икән шул...

Калган акчасын тәлинкәдән сыпырып алып, кесәсенә тыкты да, читкәрәк китеп уйга калды. Аның үзен тәрбиялисе, үз-үзенә бәйрәм оештырасы килә иде. Бу кадәр зур эшләрдән соң! Бигрәк тә рамазан аенда

үзе теләгән азык белән авыз ачарга хакы юкмы? Бу ләззәтле уй банктан чыккач та килгән уйның дәһшәтле дәвамы иде. Моннан утыз ел чамасы элек, әле бер күзе күргән чакта, анын бу тәмлекәйдән дә тәмле нәрсәне кабып караганы бар иде. Кыйммәттер инде ул, шайтан алгыры!

Затлы балык азыклары бүлеге каршыда гына иде. Сатучы кызнын чиратта Мотаһардан алдарак торган хатынкай белән киләсе якшәмбедә Актанышка бергә кайту турында чатнатып татарча сөйләшкәннәрен ишеткәч, куанып, ул да татарча сорарга булды:

—Сездә балык уылдыгы бармы?

—Нәрсә була ул тагын?—Сатучы күзләрен чекрәйтте.

—Балык уылдыгы.

—Русча әйтегез.

Аның урысчасын карт әллә бөтенләй белми, әллә белеп тә оныткан иде. “Безнең сәгать кебек, бу да телсез икән,—дип уйлап алды Мотаһар.— Монысын кем чалшайта икән?”

—Һы. Уылдык. Уылдык...—дип, булмаган уылдыкны телендә әвәләде ул.—Риба. Бнутри бивает...

—Что он говорит?—Сатучы чиратка мөрәҗәгать итте.—Что такое удырык? Еще раз назови!..

—У-ыл-дык.—Йолкыш бүрекле, сәләмәгә төренгән, төпле пимасыннан идәнгә сулар саркылган өченче гильдия потомственный сәүдәгәр улы Мотаһар ибне Җан Барыс гавам арасында аптырашка калды. Елар чиккә житеп, кабатлады.—У-ыл-дык...

Чиратта балык уылдыгының нәрсә икәнлеген татарча белгән кеше юк иде. Сүз телдән-телгә бозыла-бозыла күчеп, чиратның очына барып чыкканда “у-у, дурак” булып янгырый иде. Рәхмәт, бер хатынкай, йөгереп килеп, аңлатып бирде:

—Я учительница татарского языка в отставке, я знаю—икру, икру он спрашивает!..

Үзе сукыр, үзе җимерек картның шундый затлы азык теләвеннән чират тантаналы рәвештә хәрәкәткә килде:

—О-ho! Губа не дура!

—Акчалы, димәк!

—Гурман нашелся!

—Тәмле тамак!.. Редкий гастроном!..

—Әйе, икра... Икра бит әле...—Тавышы табанына киткән Мотаһарның пышылдарлык та хәле юк иде.—Күпме тора?

—Илле граммы утыз дүрт мен, бабай!

Мотаһарның колагы да ишетмәс булды. Аны гүя яшен сукты. Акчага дип кесәсенә кергән кулын өянәк тотты. Әмма хурлыкка калудан тартынган картка артка чигенер урын юк иде. Акча савытын чыгарып, калтырана-калтырана, илле меңлек ассигнацияне сатучыга сузып өлгермәде, сатучы:

—Мә, ал, бабай!—дип, авызыннан ут чәчрәтеп тә өлгерде.

Чыпчык баласы кебек кечкенә калай савыт картның уч төбенә ләпәште. Аның авырлыгы да юк иде шикелле. Сатучы аның икенче учына калган акчасын да чәпәде.

—Шушы гынамы?—Мотаһар уылдыкны учында тирбәтте.

—Тәмле әйбер күп булмый. Эчне китерә ул.

—Рәхмәт... Яме!..—Ачуы чыккан Мотаһарның сатучы кызны аяк астына салып таптыйсы килде. Аерылышканда сатучыдан үч алу өчен рекламаның бөтенләй мәгънәсез, сүзләрен сүгенү итеп ырылдады.—Ольвейс! Шолден-холдерс!

Бераз баргач артына борылып өстәде:

—Әтнә сбалата!..

Калай савытны сак кына пәлтә кесәсенә шудырып, ул чыгарга юнәлеш алды. Алыш-биреш вакытында тәмам изелгән, алҗыган карт элек анын юлында беркайчан да очрамаган баганаларга бәрелеп-сугылып, әллә ниткән каршылыкларга тап булып, кешеләр белән маңгайга-маңгай чәкәшә-чәкәшә

кибеттән чыга алды. Замандашларының әллә нинди киребеткән, мәнсез, мәгънәсез агымы уртасында ул кинәт кенә юнәлешен югалтып, туктап калды. Унгамы? Сулгамы? Алгамы, арткамы? Кайчакта бу агымны ул үзе алга өстери иде кебек. Икенче караганда, күзле агым аны янадан артка тәгәрәтә иде. Ходавәндә, нинди урам соң бу? Аның Әспирәте култык астында гына иде бит! Әспирәт булырга тиеш бит бу! Димәк, аңа урамны аша гына чыгарга кирәк.

—Мотаһар бабай, адаштың мәллә?

Тавышыннан саф авыл мәкаме саркылган сабый?! Аңа Казанда, үз телендә, үз исемен атап эндәшә?! Әкәм-төкәм кебек кабыгына бикләнгән ветеран бөркеттәй киерелде:

—Тукта, тукта, кем буласың әле син?

—Заһир. Сезнең өченче каттагы күршегез. Алып кайтыйммы?

—И-и, рәхмәт төшкере. Алып кайтсаңие шул.

Малай картны җитәкләп тә алды, җәһәтләп урам аша алып та чыкты. Белә, нишләп белмәсен Заһирны Мотаһар. Бик тәртипле, бик акыллы бала ул. Дөрес, бәхетсез. Ятим. Балык Бистәсеннән китерделәр аны Гыйльмениса карчыкка. Ике генә яшьтә шикелле иде әле ул. Әнисе белән әтисе Төмәннән кайтканда үз машиналары белән КамАЗ астына кереп кыйралдылар, бичаралар. Дәү әнисе, рәхмәт, Мөдәррисләр кебек, ерак-фәлән дип тормады, малайны яңа ачылган татар мәктәбенә бирде. Әнә, ничегрәк кенә сайрый татарча!..

Мотаһар җитәкчедән бигрәк, үзенә әңгәмәдәш табылуына куанып бетә алмады, малайны мөмкин кадәр сөйләндерергә тырышты.

—Син ничәнчедә укыйсың әле, күрше?

—Бишенче сыйныфта.

—Әле каян киләсең?

—Мәктәптән.

—Яхшы укыйсыңмы соң?

—Яхшы дип. Өчләләр, дүртлеләр күбрәк инде. Бишлеләр сирәк. Әй, хәзер бишлеләрен дә сатып алалар. Нигә кирәк миңа сатылган бишле? Иң ышанычлысы өчле инде аның,—дип чишелеп китте малай.—Аның каравы, минем татар теле, татар әдәбиятыннан чыпыртап торган бишле. Шигырьләр язам мин. Бер тапкыр укып та чыгам, ятлап та алам менәтерәк!..

—Тукайны да беләсеңме?

—Белмичә. Кызык син.

—“Туган тел”не дә беләсеңме?

—Белмичә ни!

—Укы әле, күрше!—диде карт туктап. Малай аңа елмая иде шикелле. Елмайган кешене ничектер күргәндәй итә Мотаһар. Аның Мөдәррисе генә, агач полицай кебек, туганда ук елый-елмая белмичә туды. Еламаган бала елмая да белми шул.—Укы әле, үскәнем.

> И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
> Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы...—

дип укып китте малай һәм бабасына ул белмәгән-ишетмәгән тарихны да чишеп салды.

—Күптән түгел безгә укытучы абый сөйләде. Тукайның “Туган тел” шигыре дүрт тезмәдән торган булган икән. Совет заманында аның дүртенчесен чыгармый килгәннәр. Хәзер без аны мәктәптә тулы килеш җырлыйбыз. Менә ул:

> И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
> Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам.

—Кара әле, син нәрсәләрне беләсең!—дип чынлап та гаҗәпләнде карт.—Ә нигә теге соңгы тезмәне чыгармый торганнар? Шигырьдә бернинди дә крамала юк бит?

—Син нәрсә?!—диде малай үчегеп китеп.—Нишләп булмасын? “Ходай”

дигән сүз нәрсә сина? "Дога" дигән сүз? Коммунистлар бит аларны яратмады!..

Заһирнын өлкәннәрдән дә ушлырак булуына Мотаһар шаклар катты. Биргән соравы да үз башына булды.

—Коммунистларны яратмыйсынмени?

—Ә ни өчен яратырга аларны?

—Ә син... дога кыласынмы сон?

—Кылмыйча.

—Ураза да тотасынмы?

—Тотмыйча.

—Намаз да укыйсынмы?—дип сорады ул куркып кына.

—Укыйм. Биш вакытын ук түгел инде. Иртәнге, икенде һәм ахшам намазларын. Дәү әни белән бергә. Мәктәптә укыттырмыйлар.

—Ә-ә-ә... Алай икән. —Карт үзенә урын табалмагандай, кузгалды.— Алай икән...

Алар бераз сүзсез бардылар. Сәнгать институтынын гомум торагы почмагында кемнәрдер аты-юлы белән сүгенеп әрләшә иде.

—Дәү әниен сине орышмыймы сон?

—Ни өчен?

—Син гаепле булганда дип әйтәм. Кыйнамыймы?

—Кыйнавын кыйнамый. Әрләштерә инде. Бигрәк тә киемне жыртып, жүешләнеп-чиләнеп кайтсам...

Өстендәге чиста кызгылт кытай сырмасы, ярыйсы ук яна кара чалбары, йөнтәс бүреге, аягындагы эре каптырмалы, үзенә бик тә килешеп торган штиблетлы киеме белән гүяки коеп куелган бу үсмер, әллә чыннан да кызыксынып, әллә кызганып, ана теләктәшлек күрсәтергә тырышып, сорап куйды:

—Мотаһар бабай, синен күзләрен кайчан сукырайды? Тумыштан түгелдер бит?

—Тумыштан тома мин,—диде карт сугышны, капитан Непейпи-воларны исенә дә төшерергә теләмичә.

—Ул чакта... синен йөзен нигә алай жимерек? Анысы да тумыштанмы?

Каһәр генә суксын бу телләр малай актыгын!

—Анысына ат типте.

—Ат?—Малай ышанырга ашыкмады.—Ат типсәме? Ат типсә, болай гына калдырмас. Пәри үпкәндер әле. Битенне юмыйча яткансындыр да. Мине дәү әнием битемне юдырмыйча яткырмый. Югыйсә, битенне пәри үбә, ди...

Карт сүзне икенчегә борырга тырышты.

—Вадимны беләсенме син? Бергә уйныйсызмы? Дуслармы?

—Дус та, дошман да түгел. Ул татар малайлары белән уйнамый.

—Ә син анын белән дуслашырга теләр идenme?

—Ничек кенә әле! Без бит бу подъездда өч кенә татар малае.

Кара әле син аны, ә? Кара әле син бу метекне! Ничек кенәләр фикер йөртә. Картнын кәефе килеп китте.

—Ә син безгә кереп йөре, Заһир. Көн саен кер. "Күрше хакы—тәнре хакы",—ди. Мин сезне Вадим белән дуслаштырырмын,—диде оныгынын аны тынламаганын белсә дә, үз өстенә гөнаһ алып.—Минем сүздән чыкмый ул...

—Кайчан керим?—диде малай, куанычын яшерә алмыйча.—Бүген үк мәллә?!

—Теләсән, бүген үк.

—Ярар.—Малай яна дус табылачагына шатланып сикергәләнде.—Керәм, Мотаһар бабай. Сәгать ничәдәрәк?

—Бишләргә кер. Анарчы Вадим да кайтыр.

—Бишләргә керәм дә, тәравих намазын бергә укыйбыз, әйеме? Син, мин һәм Вадим!—Малайнын шомырт кара күзләрендә очкыннар чәчрәде,

сөйкемле йөзе яктырып китте.—Иртәгә без гает намазына да бергә барабыз, әйеме? Сез кайсы мәчеткә йөрисез? “Кабан арты” мәчетенәме?

Бу шайтан алгыры малай тәки гөнаһ шомлыгына батыра бит!

—Без ни...—дип мыгырданды карт.—Анда күз күрер...

Шулчак картның тинтерәгән башына “Бу баланы алып кереп, балык уылдыгы белән сыйлап чыгарырга мәллә?” дигән куркыныч сөаль килде. Әмма шундук кире уйлады: сукыр карт алдыннан сыпырып бетермәсме ул уылдыкны? Алар ашап утырганда гына Вадим кайтып керсә? Тавыш күтәрсә? Аннан, гомумән, ярыймы чит кеше баласын үзенә ияртеп керү? Бер кергәнгә—мең кергән, дигәндәй, сукмак салып, бимазаласа? Бәлки ятимне хәзер үк хәер-садака белән бәхилләтергә кирәк-тер? Иртәгә изге гает тә, диләр... Иртәгәсен алла белгән, әмма бүген үк акча биреп, узындырып куюшулай ук саваплы эш түгелдер әле ул, тикшерә китсәң. Акча даулап, тәкатен корыта башласа? Балигъ булмаган балага акча бирүне дә бигүк хупламый бугай Коръән. Хупламаска тиеш. Хупламас.

—Килеп життек, бабай!

—Рәхмәт сиңа, үскәнем!

Ул жентекләп ишеген капшады, аны жентекләп ачты да, кораб корсагына чумган нәгрә колы шикелле эчкә таба ишелде. Ишекне эчтән жентекләп бикләгәч, житәкче таягын кирәкмәгән чималдай почмакка ыргытты. Анысының ятим бала сыман иңрәп авуына ул игътибар да итмәде. Ашыга, бик тә ашыга иде. Сәгате йөреп ята икән. Пәлтә кесәсеннән уылдыгын чыгарган арада ул киез итекләреннән көч-хәл белән арынды һәм юеш оек-башлары белән тузанлы идәндә шәрә эзләр калдыра-калдыра хөжрәсенә үтте. Сәгате чынлап та йөри икән. Өстен-башын салып бер почмакка томырды, букчасыннан ипи чыгарып, өстәл читенә куйды. Өстәл тартмасындагы күп япьле пәке белән савыт калаен шыңгырдатып кисте, каерып ачты, уылдыкны тәүдә иснәп, аннан бармак очлары белән чумырып алып, тәмләп карады. Зәһәр тәмле иде бу азык! Ашказанының тегермән ташы тәкатьсез дөнгердәде. Калак-фәлән эзләп торыр, калак белән маташып, шундый затлы азык бөртекләрен идәнгә коеп, әрәм-шәрәм итәр форсаты-мөмкинлеге дә юк иде. Ниһаять, караватына ишелеп төшеп, ипи түтәремен урталай гына сындырды, умырып уртлады, бармак очларыннан тәүдә авыз мәгарәсенә, аннан юньле-рәтле чәйнәп тормый карынына озатты. Шулай итеп, Мотаһар, мен ел элек кыргый мәжүсидән хак мөселманга әйләнеп, иманга килгән болгар Мотаһар, соңгы илле-алтмыш ел эчендә яңадан мәжүсилеккә куып кертелгән татурыс Мотаһар, изге Рамазан ае уразасының соңгы көненә каршы кичтә, икенде намазы алдыннан авыз ачарга тотынды. Анкауларга, теш казналарына сылашып, уылдыкның йомшак, леркелдәп торган сәйләннәре изелә һәм шундук көч керткәндәй тоела. Тәмле икән шул бу матдәи мәгъсумә! Аны министрлар да юкка гына яратмый икән шул. Алар аны майга ягып ашыйлар бугай. “Безгә, кара корсакка, майсыз да бара”,—дип уйлап куйды карт.

Ишектә кыңгырау челтерәде. Хәерсезләр! Кем булыр бу тагын? Шул ук Сәфәргали түгелме? Капкан кабымыннан төелеп, авызы ачык савытны карават астына шудырды һәм йорт нигезе буйлап жил куган тирәк мамыгы сыман тавышсыз-тынсыз гына ишек катына узды. Кыңгырау тагын челтерәде.

—Ыхту тамы?

—Хәрби комиссариаттан капитан Ярмухаметов,—диде урысча тавыш.—Безгә бөек Ватан сугышы ветераны Мотаһар Хафизович Чанборисов кирәк иде.

—Мин булам ул!—Карт урынында биеп алды һәм авыз читләренә, иреннәренә ябышып калган уылдык сәйләннәрен яларга да онытып, ишекне ачты.—Мин булам ул! Күптән көтәм, иптәш капитан, үтегез, чишенегез!..

Ишектән иң тәүдә хәрбинең сәмруг кошлы кокардасы, аннан шинель поставы эчендәге йомырка гәүдәсе килеп керде. Артында фотоаппарат аскан хатынкай да бар иде.

—Гафью итягез, мин татарча начар суляшям,—позвольте местами урысча говорить.—Капитан чишенгән һәм ханымны чишендергән арада

картны һәм тирә-якны күздән кичерде.—Минен билян фотографыбыз Сәкинә Шакировна Чернобровкина да килде. Безне фотографировать, короче. Гафью итягез, иртәрәк килә алмадык. Районыбызда 180 мен народу, 67 мен пенсионер, ветеран, инвалид. Алты мең военный, короче. Ике йуз семьдесят, сизнин кябек, постельдә яткян...

—Аллага шөкер, мин урында ятмыйм ятуын,—диде түземсезләнеп Мотаһар. Анын миеннән яшен тизлегендә "Пинсәне дә арттырырга килгәннәр икән",—дигән уй узды.

—Гафью итягез, әйе, сез сукыр гына!—диде капитан залга үтешли.—Һич кенә дә житешә алмыйбыз. Комиссариатта офицеров мало, хезмәт хакы түләнми, короче. Әгәр сизнин фамилия "А" дан башланган булся, иртяряк та пришли бы. Ә сизники "Ч"! Замыкающий.—Ул гөргелдәп көлде.—Хярби хезмятта, билясиз, ранжир, субординация, алфавит!..

Алар зал уртасында баскан килеш катып калдылар. Картнын тизрәк медальләрне тотып карыйсы килә иде.

—Сизгә короче, Рәсәй Президентыннан Жуковский медаль да плюс Ленинградский медаль тапшырырга килгян...

—Кхе-кхе... кхе-кхе...—Көтмәгәндә ишелеп төшкән бу шатлыгын кая куярга белмәгән Мотаһар кинәт трактор пускачы кебек кабынды һәм туктый алмас дәрәҗәдә кеткелди башлады.—Кхе-кхе... кхе-кхе...

—До вручения медали...

—Кхе-кхе... кхе-кхе...—Мотаһар гүя бу медальне күтеп илле дүрт ел көлмәгәнен көлә, чынаяктагы туң сөзмә кебек жепши, эреп таркала иде. Бала акылы керә башлаган, көлгәндә ихластан авызы колагына житеп чалшайган карт пенсиясенен дә арттырылачагын алдан ук сиземләп, туктый алмады.—Кхе-кхе... кхе-кхе...

Офицер "Акылдан яза мәллә бу?" дигәндәй картка укталды һәм кычкырып жибәргәнен дә сизмәде:

—Сез—защитник Отечества! Гафью итягез!..

—Әйе, әйе, мин шундый ул,—дип урынында сиртмәләнде Мотаһар.—Мин шатлыктан... Жылы сүздән... Тыела алмыйм!.. Кхе-кхе... Кхе-кхе...

Сәкинә Шакировна өнен дә чыгармыйча фотоаппаратын көйләп өлгерде.

Карт һаман көлә иде әле. Офицернын күзләре маңгайга менеп, катып калды. Таудан буш мичкә сыман дөнгердәп тәгәрәгән Мотаһар белән ул нишләргә дә белмәде. Ниһаять аптыраштан ачык килеш оеган авызыннан иң таралган хәрби боерыкларнын берсе яңгырады:

—От-ста-а-а-вить!..

—Һи-һи-һи-һи-һи...—Карт һаман тыела алмый жәфалана иде.—Кхе-кхе-кхе...

Көтелмәгән хәлдән ничек чыгарга белмәгән Ярмөхәммәтов тирә-ягына каранды, анын күзенә өстәлдә яткан камыт энәсе чалынды. Ул аны алды һәм сак кына итеп Мотаһарнын беләгенә чәнечте.

Карт көлүеннән шып туктады. Аннан соң гына нииндидер авырту сизеп, кулын тартып алды.

—Сиз нярсә?—диде капитан.—Радоваться как раб, до умопомрачения? Тормышта ласка курмагян что-ли? Биз, татарляр, достойный народ!..

—Әйе, мин татар... татар...—дип урынында тагын биеп алды карт.—Мин шундый инде...

Капитан дипломатыннан әүвәле ике кечкенә кап алып, аларны саксыз гына өстәлгә ташлады. Аннан, астарак бутанып, шешә чыгарды:

—Миня бу аракы Башкомандующий Ельциннан,—капитан шап итеп, шешәне өстәлгә утыртты.—Ә сиз, Сәкинә Шакировна, стакан-фаляннар, короче! Калай кружка еще да яхшырак булгян.

—Аракы?—диде карт танавын жыерып.—Мин эчмим бит. Мин аны менә кырык ел инде капканым да юк.

—Ну... гафью итягез, в честь байрама!..—Ярмөхәммәтов, шартына китереп, көйләп тә куйды.—Хәтерлисезме?" В тесной печурке бьется огонь..." Землянка хакына солдат йөз граммы, короче!..

—Һы.

Ул ара да булмый Сәкинә Шакировна кухняда шалтыр-болтыр китереп, өстәлгә бер калай кружка һәм ике сырлы стакан, каткан ипи кисәкләре китереп куйды.

—Сезнең орден-медальләр тагылган костюмыгыз, йә булмаса, мундирыгыз юкмы?—диде ул.—Киеп тә алсагыз, ә?

—Бар, бар! Булмыймы соң? Киенеп тә чыгыйммы?

—Сез ифрат та шәп эшләгән булыр идегез!

Карт бүлмәсенә чумды.

Ярмөхәммәтов өйрәнелгән алым белән шешә капкачын сыдырып төшерде, савытларга голт-голт итеп аракы койды; калай кружканы картка, стаканнарның берсен үзенә, икенчесен хезмәттәш хатынкаена тәгаенләп, этештерде; бүлмәгә затсыз Минзәлә аракысының сасы исе таралды...

Озак та үтми, таушалып, кыршылып, урыны белән көя төшкән, урыны белән тычкан кимергән, үтүк күрмичә тасланган, бөгәрләнгән эзләрдән генә торган, итәгеннән иңенә, аркасына кадәр медальләр, елтыр знаклар, калай билгеләр белән чуарланган кәчтүнен шул ук изрәү кофтасы, изүеннән эчке ыштаннары яктырып торган чалбары өстеннән генә кигән Мотаһар карт, диварлар буйлап капшана-капшана һәм металл чыңында зеңгелдәп, хөжрәсеннән өстерәлеп чыкты. Ул үзе иненә гүя Кызыл Армиянең соңгы илле еллык тарихын, Бөек Җиңүнең илле елдан да артык булган елъязмасын күтәргән иде. Бакча карачкысы кебек почмакланып калган, авызлары бер якка, наградалары икенче якка янтайган картны күреп, капитанның авызы ерылды. Хатынкай исә һәр бармагына диярлек кунаклаган балдакларын чеңләтеп, өстәлдә барабан какты:

—Трат-та-та! Трат-та-та!..

—Муна это да! Муна гвардеец!—Ярмөхәммәтов картны җилтерәтеп алып, өстәл каршына бастырды.—Мунда становитесь!..

Нәкъ Казан уртасында нәкъ ике татар баласы урыс азатлыгы өчен саулыгын корбан иткән өченче татар баласына нәкъ илле дүрт елдан соң бүләк тапшыру тантанасын башлады.

Сәгать йөри иде.

Вакыйга Татарстанда барганлыктан, йола тантанасы урыс телендә башкарыла иде.

Әмма капитан нишләптер Ленинград медален әлегә читкәрәк ышырып куйды. Тома сукыр картның бөтен көткәне шул иде дә бит! Билгесез сәбәпләр белән маршал Жуковның тууына йөз ел тулу уңаеннан чыгарылган һәм моннан өч ел элек тапшырылырга тиешле медаль алга чыкты.

—Мин сизгя башта Президент котлавын укып ишеттергян. Аннары Ленинградны тапшырган.—Капитан тирән итеп тын алды, муенын сузып, тамагын кыргалаштырды һәм армия алдында укыган сыман кычкырып, котлауны укырга керешге:

—Дорогой Мутагар Хафизович Чанборисов! Большая честь для меня поздравить Вас со светлым Днем—Праздником Победы. Пусть это станет доброй традицией. Нашей жизнью мы обязаны Вам, Вашему мужеству, обязаны Вашим товарищам, погибшим и уцелевшим. Дай Бог успеть отдать Вам хотя бы часть долга за счатье мирно жить на этой земле..."

Мотаһарның җаны үксеп елый һәм бу тантананы капитан Непейпивоның рухы күрә микән дип үрсәләнә иде.

"...Растить детей, строить и обустраивать наше Отечество. Здоровья Вам, бодрости и долгих лет жизни. Пусть в этот день вместе с Вами будут Ваши товарищи, близкие, дети, внуки и правнуки. Ваш Президент Борис Николаевич Ельцин".

Кемнәрнеңдер кулын кысарга теләп, карт кулларын алга сузды, әмма алар бушлыкта асылынып калды. Капитан Ярмөхәммәтовның куллары исә медаль кабында казына иде. Ниһаять, медальне алып, ул карт янына килде, аның күкрәгендә буш урын эзләп озак капшанды, аны тапкач, җәфаланаҗәфалана беркетеп тә куйды.

Хатын фотоаппаратын чәкетте.

Сәгать сугып җибәрде.

—Дан! Кәккүк!... Дан! Күккүк!..

—И час пробил!—диде капитан.

Мотаһарга анардан да бәхетле кеше юк иде бу мизгелдә. Сәгате сукты. Аның *сәгате сукты*! Нәрсәнедер эшләп бетермәгән кеше сыман, аның йөзеннән борчылу шәүләсе узды.

—Ыс-служу Сов-ветскому С-Союзу!—дип кычкырып җибәргәнен ул сизми дә калды.

—России,—дип төзәтте капитан.

—Әтнә чурт,—диде карт.

—Хязир сизгя Ленинград медален тапшырган...

Мотаһар үрә катты. Аның колагын гөрселдәүләр басты. Гүя ул ишетми дә иде. Капитанның инде хырылдап кына төсмерләнгән тавышы аңа өзек-өзек кенә ниндидер СССРларның Верховный Советларының әллә кайчангы 1944 ел указларының үз хуҗасын илле дүрт елдан соң гына эзләп табуы турындагы хәбәрләрне җиткерә иде. Тагын кемдер аның пинҗәк түшләрендә капшана башлады. Куллар медаль араларын сөрән белән сөреп, уң иңбашка күтәрелде һәм нәрсәнедер беркетеп куйды.

Хатын тагын да чәкетеп алды.

"Пинсәне арттырмыйлар микәнни?"—дип уйлап алды карт.

—Поздравляем вас, короче!..

Мотаһар төшеннән өненә кайтты. Аның сул күзләрендә зәңгәр нокта булып катып калган күз карасы чыпчык чәчкәсе сыман зәңгәрләнгән иде.

—Ыс-служу Сов-ветскому С-Союзу!..

—России,—дип тагын төзәтте капитан.

—Әтнә чурт,—дип тагын кабатлады карт.

—Гафью итягез, бу шатлыктан грех не выпить!—Ярмөхәммәтов картның кружкасын кулына алды.—Айдягиз, сам Главнокомандующий сурый сиздян йуз грамм фронтовую чарку выпить!..

—Эчмим бит мин!

—По такому случаю?!

—Уразада мин. Уразада,—дип кабатлады карт хәлен җинеләйтү өчен.

—Ураза? Святой Рамазан? Бу случайдан сам Аллах не запрещает, ветеран! Айдягиз, байрам хурмят!..—Ул калай кружканы карт кулына сонды. Хатынкай белән үзе дә күтәрде.

Сасы аракы исе Мотаһарның борынына килеп бәрелде. Шушы агуны аның инде кырык ел авызына да алганы юк.

—Ну! Тоже мне, фронтовик!..

"Ветеран", "фронтовик" дигән кадерле сүзләр картны йомшартып җибәрде. Әчәргә мәллә? Монавындый бәйрәм көнне? Аның үзен әз генә булса да кадерләргә хакы юкмыни? Сине Мәскәү кадәр Мәскәү, Президент үзе котласын да! Өстәвенә, фатирын ямьләп сәгате дә сугып утыра! Эчтәге шайтан кытыклавын дәвам итте. Нәрсә булса да булыр!

Карт авызының ачык ягына керәгәнең яртысын бушатты, бераз тын торды, аннан капшанып, савытны өстәлгә куйды.

—Рахмет, батя! Сизнин исянлика!

Капитан һәм Сәкинә Шакировна йөзләрен дә сытмыйча эчеп җибәрделәр. Хатын офицерга сарылып, үбеп алды һәм почмактагы диванга таба тартты. Ярмөхәммәтовның гаҗәпләнгән кашлары маңгаена сикерде, ул баш кагып кына ярамаганлыгын аңлатты.

Картны тагын бер тапкыр котлап, кунаклар чыгып та китте.

Өстәл җыештырылмаган килеш торып калды.

Аракы Мотаһарның башына китеп тә өлгергән иде.

Сәгать өчне сукты.

Кара әле, чынлап та нинди бәхетле көне аның бүген! Көтмәгәндә, диген. Президент исеменнән бер юлы ике медаль. "Соң булса да, уң булсын",—дип юкка гына әйтмәгәннәр шул. Аракысын да эчми булдыра

алмады. Әгәр Президентныкы булмаса, бәлки эчмәгән дә булыр иде. Коммунистларның кара дошманыныкы булса да эчте. "Җир шарында алты миллиард кеше яши, дип әйтә радио,—дип уйланды ул урынында торган килеш.—Шул алты миллиард халыктан берәр генә кеше булса да уйлый микән бүген аның турында? Белә микән аның нинди бәхетле минутлар кичергәнен? Балалары, оныгы белә микән? Фәрдүнәсе белә микән? Белә, пычагым! "Бүгенге мондый шатлыклы көндә фронтташ дусларыгыз, иптәшләрегез, якыннарыгыз, балаларыгыз һәм балаларыгызның балалары сезнең яныгызда булсын",—дип теләде бит Борис-патша. Әгәр белсәләр, кая соң алар? Бу алты миллиард әдәмчекләрнең берсе булса да кая? Нигә шылтыратмыйлар? Мотаһарның телефоны янәшәдә генә бит. Алар бит барысы да күрә, Мотаһар кебек күзсез түгелләр. Димәк, алар күрми. Сукырлар. Ә менә Мотаһар, тома сукыр Мотаһар күрә аларны. Нигә шулай икән бу? Нигә күзлеләр күзсезләрне күрми? Күнел күзең күрмәгәч, маңгайдагы күзең ботак тишегенә әйләнгәнгәме? Юк, нигә шалтыратмыйлар алар?!! Кемнәр өчен канын койды ул?! Дөрес, айга-елга бер аңа да шалтыраткалыйлар. Ләкин күзлеләр түгел, аның Сукырлар җәмгыятеннән үзе кебек күзсез дуслары. Бүген алары да тынсыз. Фәрдүнәсе дә килеп чыкмый ичмасам, аның шатлыгын уртаклашырга. Былтыр гауга күтәреп киткәненнән соң эзен дә күрсәткәне юк.

Шул чак хәтеренә төште—хөҗрәсендә ашап бетерелмәгән балык уылдыгы көтә бит! Кара, никадәр алдан күргән ул булачак тантананы, ә? Гомерендә беренче һәм бердәйле итеп! Уылдык—аның үзенеке, аракы исә Президентныкы. Аңа күзләре кайткан кебек тоелды. Ике як иңсәсеннән итәгенә кадәр медальләрне капшады. Төшеп калмасыннар тагын дип әле генә тагылган ике медальне урыннарыннан тарткалап карады, иркәләп сыйпаштырды. Балаларча куанып, эчеп бетелмәгән көрәгәсен алды да, күзле кешеләрдәй лап-лоп, туп-туры атлап бүлмәсенә марш-бросок ясады. Көрәгәсен өстәленә куйды, янадан дүртаякланып, караватт астындагы уылдыкны китереп чыгарды. Аракыдан соң картның ашказаны гүя котырган иде. Ул комсызлык белән ипи түтәрәмен авызына тыкты, исән калган азау тешләре белән умырып алды, аның артыннан бармаклары белән өерелдереп, уылдык төя башлады. Уылдыкның кызыл йөземнәре аның пинҗәгенә, орден-медаль йөзләренә, чалбарына коела, авыз тирәләренә сылана һәм аның үз кулы белән изелә-сылаштырыла иде.

Карт аракысын янә уртлады. Тагын да кәефләнү ниятендә ул көрәгәсе төбендә бераз гына калдыруны мәгъкуль күрде. Нигә Татарстанның өч миллион сигез йөз мең күзле бүкәне, Казанның бер генә булса да ышпанасы, биш мең сукырыннан берсе "Мотаһар абзый, хәлләрең ничек?"—дип шылтыратмый икән? Ә Мотаһар абзыегызның хәле, күрәсез, начардан түгел. Президентның Мәскәүдән җибәргән аракысын балык уылдыгы белән сипләп утыра әле ул. Ул үзе сезләрне котлый. Исәнлек-саулык, бетмәс-төкәнмәс бәхет, хезмәт уңышлары тели. Балаларына карата да шундый ук изге теләктә ул, мин сезгә әйтим...

Сәгать дүртенче яртыны сукты. Кәккүкләр хөрмәтенә карт аракысын тагын бер тапкыр йотты. Әйе, власть бар. Димәк, хакыйкать бар. Коммунистлар сендермәгән булса, капитан кадәр капитан, фотографлар ияртеп, Әспирәткә килеп йөрер идеме?

Ишектә янә кыңгырау челтерәде. Йә, хода! Монысы кем булыр тагын? Вадим дисәң, ул ишекне үзе ачып керә. Сәфәргалиме нервыда уйный? Картка хәл кергән иде. Уылдык савытын, аракы көрәгәсен җыештырып тормый, ишеккә таба шуышты. Кыңгырау түземсезлек белән тагын челтерәде.

—Хәзер... хәзер...—Аракыдан мие томаланып куйган Мотаһар аяк астындагы нәрсәләргә абына-сөртенә килеп, ишеккә капланды:

—Ыхту тамы?

—Мин бу. Фәрдүнә.

Биргәч тә бирә бит Ходай Тәгалә! Шушындый бәхетле минутында аңа кызын да җибәргән! Котларга килгән! Рәхмәтләр генә төшсен үзенә!..

Ул келәне шудырып ишекне ачты.

—Әйдә, түрдән уз, алтын кисәгем! Исәнме!..—диде ул, шат елмаеп.

—Алтын кисәгеннең исәнлеген үзе килгәч кенә белешәсенме? Тоже минә... эти!—Ишек белән бергә Мотаһарның үзен дә диварга җилгәреп, Фәрдүнә белән тагын кемдер фатирга үтте.

Сәгать дүртне сугып азапланды.

—Сөекле улың, киленең, оныгың кая?—Өстен-башын, аяк киемен дә салып тормаган Фәрдүнәнең тавышы кухнәдән килә иде.—Фу, мондагы сасы! Таракан оясы! Өстәлләрендә мачы сикертерлек азык булса ичмасам!—Кухнәдә туктаусыз савыт-саба шалтырый, ә биредә, ишек катында катып калган һәм җаны үкчәсенә киткән Мотаһар янында Фәрдүнә ияртеп кергән ирнең мыш-мыш тын алуы ишетелә.—Син монда эчеп-исереп, Наташалар белән зина кылып ятасың икән! Шешәсе белән аракы! Стаканнардан гына чүмерәләр, ә кызының ашарга икмәге дә юк!—Нәрсәләрдәдер актарынган, нәрсәләрнедер җимергән Фәрдүнәнең тавышы инде залдан ишетелә иде.—Яңа телевизор, стенка да алганнар, әни мирасын талап баегач. Ә кызга—шиш! Иске телевизорны мина бирер идегез, ичмасам!—Тавыш бу юлы Мөдәррисләр бүлмәсеннән саркылды.—О-һо-һо! Син монда хәрчәүнә ачкансың түгелме? Икра! Аракы! Мондагы ис! Нәрсә, киленең идәнне дә сөртмиме?—Фәрдүнә инде хәзер анын бүлмәсендә чәр-чәр килеп агу чәчә, бар дөньяны дөбер-шатыр китереп актарына иде.

—Ниш-лис-сең син анда?!—Карт кычкырып җибәрде һәм артыннан теге кешенең тын алышын да сөйрәп, бүлмәсенә өстерәлде. Аһ, авыр иде аякларга тагылган герләр!—Ниш-лис-сең син анда, алтын ки-ки-ки...

—Нишләсәм дә үз дөньям! Әни үлеп, мин моннан сынык кашык та алмадым! Җитте, күп түздем... Бөтен байлык, өч бүлмәле фатир, түшәк-ястыклар, дөя йонынnan юрганнар, машина—һәммәсе дә Мөдәррискә һәм аның сигәк хатынынамы? Юк инде. Сидереп сидегегезгә утыртам әле мин сезне!.. Миллионнарыңны аларга гына биргәч, үз өлешем артыннан килдем һәм алмыйча бу тупса аша атламыйм да!—Карават артындагы почмакта казынып маташкан Фәрдүнә таушалган, кырынмаган, кырыкка ватылып йончыган әтисен башыннан аягына кадәр елтыр калайлар өермәсендә күреп, билен турайтты һәм ботларын чәбәкәйләде:

—Ин-нә-кәй-ге-нәм!.. Парадка әзерләнден мәллә? Тоже мне, маршал Брежнев!—Кыз авызыннан ут чәчә-чәчә картка якынлаша башлады.—Әллә өйләнәсеңме, алтын кисәгем? Булачак әни белән шулай типтердегезме? Әни мәрхүмә, балаларың, оныкларың өстеннән көләргә булдыңмы?—Кинәт ул өстәлдән уылдыклы савытны алды һәм әтисенең йөзенә чәпәде.—Мә, тыгын!..

Уылдыкның лайлалы ләтчәсе анын нәкъ сул күзе чокырына кереп ләпәште. Карт ләпәкнең кызыл сәйләннәрен пинжәгенә, чалбарына коя-коя ышырып ташларга азапланды, әмма аны киресенчә, бөтен йөзе буйлап изде, кызыл балык каны бите буйлап шуышып төшеп, киемен алсулады һәм ул, ниһаять, кызыл уылдык мичкәсеннән—таңның үзеннән чыккан сыман кызарып алсуланды.

—Бар, чыгып кит!—дип җикерде тәмам айнып киткән карт.—Син хәзер шулай йортлар басып йөрисеңмени?!

—Китәрмен мин сиңа! Фәрдүнәдән җиңел генә котылырмын дип уйладыңмы?—Ул әтисе артыннан бүлмәгә үткән каракучкыл милиционерга ияк кагып, зал өстәлендәге шешәгә ымлады. Үзе әтисеннән калган көрәгәне күтәреп куйды.

Тулы капчык кебек билсез кеше тавыш-тынсыз гына шешәне бушатып, эчеп җибәрде.

—Бар, чыгып кит дим!—Мотаһар өстәлдәге телефонны капшагандай итте. Югыйсә, милитсия чакыртам!..

—Милиция күптән биредә,—диде анын кулына баскан адәм.—Оҗмахка китәсегез килмидер бит?

Әһә, болай икән. Карт нишләргә дә белми катып калды.

—Оҗмахка да, тәмугка да алмыйлар аны, Сережа.—Кызы аты-юлы

белән сүгенеп җибәрде һәм гөрселдәтеп караватны урыныннан күчерде.— Кеше түгел ул, бөҗәк! Бүгын да үзе ашаган бөҗәк!..

Залдагы сәгать дүртне сукты.

“Заһир да керми, ичмасам,—дип уйлады карт.—Нигә иртәрәк керергә кушмадым икән?”

Тышта пышылдап кына эт өрде. Пышылдап кына өрде ул.

Бүлмә пыран-заран килә, картны көпә-көндез талыйлар иде.

—Каравыл! Талыйлар!!

Карт адымын тизләтеп кызына таба юнәлгәндә караватт астыннан чыгарылган әрҗәләргә абынып егылды.

—Юк, бирмим!—Эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенеп алган Мотаһар калтыранган куллары белән сытырдай булып әрҗәне кочаклады.—Каравыл, талыйла-аар!..

Милиционер радионы тоташтырды. Аннан Мидхәт Миншин, әсәрләнеп, язгы чәчүгә әзерлек барышы турында сөйли иде.

—Үземнекен алам!..

Ишек катында милиционер авызын ачып торган капчыкка әнисеннән калган мендәрләр, дөя йонлы юрган, ниндидер каплар, төргәкләр керә башлады.

—Барысы да үземнеке! Барысы да минеке!

Фәрдүнә шатыр-ботыр китереп, икенче бер әрҗәдән көмеш калак-ужаулар, бәллүр сервиз, эчемлек савытларын әрҗә кочаклап яткан әтисе аша сикереп, капчыкка дөңгечли башлады.

—Урын өстендә яткан сукыр әтиеңне кызганыр идең, ичмасам!..

Картлач шыгыр-шыгыр урыныннан күтәрелеп, тавыш килгән тарафка сөйрәлде.

—Син кызгануга лаекмы соң? Нәрсә, бу малларны кабергә алып китәргә җыендыңмы? Чересеннәр дисеңме?—Фәрдүнә әтисен караватка бәреп екты һәм ике куллап буа башлады:

—Акчаң кайда? Әйт, акчаң кайда, бәдбәхет?!

Радиодан Заһидулла Яруллинның “Тукай маршы” яңгырый иде.

—Ю-у-ук м-минем а-ак-чам!—Чытырдап ябышкан куллардан муенын азат итәргә тырышкан картның тавышы хырылдап чыга иде.—Ю-у-ук!..

Каракучкыл кеше “Ярдәмгә килимме?” дигәндәй ымлады. Фәрдүнә “Кирәкми” дип баш какты.

—Соңгы мәртәбә сорыйм, акчаң кайда?! —Әтисе өстенә менеп атланган Фәрдүнәне күтәрә алмаган караватт гөрселдәп җимерелеп төште. Кыз әтисенең башын ике куллап как идәнгә деңкетә башлады.—Ай саен миллион! Кая куясың?! Эшсез утырган кызыңа расчет бир!..

—Җиб-бә-ә-әр,—диде карт хыр-хыр килеп.—Үт-те-рә-сең бит...

—Үлсәң, күмәрбез! Үлмисең дә, ичмасам!—Бугаз төере кысылган Мотаһар бер агарына, бер күгәренә башлады.

—Ур-ра-за-да мин!.. Ир-тәг-гә Гәй-йет!..

—Уразаң-ниең белән! Сөйләп торган була тагы, алкаш!—Кыз тагын да сүгенде.—Иман тактасына киләсе кешеме син?!

Кызының соңгы сүзе итеп карт шуны хәтерли.

“Иман тактасына киләсе кешеме син?!...”

Кемдер аның башына каты итеп сукты.

Калганын хәтерләми.

Кайчан киттеләр? Нәрсәләрне алдылар?

Аңына килгәндә бүлмәдә үлем тынлыгы иде. Мотаһарның җеп өзәрлек тә хәле юк, йөрәге белән лепкәсе дөп-дөп килеп киндер талкый, кан тамырлары тартыша, колаклары, жуылдап, шарт-шорт китереп мылтыктан ата. Бүлмәләр кыйралыш мәйданын хәтерләтәдер инде. Балалар кайтканчы аларны әзерәк булса да җыештырырга кирәк иде дә бит. Кая ди инде ул? “Ярый әле, үтермәде,—дип уйлап алды карт.—Ә үтерә дә алган булыр иде бу имансыз. Хәзер бит чебен үтерү белән кеше үтерү арасында аерма калмады.”

Карт күзләрен йомды. Әйе, сукыр күзләрен күңеленнән генә йома

торган гадәте бар аның. Гүяки күнел күзләре белән маңгай күзләрен каплый.

Ул ыңгырашып куйды. Әгәр ул телефонга тора алса, кемне чакырыр иде икән ярдәмгә? Кемне генә чакыра алган булыр иде? Иң якыннарыннан—кемне? Ул барысын да барлап чыкты, әмма беркемне дә таба алмады. Ниһаять, уенын җеп очы үзен күптән түгел генә кибеттән алып кайткан Заһирга барып тоташты. Аны шундук алып керәсе булган да бит. Уылдыгын да ашап бетмәгән булыр иде әле. Карт хәлсез куллары белән кызыл лайлалы йөзен капшап чыкты. Уылдык кызылы белән ярылган маңгаеннан саркылган кан кызылы кушылган иде хәзер. "Ычкындырып алып китмәгәннәрме?" Канлы бармакларын чәнчештерә-чәнчештерә ул күкрәгендәге медальбилгеләрне капшады, алар арасыннан яңа рәвештәге ике яңа медальне эзләп тапкач, күңеле тынычлана төште. "Ярый әле, үтереп китмәде, имансыз". Килене белән оныгы да кайтмый, ичмасам.

Бая ул үзен бер бүлмәдән икенче бүлмәгә аякларына гер тагылган килеш үткәндәй хис итсә, хәзер ул герләр аны җиргә тәмам кадаклаган. Мотаһар хәзер бүлмәләрнең божраларын өзеп үтә алмый, ә бары тик алар турында уйлый гына ала иде. Гүя ул үз божрасында үзе әсир иде. Кемнәр килеп коткарыр? Кайчандыр божраларны гына түгел, галәм кадәр галәмнәрне фашисттан коткарган иде бит ул. Кемнәр белән нәрсә хакына дуслашкан да, кемнәр белән нәрсә хакына дошманлашкан? Дус дигәне дошман, дошман дигәне дус булып чыктымы? Баксаң, аның бер генә дусты да, бер генә дошманы да юк икән бит? Ул чакта кемнәр өчен гомерен аямаган? Кемнәр өчен саулыгын-тазалыгын биргән? Үз иңендә өстерәп барган капитан Непейпивоның башсыз гәүдәсе төште аның хәтеренә. Көнләшеп куйды ул аңардан. Баксаң, Непейпиво Ватан хакына мордар китеп, бер тапкыр бәхетле булса, бу түбәнлекләрне күрми китеп баруы белән ике тапкыр бәхетле икән. Нәкъ илле дүрт елдан соң, "Ленинградны саклаганы өчен" медален алган көнне үзеннән туган кыз баланың йортын басып керүен, кыйнап чыгып китүен күз алдына да китерә алмагандыр ул!..

Кемнәрне үстергән соң ул аякларына шушы герләрне өстерәгән килеш? Аның балаларымы, аның оныкларымы соң алар? Аларны сукыр килеш тә күзле итеп дөньяга яратмадымы? Тормышка күнел күзләрен дә ачмадымы? Сукыр килеш җитәкләп, балалар бакчасына, мәктәпкә йөретмәдеме? Ашатмады, эчертмәде, киендермәдеме? Аларга җылы куыш, йорт-җир бирмәдеме? Ата-бабаларның изге кануннарында тәрбияләргә тырышмадымы? Соң нигә алар әтиләренә дошман? Юк, җәмәгате Зөлхәбирә дә, авыр туфраккайлары җиңел булсын, әтиләренә дошман итеп тәрбияләмәде. Сәбәп нәрсәдә соң? Димәк ки... Димәк ки... Карт күнел күзләрен тагын йомды. Димәк ки... Ул сеңдергән мәхәббәтне, ул биргән тәрбияне кемдер арттан торып кына юкка чыгара килгән?! Бу көч Казанның өченче гильдия сәүдәгәре Хафиз Чанборисовның якты, зәңгәр каны аккан балаларының, оныкларының шундый ук якты, зәңгәр канын бозып, агулап, җаныя сихәтләрен савып килгән?! Димәк, балалар бакчасы да, мәктәп тә, урам да, шушы радиотелевизор да алардагы кеше куәсен җен, фәрештәне иблис белән алыштырган? Ничек күрми килгән шуларны Мотаһар?! Димәк, заман аны алдаган? Ул үзе дә, балалары да алданган заман корбаннары булып чыга?

Җиде генә сыйныф белемле Мотаһар, бүген килеп, туздырылган оясында, асты өскә китереп җимерелгән караватында кансырап ятканда, дөньякүләм фәйләсуфка әйләнде. Вадим Мөдәррисович Чанборисов кем булыр да, аның балалары кем булыр? Моңа кадәр бары тик үзен надан санаган Мотаһарга бу мизгелдә үзеннән күпкә яшьрәкләр надан булып күренде. Аның җиде сыйныфы болар тәмамлаган гимназия, университет, академияләрдән югарырак булмаганмы? Белемме алар, әллә үлемме? Бу кадәр түбәнлекне сүздә сурәтләр, ачып күрсәтер, мөнбәрдән торып аңлатыр көчләрне тәрбиялиме алар? Бармы алар, гомумән? Аның бары тик үз күңелендәге сагышны, үз йөзендәге җимереклекне, җанындагы моңга сусауны галибанә сурәтләрлек, аңлатырлык, моңга-сыңга, көйгә-җыруга салырлык берәр әдип, берәр көйче, берәр сынчы бар микән бүгенге Казанда? Булса,

нигә күтәрелмиләр алар мөнбәргә?

Аның фикерләре асты өскә менә, бәйләнешсез бүлгәләнә, кисәкләнеп таркала башлады. Нигә бу кадәр кешелексез, моңсыз, таяк кебек туры бу яшьләрнең күңеле? Аларның таяктай туры йортларда яшәүләреннән, таяктай шыксыз урамнардан йөрүләреннән, таяктай шома, каты, серсез мәктәпләрдә укыганлыкларыннан, таяктай салкын, әдәпсез, денсез гаиләләрдә кашык күтәрүләреннән, ата-ананың хезмәт җиңүләре артыннан куып, сабый күңеленә юл сабарга да онытуларыннан килмиме, дип уйланды карт. Димәк ки, барысы да булган, мәгәр тәрбия генә булмаган. Барысы өчен дә Вакыт дигән нәрсә булган, мәгәр тәрбия өчен генә Вакыт табылмаган...

Әле берничә көн генә элек Рәсәй радиосы Волхов, Псков урманнарында йөз меңнәрчә совет сугышчылары сөякләренең һаман да җирләнмичә ятуын хәбәр итте. Тетрәнде Мотаһар. Ил хуҗаларының, житәкчеләрнең оятсызлыгыннан тетрәнде. Непейпиво бахыркайның да башы белән гәүдәсе әле һаман аерым аунап яталар микән? Җаны кайларда очып йөри икән? Мотаһардан мәрхәмәт көтеп, Казанга очып килмәде микән? Әле кичә генә булып үткән чечен-урыс сугышының меңнәрчә корбаннарының мәетлә-ре ата-аналары да танымаслык хәлгә китерелеп, әрме суыткычла-рында ятуын ничек аңлатырга? Нинди халык, нинди ил бу? Исән калган коммунистлар нәрсә карый?

Бу фикердән соң картның колакларына элеккеге саклык кайтты. Сәгать сукмый иде. Тагын туктаттылар, тагын чалшайттылармы?

Ул сәгатен үлем бәясенә булса да җибәрергә тиеш иде. Урыныннан кат-кат калкынып караса да, күтәрелә алмады. Озак кына азапланганнан соң, йөзтүбән капланып, кулларына таянды һәм аһ-ваһ килеп, ниһаять, аягына басты.

Мин барып житкәнче сәгатен-минутын да әйтер дип, ул көч-хәл белән радио басмагын капшады. Гадәттәгечә, радио жырлый иде. Тавышын бераз киметеп, дивардан сәрмәнә-сәрмәнә, аякларын зал тарафына шудырта башлады. Менә ул залда. Сәгатьнең тавыш-тыны юк иде. Мең жәфа белән урындыкны эзләп тапты, аны идән буйлап өстерәп, диварга китереп терәде, авыр пыймаларын чак-чак кузгатып, чайкала-чайкала урындыкка менеп басты. Бөркет колачы белән диварга капланып, кул аяларын югарыга таба шудыртты. Куллары белән ике яктан да бożраланган аралык кысылганнан-кысыла, тарайганнан-тарая барды һәм куллар, ниһаять, кайчандыр сәгать асылынып торган чөйдә килеп тоташты.

Чөй буш, сәгать урынында юк иде.

Ул табынган сәгать—ерак бабасыннан килгән Васыять сәгате—үз Вакыты урланган иде.

—Яв-выз!..

Бу аның Фәрдүнәсенә карата әйтелгән соңгы кәлимәсе иде.

Йөрәккә кинәттән нәрсәдер китереп сукты. Әлегә кадәр бары тик канатсыз булган, инде хәзер йөрәксез дә калган Мотаһарның башы әйләнеп китте һәм ул, бер мизгел урынында чайкалып торганнан соң, башы белән гөрселдәп как идәнгә әйләнеп төште.

Тәмам исәнгерәгән, үләр минутын сизенгән карт әлегә камил зиһене белән аңлады—тормышта тал тамыры кебек сакланып, монда, үз өенең как идәнендә дуңгыз кебек аунап жан бирергә хакы юк. Җимерелгән булса да, аның үз биеклеге бар. Күкрәгендәге “Мин менә кем ул!” дип, әллә кайдан кычкырып торган орден-медаль калайлары белән идән буявын тырнап һәм авызыннан да киткән канлы селәгәй эзләре калдырып, карт пластунча колачын алга ташлап үз оясына шуышты. Ул газизләрдән газиз жир йөзеннән беркемгә дә авырлык, мәшәкать китермичә китәргә тиеш. Карт солдат тешләрен шыгырдатып, божрадан божрага—кыйтгадан кыйтгага—үлеменә таба шуышты. Ничә минут үткәндер, бармак очлары жимерек карават кашагасын сәрмәде. Нининдер әржәдән аягы белән этәрелеп, ул урын өстенә үрмәләде. Жан бирү авырга туры килмәсен өчен ул чалкан әйләнергә

тиеш. Тиеш. Тиеш. Тиеш. Син тиеш. "Тиеш" буынның соңгыларыннан берсе, ыңгырашып, дәһшәтле калтыранып, идәндәге чүп-чар, кан һәм тузан катнашмасында аунаган гәүдә көч-хәл белән чалкан ята алды.

Ул үлә. Бу—хәл ителгән бик гади мәсьәлә. Күнел күзләре белән карт тагын маңгай күзләрен ачты. Карашын күккә юнәлтте. Мотаһар хәзер тирә-як мохитны түгел, бөтен дөньяны бер юлы күрә иде. Әнә Ходай Тәгаләнең зәңгәр күзләре аңа төбәлгән. Дәһшәтле мөлаем, сөйкемле кырыс иде бу караш. Гүя ул Мотаһардан сорый: "Сиңа миннән ни кирәк?". Инде мәрткә китә башлаган карт үзенә Ходай Тәгаләдән, үзеннән Ходай Тәгаләгә нәрсә кирәклеген, нәрсә тиешлеген дә белми иде...

Ишекне шарт ачып, тыштан Вадим керде. Букчасын идәнгә ыргытты да, саңгырау сыман, барлык тавышына гөрләтеп, телевизорны тоташтырды. Кемдер телефоннан шылтыратты. Мотаһар боларның берсен дә күрми дә, ишетми дә, хәтта сизенми дә иде. Әнә, аны ниндидер ак фәрештәләр сырып алган. Мәрхүм дәү әтисе белән дәү әнисе, әтисе һәм әнисе, җәмәгате Зөлхәбирә, абыйлары һәм сеңелләре бит болар! Каян алганнар алар бу кадәр ак кием? Ә Мотаһарның үзенең араларына керергә ак киеме бармы? Маңгаенда бердәнбер мөгезе булган, чабата кашлы, киеренке борын тишекләреннән менә хәзер йомран килеп чыгар кебек күренгән бер иблис аларны тальянда биетә, имеш...

Аның көндәлек, хәтта гомерлек яшәү даирәсен тәшкил иткән алты аралыгы—һәркайсының үз исе, үз төсе, үз хисе һәм үз көче булган кухнә, ванна бүлмәсе, тышкы ишек каты, зал, яшьләр бүлмәсе, шәхси хөҗрәсе җир шарының алты кыйтгасы—Азиясы, Европасы, Африкасы, Төньяк һәм Көньяк Америкасы, Австралиясе менә шулай йолдызга-йолдыз, бөҗрәгә-бөҗрә тәңгәл килеп, менә шушы төштә, Мотаһар җан биреп яткан салкын тактада бер бөтен булып төенләнде. Гүя ул аларны ниндидер азатлык хакына шуышып үткән дә, аларга үзе үк коллыкка төшкән...

Аның йодрыклары җан көче белән чәчрәп төйнәлде.

Читтән караган кешегә бу кипшенгән, озын, пәһлеван буйлы, зәңгәр төркиләр сыман үркәч танаулы, үз күкрәгеп, кәмитче кебек, калай кисәкләре белән чуарлаган, балык уылдыгы һәм соңгы каны кызарткан Адәмзат хәятнең барлык җен-пәриләрен, иблисләрен, мәҗүси интернацио-налын идәннән булса да йодрыклы кочагына кочарга һәм аларны соңгы талпыну, соңгы көчәнү белән кысып, эчләрендәге гасырлар буе тупланып килгән бәвелләрен һәм нәҗесләрен сытып чыгарырга җыенып яткан кебек күренә иде.

—Х...ш...р...т...л...р...

Авыз эчендә телен чак-чак әйләндереп, ыңрәп һәм гырылдап, ул үзеннән бары тик шушы алты тартык авазны гына сыгып чыгара алды. Кемнәр иде ул "хәшәрәтләр"? Нәрсә иде бу? Бөтен дөньяга ләгънәт идеме? Иртән башланган мактауның кире әйләнеп төшкән шәүләсе, тотлыккан айның кара сурәте идеме?

Аның миендә нәрсәдер яктырды.

Күктән теге зәңгәр, мөлаем кырыс күзләр һаман аңа карап тора, имеш. Ә ул шушы киемнәрендә, юынмаган-кырынмаган килеш ләхеттә ята. Мөнкир белән Нәнкир аңардан беренче сорауны ала:

—Өммәтең кем?

—Татар мин,—ди Мотаһар. Аннан өстәп куя.—Мөселманмын.

—Һәр татар мөселман дигән сүз түгел,—ди Мөнкир.

—Һы,—ди Мотаһар.—Кем соң мин?

—Син мөселман түгел,—ди Нәнкир.

—Һы,—ди Мотаһар.—Кем соң мин?

—Монда ымлыклар белән сөйләшмиләр,—ди Мөнкир.—Җаваплар ачык булырга тиеш. Ходай Тәгалә күреп-ишетеп тора.

—Бар, кем икәнлегеңне белеп кил,—ди Нәнкир.—Ымлыкларыңны өеңдә калдыр.

Мотаһар мавыктыргыч, зиначыл неон утлары уйнаклап торган кечкә Казан урамнарыннан чаба һәм очраган бер кешедән сорый, имеш: "Кем

мин?" Ә тегеләр аның күкрәгендәге калайларга төртеп күрсәтеп, көләләр: "Тиле син! Динсез син! Тиле син! Динсез син!" Тишек танаулы Иблис исә уйнап торган тальянын һавага чөйгән һәм янадан тотып алган арада аны зина йортына чакыра: "Монда кер! Ожмах бирерә!"

Кинәт күк капусы ярыла һәм аннан хөкем карары яңгырый:

—Җаны белән тәне аерылган, алар мәңге кавышмаячак хәкыйрь син! Тәмугъ бер кисәвен, ожмах сиңа бер йотым суын да кызганачак адәм син! Мәңге шулай тәмугъ белән ожмах арасында кибәчәк ач хәлвәфруш, ике арадагы мәҗүси мөсафир син!..

Аның мие икенче тапкыр яктырды.

—Мотаһарның башы котырып эшли иде әле.

Бу ми, карт үзе теләмәсә дә, тормыш алдында хисап тота, кансыз карарын чыгара иде...

Баксаң, ул барлык юнәлешләрдә дә җиңүче түгел, җиңелүче булган бит. Чын җиңүченең җиңү яктысы балалар йөзендә чагыла икән. Телендә, иманында, хезмәтендә чагыла икән. Ул, Мотаһар, җиңүче, үзен җиңү, түбәнсетү, ата хакын таптау хакына вак кесә карагын һәм көпә-көндез талаучыны үстергән икән. Нинди кәмирсәнт булсын ул Мөдәррис? Нинди сәүдәгәр оныгы булсын? Хәерченең ялчысы ул, менә кем! Аек акылы белән Мотаһар улыннан һәм кызыннан ваз кичте. Нәгълэт аларга, нәгълэт! Үзенең Вакыты намазсыз булганга бәхетсез булмаганмы соң ул? Үзе бәхетсез булганга балалары да бәхетсез булмаганмы? Бәхетле була ала идеме алар? Бәхетле булу өчен беренче чиратта нәрсә кирәк? *Үзенә генә хезмәт итә торган иманлы, намазлы вакытың кирәк.* Бармы соң *Казанда иманлы Вакыт? Юк. Казанда читят вакыт.* Китертелгән *вакыт.* Шушы *вакытсыз вакыт* куып кертмәдеме аларны вак хәйләкәрлек, ясалма тыйнаклык һәм коллык түземенә?

Ярый әле акчаларын кассага салып өлгергән!..

Ул бу минутта акчаларының дошман кулына барып керүенә дә үкенми иде. Чөнки *аның вакытын үз балалары урлады.*

Кинәт ул тартышып куйды. Талпынып урыныннан күтәреләсе, кулына актан-ак чиләк, якты чүпрәк һәм пумала алып, Казан урамнарына чыгасы, аның пычранган күген, агуланган җирен, бозылган суларын, һәр урамны, һәр йортны, һәр диварны, һәр ташны, һәр кошны, һәр төшне, керәмәлне, һәр гыйбадәтханә, һәр мәсҗедне, һәр кешене, һәр кешенең миен һәм йөрәген чишмә суларында чайкап юасы, чайкатасы, коендырасы, мунча кертәсе, кыргычлап юындырып, чәчләрен алып, сакал-мыекларын кырып, матур, чиста киемнәргә киендереп, кулларына Изге Китап тотты-рып, үз тарафларына таратасы килде. Нәгълэт! Нәгълэт! Нәгълэт! Ашыгыгыз! Ожмах кына түгел, тәмугъ та кабул итми, мәңге ике арада чабып кибәчәк мөсафирга әйләнсәгез, нишләрсез?!

Ниндидер көч яңадан йөрәккә һәм баш миенә бер юлы китереп сукты һәм житмеш дүрт яшенә җитеп, тыныч тормышта бер генә тапкыр да табибка бармаган, йөрәк дигән нәрсәнең кайсы тирәдә урнашканлыгын да белмәгән карт бер генә тапкыр "аһ!" дигән аваз чыгарып, гүяки җир тетрәвен алдан сизгән кит балыгы шикелле, үз-үзен ярга ыргытты һәм таш кебек катып калды...

Казан радиосы пышылдап кына "Соңгы хәбәрләр"ен тапшыра башлады. Моннан кырык дүрт ел элек нефть һәм иярчен газ чыккан нефть башкаласы—Баулы авылларына газ кертелү барышы турындагы гадәттән тыш" вакыйганы исәпкә алмаганда, "Соңгы хәбәрләр"дә башка бернинди дә хәбәр юк иде.

Ишектә кыңгырау чәрелдәде. Әнисе кайткан дип уйлаган Вадим ишекне сорамыйча да ачты. Анда Заһир басып тора иде.

—Кем кирәк сиңа?—диде ул урысчалатып.

—Мотаһар бабай мине бүген бергәләп тәравих намазы укырга чакырган иде,—диде малай, беркатлы елмаеп.—Ул безнең икебезне дуслаштырам да дигән иде...

—Һы, кызык икән.—Вадим ым белән баш какты.—Эчке бүлмәгә үт.

Ут яктысында Заһирның яшел сырмасы ташны тишеп чыккан үлән кебек тагын да яшәрде. Малай аякларын салып, оекчан килеш күрсәтелгән бүлмә караңгылыгына чумды. Күп тә үтми күзләреннән яшьләре коелган Заһир залга чыкты:

—Синең... дәү әтиең... үлгән.

Заһир үксеп елап та җибәрде.

—Ничек үлгән?—диде Вадим, телевизордан күзен дә алмыйча.—Үтерерсең аны. Гел шулай ята ул кош тотып.

—Үлгән дим мин сиңа!..

—Һы.

Вадим чыраен сытып, теләр-теләмәс кенә адымнар белән Заһир артыннан бүлмәгә үтте. Караңгылык шактый куерып җиткән, барлык әйберләр пыран-заран китерелгән бүлмә идәненә җимерелеп төшкән караваты өстендә сирәк кием, сәер кыяфәттә яткан дәү әтисен күреп катып калды.

—Дедушка... дедушка...

Мәгәр карт тавыш-тынсыз иде.

Бер-берсен белергә тиешле булып та бөтенләй белмәгән ике малай, ике ут-күрше, тәмам аптырашта иделәр. Тынлыкны беренче булып Заһир бозды:

—Мәетне болай яткырырга ярамый.

Ул радионы сүндерде. Черт итеп утны кабызды. Нурлар Мотаһар күкрәгендәге медальләргә кунаклады. Әти-әнисен җирләүдә катнашып, азмы-күпме тәҗрибә туплап өлгергән ятимнең ушы бар иде. Әле суына да башламаган мәетнең кулларын терсәктән бөкләп, медальле күкрәгенә кушырып куйды. Тик йодрыкны гына яздыра алмадылар. Ул йолдызташ булып каткан иде.

Заһирга Мотаһар бабасының йөзе бик тә нурлы күренде. Гүя ул үлмәгән, әйдә, кыланасын кыланып калыгыз, дип, елмаеп кына ята иде. Малай бабайның зәңгәр чыпчык чәчәге кебек зәңгәр нокта булып сәякләнгән күзен йомдырды, авызын хәленнән килгәнчә яптырды. Мәетне караватчына яткан ак җәймә белән капладылар.

—Бисмилла иррахман иррахим...

Заһир исенә төшкән сүрәсен укып, дога кылды.

Алар залга чыктылар.

—Сүндер телевизорыңны. Мәет чыккан йортта уен-көлке хәрам.

Әллә дәүәтисенең үлеменнән, әллә телевизорны сүндерү кайгысыннан шыңшый башлаган Вадим төймәгә басты. Өй эче тынып калды.

Заһир елый иде.

—Синең дәү әтиең шундый бәхетле кеше...

—Нигә?

—Иртәгә Ураза бәйрәме бит. Гает көне. Ә ул бүген Гает бәйрәменә каршы савaплы кичтә үлде. Димәк, аның урыны җәннәттә булачак. Әллә белмисеңдәме?

—Белмим. Нәрсә ул ураза?

—Аны озын-озак сөйләп торыр чак түгел,—дип туктатты аны Заһир.—Хәзер картларны җыярга, мәрхүмгә ясин чыгарга кирәк. Соңыннан сөйләрмен, ямe?

—Һы. Кызык икән.

—Син дәү әтиеңне ярата идеңме, Вадим?

—Нигә алай дип сорыйсың?

—Болай гына. Бик һәйбәт кеше иде ул. Кызганыч кеше иде...

—Белмим бит мин аны,—диде малай, борынын мышкылдатып.—Аны әти дә, әни дә яратмыйлар...

—Ә мин аны бик тә ярата идем. Безнең кебек чакта аның күзенә ат типкән. Ул шуннан сукыр калган.

—Ха! Әйттең тагын!—дип көлеп җибәрде Вадим.—Фронтта, сугышта күзсез калган бит ул!..

Бу Заһир өчен көтелмәгән ачыш иде.

—Сугышта?!

—Әйе, сугышта.

—Бу орден-медальләр дә аныкымы?

—Кем белсен инде аны...

Заһир яңадан елый башлады. Вадим да шыңшырга кереште.

—Болай ярамый. Мәет өстендә еларга ярамый...—Ул яшьләрен җиң очлары белән ышырып алып, елавыннан туктады. Аңардан күреп, Вадим да шыңшуын басты. Нәрсәнедер исенә төшергәндәй, кинәт кенә сискәнде һәм сорап куйды.—Сәгать ничә икән, Вадим?

Малай гадәтенчә диварга күз ташлады һәм анда үз гомерендә беренче мәртәбә сәгатьне, дәүәтисе белән икесе арасында низаг чыганагына әйләнгән, аларны дошманлаштырып торган кара самшит сәгатьне урынында күрмәгәч ап-ак булды. Аннан чак ишетелерлек итеп, аннан торган саен көчәя төшеп елый башлады.

Бу Заһирга бик сәер тоелды.

—Нигә елыйсың, Вадим?—диде ул аптырап. Күршесенең иңенә кулын салды.—Елама, дружок.

—Еламассың монда!—Вадим аңа үпкә белдереп, терсәге белән дусларча төртеп алды.—Безнең өйгә угърылар төшкән бит! Алар бит дәүәтиемнең кадерле сәгатен урлаганнар! Дәүәтиемне дә шуның өчен үтергәннәрдер әле!—Малай үксеп еларга тотынды.—Әлбәттә шуның өчен үстергәннәр!

—Булмас ла!—диде Заһир.—Ниндидер иске сәгать өчен Казан кадәр Казанда кеше кадәр кеше үтермәсләр!..

—Үтермәсләр сиңа!—Ул бит Наполеон заманыннан калган сәгать иде. Бәлки Наполеонның үзенеке дә булгандыр әле... Бүген базарда ул кимендә ун миллион! Иске акчага түгел, яна, деноминацияле акчага!..

Заһир тынып калды. Ул бу кадәреләрен аңламый иде.

—Мафиозлар, димәк. Француз мафиясе дә булуы мөмкин,—диде барысын да чын итеп кабул иткән Заһир һәм уйланып калды. Матур булган саен кыйммәтрәк сатыла микәнни ул сәгать дигәннәре? Күрсәткән вакытлары шул ук бер вакыт бит инде югыйсә. Вакыт та сатыла мәллә?

Ул сискәнеп тартылды һәм тыпырчынып Вадимны талкый башлады:

—Юк, юк! Сәгать сатылса да, вакыт сатылмый! Вакыт сатылмый!..

—Тукта, тукта!—диде Вадим, исенә килгәндәй. Ул көлемсерәп, тирә-ягына каранды, барлык туздырылган, ботарланган әйберләрне күздән кичереп чыкты.—Нинди француз мафиясе?! Үзебезнекеләр!.. Әмәт тавыннан!.. Бездә бит дәүәтиемнең кызы Фәрдүнә апа булган! Аның ел саен шундый погром оештырып китә торган гадәте бар... Сәгатьне дә ул гына урлаган!.. Башка әйберләрне дә урлагандыр әле ул!..

Малайлар бер мизгелгә тынып калды.

Тынлыкны тагын да Вадим бозды.

—Без ул сәгатьне табарга һәм, дәүәтинең йортына кире кайтарып, шушы урынга эләргә тиешбез, Заһир!—диде ул яшьтәшенең күзләренә туры караган килеш диварга күрсәтеп.—Без ул сәгатьне табарга тиешбез!..

—Табарбыз Ходай кушса,—диде Заһир тыныч кына.—Табарбыз. Ул иманлы сәгать булгандыр. Мотаһар бабай бик тә изге күңелле, иманлы кеше иде, Вадим...—Заһир тагын дога кылды.—Сәгатенең фәрештәләре, иңнәренә кунып, аны оҗмахка алып керсен, амин... Хәзер исә тиз генә өлкәннәргә хәбәр итәргә кирәк. Мин хәзер үк дәүәниемне алып керәм. Әйдә, әтиенә шалтыратыйк.

—Ул командировкада.

—Әниенә алайса.

Ике малай, иңгә-иң торып, шалтырата башладылар.

Тышта 1998 елның 22 гыйнварына каршы кичнең сүрән генә шәфәгы төсмерләнә иде.

*Гыйнвар—май 1998 ел.*

*Чаллы—Алабуга—Чаллы.*

## ШИГЪРИЯТ



# Илдус Гыйләҗев

## МОҢЫМ КАЙТЫР БАСУ ЯГЫННАН

### Эчтәлексез паспорт

Испания.
Таможняда чират торам.
Кыяр-кыймас сузам паспортым.
Гаҗәпләнеп, кат-кат тикшерәләр,
Карашлары усал, астыртын.
Әйтерсең мин үткән гасырлардан,
Мәгарәдән чыккан кырагай.
Бәлки, чынлап шулай тоеладыр?
Язмышымны... Ходай каргаган.
Паспорты бар, әмма дәүләте бит
Кисәкләргә бетте туралып.
Җир шарының күпме кыйтгасында
Бәхетсезләр йөри уралып.
Безнең тамга—сугыш чукмарлары...
Дөнья күрми яттык бикләнеп.
Көнбатышның азат халыклары
Карый безгә һаман шикләнеп.
Күрше илдән килгән сәйяхчеләр
Янәшәмнән үтеп китәләр.
Алар монда—көтеп алган кунак,
Виза кирәк түгел—кертәләр.
Бер-беренә шундый ягымлылар,
Сәламлиләр йомшак эндәшеп.
... Өйдә горур да мин, читкә чыксам,
Гел шуларга карыйм көнләшеп...

### Чәчүлек

Җир кешесе җирне уйлый икән,
Океаннар аша үтсә дә.

Өйдә калган эше тынгы бирми
Бай илләргә барып җитсә дә.
Рәхәтләнеп кенә йөрисе дә...
Бу муллыкны без бит күрмәдек.
... Башлап куйган түтәл калган иде,
Шуны уйлап, йокы кермәде...

## Шулай булсын

Әйләнәм дә кайтам Ык буена,
Малайларга карыйм кызыгып.
Әй, йөрергә иде шулар белән
Балык тотып, комда кызынып.
Әйләнәм дә кайтам авылыма,
Яңалыклар булса, сөйләрләр.
Тик чыкмас шул инде, сызгырсам да,
Үкенечкә калган сөйгән яр.
Әйләнәм дә кайтам туган якка,
Истәлекләр җанда сулмасын.
Тормышымның шунда татлы ягы...
Соңгы кайту гына булмасын.

## Егетлек

Өлкәннәрне тәгәл алыштырдык,
Шәҗәрәдә юк бер өзеклек.
Үз вакытың җиткәч, соңга калмый
Килә белү—үзе егетлек.
Тормыш кадерен белгән кешеләрне
Торасы юк һич тә үгетләп.
Сәгать теле кебек, дөрес йөрү,
Дөрес яшәү—бик зур егетлек.
Гомер—вакыт, һәрчак хәрәкәттә,
Уза диеп күңел җебетмик.
... Үз вакытың җиткәч, тыныч кына
Китә белү дә бит—егетлек...

## Хак сүз

Минем ике тарихым юк...
Еллар шаһит, яулап алгансың.
Күпме халыкларны киләчәксез
Калдыргансың, богау салгансың.
Минем ике Ватаным юк...
Татар иле—тормыш бишегем.
Шунда тудым, шунда гомер итәм,
Шунда ачтым бәхет ишеген.
Минем ике гомерем юк...
Әйтеп китәм, үзең белмәсәң:
Тәртип урнашалмас синдә, Рәсәй,
Халыкларга Ирек бирмәсәң...

## Игенче догасы

Яңгыр кирәк, Яңгыр!
Чык та төшми.
Ярыла җир, килә ачулар.
Түземлек бир, Ходам, игенчегә
Сусыз интеккәндә басулар...

Кая киттең, Кояш?
Көн-төн яңгыр.
Кайтыр микән аяз ул көннәр?
Сабырлык бир, Ходам, игенчегә,
Черек яткан чакта игеннәр.

... Яңгыр белән Кояш—
Безнең язмыш...
Җитсә ярар иде чыдамлык.
Тапкырлык бир, Ходам, игенчегә,
Шул язмыштан өстен чыгарлык...

* * *

"Дөнья бетә",—диләр.
Ялган фикер!
Җитә алмыйм шуңа төшенеп—
Кем соң алып китәр икән аны?
... Дөнья калыр! Бетәр—кешелек...

## Барсы да буразнада

Хисләремне чәчтем буразнага,
Дәвасыннан җаным савыкты.
Тургайларым сайрый җырга салып,
Тезем-тезем шигырь калыкты.
Өметләрем тамды буразнага,
Тормыш ямен шунда төшендем.
Горур яшим! Йөргән эзләремдә
Тезем-тезем иген тишелде.
Елларымны күмдем буразнага,
Моңы кайтыр басу ягыннан.
... Бер калкулык калыр җирдә миннән,
Буразнадан өзеп алынган...

## Игезәкләр янында

Гомер бакый таладылар,
Кушып, бүлеп карадылар.
Даныгызны чүпрәк итеп
Ил бишмәтен ямадылар.
Аның саен яшәрәсез,

Кияү, килен ярәшәсез.
Авырда да, җиңелдә дә
Икегез гел янәшә сез.
Үчлек, хөсет белмәдегез,
Дошманга сер бирмәдегез.
Иң татлы сүз, тәмле икмәк
Булды безгә бүләгегез.
Хәйран калам даныгызга,
Һәрчак булыйм яныгызда,
Татар халкы һәм авылы!
Башым иям алдыгызда...

## Шул гына калды

—Балталары суга төшкән сыман,
Ник караңгы йөри кемсәләр?
—Салым түләтерләр дип куркалар,
Көлгән өчен, әгәр күрсәләр...

* * *

“Мин вакланмыйм, синнән бәхетлерәк,
Бөтен килеш яшим гел”,—дисең.
... Шундый хәлдә сине саклар өчен
Бүлгәләнгәнемне белмисең...

* * *

Карашыңны алма миннән берүк,
Синең якка тарта кашларым.
Тиктомалдан синме шырпы сыздың?
Ул кабынды, яңа башладым.
Түзәм, түзәм! Китә генә күрмә,
Кем икәнең әйтмәм, кычкырмам.
Беләм бит мин—хисләр илендә дә
Зур ут чыга нәни очкыннан...

## Ышаныч

Малыңны сорасам,
Малыңны бирерсең.
Җаныңны сорасам,
Җаныңны бирерсең.
Син минем артымнан
Утларга керерсең.
Тәмугка эләксәм,
Анда да килерсең,
Янарбыз бергәләп...—

Ул шулай булачак:
Без-ике кисәүдән,
Мәхәббәт туачак.
Хак шулай булачак!

## Кирәксә...

Сине эзләп чыктым юлларга,
Яшәү авыр, сагыш сакласаң;
Үкенечләр басымыннан дөньям
Җимерелер, сине тапмасам.
Барып җитәремә ышанам,
Җиңел юллар сайлап йөрмәдем.
Яшәгәнче көн-төн утлар йотып,
Тузан йотыйм, янмас йөрәгем.
Гаеп миндә. Барсына риза,
"Соңга калдың",—диеп әйтмәсәң.
Алларыңа килеп тезләнермен,
Аягүрә кабул итмәсәң..

*Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникигә 90 яшь*

# ОЛУГ ӘДИБЕБЕЗ БАР!



*Миңа калса, язучы*
*һәрвакыт матурлыкка сусап,*
*матурлыкны сагынып яшәргә тиеш...*
*Гыйбрәт алыр, күңелне баетыр,*
*теләкләрне үстерер өчен генә түгел,*
*һәртөрле түбәнлек-ваклыклар,*
*ямьсезлек-әшәкелекләр белән*
*килешмәс өчен, шуларга*
*нәфрәт саклар өчен дә кирәк бу...*

Әмирхан Еники

## Аның турында замандашлары, каләмдәшләре

### Фатих Хөсни:

Әмирхан Еники турында сүз әйтү бер үк вакытта читен дә, рәхәт тә. Читен, чөнки ул бик катлаулы, үтә дә нечкә күңелле художник. Әйтә белмичә әйтсәң, тота белмичә кулдан төшереп ваткан хрусталь ваза кебек, аның иҗатын чәлпәрәмә китерүең дә мөмкин. Рәхәт, чөнки аның иҗаты уйланырлык азык, күңелгә шатлык, колакка музыкаль аһәң бирә.

... Яшь, зифа буйлы, кара чәчле, мөлаем егет, ул әдәбиятка ничектер кыяр-кыймасрак килеп керде һәм хәзергә хәтле, башы пеләшләнә башлагач та, уннарча повесть һәм бик күп талантлы хикәяләр авторы булгач та, безнең барыбызның да, иң әһәмиятлесе, киң катлау укучыларның ихлас мәхәббәтен казанганнан соң да, шулай кыяр-кыймас кына барган кебек. Аның бу тыйнаклыгы үзенең көчен белмәгәнлектән түгел, юк, ул үзенең әфсенле көчен бик яхшы белә, аның бу тыйнаклыгы халык алдындагы бурычын тирәнтен аңлавыннан. Юк, әдәбият уйнар өчен түгел, әдәбият дан казану, акча эшләү мәйданы да түгел, әдәбият—энә белән кое казу, әдәбият—кеше күңелен тәрбияләү, әдәбият кешеләрне яхшы булырга, көннән көн яхшырак була баруга этәрү коралы. Без менә шул бөек бурычны үтибезме? Барыбыз да бертигез үтибезме? Әмирханның тыйнаклыгы, минемчә, әнә шул сораулардан килеп туадыр кебек.

... Гомумән, Әмирхан Еники иҗаты өчен иң күренекле сыйфат: ул да булса аның әсәрләрендә, бөтенесендә, әлбәттә төрлесендә төрле дәрәҗәдә, кеше җанының хәрәкәткә килүе. Ясалма конструкцияләргә чуар бизәкле какшау бина корудан ерак тора Әмирхан. Аның әсәрләрендә—бөтенесендә дә—җанлы кешеләр, уйлана, газаплана һәм шатлык кичерә белә торган кешеләр яши! Әмирханның укучыны сихерле ала торган көче нәкъ әнә шунда да инде.

Әмирханны үзенчәлекле художник итеп танытkан хосусиятләрнең тагын берсе—аның теле. Аның хикәяләрен, повестьларын укыганда телебезнең нинди көч-кодрәткә ия булганлыгын янә һәм янә бер кат төшенәсең. Логик эзлеклелек, сүз асты дөньясының тигез һәм тыныч агышы, нәкъ үз урыннарына утырган сүзләрнең, берсе икенчесеннән көч алып, музыкаль аһәнлелек белән җырлап торулары—боларны һәм әйтәм дигәндә телгә килмәгән башка күркәм якларны, беренче нәүбәттә, нәкъ менә Әмирхан иҗатыннан табабыз.



*Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Минский. 1958 ел*

"Табабыз"—урынлы әйтелмәде. Аларны эзләргә кирәк түгел, алар әсәрнең тукымасында, алар—тасвирлана торган хәл-әхвәлләрнең мускулы, эчке пружинасы буларак, укучыны шундук эләктереп алалар һәм алып китәләр. Бу тасвирның әфсененә бер эләктенме, ычкынырмын димә. Ул сине тирбәтеп һәм моңландырып, уйланырга һәм тормыш, көнкүреш картиналарына үз күзең белән карарга мәҗбүр итеп, алып бара, алып бара...

... Кыскасы, безнең Әмирханыбыз, безнең нечкә һәм сизгер күңелле, коеп куйган художнигыбыз, Әмирхан Еникиебыз бар. Ул безнең арада, безнең белән иҗат итеп, бергә шатланып, бергә борчылып, дөньяга һәм кешеләргә бәхет-сәгадәт теләп яши. Аның бәйрәме безнең дә бәйрәм!

*1979 ел*

## Наҗар Нәҗми

### "Тискәреләр"

*Әмирхан ага Еникигә*

Бар ул үзсүзле булганнар—
"Тискәре" күренгәннәр.
Иманына инанганга
Илдән дә сөрелгәннәр.
Бар ул ят тәртәгә кермәс,
Авызлыкланмас затлар.
Тик үз бураэнасын ярып,
Җир-гомер сөргән "атлар".
Бар ул—сөргәнне дә сөрү...
Тик авыр—чирәм ачу.
Үз орлыгын—табышынны
Үз басуына чәчү.
Без берләшкәндә бер рухи
Күмәк хуҗалык корып,
Тик "тискәре" торып калды
"Единоличник" булып.
Әлеге шул үзенеке
Арбасы, тәртәләре—
Ә юлга тотылган күмәк

Шөгыльнең киртәләре.
Өстән, астан, уннан, сулдан
Яман сүз сибелгәндә,
Шикләнүләр, чикләнүләр
Йөрәкне кимергәндә,
Хәтта җимергән чакларда
Юлдагы күперләрне,
Үз-үзенә күпер салды
Уйлары, фикерләре...
Үзгәрә "әшьялар төсе",
Югала кичәгеләр.
Дөнья үзсүзлечә бара—
Яшәсен "тискәреләр!"

*1998, декабрь*

## Равил Фәйзуллин:

Тулы бер гасырның буеннан буена диярлек гомер кичеп, җисмән исән-сау, рухан сәламәт булып кала алганнарга хәйраннар калырлык. Гасыры да нинди бит!— гел катаклизмнардан гына торган диярсең. Сынган-сындырылганнар, югалган-югалтылганнар никадәр! Шулай да, шөкер итә дә белик: вөҗданнарына хыянәт итмичә, иманнарын саклап, идеалларына тугры калган бөек шәхесләребез дә юк түгел. Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт... Алар рәтеннән бүген дә безнең арада үзгә бер дәрт белән иҗат итүче мәшһүр әдибебез Әмирхан Еники бар. Ихтимал, Рәсәйдәге яшәү рәвешенә, яшәү мохитенә нисбәтән, Табигать биргән талант-сәләтләренең бар куәте ачылып ук бетә дә алмагандыр аларның... Хәер, булганы, иҗатларының халыкка ирешкәннәре дә сокланырлык, таң калырлык. Милләтебез өчен Ходай саклагандыр аларны. Дөрес, "саклангнны саклармын!" дигән гыйбарә дә бар. Әмирхан ага үзе дә гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта, чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк.

Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул, барыбер, Вакыт галиҗәнабләре белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның "ялына ябышып булса да", хезмәтләре белән Аңа үз исеме белән мөһер суга... Киләчәктә Идел-Урал тирәлегендә XX гасырның төрки прозасы турында сүз чыкса, иң беренчеләрдән булып, Ә. Еники исеме телгә алыначак. Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый сабаклар да бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да)— язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, Тормыш Дөреслеген язарга тиеш. Бу—Аның язучылык кредосы, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты. Тагын икенче бер гыйбрәтле сабак-нәтиҗә: хикәяләү, тасвирлау шигырь рухы белән сугарылмаса, чәчмә әсәр шигъри телле булмаса, чын проза әсәре юк ул.

Ә. Еники—олуг әдип, олуг фикер иясе. Ул инде бу фани дөнья хикмәтләрен күп күргән, кичергән, аңлаган кеше... Ни хикмәт, ул—кайбер "бар нәрсәне белгән" яшьрәкләрдән аермалы буларак, яшәү хәлләренә һаман гаҗәпләнә, теге яки бу хәлне аңларга тырышып гасабилана, икеләнә, кинәшләшә, үзенә һәм бүтәннәргә сораулар куя, борчыла, илдәге вакыйгаларны йөрәге аша үткәреп, үзенчә киләчәкне фаразлый... Әмирхан Еники исән чагында данда коенып, иҗатына тиереннән артыгын алган (андыйлар да булды!) язучы түгел. Чын бәһасе киләчәктә алыначак әдип ул. Әмирхан учагы әле дөрли генә башлады.

*21 февраль, 1999*

## Фәрваз Миңнуллин:

Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... Гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә—моңга-сагышка манып язылганнар. Аның әсәрләрендә, моң-сагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар...

Шуна да жаныңны кая куярга белми бәргәләнгәндә кулыңа Ә. Еники әсәрләрен аласың.

Укыган саен укыйсы килеп тора аның әсәрләрен. Күбрәк укыган саен, иҗатының сихри көченә соклану хисе арта, шуның сәбәпләрен беләсе, ачасы



*Хатип Госман, Әдип Маликов, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Әхмәт Исхак, Гомәр Бәширов*

килү теләге көчәя. Шуның белән бергә, тормышның үзе кебек үк гади һәм табигый, тормышның үзе кебек үк катлаулы да аның иҗаты. "Туган туфрак", "Яшьлек хатасы" кебек бер-ике әсәрен санамаганда, Еники әсәрләренең идеясе бервакытта да "мин монда!" дип, алга чыгып кычкырып тормый. Идея образга тәмам сеңеп, аңа кушылып, эреп беткән була. Язучы укучы аңына юлны аның йөрәге аша сала белә. Бу—бары олы художникларга гына хас бер сыйфат булса кирәк.

*1983 ел*

## Рафаэль Мостафин:

Әмирхан Еники хикәягә ифрат зур җаваплылык хисе белән килә торган искиткеч таләпчән язучыларның берсе. Художник буларак аның төп үзенчәлегеен бер сүз белән әйтеп бирү соралса, мин бер дә арттырмыйча, татар әдипләре арасында ул иң музыкаль язучы, дип җавап бирер идем. Аның фразалары һәрвакыт җиңел, үтә күренмәле, музыкаль яңгырашлы. Хикәяләре, әйтерсең лә, ниндидер бер сихри көчкә, тылсымга ия, аларның һәркайсы укучыда билгеле бер настроение уята. Еш кына очракларда хикәяләүдәге якты, җиңелчә моңсулык әбиләр чуагының көмеш пәрәвезләре сыман зәңгәр һавада тирбәлеп тора сыман.

Ә. Еники—менә дигән тел остасы һәм бик сизгер стилист. Аның әсәрләренең русча тәрҗемәләрен укыганда, мин, мәсәлән, үземне бик кыен хәлдә калгандай хис итәм. Юк, тәрҗемәләрнең ул чаклы ук начар сыйфатлы булулары өчен түгел. Бу язучы татар теленең үзенә генә хас стихиясе, милли фикерләүнең,

дөньяны танып-белүнең татар кешесенә хас булган үзенчәлекләре белән шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, иң әйбәт эшләнгән тәрҗемәдә дә ниндидер югалтулар котылгысыз. Еникинең Бөтенсоюз укучысына чагыштырмача аз билгеле булуын да бәлки әнә шуның белән аңлатырга кирәктер. Югыйсә бит аның иҗат багажында иң өлгереп җиткән теләсә кайсы әдәбият укучысын да сокландыра алырлык "Бер генә сәгатькә", "Ялгызлык", "Әйтелмәгән васыять", "Тынычлану" һәм башка хикәяләр бар.



*Әмирхан Еники, Шәүкәт Галиев, Нәби Дәүли, Сибгат Хәким.*

Прозаикның оригинальлеге барыннан да элек аның фикерләвенең оригиналь булуында. Художестволы фикерләү! Әмирхан Еники хикәяләренә анализ ясагач, менә шундый нәтиҗәгә киләсең. Еникидә бернинди әзер чишелеш юк, тормышны ул әдәби схемаларга "куып" яки көчләп кертергә тырышмый. Ул үз идеясен турыдан-туры тәгъбирләүдән кача, үз мөнәсәбәтен тегe яки бу персонажга бәйләргә теләми. Нәтиҗә ясауны укучының үзенә калдырып, тегe яки бу күренешне гаделлек, риясызлык һәм объективлык белән сурәтли. Менә шуның өчен дә аның күпчелек әсәрләре бәхәсләр һәм капма-каршы фикерләр көрәше китереп чыгара.

Ә. Еники башлыча кешенең эчке дөньясы, аның хисләре, мораль һәм әхлакый сфера белән кызыксына. Аның әсәрләрендә турыдан-туры күзгә ташланып торган "производство конфликтлары" да, көннең кадагына ашык-пошык кына "сугу" да юк. Әмма алар кешеләргә тирән мәхәббәт белән сугарылганнар, кеше күнелендәге иң яхшы, иң матур якларга мөрәҗәгать итүгә юнәлдерелгәннәр.

Язучы матурлыкны, ул тышкы ямьсезлек һәм хәтта гариплек артына яшеренгән булса да, тоя һәм күрә белә. Беренче карашка кечкенә, әһәмиятсез булып күренгән нинди генә вакыйга турында язмасын, Еники ул һәрчак күренешнең асылына төшенергә, фактның фәлсәфи мәгънәсен ачып бирергә тырыша.

*1979 ел*

## Әхсән Баян:

Әмирхан аганың әхлакый ныклыгы, теләсә нинди шартларда иманга тугрылык саклый алуы безгә дә әйбәт үрнәк булып килде һәм хәзер дә тормыш сынауларын уза белергә ярдәм итә.

Язмыш безгә озак еллар әдәбиятта бергә эшләргә мөмкинлек бирде— Әмирхан Еники кебек затлы кеше белән очраштырды. Үзем өчен мин моны сирәк бәхетләремнең берсе дип исәплим.

*1999 ел*



*Әмирхан Еники үзенең җәмәгате Нәҗия ханым белән.*

## Илдар Юзеев:

Язучының үзенчәлекле хикәяләү алымы халыктан килә: әйтерсең, син якын дустың белән чәй эчеп утырасың, ул сиңа бер дә кабаланмыйча гына, күңелдәге йөгәнсез дәртне тыштан яшерә-яшерә, күзенә бәреп чыгарга торган яшь бөртеген эчкә йота-йота, сөйли. Ул сөйли, ә син күпне күргән, күпне кичергән бу тылсым иясенең авызына карыйсың да аның сихри сөйләме артыннан ияләсең. Сөйли генә түгел, көйли дияр идем мин. Прозасының шагыйранә үз ритмы бар. Иренгә тидерүгә көй уйный башлаган ялан курае сыман, сөйләме табигый, иркен ага. Ул сөйли, ул сиңа халыкның катлаулы язмышын, тугрылыгын, вөҗданын, мәхәббәтен тасвирлый. Син тыңлыйсың һәм татар халкына гына хас булган кабатланмас милли характерларны, ерак бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне, этнографияне күзаллыйсың.

*1978 ел*

## Зөлфәт

### Асыл курай

Тау куенында, кояш иркәсендә
кура үсә, пешә, тырая...
Чын курайчы аннан курай уя,
Әверелә кура
курайга...
Курай дисәм, Еникине уйлыйм.
Ул—
нәкъ кеше курай!
Үзе лә!
Аның ипле, кайнар сүзләре дә
Курай моңы булып тезелә.

Аксакаллар бөек сер шикелле—
Әйтик кошның нурга кунышы...
Гүя алар уйчан курай сыман—
Җирнең дымы, күкнең сулышы!

Берчак башкорт курай тарта иде...
Күз төшердем әдип-морзага—
Аңламадым,
Кураймы соң әле,
Еникиме әллә моңлана?
Асыл курай асыл булып калыр...
Бәхәсләшмик...
Ни ул? Кемнеке?
Әнә!
Курай тарткан сыман яза,
Яши безнең морза—
Еники!

Күз алдында—ак кылганлы дала,
Җиз кыңгырау—күркәм дугада.
Һәм Ак әби килә...
Укыйсың да—
Яшиселәр килә дөньяда!

Дугадагы кайтмас шул кыңгырау
Мең сагышлар җанда кабыза...
Пеше курай гына түгелдер бу!
Кеше—курайдыр ла
Бу морза!

... Кызганам мин
бездән соңгыларны—
Сәер
Алар кичәр дөньялар.
Бу кыңгырау чынын ишетмәс тә,
Ишетсә дә
тоймас бит алар!

Буталчыкка бик тиз ияләштек,
Аларга тик
туры юл ятыр,
Пеше курай түгел,
эшле курай
Аларга үз көен уйнатыр.
Аларга үз көен уйнатыр да,
Әллә нинди көйгә биетер,
Тимер курайларның тимер көе
Яшәешне дер-дер селкетер.

Аксакаллы туры килде язмыш...
Безнең гомер
монда үтәчәк,
Шушы моң бетәрме?
Бетә икән,
Димәк,
дөньясы да бетәчәк.

Юк, ышанып булмый!
Сүнәр көннәр
Килмәс...
Казан төнен кабыза.
Асыл курай булып,
милләт өчен,
Һаман моңлан, Еники морза!

*21 декабрь, 1998 ел.*

## Әмирхан Еники

# ШАЯРУ

хикәя

### I

Кечкенә генә Идел пароходы, өч тапкыр өзеп-өзеп кычкыртканнан соң, акрын гына дебаркадердан аерылды. Халык җыелган якка шактый кырынаеп, үзенчә гайрәтләнгән булып, зур калаклы тәгәрмәчләрен шапылдата-шапылдата, ул елга уртасына таба борылды. Кайчандыр тар суларда аккош төсле горур йөзеп гомерен уздырган бу пароход, хәзер инде ашын ашаган, яшен яшәгән бабайга охшап, киң Идел уртасыннан ашыкмыйча гына түбән төшеп китте. Аның юлы Уфага чаклы, шушы юлда йөреп картайды ул. Бәлкем, Агыйделгә барып кергәч һәм аның үрелеп сыйпарлык чәчәкле тугаен күргәч, пароходыбыз борынгыча яшәреп, дәртләнеп тә китәр, әмма хәзер исә, ярларыннан чыккан дәрья уртасында, ул ничектер көчсез дә, мескен дә булып күренә иде. Әйе, үтә икән шул, үзгәрә икән шул барысы да!

...Палубада каюта ачкычын кулында уйнаткалап басып торган ялгыз ханым, пароход пристаньнан бераз ераклашкач та, урыныннан кузгалып китте. Ярдан кулъяулык болгый-болгый озатып калучылар арасында аның күздән югалганчы карап барырлык беркеме дә юк иде. Ирен ул пароходка утыргач та кайтарып җибәрде, чөнки ире аның бик эшле кеше, һәр минуты исәптә... Хәер, тор дисә, ул торыр да иде, кешеләр арасыннан такыр башын елтыратып, бу күздән югалганчы эшләпәсен селкеп тә калган булыр иде, ләкин ханым аны тотмады инде. Ире үзеннән яшькә күп олы булганга күрәме, ханым аның белән кешеләр күзенә артык чалынырга, ирле-хатынлы икәнлекләрен ачык сиздерергә бик үк яратып бетерми иде. Ире үзе дә моны сизенә иде шикелле. Ләкин алар арасында бу нәрсә бервакытта да, ялгыш кына да телдән әйтелгәне юк, киресенчә, яшь аермасын әнә шулай эчләреннән генә уйлаган хәлдә, алар бик тату яшиләр иде... Моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки ире аны уч төбендә генә кадерләп тота иде.

Ханым палубаны бер әйләнде, ике әйләнде, ахырда, йөрүдән кызык тапмагач, стена буендагы үргән креслоларның берсенә килеп утырды һәм уйсыз-нисез генә ерак ярларга карап бара башлады. Бу әле утызга да житмәгән, төскә шактый чибәр генә бер ханым иде. Өстендә аның инде тулылана башлаган гәүдәсенә ыспай ятып торган тар итәкле ачык изүле әфлисун төсендәге йон күлмәк, аягында кара "лодочка" туфлиләр, ялангач беләгендә кечкенә алтын сәгать. Куллары аның бик ак, бик нәфис, тырнакларына тип-тигез алсу кына салган, бер бармагында кечкенә бриллиант каш яна. Чем-кара шома чәченең озын толымнарын бик пөхтәләп артка өеп куйган, һәм ап-ак муенында сөйкемле генә кара миңе дә бар. Кашлары да бик нечкә итеп сызылган, сөрмәле күзләренең кара керфекләре дә бераз мләп диярлек югарыга һәм түбәнгә матурлап бөгелгән—кыскасы, әнә шулай шартына бик житкереп көязләнгән, үзе чибәр, үзе яшь, үзе нигәдер боек бу ханымга игътибар итмичә узарлык түгел иде.

... Күпмедер утыргач, ханымның тагын эче поша башлады. Бөтен әйләнәдә күңелсез бертөрлелек: су да су, ярлар ерак, җәйге матур яшеллекне якыннан күреп тә булмый. Аннары бит ул биредә ялгызы... Барысы да бар кебек—байлык та, яшьлек тә, хөрлек тә—ләкин берүзе генә ул алар белән нишләсен? Менә ул өендә дә һаман бертөрлелектән туеп, тик ятудан йөдәп беткәч, тотты да "әниемне күреп кайтыйм" дип шушы юлга чыкты. Күңеле

талпынып, бик теләп чыкты ул бу юлга. Идел өсте, ак пароход, аулак каюта, гүзәл салон—болар барысы да аның хыялын котыртып, нииндидер кызык, нииндидер онытылмас күнелле хатирә вәгъдә итәләр иде кебек.

Ләкин пароход ялгыз йөрүчеләр өчен кызыклы урын түгел ул. Менә кузгалып китүенә озак та үтмәде, безнең ханым инде үзен үги кешедәй хис итә дә башлады. Дөрес, уфтанырга бик иртә әле, алда ике тәүлеккә якын юл бар. Бу аз вакыт түгел, ике тәүлектә ни булмас!

Ханым палубада йөрүчеләрне дикъкать белән күздән кичерде. Ул, әлбәттә, танышыр өчен кеше эзләми, күнеле аның андый нәрсәдән ерак иде, хәтта берәрсе танышырга чамаласа да, ул әле уйлап карар иде. Һәрхәлдә, абруен төшермәячәк ул... Ләкин кешеләр белән кызыксынмаска мөмкинме соң? Һәркемгә дә хас бер гадәт ич бу. Шуңа күрә ханым бер ирләрне генә түгел, гомумән, һәркемне күздән кичермичә калмый иде.

Ләкин күпме генә күзәтеп утырса да, ул кызыксыну уятырлык кеше очратмады. Яшьләр юк диярлек, күбрәк парлы халык, ә сирәк-мирәк очраган ялгыз кешеләр әллә нинди шунда күңелсез, таушалган бәндәләргә охшыйлар.

Ханым утырган жиреннән торып китте, тагын палубаны бер әйләнде, икенче әйләнүендә, пароходның арткы очына житкәч, палуба рәшәткәсенә таянып, койрыкта баручыларны күзәтергә кереште. Анда кызыграк та, күңеллерәк тә кебек иде. Кешеләре дә бүтән—авылларына кайтып баручы агайлар, жиңгиләр, студентлар. Кайберсе тимер идәнгә аягын сузып утырган да капчыгын чишеп янына гына куйган, ак булка һәм уалган хәлвәне капчык авызыннан гына алгалап, зур калай кружкадан өрә-өрә чәй эчеп бара. Кайберсе аулаграк урынны сайлап, төенчеген баш астына салып, шунда йокларга жайлашкан. Әнә ике кыз койрыкның иң очына кочаклашып утырганнар да пароход артыннан ургылып калган суга карап баралар. Алар үз алларына акрын гына жырлыйлар шикелле, тик пароход шаулавыннан ишетелми генә... Ә болары кемнәр? Ишектән читтәрәк өч егет һәм бер кыз нидер сөйләшеп торалар. Уртагарак баскан, иптәшләреннән калкурак буйлы, гәүдәгә какча булса да, шактый киң жилкәле таза егетнең кулында ефәк баш яулыгы. Сүз шул яулык турында бара ахрысы, чөнки әле берсе, әле икенчесе яулыкны тотып-тотып карый да башын селкеп куя. Ара-тирә аларның:

—Кайдан алдың моны, малай?

—Ну тапкансың бит үзең дә!—дигән кебек сүзләре дә ишетелеп калгалый.

Ә егетнең кулындагы яулык искиткеч матур иде. Нинди генә бизәк, нинди генә төс юк анарда, нәкъ менә ачылып киткән тавис койрыгы диярсең! Егет башта, бәлкем, үзе дә бу кадәр гүзәл нәрсә алуын аңлап житкермәгәндер, ә хәзер исә, иптәшләре исләре китеп мактагач, аның куе кара кашлы ак чыраена гажәпсенү катыш балаларча сөенү жәелгән иде. Сүзен дә әйтә алмый ул, бичара. Яулыгын ике кулына тоткан килеш, иптәшләренең мактавына бары баш кагып кына тора.

Егет үзе дә, аның кулындагы нәфис яулык та безнең ханымда гаять зур кызыксыну уятты. Кем ул, нинди яулык аның кулында, каян алган, кем өчен алган ул аны? Кинәт ханымның түбәндә, шул яшьләр арасында буласы килде, яулыкны тотып карыйсы, битенә куеп карыйсы килде. Нигәдер, ни сәбәптәндер аның хәтта яшь буласы, ваемсыз-шат буласы, әле берни дә үтмәгән, барысы да—мәхәббәте дә, бәхете дә—алда булачак дип ышанасы һәм әнә шул яшьләр шикелле, юк кына нәрсәдән дә куаныч табып, хыялланып, өметләнеп яшисе килеп китте. Шунда ук яннарына йөгереп төшәрдәй булды, ләкин... бу мөмкин түгел иде. Ара ерак. Ул югарыда, алар түбәндә. Әгәр шуннан юләрләнеп төшсә дә... көлкегә генә калыр иде.

Ханым тирән итеп бер сулады һәм каядыр алып киткән хыялларыннан айнырга теләгәндәй башын чайкап куйды. Үзе һаман, түбәндә баручы яшьләрдән күзен ала алмыйча, онытылып карап торды. Менә егет яулыкны, ак кәгазьгә иплән кенә төреп, эчке кесәсенә салды, шуннан, янә бераз сөйләшеп торгач, алар барысы да эчкәре кереп киттеләр. Ханым да кузгалды...

"Студентлар ахрысы?"—дип уйлады ул эченнән. Аннары: "Нишләргә сон?"—дип тә уйлады. Каютасына ни өчендер керәсе килми иде, ялгыз палуба таптау да килешми. Таушалган пижамаларын киеп, китап тотып чыккан эчпошыргыч "командировочныйлар" ул үтеп киткән саен китаптан башларын күтәреп, аның артыннан карап калалар. Ни уйлап карыйлар өнсез, йөрәксез балыклар? Үзләре әле шулай да, зәһәр йоткан хатыннарын исләренә төшереп, эчләреннән калтыранып та куя торганнардыр. Хатыннарыннан курыккан ирләрне ул, үзе әйтмешли, терпеть не могла!

Ханым, палубаны ташлап, беренче классның салонына килеп керде. Төшке аш вакыты күптән узганга, ә кичке ашка әле бик иртә булганга күрә, салонда беркем дә юк иде. Ханым тирән эчле йомшак креслоларның берсенә утырды. Салон эче тын, бары бөтен жирендә вак кына калтырау сизелә, официантканың бер өстәлгә жыеп куйган бокал-стаканнары акрын гына зыңлыйлар, ә көн яктысыдай тоташ калын тәрәзәдән ничектер ачыкланып, якынайгандай булып күренгән яшел урманлы тау битләре акрын гына артка таба йөзәләр. "Нишләргә сон?"—дип, тагын пошынып уйланды ханым. Ашыйсы-эчәсе дә килми, чөнки ире белән соңгы тапкыр каракаршы утырып, өеннән бик әйбәт сыйланып чыккан иде. Шулай да официантка кыз салонга килеп кергәч, ул аңа бер стакан чәй белән пирожный китерергә кушты.

Менә шул бер стакан чәй белән юанып, ул зур тәрәзәдән әлеге артка таба йөзгән тау битләренә, арыш кырларына озак кына карап барды. Ләкин бу күренешләр, жансыз күзгедә чагылган шикелле, аның күңелендә берни уятмыйча, хәрәкәтсез төбәлгән күзләреннән генә кичәләр дә кичәләр. Барыбер нидер юк, нидер житми, ә калын пыяла аша күренгән табигать үзе генә аның күңел бушлыгын тутыра алмый иде. Нәрсә теләгәнен ул үзе дә белми, бөтен нәрсәсе бар да кебек, ә шулай да жаны тыныч түгел, жаны һаман нидер тели, нидер көтә.

Акрынлап кына кояш та жир читенә якынлашып бара, Идел өстендә алсу шәүләләр уйнаклый башлады. Биек ярларның суга яткан күләгәләре торган саен киңәя һәм караңгылана, ә кояшка каршы яктагы чиксез Идел түре, аннан да ары сөзәк кенә күтәрелгән күгелҗем кырлар өсте аеруча яктырып балкый иде. Ханым, палубаны тагын бер әйләнергә булып, салоннан чыкты.

Пароходның койрыгына житкәч, ул нигәдер түбән карады һәм ихтыярсыздан тукталды. Түбәндә баягы таза чандыр егет ялгызы гына әржәләр өеменә йөзе белән борылып, әлеге тавис койрыгыдай яулыгына карап тора иде. "Бу ни хәл,—дип уйлады ханым,—әллә тилергәнме ул, шулкадәр исе киткән!" Ә егет чынлап та, бераз гына шөребе какшый башлаган кешедәй, аны-моны сизмичә яулыгын бер жәеп карый, бер йомарлый, битенә дә куеп ала, иснәгән кебек тә итә, гүя сихерләп маташа. Аннары бик сак кына ак кәгазьгә төреп, эчке кесәсенә салып куя.

Бу күренеш ханымда шундый бер сабырсыз кызыксыну уятты ки, аның ничек кенә булса да егет белән танышасы һәм яулыкның серен беләсе килде. Ә кичкырын түбәндә баручы кыз, егетләрнең берсен ияртеп, палубага менде. Алар сагаеп кына бер әйләнделәр дә, пароходның алгы очына туктап, Идел өстенә карап бара башладылар. Ханым алар янынннан бер-ике тапкыр сүзләренә колак салып үтеп китте. "Әйе, болар студентлар булырга тиеш". Кечерәк кенә буйлы жыйнак кыз беренче кышын гына шәһәрдә үткәргән ахрысы, район кыяфәте үзеннән китеп тә бетмәгән әле; көл төслерәк чәчләрен уртадан ачып, калын толымнар итеп үреп салган, өстенә кызыл бөрчекле ак ситсы күлмәк киеп, билен тар гына каеш белән буган, ә аягында арзанлы оек белән үкчәсез кара туфли... Егет исә шәһәрчәрәк: өстендә аның эре шакмаклы, "молния" каптырмалы күлмәк, балаклары бөрмәле күк шаровар, аягында "тапочка" дип йөртелгән резин чүвәк,—базык, тыгыз гәүдәсенә караганда, ул берәр институтның спортчысы булса кирәк.

Ханым алардан аз гына читкәрәк килеп туктады да, кирәк кадәр

тынып торгач, гади-мөлаем булырга тырышып, яшьләргә дәште:

—Иркәләрем, кая кайтып барасыз?

Яшьләр җәһәт кенә аңа борылып карадылар; кызның, борыны кечкенә булганга күрәме, соры күзләре бу минутта аеруча зур да, якты-матур да иде. Шәп киенгән чибәр, көяз ханымны күргәч, ул бераз гаҗәпсенебрәк, теләр-теләмәс кенә:

—Төрлебез төрле җиргә,—диде.

Аның болай кырын торып, салкын гына җавап кайтаруына ханымның артык исе китмәде: хатын-кыз башта бер-берсенә шулайрак була инде, нишлисең! Мөлаем ягымлылыгын саклап, ханым сораша бирде:

—Шулаймыни? Бик әйбәт. Сез студентларсыздыр инде?

—Әйе, студентлар.

—Шулайдыр дип уйлаган идем. Танып була бит. Кайчан гына әле мин үзем дә студентка идем.

Яшьләр һич тартынусыз ханымга тагын бер сынаулы караш ташладылар. Ханымның үзен менә шулай гади-якын итеп тота белүеме, әллә соңгы сүзен әйткәндә ничектер сагышлы көрсенеп куюымы—нидер яшьләрнең салкын торып маташуларын бик тиз эретә башлады. Озак та үтмәде, телләре дә чишелде һәм сөйләшеп тә киттеләр.

Башлап үзләре үк ханымның исемен дә сорап белделәр. Ханым аз гына көттереп, гүя чын исемен әйтергә икеләнгәндәй, җавап бирде:

—Мин... Диләрә.

Аннары ул үзе сораша башлады. Яшьләр, билгеле, икеләнеп тә, яшереп тә тормадылар—аларныкы уч төбендә!

Тиз арада ханым һәркайсының исемен белде, кайда укуларын, кая кайтуларын белде, тик бер генә төер аның күңелен һаман борчып торды. Ул теге яулык хуҗасы чандыр егет тә менмәсме икән дип көтте, әмма егет менмәде. Бер-ике тапкыр ханым җай чыгарып аның хакында сорашырга да теләп карады, әмма булдыра алмады. Бары аерылышканда яшьләргә:

—Сезнең белән танышу бик әйбәт булды әле. Иртәгә дә менегез, бергә-бергә кайту күңелле ич!—дип калды.

Яшьләр:

—Рәхмәт, апа, килербез,—дип, түбән төшеп киттеләр.

Ханым ялгыз калгач та каютасына керергә ашыкмады. Палуба баганасына сөялеп, битен кичке саф җилгә куеп барды. Төн, тынлык, елга өсте кап-кара, аз гына чи балык исен аңкытып түбәннән дым килә. Ярлар күренми, каршы очраган пароход та, вак утларын ерактан гына җемелдәтеп, тавыш-тынсыз уза...

...Менә түбәндә ничәдер тапкыр җиз кыңгырауга суктылар—һәр сугудан, гүя ике кат тавыш чыгарып, сәер генә яңгырады ул... Диләрә ханым иренеп кенә урыныннан кузгалып китте, каютасына керде, ашыкмыйча гына урынын рәтләп, чишенә башлады. Аяк йөзеннән үк яткан төнге ефәк күлмәген киеп, көзге каршына баскач, ничектер уйга китеп, тулы-тыгыз күкрәкләрен акрын гына сыйпап торды. Әйе, ул яшь, ул таза, ул чибәр әле! Ләкин... нигә соң болай йөрәген савып, эче поша икән аның? Ни җитми, ни кирәк? Тагын әлеге ак чырайлы чандыр егет аның исенә төште. Кем ул, ни өчен ул да, кешедән яшерен сере бар шикелле, иптәшләреннән үзен читтәрәк тота, йөрми, күренми? Тагын эчке кесәсендә генә саклап йөрткән яулыгы... нигә ул аңа бик кадерле?

...Кинәт ханымда шул яулыкны егет кулыннан ничек тә тартып аласы килү теләге туды. Яулыгын алырга, яулыгы белән бергә серен алырга!

Һа, ул моны булдыра алмасмыни? Нинди егетнең әле яшь чибәр хатын сихереннән котыла алганы бар? Теләү генә кирәк, теләү генә—иблисен дә тез чүгәр!

## II

Иртәнчәк Диләрә ханым палубада кемнәрнендер кычкырып сөйләшкән-көлешкән тавышларыннан уянып китте. Тәрәзәгә тарткан кыек рәшәткәнең ярыкларыннан кергән яктылыкка караганда, вакыт шактый булырга тиеш иде инде. Ханым, урын өстендә бераз киерелеп-сузылып ятканнан соң, кинәт нидер исенә төшкәндәй, ашыгып урыныннан торды. Тиз генә чуар халатын киеп, тәрәзәнең рәшәткәсен шылдырып җибәрде. Илаһи, көне дә көне! Үзе тын, үзе нурлы, үзе җылы, әйтерсең, балачакта күргән бәйрәм иртәсе! Су өсте тип-тигез, яланаяк йөгер дә кит! Пароход та аның өстеннән гүя шуып кына бара. Кояш та әле яңа күтәрелеп килә икән,—җылына башлаган елга урыны-урыны белән сөттәй ак пар көйрәтеп ята. Ярлар да биредә якын икән,—әнә көтүләре белән кузгалган карлыгачлар канат какмыйча гына кыеклап-кыеклап бер югары менеп китәләр, бер түбән атылып төшәләр. Юк, мондый иртәне, мондый нурлы иртәне йоклап күрмичә калырга ярыймы соң!

Диләрә ханым тиз генә юынды да, яңадан рәшәткәне тартып, киенә башлады. Бүгенге иртәнең үзенә охшарга теләп, иң матур, иң килешле алсу күлмәген киде, энҗе муенсасын такты, күзләренә оста гына итеп сөрмә тартты, шуңардан ахры керфекләре дә аска һәм югарыга таба матур гына бөгелгән кебек булдылар. Бизәнеп беткәч, чәченә, түшенә "Ак сирень" хушбуен бөркеде, шуннан соң, рәхәт бер җиңеллек хис итеп, палубага чыкты.

Палубада куанычлы бер җанлылык иде. Бар да торып чыкканнар, бар да иртәнге елга өстен һәрьяклап күрергә теләгәндәй, төркем-төркем күчеп йөриләр, кулларын сузып, бер-берсенә нидер төртеп күрсәтәләр, һич юктан да шатланып көлешәләр. Диләрә ханым да чыгу белән сөттәй ак пар шуышып йөргән елга өстенә, нурлы пәрдәгә төренгән тау битләренә бер мәл сихерләнгәндәй карап торды. Бу кадәр дә матур, сөйкемле булыр икән! Әйтерсең, менә бөтен дөньясы назланып, елмаеп алдында ята синең! Әгәр Диләрә ханымның канатлары булса, шуларны җәеп, пароходтан төшәр иде дә, аякларын суга тидерер-тидермәс кенә атлап, тын, якты тауларга таба китәр иде. Күргәннәр: "Бу нинди фәрештә, кайдан гына иңде әле ул!"—дип, тик хәйран булып калсыннар иде.

Шулай сихерләнеп, хыялга бирелеп, күпмедер торганнан соң, ул акрын гына кузгалып китте. Пароходның арткы очына җиткәч, тукталып, ихтыярсыздан түбәнгә караса, әлеге таныш яшьләрнең койрыкта, тимер идәнгә газеталардан табын җәеп, күңелле генә ашап-эчеп утыруларын күрде. Аның йөрәге кинәт урыныннан купкандай булды, җанын әллә нинди бер түземсез талпыну биләп алды. Бик якын идеме алар аңа, әллә мондый иртәдә үзенең ялгызлыгы белән һич килешә алмаганга күрәме, әмма ничек кенә булмасын, аның чын ихластан тизрәк шулар янында буласы килде. Һәм, бер дә уйланып-икеләнеп тормыйча, ул ашыгып түбәнгә төшеп китте.

Яшьләр аны якты каршы алдылар. Дөрес, ханымның бик шәп киенгән булуы, бигрәк тә "югарыдан" төшүе аларны беркадәр ятсынырга мәҗбүр итә иде. Ханым үзе дә моны сизмичә калмады, ләкин игътибар итмәскә тырышты.

Яшьләр бераз каушабрак аңа табын янына утырырга тәкъдим иттеләр. Ханым, чүгәләп, күлмәк итәген кайтара төште дә, чистарак урынны чамалап, җылы тимер идәнгә утырды. "Табында" газетка турап салган ак икмәк, арзанлы колбаса, йомырка, яшел суган, шырпы тартмасында тоз,—нәкъ менә безнең кадерле кунак өчен генә әзерләнгән сый!.. "Табын"ның хуҗасы—әлеге чәчләрен уртадан ачып тараган бала чырайлы кыз икән. Ханымны да башлап ул кыстарга керешә:

—Апа, рәхим итегез! Безнең табын студентларча, такы-токы гына инде, гаеп итмәссез!

Ханым ничек тә гади, үз булырга тырышып:

—Сөйләмә, иркәм!—диде.—Бик әйбәт, тагын ни кирәк?

Һәм бер йомырканы алып, идәнгә бәреп ватты да әрчергә тотынды.

Егетләрнең берсе аның алдына колбаса телемнәрен этәрә төште:

—Менә моны да алып карагыз, әгәр яратсагыз... "Халыклар дуслыгы" дибез без аны, ите—атныкы, мае—дуңгызныкы...

Яшьләр көлештеләр, ә ханым комачтай кызарды, шулай да сынатырга теләмәде.

—Беләм, беләм!—дигән булды.—Ашаганым бар, әйбәт була ул ат казылыгы...

Һәм бер-ике түгәрәкне батыр гына ашап та җибәрде. Алай авызга алмаслык нәрсә түгел икән. Тик кызыл ит арасында сирәк-мирәк очраган бармак башыдай дуңгыз мае гына чәйнәр өчен авыр икән. Ярый инде! Менә артыннан яшел суган капкач берни булмас, үтәр әле.

Ә шулай да бик күңелле! Пароход, тип-тигез су өстен ертып, тонык кына шаулап бара, йомры-якты дулкыннар ике якка салмак кына куышып китәләр. Җылы, рәхәт... Егетләр, әвен сугучылар шикелле, бик тәмләп, авыз тутырып ашыйлар. (Диләрә ханым исәбенчә, боларның ашказаннары ташыңны да сеңдерер!) Тик яулык иясе егет кенә ашауга артык исе китмәгәндәй күренә. Ул аякларын идәнгә сузып, табынга кырын утырган, ашыкмыйча гына чәйни һәм күбрәк читкә, су өстенә карап бара. Ханымга ара-тирә генә күз ташлап куйгаласа да, артык кызыксыну да, ятсыну да күрсәтмичә, ничектер битараф кала бирде. Шулай да бер мәртәбә, ханым нидер әйткәч, ул зур кара күзләрен тутырып, үтә сынау белән аңа карап алды. Әллә нишләтеп җибәрде бу караш Диләрә ханымны, әмма ул аны батыр күтәрде, хәтта горур гына башын да чөеп куйды. Тынычлыгын саклап, ул берни булмагандай сөйләнә бирде:

—Урыныгыз да ямьле, ашыгыз да тәмле, ярый төштем әле яныгызга.

—Ә югарыда... нигә, начармыни?—диде кичә танышкан шакмак күлмәкле егет...

—Югарыда... сезнең кебек күңелле компания юк.

—Нишләр булмасын! Әнә анда нинди шәп абзыйлар баралар.

—Абзыйлар шул. Ә миңа үз тиңнәрем кирәк.

—Ә-ә, алай икән!

Егетләргә күңелле булып китте ахрысы, дәртләнеп, баш кагып елмаештылар. Юк, бу ханым, нинди генә асыл кош булмасын, "түбәндәгеләр" компаниясенә алырлык икән. Үзен әнә ничек иркен, кыю, гади тота ул!

Ләкин табынчы кыз, сокланырга ашыкмыйча, күбрәк белергә теләп, житди генә сорап куйды:

—Кем буласыз соң сез, апа?

Диләрә ханым кинәт сагаеп калды.

—Ничек инде ул... кем буласыз?

—Кайда, нинди эштә эшлисез дип соравым,—диде кыз, бераз уңайсызланып.—Сез тагын ачулана күрмәгез, апа!

—Юк, нишләп ачуланмыйм,—диде ханым, елмаерга тырышып, әмма кыз аның иң авырткан җиренә кагылды. Мондый сораудан ул һәрвакыт курка торган иде. Ни дип кенә җавап бирергә соң? "Институтны бетерер-бетермәс зур кешегә иргә чыктым да шуннан өйдә утырып калдым",—дип әйтә алмый бит инде ул. Ләкин берни сиздермәгән кыяфәт белән тизрәк җавап бирергә ашыкты:

—Мин финансово-экономическийны бетергән идем. Мин—финансист! Менә шулай!

—Һо, финансист!—диде егетләрнең берсе, күзләрен зурайтып.—Алайса, сез бик байсыздыр?

Ханым кызарды, шулай да югалып калмыйча, шаяруга каршы шаяртып әйтте:

—Гаҗәп инде, нәкъ менә Драйзерның финансисты кебек...

Кырын утырган егет тагын бер карап куйды, бу юлы шактый кызыксынгандай итеп, һәм ханым үзе өчен өметле булган бу карашны бик тиз тотып алды. Ул шунда ук сүзне яшьләрнең үзләренә күчерде:

—Ә шулай да студент вакытка ни житә. Бөтенесе алда: матур хыяллар,

зур планнар... Әгәр мөмкин булса, янадан сезнен хәлгә кайтыр идем. Нинди рәхәт ич! Бергә уку, бергә кайту, бергә ял итү.

—Ә безнең тизрәк бетерәсебез килә,—диде шакмак күлмәкле егет.—Укуы бер дә рәхәт түгел, бигрәк тә финанс ягы такыр булган чакта... Аннары, сез әйткәнчә, бергәләп ял итүләр дә бик тәтеми хәзер. Менә бер айга гына җибәрделәр, кайтып, әни карчыкларга утын, печән әзерлибез дә, аннан, давай, кире шәһәргә!

—Ни өчен шәһәргә?

—Целинага китәр өчен... Беләсезме, нәрсә ул целина? Һо, целина, апа җаным, бик интересный җир ул! Менә кайда кәҗә майларын чыга.

—Быел Фәнияне дә үзебез белән алып барабыз,—диде егетләрнең икенчесе, табынчы кызга җылы көлемсерәп.—Курыкмыйсынмы, Фәния?

—Исем китә!—диде Фәния, эре генә.—Куркып торырга, сездән кай җирем ким минем?

Ул табында калган азыкларны әйбәтләп төреп җыештырырга кереште, егетләр "прибой"ны кабызып җибәрделәр. Диләрә ханым кемнәрнеңдер югары палубадан аңа сәерсенеп карап баруларын күптән шәйләп алган иде. Шулардан унайсызланып булса кирәк, үзенчә сылтау табып, җәһәт кенә урыныннан торды.

—Карагызчы, бу акчарлакларны әйтәм, бер дә пароходтан калмыйлар бит! Нигә икән?

Егетләр дә урыннарыннан тордылар. Кыз газеттагы сынык-саныкларны илтеп су өстенә селекте:

—Менә шулар өчен ияреләр инде алар! Әнә, әнә, күрдегезме, икмәк кисәкләрен ничек кенә эләктереп алдылар!

Ә шакмак күлмәкле егет, папиросын тирән суырып:

—Их, акчарлак шикелле, менә шулай җелт иттереп кенә берәр җәенне сыртыннан эләктереп алсаң иде!—диде.—Ярап куяр иде ул безгә обедка!

Икенчесе яулык иясе егетнең аркасына сугып алды:

—Эләктерсә Харис эләктерә инде аны, безнең иң шәп йөзүчебез!

Харис моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, тик аның уйчан ак чыраенда нindидер сызлану аша боек көлемсерәү чагылып киткәндәй булды. Ә кыз шунда ук егетләргә, дәү апаларыдай, житди генә әйтеп куйды:

—Тимәгез сез аңа! Белмисезмени, җәен кайгысы түгел, җан кайгысы ич аңарда.

—Җанаш кайгысы диген, дөресрәк булыр.

—Җанаш кайгысы—җан кайгысы инде ул!—диде шакмак күлмәклесе, авыр көрсенгән булып.

Барысы да, иптәшләренең хәтерен калдырмаска тырышкандай, аңа карап, тыелып кына көлешеп алдылар. Харис һаман шулай уйчан, тыныч калды, ә Диләрә ханым исә, күзләрен елтыратып, егеткә тәмам йотылып карап торды. Шаярып кына әйтелгән бу сүзләр, егетнең килешкәндәй дәшмичә калуы аңа бик хикмәтле булып тоелды.

Бераздан ул, яшьләрне югарыга чакырып, палубага менеп китте... Харис, Харис! Бу исем һаман аның телендә әйләнде, "җанаш кайгысы" дигән сүзләр һич күңеленнән чыкмады. Шунда ул егет куенындагы әлеге матур яулыкны да исенә төшерде. Яңа гына ишеткән сүзләр белән бу яулык арасында тәгаен бер бәйләнеш барлыгын да ул сизмичә калмады. Көнчелеккә охшаш бер хис кузгалып куйды аның йөрәгендә, һәм егетнең үзен дә, аның серен дә тизрәк беләсе килү аны чын-чынлап котырта башлады.

Хәзер инде ул хөрмәтле Харис иптәшне тынычлыкта калдырмаячак! Үпкәләштән булмасын, үзе гаепле. Аңа, роза чәчәгедәй ханымга, нindидер студент кисәге шулкадәр кырын, салкын торсын, имеш! Гаҗәп бит! Кайчан әле мондый хәлнең булганы бар? Бүтәннәр аның кулын бер үбәр өчен генә дә түшләре белән җирдән шуарлар иде. Ә ул?... Нindидер яшерен сергә төренеп, үзен чуен статуя шикелле тотып маташа. Мәхәббәт трагедиясе кичерә, янәсе! Туктале, менә без, җан кисәгем, синең өчен дә яраклы ачкычны таба белербез!

Ул яшьләрнең югарыга менүләрен күтәп йөри башлады. Алар, әлбәттә, менәчәкләр, тик менә Харис менәрме? Бу шик аңа бер дә тынгылык бирми иде. Әгәр барысы да менсәләр, ул аларны үзенең каютасына кунакка чакырырга булды. Аның әле башланмаган тавыгы бар, вак бәлешләре, паштеты, печеньесы, кыйммәтле конфетлары бар,—сые житәрлек. Шулар янына берәр шешә яхшы вино алганда ничек булыр икән,—менә шул хакта гына ул бераз уйланды. Ахырда теге целинага барудан да курыкмый торган, егетләргә карата үзен хужа сыман тоткан ябык кыздан ничектер яхшысынмыйча вино алу ниятеннән кайтты. Шул кыз булмаса, ике дә уйлап тормас иде ул, әлбәттә.

Күпмедер вакыт узганнан соң, яшьләр палубага менделәр. Харис та алар белән бергә иде... Диләрә ханым палубага чыга торган ишектән уң якта, беркадәр читтәрәк утырып тора иде. Яшьләр ишектән сулга таба борылып киттеләр. Бу хәл ханымга бик начар тәэсир итте, хурланудан ачуы килеп, торырга омтылган жиреннән кузгалмыйча, утырып калды. "Үзләренә күрә түгел, йолкышлар!"—диде ул, эченнән усалланып. Ләкин бераздан яшьләр палубаның икенче очыннан килеп чыгып, аңа якынлашкач, ханым каршыларына торып басты. Үзен көчләп булса да елмаерга мәжбүр итеп:

—Менә тагын очраштык!—диде.

—Бик әйбәт, бик әйбәт!—диештеләр егетләр.

Әлбәттә, бу яшьләрдә Диләрә ханымны ачыктан-ачык ят күрү яки өнәмәү дигән нәрсә һич юк иде. Бигрәк тә бер табынга утырып ашап-эчкәннән соң, алар аңа инде ияләшеп тә өлгергәннәр иде. Тик әле шомарып житмәгәннәр, ханымнарга, аеруча Диләрә кебек ханымнарга, бик игътибарлы булырга кирәклеген белеп бетермиләр,—һаман шул "культура" житмәү бәласе инде.

...Сөйләшә-көлешә палуба буйлап киттеләр, ләкин алар тар юлга барысы да сыя алмыйлар иде. Кыз белән Харис арттарак калдылар. Палубаның арткы очына житкәч, Диләрә ханым тукталды һәм, нечкә тимер терәүгә тотынып, күкрәген киереп бераз тынып торды.

—Яратам менә шулай пароходтан ярылып калган эзгә карап барырга!—диде ул, очарга торган кош сыман күзләрен алга текәп.

—Ә сикерәсегез килмиме шунда, бөтерелеп аккан суның нәкъ уртасына?—диде егетләрнең берсе.

—Килә!—диде ханым, башын кисәк кенә артка чөеп.—Кайдан сизеп әйттегез әле моны?

Харис та, килеп, бер читкәрәк туктаган иде. Аның һаман да сүзгә катнашмыйча салкын-житди генә басып торуы безнең ханымны ничектер тагы да кыюландыра төште. Ул торган саен жанланыбрак сөйләде, гадәттәгедән кычкырыбрак көлде һәм һәр әйткән сүзеннән соң егеткә туп-туры карап куя торган булды.

Аннары тагын палуба буйлап киттеләр. Харис белән кыз тагын арттарак калдылар. Бер әйләнгәч тә, Диләрә ханым, эчкәре уза торган ишек каршында туктап, кинәт кенә:

—Әйдәгез, минем каютага кереп утырабыз!—диде.

Кыз аптырап калды:

—Нигә, апа?

—Ә минем сезне кунак итәсем килә,—диде ханым, бик гади генә итеп.

Яшьләр, сәерсенеп, бер-берсенә карашып алдылар, әллә ничек кенә булып тоелды бу чакыру аларга.

—Мин сезнең яныгызга төшеп сыйландым бит,—диде ханым.—Инде минем чират, мин сыйлыйм. Әллә кермәс идегезме?

Һәм яшьләр риза булдылар. Дөресен әйткәндә, студент халкы сыйлаганны ярата ул, тик сыйлаучы гына булсын.

Харис та аерылып калмады, һәм ханымның рухы бердән күтәрелеп китте.

Бер генә кешелек каюта тыгыз иде, шулай да сыйдылар. Ханым

кунакларын койкага тезеп утыртты. Рәшәткәне шылдырып куйдылар. Яктырып киткән каюта эчен егетләр бик сокланып карадылар; аларның кайберләре мондый рәхәт, чибәр урынны беренче тапкыр күрәләр иде әле.

Ханым үзе, урындыкка утырып, зур гына сумкасын алдына алып, шуннан бөтен сыен өстәлгә чыгарып салды. Тавыкны да оста гына ботарлап куйды, аннары егетләрне чын ихластан кыстарга тотынды.

—Йәгез әле, иркәләрем, житешегез! Менә тавыктан, менә бәлешләрдән... Йәгез, йә!

Хәер, егетләр кат-кат әйттереп тормадылар, бер дә тартынмыйча гына ханымның сыйларын "ура" башладылар. Тик Харис кына баштарак тыелып утырды, чөнки ханым анардан бер дә күзләрен алмый иде. Аннан инде ул да: "Син мине ашасаң, мин бәлешеңне ашыйм әле",—дигәндәй, иптәшләреннән калышмыйча, ләкин алар шикелле бик кызуламыйча капкаларга тотынды. Иптәшләре, бу сыйлау өчен мактау кирәктер инде дигән дигән төсле, капкан саен берәр сүз әйтмичә калмадылар:

—Ну бәлешләрегез, апа! Үзегез пешердегезме?

Диләрә ханым исә, бик хуш булып, раслап кына утыра:

—Үзем, әлбәттә!

—Тавыкны да үзегез куыргансыздыр инде?

—Үзем булмыйча!

—Ә менә бу нәмәстәкәйне?—диде егетләрнең берсе, зур гына паштет кисәген урталай тешләп.

—Анысын да үзем пешердем.

—Их, минем дә булачак хатыным шушындый ашлар пешерә белсә иде!

—Пешерә белгәнгә өйләнегез.

—Алмас борын белеп буламыни аны!

—Ә син, алырдан элек, өенә йөреп бәлешләрен ашап кара!—диде егетләрнең икенчесе.—Мин үзем шулай итәчәкмен.

Көлештеләр. Ләкин авызлары тик тормады, сумса, бәлешләрдән валчыклар гына торып калды, тавыкны да ялт иттерделәр. Ханымга аларның берсе дә кызганыч түгел, тик күнелендә яткан теләге генә булмыйча калмасын иде. Ә теләге аның шул һич сүзгә катнашмыйча утырган, бары ялкау гына елмаеп куйгалаган Харисга... Шул ак чырайлы, куе кара кашлы Харисның телен чишәсе килә, шул горур-салкын егетне ничектер менә котыртасы, үзенә каратасы, һич булмаса үзе белән хисаплашырга мәжбүр итәсе килә. Һәм менә, һәрбер оригиналь уй кинәт туган шикелле, аның башында әллә каян гына килеп гаҗәеп бер мәкерле хәйлә туды. Үзе кимереп куйган жәдәч сөяген алып, ул егетләргә шаян гына:

—Әйдәгез, кем белән жәдәч аерышабыз?—диде.

Шакмак күлмәкле егет шунда ук кулын сузды:

—Минем белән.

Ләкин ханымның күзе Хариста иде. Ул кулын сузучыга карамыйча, назлы гына итеп:

—Ә минем менә... Харис иптәш белән аерышасым килә,—диде.

Харис аз гына кызарынып елмайды, нидер әйтмәкче булды, ләкин иңбашын гына җыерып куйды. Иптәшләре аны кыстарга тотындылар:

—Йә, Харис, бәхетеңне сына. Курыкма, курыкма! Оттырсаң, үзебез түләшербез.

Ханым инде жәдәчен аңа сузып ук тора иде. Харис шикләнебрәк ханымга карады.

—Йәгез,—диде ханым, кыю гына.

—Нәрсәдән соң?—диде Харис, ашыкмыйча гына кулын сузып; аның тавышы да көр, матур иде.

—Нәрсәдәнме?..—Ханым аз гына уйланып торган булды.—Юк, баштан билгеләмибез. Американча булсын!

—Анысы тагын ничек була?

—Ә менә ничек: сез отсагыз—миннән теләгән нәрсәгезне сорыйсыз,

мин отсам—үзем теләгән әйберне сорыйм.

Егет кулын кире алды.

—Юк, булмый!

Ханым, күзләрен кыса төшеп, егеткә төбәлде:

—Куркасызмыни?

—Юк, курыкмыйм... Ләкин ни өчен американча?

—Йәгез, йә,—диде ханым, елмаеп.—Мин бит студент кешенең хәлен беләм, әллә ни сорамам.

—Әйдә, рискуй,—диделәр иптәшләре дә.—Синең ни... кашың да күзең... нәрсәңне алсын ул?

Һәм алар җәдәчне аердылар,—егет кулында зуррак чаты, ханым кулында кечкенә чаты калды. Ни өчендер егетләр ханым отарга тырышмас, киресенчә, үзе юри оттырыр дип уйладылар. Әйе, ханым отарга ашыкмады, ләкин егет бирәр әйбер сузган саен, ул, сөйкемле елмаеп кына: "Исемдә!"—дип әйтергә дә онытмады. Аннары Харис та ханымга еш дәшүдән тыела башлады, чөнки сөйкемле елмайган ханым, әледән-әле тынгысыз күзләрен кечерәйтеп, ничектер аның эченә үтеп керергә теләгәндәй карый, һәм бу егетне ихтыярсыздан шомланып куярга мәҗбүр итә иде.

Алар бөтен төркемнәре белән тагын палубага йөрергә чыктылар. Бүтәннәр барысы да алдан китте, Харис гадәтенчә арткарак калды, ә ханым иң арттан иярде. Пароход борынына җиткәч, ул җилдән тузгый башлаган чәчен рәтләргә теләп, кырын баскан килеш, кулындагы ридикюлен егеткә сузды.

—Тотып кына торыгыз әле!—диде ул, чәче белән мавыгып.

Егетнең һични уйламыйча алуы булды, ханым кинәт кычкырып та җибәрде:

—Җәдәч!

Барысы да аларга борылып карадылар. Харис тәмам аптырап калган бер кыяфәттә кечкенә ридикюль тотып тора, ә ханым бөгелә-сыгыла рәхәтләнеп көлә иде.

—Их син... дус кеше! Тәки оттырдың, ә?—диде егетләрнең берсе, ачынып.

—Үзебез гаепле,—диде икенчесе,—саклый белмәдек. Уйлары аның җәдәчтәмени!

—Ярар, телегезгә күп салынмагыз!—диде Харис кырыс кына һәм ханымга ридикюлен кире бирде:—Йә, ни сорыйсыз?

—Тукта, ул хәтле ашыкмагыз!—диде ханым, ничектер берьюлы тынычланып.—Иң элек менә шушында утырыйк.

Башлап ул үзе ак эскәмиягә утырды, аннары Харисны да кыстап үз янына утыртты. Шуннан соң гына ул, ни таләп итсә дә хакы бар кешедәй, ашыкмыйча иплән кенә егеткә әйтте:

—Кичә сезнең кулыгызда бер яулык күрдем. Шуны сорыйм мин!

Егет кашларын җыерды.

—Юк, мин аны сезгә бирмим.

—Ә миңа бары шул кирәк.

—Булмый. Бирә алмыйм. Бүтән нәрсә сорагыз.

Ханым, тынып, җитди сынау белән егеткә беравык карап торды.

—Хәтерләгез әле, без ничек килештек? Әгәр сез отсагыз, мин сездән бернәрсәмне дә кызганмаган булыр идем...—Ул сүзен әйтеп бетермәде.

Харисның ак чыраена кызыл таплар бәреп чыкты; дәшмәде ул, тик иреннәрен нык кысудан яңак сөякләрен уйнаткалап куйды. Шул чакта Фәния ашыгып һәм борчылып әйтте:

—Апа, сез аңардан ул яулыкны сорамагыз инде.

Диләрә ханым, аңа күтәрелеп тә карамыйча, үтергеч бер салкын "әдәпсезлек" белән:

—Иркәм, сезнең өчен алынган яулык түгелдер ич ул, нигә тыгыласыз?—диде.

Кыз кайтарып җавап бирә алмады. Ул әле болай, гүя үтеп барышлый

гына, кешенең бәгыренә кадап китүне күргәне юк иде. Ханым исә, берни булмагандай, шунда ук егетләргә сүз катты:

—Әйтегез инде менә сез, аның дуслары, егет кеше сүзендә торырга тиешме, түгелме?

Егетләр, җилкәләрен җыерып, икеләнеп кенә:

—Конечно, шулай инде ул,—диештеләр.—Сүздә тору кирәктер инде... Ну бит...

Ләкин ханым, артыгын тыңламыйча, тизрәк Хариска борылды:

—Ишеттегезме, Харис иптәш, дусларыгыз ни диләр? Чыгарыгыз яулыкны!

—Мин сезгә яулык вәгъдә итмәдем,—диде Харис, тәмам караңгыланып.

—Сез мин сораган әйберне бирергә булдыгыз!

—Сорагыз бүтән нәрсә.

Ханымның күзләре кысылды, усал карашы, энәләр шикелле, егеткә кадалды.

—Их сез!—диде ул.—Мин сезне чын егет дип торам, ә сез...—Ул, сүзен әйтеп бетермичә, җирәнгәндәй борынын җыерып, кулын гына селтәде.

Бу мәсхәрәләп кул селтәү ин авыр сүздән дә әшәкерәк тәэсир итте егеткә. Ул ихтыярсыздан артка тайпылып куйды, кинәт үтә бер гарьләнү белән: "Ни өчен әле мин үземне шушы курчактан бу кадәр хурлатып торам?"—дип уйлап алды һәм шул секундта ук эчке кесәсеннән ак кәгазьгә төргән яулыкны чыгарды да ханымның алдына ташлады:

—Мәгез!

Ханым егетнең бу бер генә сүзгә никадәр ачу-нәфрәт салып әйткәнлеген ачык сизде, әлбәттә, ләкин юри, гүя ныграк үртәргә теләгәндәй, балаларча кычкырып куйды:

—Менә, молодец!

Һәм яулыкны, кәгазеннән алып, сүтеп тә җибәрде. Яулык, нәкъ тавис койрыгыдай әллә ничә төрле төсләр уйнатып, аның кулында җилферди иде.

—Нинди матур! Нинди матур, ходаем!—дия иде ханым, гадәттән тыш сокланып.—Килешәме мина?

Ул яулыкны башына каплады, һәм чибәр яулык чынлап та аны бердән нурландырып җибәргәндәй итте. Барысы да бу минутта ханымның чәчләре өстендә йомшак кына яткан яулыкка аптырау-кызгану катыш чын соклану белән карап торалар иде. Харис, кире тартып алудан тыелып калуына ышанмыйча ахрысы, кисәк кенә торды да кызу-кызу атлап китеп тә барды.

—Нигә качасыз!—дип кычкырды ханым аның артыннан һәм тилерергә җитешеп көләргә тотынды.

Әллә ни булды аңа. Яулыкны әле башына каплады, әле муенына чолгады, әле иненә салды. Кулында болгап йөртте. Үзе көлде, очынды, тилерде... Ә бераздан япа-ялгыз калуын күрде: Харисның иптәшләре дә, үзлекләреннән юкка чыккандай, каядыр китеп беткәннәр иде.

Ханым кинәт аңлады: ул яшьләрне үзеннән качырган икән ләбаса! Тынып, аптырап калды ул, ничектер берьюлы шиңде дә төште. Бераз каранып торганнан соң, яулыкны бер почмагыннан тотып, әле генә бергә уйнаган тиңдәшләрен югалткан баладай, нәүмизләнеп, елыйсы килеп, палубаны акрын гына әйләнеп чыкты. Аннары, каютасына кереп, хәлсезләнеп, урынына утырды. Уйга калды... Менә ничек икән ул! Ят кеше икән ул аларга! Тиң күрмиләр икән алар аны! Ташладылар да киттеләр... Ни өчен? Шушы яулыкны ирексезләп алган өченме? Шаярды гына бит ул, шаярды гына! Кайтарып бирәчәк бит ул аны!

Диләрә ханым, кинәт урын өстенә капланып, тавышсыз гына калтыранып еларга тотынды... Аңа шаярырга да ярамый икән хәзер. Ул яшьлеген, ваемсыз, хәр яшьлеген югалткан икән инде!.. Нишләргә тиеш соң ул? Үзеннән егерме дүрт яшькә олы кешенең хатыны булгач, абыстай шикелле бөтенесеннән качарга, бәрәү белән дә уйнамаска-көлмәскә тиешмени инде ул? Нигә мондый вафасызлык? Нигә бу яшьләр шулкадәр каты йөрәкле,

бер дә кешенең хәленә керә белмиләр?

... Көнчелектән бу, көнчелектән! Алар аны үзләреннән рәхәтрәк яшәгән өчен яратмыйлар. Әйе, чибәр, таза булуы өчен, яхшы, матур киенүе өчен, ялгызы аерым каютада иркенләп баруы өчен ят күрәләр. Ә күңелендә аның нинди бушлык, ни җитми аңа—бу хакта белергә дә теләмиләр.

Шулай рәнжеп, елап ята торгач, ул изерәп йокыга талгандай булды.

Күпмедер вакыттан соң, берәү сак кына аның ишеген какты. Ханым сискәнеп башын күтәрде, өстәлдәге көзгесенә карап, тиз генә күзләрен сөртте, чәчен рәтләде. "Улмы икән әллә?"—дигән уй яшендәй күңеленнән узды һәм ниндидер бер өмет чаткысы йөрәгендә яңадан кабынгандай булды.Ашыгып, шактый дулкынланып ул:

—Керегез!—диде.

Ишек ачылды һәм Харисның иптәшләреннән әлеге шакмаклы күлмәк кигән егет килеп керде.

—Апа, борчыган өчен ачуланмагыз, мин бер йомыш белән генә,—диде ул, ишек төбендә тукталып.

—Узыгыз!—диде ханым, өмете сүнсә дә ачык чырай күрсәтергә тырышып.

Егет эчкәрәк узып урындыкка утырды һәм, сүзен нидән башларга белмәгәндәй, бераз тезләрен угалап торды. Ханым үзе башлап сорады:

—Йә, ни йомыш соң?

—Әлеге шул яулык турында инде,—диде егет, сер әйткәндәй тавышын акрынайтып.—Сез аны шулай да кире бирсәгез иде.

—Иптәшегез сезне үзе җибәрдеме?

—Юк, ул җибәрмәде. Без, үзара гына сөйләшеп, сездән сорарга булдык. Беләсезме, Харис бит ул яулыкны берәүгә бүләк итеп алып кайта иде. Сездән яшереп тору кирәкмәс: берәү дигәнебез аның яратып йөргән кызы була инде. Ә ул кыз яңарак кына каты авырудан терелгән икән. Менә ничек бит ул!.. Харис аның янына бер дә буш кул белән кайтырга теләмәгән иде, ә студент кешенең хәлен беләсез инде, кат-кат бүләк ала алмый ич ул... Аннары бу яулыкны табуына бик куанган да иде. Инде менә, уеннан уймак дигәндәй, ычкындырды да куйды! Ә сезгә ул яулыкның әллә ни кирәге юктыр, шәт? Ахыр чиктә без бергәләп сезгә берәр нәрсә...

Ханым егеткә сүзен әйтеп бетерергә бирмәде.

—Кемгә саныйсыз сез мине?—диде ул, ашыгып һәм гасабиланып.—неужели сез менә мине берәүнең кадерле нәрсәсен тартып алыр дип уйлыйсыз? Шаяру гына ич бу, шаяру гына, аңлыйсызмы шуны? Миңа бернәрсәгез дә кирәкми, бирәм, бирәм, яулыгыгызны да бирәм! Тик... ни өчен соң иптәшегез... Харис... үзе минем белән ачык кына сөйләшергә теләми? Ояламы, хурланамы, горурлыгына көч килер дип куркамы? Бер дә юкка лабаса! Менә сез әйтегез үзенә, килсен, мин үз кулым белән аңа бирермен.

Егет маңгаен ышкып алды.

—Менмәс ул!

—Ни өчен?

—Ялына торган егет түгел ул!

—Ходаем, ни өчен ялынырга? Миңа аның ялынуы кирәкми. Минем просто яулыкны үз кулым белән аңа бирәсем килә. Аннары... минем аның белән сөйләшәсем килә. Аңлыйсызмы? Безнең арада берниндидә үпкә, ачу калмасын иде. Сез шулай дип әйтегез дә: апаның, диегез, сиңа әйтәсе сүзе бар икән, диегез. Ярыймы?

—Ай-һай!—диде егет, башын чайкап.—Шикләнәм, килмәс. Яман хәтерен калдырдыгыз сез аның!

—Ни белән?—диде ханым, өзгәләнеп.

—Бик кадерле нәрсәсе белән уйнадыгыз ич!

—Юк, юк, дөрес түгел! Мин аңлатырмын, кирәксә гафу үтенермен, тик килсен генә!

—Ярый, әйтеп карармын!—диде егет сүлпән генә һәм теләр-теләмәс

кенә каютадан чыгып китте.

... Әмма Харис менмәде. Ханым, яулыкны әйбәт кенә төреп, күкрәгенә кыскан килеш, каютасыннан бер чыкты, бер керде, палубаны әллә ничә тапкыр әйләнде, ләкин һич юкка! Егетнең хәтта иптәшләреннән берәү дә янадан менмәде. Димәк, Харис үзе килмәү генә түгел, аларны да сорап йөрүдән катгый рәвештә тыйган булырга тиеш—шулай аңлады Диләрә ханым. Бу нәрсә аны гаять авыр хәлгә куйды, чөнки хәзер ул үзе дә алар янына төшә алмый иде инде. Төште исә, шул тәкәббер "малайлар" алдында үзен тулысынча гаепле дип санау булачак. Әмма гаеплемени соң ул?

Шулай ук бу яулыкны үзендә калдырырга да ярамый иде. Йә, нишләтергә тиеш ул аны? Иделгә ташларгамы?

... Җәйге озын көн акрынлап кына сүнде; ниһаять, төн булды, пароход халкы да тынды. Салонда, палубада утларны сүндерделәр. Тик борындагы мачта башында гына нурсыз ут караңгы бушлыкта ялгызы гына йөзеп баргандай күренә иде.

Диләрә ханым, әйләнеп-тулганып йөри-йөри тәмам арыгач һәм бөтен палубасында бер ялгызы торып калуын күргәч, ахырда каютасына керде... Керү белән, чишенмичә-нитмичә, койкасына утырган килеш кенә башын мендәргә куйды һәм шунда ук оеп та китте; күрәсең, аруы, йончуы бик житкән иде... Бу—хәлсезләнеп, минрәүләнеп, әмма җан сызлавын оныта алмыйча йоклау күпме дәвам иткәндер, менә бер заман ул пароходның селкенеп шыгырдавыннан һәм каяндыр түбәннән ишетелгән кешеләр тавышыннан уянып китте. Күзен ачты, башын калкытты, түбәндә ни барын аңларга тырышып, аз гына тыңлап торды, аннары кинәт нидер сизенеп, урыныннан сикереп торды да каютасыннан атылып чыкты. Яулыкны ул йоклаганда да кулыннан ычкындырмаган иде. Һәм, шуны күкрәгенә кыскан килеш, ашыгып пароходның дүртенче классына төште, ары-бире сугылып, теге яшьләрне эзләргә кереште. Ахырда таба алмагач, түбәнге сәндерәләрнең берсендә йоклап яткан баланың аяк очында йокымсырап утырган бер олы яшьтәге апайдан сорады:

—Апа, монда студентлар баралар иде. Өч егет, бер кыз... Шулар кайда?

—Сту... студиннар!—диде апа, тыела алмыйча исни башлап, һәм авызын учы белән каплады.—Кайсылар икән ул?

—Менә инде ни... берсе озын гына буйлы кара егет... берсенең өстендә шакмаклы күлмәк...

—Ә-ә!.. Аларны әйтәсез икән... Төштеләр шул алар, чибәрем.

—Төштеләр?—диде ханым, кисәк кенә апага омтылып.—Кайчан, кайда?

—Менә хәзер генә төшеп калдылар. Күрмәдегезмени? Әле яңа гына кузгалдык ич.

Диләрә ханым, шунда ук борылып, пароход ишегенә йөгерде. Ләкин киң ишектән ул караңгы судан башка берни дә күрмәде. Шуннан йөгереп югары менеп китте, чабып пароходның койрыгына барды... Менә, менә күп булса, йөз илле-ике йөз адымда гына сирәк утлары белән җемелдәп кечкенә пристань күренә. Әле ярга чыккан кешеләрне дә шәйләп булырлык... Диләрә ханым, нишләгәнен белештермичә, кулын күтәреп, ачынып бер кычкырды:

—Ха-а-рис!

Ләкин артык ашкынудан көчсез яңгыраган тавышы аның төнге бушлыкта бик тиз сүнде—йотылды, хәтта үзенә дә юньләп ишетелмәде. Бер мизгел ул, күзләрен йомып, баганадай катып торды, аннары кинәт кенә кулындагы яулыкны сүтте дә һавага, Идел өстенә, очырып җибәрде. Ефәк яулык, аның кулыннан ычкынуга, югары күтәрелде, бер талпынды, бер тибрәнде дә, караңгылык эчендә үзлегеннән эрегәндәй, юкка да чыкты...

Пристань инде еракта калды. Төн, берни юк, берни күренми. Тик ярдагы утлар гына, гүя Диләрә ханым йөрәгендә көйрәгән күмерләр төсле, аны үртәп, аны газаплап яналар иде...

# ШИГЪРИЯТ



## Рәдиф Гаташ

### СИНЕҢ АША—ҖАНКАВЕМНӘР ЭНДӘШӘ...

* * *

*Кереш газәл*

**Кайда ул ил? Илтә нинди юл?—Туран...**
**Баглымы шул илгә исмең, Гөлтуран?**

**Төрки ватан, Ана йорт—изге җирнең**
**Эзен күммәгән бит вакыт—ком, буран?**

**Тарих итеп, бактым синең күзләргә,—**
**Мәңгенең рух язуын кем укыган?**

**Чүлләр илен, гөлсәхра, җил хәтерен**
**Уятсын, диптер Хак сине бар кылган?!**

**Синең аша җанкавемнәр эндәшә:**
**Төркиләр! Сибелгән чәчәк-гөл сыман...**

**Чин-дивардан Әдрәнгәчә уйнаклый**
**Бабайлар даны, тузаны—үз томан!**

**Айнымас Иран—шөһрәтле Туранның**
**Горур ярлар калдырган илһамыннан.**

**Төрки гөлләр исен онытмас Гаташ—**
**Милли дөньям исмеңдә үк: Гөл... Туран!**

* * *

**Назларымнан качтың һаман, дидең:—Аһ,**
**Ярамый бит... Кит, аңлыймсың, бу—Гөнаһ...**

Читкә кудың—гел кабаланган кулны,
Иреннәргә дә адаштырдың юлны.

Аннан үзең үк сыендың кочакка...
(Күзләрең тулган күл иде шул чакта!)

Тагын нидәндер куркып син сискәндең:
—Нишлибез без... Бу гөнаһ бит, и Тәңрем!

... Ихтыярсыз бактым да Күк-һавага:
—Языкмыни,—дидем,—пакь хисем—ярга?
Йөзем каралт, әгәр булса бу—гөнаһ!

... Күзең—күзге: яна битем... Йөзем—ак!

## Борынгы җырларга яңа сүзләр

* * *

Сезнең тирәдә... козгыннар очадыр?
Безнең илләрдә йөрмәскә кушадыр?
Ак күгәрченемне күрмим күптәннән,
Су читендә суга сусап, үртәләм.

Ага чишмә—дәрте күпкә җыры күп;
Шунда, йөрәк, күз яше итеп моңың түк!
Хисемнән, күкрәп дөньяга, очындым,
Сизмәдем: кулымнан кошым очырдым.

Урамнарга сыймый ялгыз җан җыры—
Урманнарны урый, төннән ял сорый...
Ак бәхетемне, аһ, ятлардан алдырдым.
Хәсрәт-утта гомеремне яндырыйм...

Сөю, күгеңдә козгыннар очраса,
Юлың кисәр карчыгаң бар ләбаса?!
Алдырмагыз, кыюлар, кулдан ярны,—
Аермагыз ак күгәрченнән җанны!

* * *

*Синең җавап җырың*

Ә сезнең соң күңелдә нинди кошлар?—
Оя коргандыр ул "күл"гә аккошлар?—
Каңгылдап, яңгырап килә тавышлар!
Сезнең илләрдә тик аккош моңыдыр?
Башка кошларны оныткансыз булыр.

Оегансыздыр тере шул аклыкка.
Белегез, күңләвем түгел аккоштан,
Җаныма тансык—талпына сафлыкка!

**Берүк ак җан хәтерен калдырмагыз,**
**Каралмасын—сез күздән яздырмагыз!**

**Юлыкмасын пакьлек көнчел көчләргә,**
**Рәнҗеше төшмәсен күңел-күлләргә,**
**Ихлас дога белән багам сезләргә:**
**Илегезгә юл ник ачылмый һаман—**
**Аккош мамыгы кебек ак бураннан?!**

* * *

*Агыйделнең аръягында болыт тора.*
*Яңа ярлар иске ярны оныттыра.*

Борынгы җыру.

**Агыйделдә таралгандыр инде болыт?—**
**"Яңа яр" дип, имеш, иске ярны оныт...**

**Бездә әле көннәр аяз, матур тора.**
**Кемнәр кемне оныттырыр? Сагындыра...**

**"Ике күздән яшь китерә" кайсы ярның?**
**"Табак белән аш китерә—сыйлый җаның?**

**Кемгә синдә хәйләң—"ефәктән дә нечкә?"**
**Нигә бу җыр якын шулай бүген хискә?**

**... Кул изим дә аръяктагы болытларга,**
**Күпер сузыйм "иске яр"дан "яңа яр"га!**

**Мин аларны килештерер сүзләр табыйм...**
**Заманнарны заманнарга ничек ялгыйм?**

**... Гыйбрәтле җыр... ә мин менә—оныта алмыйм!**

* * *

*... Хәйран калам*
*Яшь имәннең бөгелгәненә.*

Керәшен җырыннан.

**Булырсың чын хәйран, очрый калсаң**
**Карт имәннең бөгелгәненә:**
**Каты нык ул имән—**
**Нидән башын игән?**

**Чал гашыйгың гаҗәпләнә үзенә, әй Яр,**
**Синең өчен өзелгәненә.**
**Гасыр кичкән имән—**
**Ябалдашын игән!**

**Калырсыңмы хәйран, колак салсаң**
**Шул имәннең җан авазына?**

Яңа язлар килгән—
Яшәргән чал имән.

Яшьлегеңдә татлы Сөю хисе, әй Яр,
Ник көчлерәк гомер азагында?!
Шуңадыр ир-имән
Авыр башын игән!

* * *

*Безнең жанкәйләрне сорасагыз,*
*Мамык калфак башында,*
*Үзе унжиде яшендә.*

Мишәр жыры.

Жаныем, чәчең чыннан дамы бөдрә?—
"Арасыннан жилме йөгерә?"
Нигә калфак юк чәчеңдә,
Шул унжиде яшеңдә?

Буйларыңмы кечкенә?—син "төш кенә!"
Жан матурлыгыңмы сөйдерә?
Ник калфагың юк башыңда
Жырга кергән яшеңдә?

Жаныем, чәчеңнәнме син юллар салган?
Күз тимәскәме ул таралган?
Нигә калфак юк чәчеңдә—
Чәч тузгыткан яшеңдә?

Чәчкәйләрең, күз-кашың, миңең белән
Шушы жырым өчен син яралган!
Ник калфагың юк башыңда,
Яр, унжиде яшеңдә?!

* * *

Куркытмыймы алда имтиханың, Яр?
(Очрашуны көттерү ихтималың бар!)

Тапшырырсың: ышанам мин акылыңа,
Сөйләрсең төрки дәүләтләр хакында.

Яд итәрсең олуг зат—хәкимнәрне,
Якларсың мәхәббәт колы ирләрне,—

Кыйммәтле, дип, алтыннан—сөю хисен
Олыларсың,—гүя пәйгамбәр исмен.

Мисал итеп халкыбыз сүз сәнгатен,
Мактарсың, беләм, шагыйрьләр өммәтен!

Ә сөйләсәң шунда син минем хакта,—
Багышлау укып үзеңнең китаптан?

Шагыйрьлеккә хәлфәң дә дәгъва итсә?
Юри сиңа гел кыен сорау бирсә?

Бармы чынлап "батыру" ихтималы?
... Без хисләрдә бирдек зур имтиханны!

Шуңа да, уртак горурлык хакына,
Бергә җавап тотыйк Ходай каршында!

* * *

Гүя лалә йөзендә тап-миңеңне
"Сөю мөһере" итеп, Ходай бирдеме?—
Ташкын чәчләр япкан ап-ак муеныңны,—
Хәүва тәне дә гаурәт-пакь идеме?!

Лаләгә тиң йөзеңдә йолдыз-миңне
Күреп, күккә ашкан—шашкан тик минме?
Күпме яшь Адәм чын сурәт-Сүз эзләп,
Кичте дөньядан—тапмаган өченме?!

Яшь лалә-Яр сере—табышмак тап-миң!
Уза гомрем... мин дә бер җавап тапмыйм...
Эзләүләрдә элгәрләрдән уздырдым:
Миңъяр, дип, ник алмыйм тәхәллүс-ат мин?

Шуңа, бәлки, моң бар миңле йөзеңдә?
Якты моң катыш чал Гаташ сүзе дә:
Лалә йөзең, миңең, күзләрең үптем:
Гөл исле җырлар калсайде эземдә!

## Яңа газәлләр

* * *

Агыласыз, меңъеллыклары Җирнең!
Ашыгасыз—кушуымы Тәңренең?

Егерменче йөзнең ахрыннан карыйм,—
Таныйм Җан узган юлларны—кадерлим.

Мең газаплы, ләззәтле Хис тарихым!
Җирдәге һәр эзеңне мин хәтерлим:

Һәйкәлләрдән, Сөю, күпме харәбәң!—
Нинди чорлар аша уздың, Хәтер?—дим.—

Лаекмы соң яңа меңъеллыкка мин?
Гөнаһлардан тәүбә, хисап әзерлим...

Йолдызым сүнсә тиз, яңа дәвердә?
Мең саваплыдыр—хис табар әҗерен.

Сиңа сакларга Мәхәббәт маягын!—
Бул дәвамчым, бул догачым хәзер, дим.

Синең хакка Күккә ашсын соңгы Җыр,—
Күкрәгеңә салам башны, кадерлем!

* * *

Җырда ярый зарлану... бары—Ярдан!
Ул мең яхшы иргә, дөньяга зардан!

Сакла, Аллам, күз яшен кәсеп итеп,
Йомшаклыкны бер һөнәр кылганнардан!—

Кызгандырып теләнгән хәерчедәй,
Елап, шәхесен сатуга барганнан!

Мөнафикъ шагыйрьдә ул зар—җиңел дан-
Дәрәҗәгә астыртын омтылганнан.

... Яр өчен зар—яшь Тарих жанында:
Мирас алтын җырлар—шул елаулардан!

Синең дә, дустым, газәлең—ихлас яшь...
Аерырмы яр—бүгенге ялганнардан?

* * *

Юлбарыс Елының кыен язы бу!
Кырыс—гүя чал ирнең яшь яры бу!

... Ямьсезләнә ник күз алдымда дөнья?
Ахырзаман! Шуның шомлыклары бу!

Матур, дисәм, дус-ишләр... Күр: карт, төссез...
Мин—яшь, имеш... Хыял шуклыклары бу!

Нинди язмыш: Яз белән Көз—бергә без,
Табигатьнең ахры ялгыш пары бу?!

Әллә күкләр үзе шулай кушканмы?
Хисләрнең саф, илаһи, кайнары бу!

Быелгы сәер яздан җыр—сиңа, Яр:
Сүрән генә елмаеп, әйт:—Ярый бу...

* * *

Сиңа ошармы бу бүләк—ядкарем?
Ни кичерсәм, язган Көн-дәлекләрем...

Ниндидер бер сихри Нурың кагылгач
Җанда үскән яңа Гөл-дәлекләрем!

Янган минем яшьлекнең шәп Китабы!—
Көле—монда, Сиңа Көл-дәлекләрем?!

Күңел-дәлекләрдә яңа Бәхетемме?
Булыр мәллә буш Өмет-дәлекләрем?!

Бел, дәфтәрем—түгел антым көннәргә—
Ай, елларга!.. Ул—гомер-дәлекләрем!

* * *

Минсезниләр били синең җаныңны?
... Аякларың кочкан—шашкан чагымны

Искә аламсың? Минем, елап, тезләнгән,
Синең салкын, горур, таштай чагыңны?

Мин һаман да шул халәттә, күзләрем
Эзли күктән—шунда ашкан чагыңны:

Йолдыз идең, Ай идең син ул кичтә!—
Мин белмәм дә бугай башка чагыңны!

Туган көнем һәм "төш"ем ахры, димме:
—Йә, җиргә төш!—дип, "уяткан" чагыңны?!

* * *

Быел сүзен дөнья бик кырыс әйтте:
—Бала булма!—диде ул,—дөрес әйтте:

Икейөзле күзгә карап алдаса,
Чынын гүя, бәреп, туры дус әйтте.

Караштанмы аңлап арган җанымны,
Назлы бер сүз—яз карашлы Кыз әйтте.

... Синнән гайре бар да—үгет йә киңәш,
Сабак бирде сабыйга—дәрес әйтте:

—Башың җуйма, сөеп бу яшьтә, Гаташ!
—Зөлфәт—үлмәс!—диде,—Мөдәррис әйтте.

* * *

Газәлләргә тиңсез "азык"—гүзәлләр!
(Сөймәү—үзе, шиксез, язык гүзәлләр!)

Күпме жырга—безгәчә һәм бездән соң!—
Гомер биргән, күпмесен Сез—өзгәннәр...

Гашыйк жаннар, бөек ирләр—ярлыкап,
Сөйгәч, холык-фигълегезгә түзгәннәр!

Үзгәртергә мөмкинмени Хәуваны?—
Алар Адәм васыятьләрен белгәннәр.

Ә ничек бар, шулай Сезне яраткан
Шагыйрь кадерен белгәнме сез, дилбәрләр?!

Зәукы өчен, уйнап, жаннарны кыйган
"Шаян"нар, чын гашыйктан тик көлгәннәр,

Сезнең онык бүген мине газаплый;
Бөекләрдән, бәлки, киңәш сүзләр бар:

—Нишләтсә дә гүзәл яшь Яр—бәхилләә...
Тик яшәсен гашыйк аһы—газәлләр!..

* * *

*Тәмамлау-мәдхия*

Тигезсез без! Үз-үземнән оялам:
Жырда да ахры, мин тиңең булалмам!

Сиңа ошармы ул? Нидер житми күк,
Сизәм, сурәтләр ачылып бетми күк.

Төзәтерсең, күреп бер көн хатасын:
Бүген мактаганнан ялгыш табарсың!

... Аксакалга бу шөбһә-шик ятмы соң—
Яшь гүзәлдә күрсә үз илһамчысын?

Ул—шагыйрә һәм, шиксез, өстен булса?
Гажәпмени каршылыклы хис туса?

... Ләйлә шигырь язганмы? Чүлләр дәшми,
Ул Мәжнүне газәлләрендә яши.

Булган бездә, кем, яр-шагыйрәләр дә:
Төркиләрдә тиңсез Надирәләр дә!

Шулар янында дип синең урының,
Алдан күрүе бу, бәлки, жырымның?!—

Киләчәгең белгәнгә ул оялган...
Бөек бул, яме?!
    Мин инде—булалмам...

*1998—1999*

## Чәчмә әсәрләр



**Әмирҗан Моталлапов**

# НИГЕЗ

ПОВЕСТЬ

1

Хисмәтулланың өй салу артыннан йөри башлавы авылдашлары тарафыннан сәеррәк кабул ителде. “Кара әле бу Хисмәтулланы, башлы-күзле булу хәстәренә кергәнче , өен яңарту ягын карый икән”—диде берәүләр. “Хатынының васыяте шулай булган”,—диде икенчеләре...

Өй салуның уен эш түгеллеген Хисмәтулла яхшы аңлый. Кесәңдә акча була торып та төзелеш материалларын табу, кайтарту бик мәшәкатьле шөгыль. “Өй салуның ние бар: мүклисе дә чутлыйсы”, имеш. Шулай җиңел генә булса икән ул...

Мәшәкать җиксендерми Хисмәтулланы. Бер караганда, авыртмас башка тимер таяк юллап йөрүнең бөтенләй кирәге дә юктыр кебек. Кем өчен дип тырышырга? Кызлары, малае башлы-күзле булганнар, үз фатирлары белән яшиләр. Авылга кайту ниятләре дә сизелми... Ә икенче яклап караганда... Үзең үлү белән, артыннан ук өең җимерелеп төшсә, бөтен ихатаң шундук юкка чыгачак, ата-баба нигезе корыячак. Үзеннән соң да милектә яңа өй калдырасы килде Хисмәтулланың. Асиясе дә яңа өй салырга кушып, васыять әйткән иде: “Үлгән артыннан үлеп булмый, тыштан ялтырап, эчтән калтырап торган өй белән яшәмә, кулыңда көч барда яңа куыш кору ягын кара, Хисмәтулла”,—диде аңа хатыны. Мәрхүмә нәрсәне күз алдында тоткандыр. Әллә балаларның кайсы да булса берсе кайтып тернәкләнер дип өмет иткәнме?

Бу ышаныч Хисмәтулланың үзендә дә бөтенләй үк юк түгел. Өйне салышырга, әлбәттә, малае Исхак, кияүләре Нәҗип белән Латиф кайтачак. Шуларга өметләнә ата. “Хәзер нигәдер, балалар авылны чит итәләр, ата-ана хакын санламыйлар, туган нигезне, туган туфракны нәсел тамыры беркә торган изге урын итеп карамыйлар. Элек балалар гел туган нигез тирәсендә тупланып яшәүне хуп күрә иделәр, бер-берсенә ярдәмләшеп көн кичерделәр. Ә хәзер авылда гаиләсе чәчелмәгән бер генә өй дә юк”,—дип уйлана Хисмәтулла еш кына. Алар үскән чорда һәр сүз, һәр җөмлә гомергә хәтердә уелып кала иде. Хәзер дә өйрәтәләр, өндиләр. Телевизордан, радиодан күпме сөйлиләр, газеталар яза! Барыбер тәэсире юк: таш стенага борчак аткандай гына. Ни өчен алай? Ишле бала үстереп тә ата-ана картлык көнендә ни өчен япа-ялгыз, ташландык бер ятим

булып кала? Беребез дә балаларыбызны юньсезлеккә өйрәтмибез ләбаса! Шушы сорауларга Хисмәтулла күп еллардан бирле җавап эзли, таба гына алмый.

Иркен өйдә ятим булып, бер үзе утырганын искә төшереп, ул авыр сулап куйды, үзенә үзе кызганыч тоелды, күнеле тулды. Карчыгы Асия исән чакта, балалар турында ул кадәр үк уйланганнары юк иде. Искә алдылар алуын, тик юксынудан түгел, сагынып кына. "Үз бәхетләре үзләре белән йөрсен, сихәт яшәсеннәр",—диләр иде. Балалар үз көннәрен үзләре күреп яшәсәләр, ата белән анага аннан да зуррак бәхет юктыр сыман тоелды. Хисмәтулла күнеленнән үзен хатынына караганда иртәрәк үләрдәй итеп исәпләп йөрде. Гадәттә, хатыннарга гомер күбрәк бирелә бит.

Хисмәтулла хәзер ялгызлык турында еш искә төшерә башлады, киләчәген күз алдына китерергә тырышты. Җан биргәндә кем күзенә карар ул? Авызына су салып, баш очында кем торыр?.. Кабат өйләнгән тәкъдирдә, яшь хатын аңа иптәш булыр булуын. Әмма милек, ата-баба нигезе кемгә калыр? Тәмам корырмы? Балаларның янәшә яшәүләре менә ни өчен кирәк ул!

Их, балалар! Нигә бәхетегезне читтән юллыйсыз сез? Шәһәрдә генә тотыла торган канатлы кош түгел бит ул! Барыгыз да китеп барсагыз, авылда кем калыр? Аның киләчәге турында кем кайгыртыр? Икмәк үстерергә дә, ит, сөт җитештерергә дә кешеләр кирәк. Авыл үлсә, шәһәр дә юкка чыгачак бит...

Хисмәтулла дөньяның гел болай бармасына, авылларда да кешеләрнең ныгып яши башлар көн килүенә ышана, тик ул андый заманаларның кайчан килеп җитәсен генә гоманлый алмый. Авылдагы хәзерге авырлык-ның бөтен сәбәпчесе итеп Хисмәтулла яшь-җилкенчәкләрнең китүен саный. Эшче кул калмый, урып-җыю чорына шәһәрләрдән кешеләр чакырып кына икмәкне җыеп бетереп булмый. Икмәктә генә мени әле хикмәт, фермасында эшләргә дә кеше юк. Бер эшче авырса, аның сыеры көннәр буе савылмый. Культура юкка яшьләр китә, диләр. Аларсыз нинди культура булсын? Клубка картлар йөрмәс бит.

Аның балалары нигә китте соң әле?.. Хисмәтулланың үзенә калганда, балаларын кагын-сугын китермичә, ач-ялангач итмичә үстергән кебек. Белем алдыртырга да тырышты. Дөрес, олы кызы Халисә укуга бик үк хирыс түгел иде. 10 классны бетерү белән, Казанга китеп, тегү фабрикасына урнашты, кияүгә чыкты. Ире Нәҗип белән ике бала үстерәләр. Фатирлары менә дигән, кияү төшеп калганнардан түгел. Башта бер түрәнең шоферы иде, шул чакта иркен фатирга күчеп калды—хуҗасыныкына чыкты. Хәзер Нәҗип зур бер автохуҗалыкта баш механик. Үзенең әйтүенә караганда, дәрәҗәле, абруйлы кеше булган инде.

Исхак укыды. Тырышлыгы да, көнчеллеге дә бар иде. Максатына ирешергә омтыла торган булып үсте. Андагы бу сыйфатларны сизенеп, Хисмәтулла шөлләштерә дә башлаган иде. "Көнчеллек кайчагында комсызлыкка да китерә, үз башына үзе җитмәсә ярар иде",—дип хәвефләнде, улын кисәтә-кисәтә килде. Исхак, институт бетереп, инженер булды. Әйбәт кенә эшли. Үзен яраталар да икән. Моның өчен Хисмәтулла бик шат. Баласын мактаганны кем яратмый!

Төпчек кыз Илсөяр, иркәрәк үссә дә, бөтенесеннән дә арттырып җибәрде. Сәләтле булып чыкты, җиңел укыды, университет тәмамлады, аспирантура бетерде. Илсөяр өчен Хисмәтулланың күңеле һәрвакыт тыныч иде. Хәзер ул ире Латиф белән бер институтта эшли. Тик балалары гына бераү. "Икенең берсе бар, бернең ние бар",—дип элек юкка гына әйтмәгәннәр, тагын бер бала булса да кирәк иде",—дип фикер йөртә бу хакта Хисмәтулла. Үзләре дә өчне генә үстерделәр. Әгәр күбрәк булсалар, бәлки берәрсе авылда да калган булыр иде...

* * *

Балалар авылга сирәк кайттылар. Алар күзгә күренгән саен, Хисмәтулла:

—Җәй айларында Агыйдел буйларында ял итү—үзе бер гомер,—дип ни чаклы гына тукымасын, кызлар, кияүләр Кара диңгез буен артыграк күрде. Исхак җәй айларында ял бирмәүләренә зарланды, кайтмау сәбәбен шуңа сылтады. Аналарын җирләгәч, бөтенләй сирәкләделәр. Мәрхүмәнең җидесен үткәргәннән соң, Халисә генә урап китте. Берүзе кайтты, анасының әйберләрен барлады. Кайсын алып китте. Алсын. Бирсен дә тарсынган юк. Вак-төяге генә түгел, дөньясы да балаларга каласы.

Китәр алдыннан Халисә атасының тел төбен тартып карады:

—Гел ялгызың гына яши алмассың бит. Киләчәгең хакында ничек уйлыйсың соң?—дип кызыксынды ул.

—Әлегә үзем генә яшим. Җәйгә балаларны кайтарыштырырсыз. Пенсиягә чыккач, өйдә күбрәк ятарга туры килер. Бергәләп көн үткәрербез,—дип җавап бирде Хисмәтулла кызына.

—Әллә үзебезгә генә киләсеңме?—дип кызыксынды Халисә.

—Юк. Көч-куәт барда аерым торуым хәерледер. Ник сезгә мәшәкать тудырырга? Үз көнемне үзем күрә алам бит,—дип күңелдәгесен әйтеп салды Хисмәтулла.

—Бер үзең өчен мал асрап, ир башың белән сыер савып, суга барып, кер юып яшәрсеңме?

—Авылда малсыз яшәүнең мәгънәсе юк. Беләсең килсә, яшәүнең бөтен кызыгы мал белән көн итүдә. Хайван караудан бер дә тарсынган юк. Сыер саву да, суга бару да берни тормый. Күршеләр дә ярдәм итәләр,—диде әтисе, соңгы сүзләренә аеруча басым ясыйсы килеп.—Әүхәдинең хатыны да, килене дә булышырга гына торалар.

—Хатын табуда да исәбең юк түгелдер әле?—дип үз алдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды Халисә, байтак кына тын торгач.

—Бу хакта уйланган юк. Башта икенче кайгы әле...

Хисмәтулланың өй салу артыннан йөрүе, әнкәсенең теләге шулай булуы турында сөйлисе килгән иде, кызының чырае сытылуын күреп, туктап калды.

—Шушы кадәр байлыкның башына җитәрсең инде,—диде Халисә, һәр сүзен теш арасыннан сыгып чыгаргандай сыкранып. Хисмәтулла, ни әйтергә белмичә, бер мәлгә телсез калды. Йөрәген ут өтеп алгандай булды, тамак төбенә төер утырды. Ачу катыш үпкәсе ничек кенә кабармасын, үзен тыйды, кулга алды. Санаулы гына көннәргә кайткан кызы белән әрепләшүне урынлыга күрмәде, көчсезлек галәмәте дип санады.

—Хафаланма, кызым, син тапкан байлык түгел,—диде ул, үзен тыныч тотарга тырышып.

—Синеке генә дә түгел, әнкәйнеке дә...

—Аның да өлеше бар.

—Бер хәерче шуларга хуҗа булыр әле!

—Курыкма, сиңа үзеңнеке тияр...

—Әллә кем балаларына яздырыр, безгә тәтемәс...

Хисмәтулла телен тешләде. Җанга яра салырдай сүзләр ишетү күңелле булмаса да, үзеннән яралган зат белән дөнья байлыгы өчен әрепләшеп тору матур түгел иде. Тәмам кәефе кырылды, онытыла башлаган кайгысы яңарды. Өзелеп-өзелеп сөеп өйләнешмәсәләр дә, күп еллар бергә торып, бер-беренә тәмам күнегешеп беткән, иң якын сердәшкә әйләнгән кешесен—Асиясен юксынды. "Ходай Тәгалә тигез гомер бирсен",—дип юкка гына тукымыйлар шул. Уйламаганда килгән ятимлек авыр икән...",—дип көрсенде Хисмәтулла күңеленнән. Иске өйне, бөтен мал-мөлкәте белән, бикләп кую кирәклегенә үз-үзен ышандырасы килде. Ана бер

нәрсә дә кирәкми. Бөтенесе балаларга булсын. Телиләр икән, хәзер үк кайтып керсеннәр, тора башласыннар... Кайтмыйлар икән, ул үлгәч бүлешерләр. Яна өйне дә очларлар...

Бер чөй кагарга көчләре кермәде, үзара тавыш-гауга чыгарып, адәм көлдермәсеннәр генә инде. Үзләренең балалары үсеп килә, ата-ана комсызлыгын күрә торып, аларның да шулай кыланмаулары ихтимал дип, кем иман китерә ала?

Хисмәтулла кызына карады. Халисә, аскы иренен тешләп, кызарып-бүртенеп, юлга чыгасы әйберләрен төйнәп йөри иде.

—Нигә ул кадәр кабаланасың? Иртәгә китәр идең,—диде Хисмәтулла, авыр тынлыкны бозып.

—Минем ирем, балаларым бар. Ялгыз башым гына түгел,—диде Халисә, күтәрелеп тә карамыйча. Тыныч кына әйтелгән сыман тоелса да, бу сүзләрне дә авыр кабул итте әтисе. Аның бакчасына кызы таш ыргыта кебек тоелды. Халисә белән бер төнгә дә каласы килми иде аның. Кайтуын көтеп алган иде, инде менә китүен дә ашыгып көтеп утыра. Ялгызы калса җиңеләеп китәр сыман.

Нилектән болай килеп чыкты соң әле бу? Бу чаклы комсызлык, кырыслык каян килә?

—Әткәй, мин киттем...

Хисмәтулла, йокыдан куркып уянгандай, сискәнеп китте.

——Вакыт җиттемени?.. Хәерле сәгатьтә. Тагын кайт. Бергәләп кайтыгыз... Балалар... кияү...

—Быелга булмас. Июньдә Сочига китәбез.

—Исән-имин ял итеп кайтыгыз. Бераз вакытыгыз калса, бәлки урап та китәрсез.

—Белмим, белмим... Дачада да эш күп...

Хисмәтулла кызын автобус тукталышына чаклы озатты. Алар барып җитүгә, автобус та килеп туктады. Халисә кереп утырды, артына борылып карамыйча да китеп барды.

Автобус, тузаннар уйнатып, борылмадан кереп югалганчы Хисмәтулла аның артыннан карап калды. Ул күздән язуга, йөрәгеннән кинәт нәрсәдер өзелеп төшкәндәй тоелды, күңелен ятимлек биләп алды... Яманмы-яхшымы, үз сөяге шул. Аның гадәтсезлеге өчен кемне гаеплисең инде? "Үзеңнең кемлегеңне беләсең килсә, балаңа кара",—дип юкка гына әйтмәгәннәр. Димәк, Халисә минем көзгем була...

Үзенә калганда, Хисмәтулла гомере буе хәерсез гамәл кылмады, берәүгә дә ярдәмен кызганмады. Анасына булышты, тәрбияләп, соңгы юлга озатты. Мәрхүмәнең гомере генә кыскарак булды, тормышлар бөтәя төшкәч кенә китеп барды. Әнкәсе исән булсын иде әле! Йөз ел карарга да риза булыр иде... Нигә аның балалары шундый теләк белән яшәмиләр? Хисмәтулла бу сорауга һич кенә дә җавап таба алмый. Кул астыннан ычкындырганы өчен үзенә дә үртәлә. Кызларының мәрхәмәтсезлегенә мәрхүмә хатынын да гаепләп куя. Авыл балаларын тартып алып, тәмам инкубатор чебешләренә әйләндереп бетергәне өчен шәһәрнең дә тетмәсен тетә...

Тик соң инде. Боларның бөтенесен үзгәртү өчен кабаттан яши башларга кирәк.

Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай,—

дип Хисмәтулла җыр юлларын шыңшып үз уйларына үзе җавап бирде дә ихата эченә атлады. Ишек алды уртасына басып, иске өйнең кыяфәтенә багып, уйга батты...

"Өй". Нигә шулай атаганнар? Өясе дә, өясе булгангамы? Мәшәкате күплелектән шулай аталганмы?

Бүрәнә өй салырга хәлдән килмәс. Финские ярап торыр. Бер җәйдә очына чыкса, икенчесендә кирпеч яки шифер белән тышлау хәстәренә

керер. Менә дигән, курчак кебек өй килеп чыгачак... Булачак өен күз алдына китергәч, ничектер җинелрәк булып китте, өй салырга булган омтылышы көчәйде Хисмәтулланың.

## 2

Хисмәтулла Талморза авылында туды. Алты яшен тутырып килгәндә әтисе мәрхүм булды. Анасы Мөхлисә, сугыш башлангач, Хисмәтулланы ияртеп туган авылы Иркәшкә кайтып яши башлады. Иркәш белән Талморза арасы ике чакрым гына. Авылда дүрт класс тәмамлаганнан соң, Хисмәтулла Талморза җидееллык мәктәбенә йөреп укыды, аны бетергәч, колхоз эшенә кереште. Сугыштан соңгы иң авыр чак иде. Авылда рәтле-башлы ирләр заты калмаган бу чорда Хисмәтуллалар классыннан алты малайның берьюлы эшкә тотынуы иртәдән алып кичкә кадәр хезмәттә кайнаган колхозчылар өчен байтак җиңеллек китерде. Хисмәтулланың үзенә генә бик җинелдән түгел иде. Кечкенә чактан күз атып, исәя төшкәч ярата башлаган, ә инде хәзер чын мәхәббәткә әверелгән, ялкынлы хисләре белән сөйгән кызы Айгөлсез генә нишләр?

Айгөл мәктәпне тәмамлагач, авылда каласы итмәде, Казан педагогия училищесына укырга китте. Хисмәтулла кызның укуы өчен, берьяктан, шатланса, хыянәт итүе мөмкинлеген уйлап, икенче яклап көенде. Укып чыккач: “Миңа колхозчы кирәкми”,—дисә, нишләрсең?

Анысы Хисмәтулланың да калышырга исәбе юк. Ул йә урта мәктәп, йә техникум тәмамларга ниятләнеп тора. Елга техникумында бик укыйсы килә. Төпләбрәк уйлый башладымы, аптырый да кала: бер һөнәр сайладымы, икенчесе кызганыч кала кебек. Җиденче класста укыганда кем булу турында инша язганда да төпле бер фикергә килә алмаган иде ул.

Хисмәтулла иң әйбәт укучылардан саналды. Тазалыкка да, кыяфәткә дә сөбханалла гына булып үсте. Чаңгы ярышларында, йөгерешеп узышуда алдынгылыкны бирмәде. Мәктәпне бетергәндә хәтәр буынлы гына егетләр белән бил алыша башлады. Авылда оста гармунчылардан иде. Клубта җырлап, биеп үсте. Шуңа микән, кайчагында музыка училещесына керергә дә хыялланып ала иде. Аны бу фикереннән сугышның ачысын-төчесен күргән Минтимер абзыйсы кире кайтарды. Сүз иярә сүз чыкканда, Хисмәтулла, әллә музыкант булыргамы, дигән уен белдергән иде, Минтимер кулын гына селтәде:

—Әгәр оркестрда уйный торган музыкант булсаң, торбаңны бакыртып, пүле астына керәчәксең,—диде ул.

—Сугыш бетте бит, Минтимер абзый...

—Соңгысы булыр дисеңмени?.. Син, энем, юкны сөйләмә инде! Шушы кадәр гәүдәң белән гармун уйнап тамак туйдырырсыңмыни? Әдәм көләр,—диде Минтимер, аның кәефен төшереп.

... Аннары Хисмәтулланың мавыккан кәсебе—китап уку иде. Үзе белән йөртә ул берәр китапны, аз гына вакыты чыктымы, укырга ябыша. Аулак өйләргә бардымы, аңа йә укыган китабын, йә әкият сөйләргә кушып зиңкетәләр. Артыгын кыстатмый ул, сөйли. Китапханәдәге яңа китапларны башкалардан алда укып, беренче булып сөйләү теләге торган саен өстенлек ала башлады. Мөкиббән китеп тыңлыйлар иде үзен. Әнкәсенең генә килешәсе килми, күп укып, Хисмәтулланың күзен бетерүеннән курка.

—Сукырайгач исеңә төшәр, әмма соң булыр,—ди торган иде.

Хисмәтулланың авылда калуын вакытлыга исәпләделәр. Аның гомер буена колхозда эшләп, шыгыр-шыгыр арбаларда утырып көн күрәчәгенә берәү дә ышанмады. Акылы авылга гына сыймый аның дип исәпләделәр.

Бөтен юрауларны кире кагып, Хисмәтулла колхозда эшләп йөрүен дәвам итте. Шулай кирәк иде. Өйләре бик искергән. Яңасын салу турында башка да китерәсе юк, сипләргә туры киләчәк. Ә өйне гамәлгә керткәч

Хисмәтулла үз юлын үзе карар.

Фәкыйрьлеккә тәмам күнеккән, заманның авырлыгын кичерергә өйрәнгән күнелгә җан өреп, бәхет елмайды—Хисмәтуллалар заемга акча оттылар. Соңгы елларда якын-тирәдә чыккан күләмле отышларның берсе иде бу. Бүтәннәргә караганда, үзләре ныграк гаҗәпләнде: акча акчаны ярата, ничек ул фәкыйрь кесәгә керергә ният иткән? Маясыз ояга тавык та йомырка салмый бит.

Заем акчасына кеше тормаган иске бер өй сатып алдылар. Икедән берне чыгару исәбенә керделәр. Яшәү хәтәр ямьләнеп киткәндәй тоелды. Сугыштан соң беренче тапкыр һәр хезмәт көненә ике килодан артык икмәк алдылар. Хисмәтуллалар биш йөз хезмәт көне эшләгәннәр иде, ихатага кайткан ашлыкны кая куярга белми аптырап беттеләр.

—Кыш буе ипи ашап чыгачакбыз икән!—диде Хисмәтулла, бура өстендә өелеп торган икмәккә ишарәләп.

—Алла боерса, диген, дөньялар имин торсын,—диде Мөхлисә, улының шатлыгын уртаклашып. Аннан соң өстәде:—Гел ашауда гына бетмәс, улым, беразын сатып, синең өс-башыңны карарбыз. Егет булып життең...

—Быелга кирәкмәс, әнкәй, барыбер армиягә китәсе. Кайткач күз күрер,—дип җаваплады Хисмәтулла.

Ул белеп әйтте, шул көзне аны армиягә алдылар...

Хисмәтулланың китүенә бер ел тулганда, Айгөл авылга кайтып укыта башлады. Хат алышып тордылар, тик Айгөлнең Хисмәтуллага язган сүзләре акрынлап суына барды. Хисмәтулла нидер сизенде, хисләренең ни өчен туңа баруын сорап язды, ләкин Айгөл "бернинди үзгәреш юк" дигәннән арыны әйтергә теләмәде. Шик Хисмәтуллага тынгылык бирмәде. Авылда берсенең хәлен икенчесе белми калмас дигән ышаныч белән, ул күршесе Әүхәдигә язарга булды. Әүхәди җавап белән озаклатмады. Кыска гына хат кисәгендә Хисмәтулланы кызыксындырган сорауларга җавап биргән иде ул. "Хисмәтулла, Айгөлнең сиңа хыянәт итүенә инана алмадым. Кешеләр сөйләделәр, ә мин гайбәт, дип уйладым. Ләкин гайбәт булып чыкмады, Айгөл каладан авырга узып кайткан. "Иргә чыктым, озакламый кайтып алып китә",—дип сөйли икән дигән ым-шым бар, никадәр хактыр, иман китерә алмыйм",—дип язган иде Әүхәди.

Ике айдан Әүхәдинең икенче хаты килде. Ул Айгөлне ире алып китүе турында хәбәр иткән. Үзенең дә озакламый армиягә алыначагын язган...

* * *

Хисмәтулла өч ел армиядә булды, җиде ел шахтада эшләде. Армиядән кайтып, әнкәсен җирләп килгән иде ул. Хәзер аны авылга тартырлык көч калмады. Әйбәт эшләде, күп акча алды, макталды. Тулай торакта яшәде. Ләкин күнеле шәһәргә утыра алмады. Еллар үткән саен Хисмәтулла биредә озакка кала алмасын аңлады. Яшь болай да бара. Шуңа күрә ул туган нигезгә кайтып төпләнү чарасына керде.

Кайтты. Озакка сузмыйча, Асия исемле кызга өйләнде. Асия ятим үскән. Техникум тәмамлагач бирегә килеп, китапханәче булып эшли иде. Күңелле генә яшәп киттеләр. Бер елдан кызлары Халисә туды. Өйгә тагын ямь керде, нур өстәлде. Ике елдан уллары Исхак дөньяга килде, Хисмәтулланың күңеле утырды, хыялы тамыр җибәргәндәй тоелды. Ни әйтсәң дә нәселне дәвам иттерүче, нигезгә хуҗа булып калучы бар.

Илсөярне Асия авырлык белән тапты. Врачлар аңа яңадан бала табарга киңәш итмәде, тормышын кыл өстенә куячагын кисәттеләр. Дөресе шул булгандыр: Асия какшап калды, сәламәтлеккә туймады. Хисмәтулла колхозда бирелеп эшләде, өйдәге хезмәтнең дә зур өлеше аның җилкәсенә төште. Зарланмады, сыкранмады, язмышына тигән өлеш

сыман кабул итеп, Асиясенә хөрмәт күрсәтеп яши бирде.

Утыз ел бергә, тату яшәделәр. Балалар үсеп, таралышып бетте. Икәүдән-икәү торып калдылар. Еллар үткәч, Асия көрсенеп әйтеп алды:

—Тагын берне табасы калган икән. Бәлки, үзем дә сихәтләнеп киткән булыр идем, картлык көнебездә үзебезгә иптәш тә калыр иде,—диде.

—Сөйләп торасың, карчык, дүртне түгел, ачуым килмәгәе, кырыкны тапсаң да калмаслар иде. Чоры икенче бит хәзер. Авылны кешеләре-ние белән талап бетерделәр. Барыр җире булмаганнар, кулларыннан эш килмәгәннәр генә калды... Менә шулай, карчык, безнең дә кырыгы булса кырыгы олагып бетәр иде,—диде Хисмәтулла, аптыраган кыяфәт белән.— Хәер, оҗмахны ташлап кем тәмугка керә? Авылда рәхәт булса, күз күрмәгән җирләрдән бәхет эзләп йөрерләр иде микән? Ай-һай...

Төрлесен уйлый Хисмәтулла. Ул җирләрне кешеләргә өләшеп бирү турындагы бәхәсләргә дә каршы. Төптән үк түгел-түгелен. Анысы, уйламыйрак эшлиләр кебек. Өйне аскы нигезеннән сүтәләр сыман тоела аңа. Үзенә калса, ул башта эре колхозларны ваклап, элеккеге хәленә кайтарып бетерер иде, ягъни һәрбер авылны аерым бер хуҗалык итәргә кирәк. Шулай эшләгәндә, авылның зурлыгына карап, эре һәм вак колхозлар барлыкка килер. Эшләп карасыннар: кайсысы хикмәт кыра алыр? Хисмәтулла уйлавынча, вак колхозлар алдырып китәргә охшый. Чөнки алар сугыш елларында да авылны туйдырып тордылар. Фронтны да икмәк белән тәэмин иттеләр. Әгәр алай да хикмәт чыкмый икән, җирләрне бүлгәләргә дә ярый. Колхозларны эреләндерәбез, дип, егерме авылны юкка чыгардылар. Җир биреп, теләгән кешеләрне нигә шул авылларга күчереп утыртмаска? Авыллар кире аякка басар иде.

Бу хакта ул күптән түгел колхозның гомуми җыелышында да сөйләп карады. "Дөрес! Дөрес!"—дип хуплап тыңладылар, тик эш шуның белән бетте. Районнан килгән вәкил аңа сорау да бирде әле:

—Син, Хисмәтулла абый, бәлки яңадан МТСларга да кайтырга исәп тотасыңдыр? Артка таба тәгәрәү була түгелме соң?

Хисмәтулланың бирешергә исәбе юк иде:

—Авыл хуҗалыгын күтәрәбез, дип ел саен дөнья буып кычкырып, карарлар чыгарып, нәрсә кырдык соң? Файдалы икән, артка карау да зыян итмәс. Әгәр техника МТСта туплана икән, бу файдага гына булачак. Аны колхозлар кирәк чаклы гына, хаҗәтендә генә алып торачаклар. Файдаланган өчен акчаларын күчереп барырлар. Ичмасам, техникага бер хуҗа булыр, үзе карар, үзе төзәтер. Колхозлар запас частьлар юллап вакыт әрәм итмәсләр, акча тотмаслар. Аннары кечкенә авылларга дистәләгән трактор, автомашина нигә кирәк? Дөньяга сыймастай зур К-700 тракторлары, "Дон-1500" комбайннары, КамАЗ кебек автомобильләр нигә? Районда бер урынга җыйналсын алар, кирәге чыккач алып торырлар...—Хисмәтулла кызып китте. Бу турыда бәхәсләшергә сүзләре җитәрлек иде.

Килгән вәкил, буш фәлсәфә сата дип уйлапмы, аны бүлдерде:

—Өстә утырганнар синнән-миннән әйбәтрәк beләләр. Безнең катыш кирәкми аларга, Хисмәтулла абый,—диде ул, юк сүз сөйлисең дигән кебек, читкә карап.

—Утыруын утыралар да, икмәкле җирдә яшәп, чит илдән килгән ипине ашау бер дә егетлек түгел бит,—диде Хисмәтулла янә кызып.

Залдан: "Дөрес! Дөрес!" дигән хуплау авазлары ишетелде. Вәкил дә аның белән килеште бугай, аптыраган кыяфәт белән җилкәләрен җыерып, залга күз салды да, бу сүз миңа кагылмый, дигәндәй янында утырган колхоз рәисе белән сөйләшеп алды...

* * *

Хатыны үлгәнче зур хыяллар белән яшәде Хисмәтулла. Исхакны да авылга кайтарып, үзләренә бер аерым җир участогы алуда да исәбе

юк түгел иде. Хыяллары турында хатынына да сөйләп караган иде, Асиясе исә бөтенләй өмет өзгән булып чыкты.

—Юкны сөйләмә, карт, авылны ташлап, яшьләр һаман кача торганда андый хәл булыр микән? Үзеннең көченә ышансаң гына инде,—диде ул, иренең планнарын бөтенләй үк кагып бетермичә. Аннары әйтеп куйды:— Ул көннәрне мин күрәлмәм инде...

—Шыгырдык агач шыгырдап утыра, ә тазасы шартлап сына,—диде Хисмәтулла, хатынының шомлы уйларын куарга теләп.

—Юк шул инде, картым, шыгырдарга да рәт кирәк, миндә анысы да бетеп бара. Үз хәлемне үзем беләм мин...

—Йә, йә, күпме хезмәт куеп, рәхәтләнеп ял да итмәгәч, ун ел булса да пенсия акчасы ашамыйча китеп баралармыни? Югыйсә, бу дөньяга килүнең ни хаҗәте бар!

—Шулайдыр да. Нишлисең...

Бу сөйләшү Хисмәтулланың күнеленә тирән уелып калды. Хатыны алдында үлем хакында янадан сүз кузгатмаска тырышты. Асиясенең хәлен үзе дә яхшы аңлый, көннәре санаулыга калып бара, ахры...

Һәм ул көн озак көттермәде. Алмагачлар чәчәк атканда, Асия якты дөнья белән хушлашты. Хисмәтулла иң якын кешесен югалтты, олыгайган көнендә ятим калды...

## 3

Өй салу мәшәкатенең тиз арада хәл ителүенә гаҗәпләнеп, күнеле кырланудан Хисмәтулла шөкерана кылып куйды. Тегесен-монысын юнәтә алмыйча, байтак чабуларга туры килер сыман тоелган иде, бәхетенә, бөтенесе дә җинел аткарылды. Өй алу өчен чиратка басу уе белән район үзәгенә барган иде, "Станциягә кайтканы бар, тизрәк барып ал",—диделәр.

Авылга кайту белән, колхоз рәисе Мөхәммәтнур янына килде.

—Картая төшкән кешенең өй артыннан йөрүе гаҗәептер дә. Энем, мин шундый уй белән чабулый башладым бит әле. Кәчәү ягына чыгып, такта өйлек алып кайту өчен машина кирәк иде,—диде Хисмәтулла.

—Өй дисең инде алайса?—дип кабатлап сорады рәис.

—Шулайрак иде...

—Изге теләк. Тик нигә мәшәкатьләнәсең соң? Колхоз көче белән салып бирер идек.

—Миннән башка да мохтаҗлар җитәрлек. Үзем пычранып карыйм әле. Әлегә рәт барда диюем...

—Дәртең бар икән, тотын. Кулдан килгән ярдәмне кызганмабыз. Авылда яңа өй артуга кем каршы килер. Шулайдыр бит?

—Анысы да хак...

Мөхәммәтнур яныннан канатланып чыкты Хисмәтулла. Шоферларны эзләп тапты, китү вакытын килеште. Җинел башланган эш җинел тәгәлләнә икән. Икенче көнне Хисмәтулла ишек алдына өйнең бөтен кирәк-ярагы кайтарып аударылды. Хисмәтулла күтәреп куюның да җинел генә чыгарына өмет итте. Малае, ике кияве кайтса, жирнең тамырын актарырга була. Атна-ун көн эчендә яңа өй эчендә чәй эчеп утырырга да мөмкин булачак, Алла боерса... Күнеленнән балалары белән киңәште, ничегрәк эшләү турында фикерләште-серләште...

"Чакырырга кирәк, кайтсыннар, бер әткәләренә ярдәмнәрен тарсынмаслар әле",—дип, Хисмәтулла өч баласына да хат язды. Эченә сыймаган сөенечен җиткерү нияте белән дә язды. "Мин сезнең озаклап ятуыгызны өмет итмим. Берничә көндә эшне тәгәлләрбез. Бетми икән, булдыра алганча калыр, үзем түгәрәкләрмен",—дип язды ул һәм җавап көтә башлады...

Иң элек хәбәр Халисәдән килеп төште. "Әткәй, акылың чыга башлаган бугай, картаеп беткәч, кем өй салам, дип йөрсен инде! Ике гомер яшәргә

исәпли торгансыңдыр. Үзең дә тынмыйсың, башкаларга да тынгылык бирмисең... Мин кайта алмыйм. Киявенә әйтеп карармын. Ул әлегә командировкада. Белмим, аннан хикмәт чыгар микән? Кулына чүкеч алып, кадак та какканы юк бит аның. Үзебез дә кешегә кушып эшләтәбез..."—дип язган иде Халисә.

Хисмәтулла өметен өзмәде. "Исхак белән Латиф кияү кайтса да очлап чыгарбыз",—дигән ышанычта яшәде. Нәҗип кияүдән хикмәт чыкмасын чамалый иде ул. Кулы эш белмәгәннән түгел, тәкәбберлектән тотынасы килмәс аның. Эшен кешегә эшләтсә, үзен начальник дип хис итә башлый. Янәсе, ул кемнән ким! "Минем белем сезнеке чамасы булмаса да, берегездән дә ким яшәмим",—дип, Латиф белән Исхак алдында әтәчләнергә ярата.

Хисмәтулла олы киявен ярдәм көтеп түгел, бергә-бергә кайтсыннар, очрашсыннар, бераз булышып та китәрләр, дигән өмет белән чакырган иде. Әйтми калганда, Нәҗипнең үпкәләве дә ихтимал. Юри булса да сөйләнәчәк...

Әмма икенче хат та аңа сөенеч алып килмәде. Кызы Илсөяр белән кияве Латиф чит илгә эшкә китәргә җыеналар икән. "Җәй документ артыннан йөреп, китәргә әзерләнеп үтеп китәр инде",—дип язган кызы. Кайта алмауларына гафу үтенгән.

Кайта алмаулары кызганыч, әлбәттә, әмма ни хәл итәсең? Зур кешеләр бит. Чит ил хәтле чит илгә җибәрсеннәр әле! Уен эшмени?

Кем балалары? Хисмәтулланыкылар! Берара, Хисмәтулланы горурлык та биләп алды. Тик ярдәм итүче булмаса, горурлык белән генә өй салып булырмы?

Аның төп таянычы—Исхак бар! Төзүче-инженер. Тотынса—кулыннан килә, үзенә охшаган...

Исхак хаты күңелне тынычландыра төшсә дә, уйланырга да мәҗбүр итте. "Әткәй, мин больницада ятам. Сызланам. Бер дә алга түгел әле. Артыгын кырып ярдәм итә алмасам да, бераз сихәтләнгәч кайтырмын. Минсез эшкә керешми тор",—дип язган Исхак. "Хәзер врачлар үлгәнне дә терелтәләр, иншалла, улымны аякка бастырырлар әле. Шәһәр врачлары бит, галим кешеләр",—дип, Хисмәтулла үз-үзен тынычландырды...

* * *

Исхак якшәмбе көнне кайтып төште. Исәнлек-саулык алышып, ирләрчә күрештеләр. "Мин кайтмый торган арада нинди үзгәрешләр булды икән?"—дигән кебегрәк караш белән, Исхак өй эчен җентекләп карап чыкты. Үзе шактый бирешкән: ябыккан, йөзе аксыл.

—Хикмәт чыгарып булмаса да кайттым әле, әткәй...

—Кайтуың бик әйбәт, улым! Син инженер кеше, киңәш биреп торырсың,—диде Хисмәтулла, улының кәефен күтәрергә теләп. Моны Исхак та аңлады һәм әйтеп куйды:

—Төзү эшендә син, әткәй, минем киңәшкә мохтаҗ түгел анысы.

—Бер баш—әйбәт, ике баш—тагын да яхшырак, диләр. Борчылма, киңәш-табыш итешеп, бергә-бергә ничек тә очлап чыгарбыз әле,—дип, Хисмәтулла газ плитәсе тирәсендә кайнаша башлады. Иртән пешергән ашын җылытырга куеп, электр чәйнеген тоташтырды.—Өйдәгеләр ничек калды? Оланнар исән-саулармы?

—Әйбәт калдылар, әткәй, сәлам тапшырырга куштылар.

—Рәхмәт, рәхмәт... Оланнарның берәрсен алып кайтасы итмәгәнсең?

—Укулары бетмәде бит әле, әткәй.

—Әй хәерсез, мин аларның укый башлаганнарын да онытканмын... Мин күргәндә кечкенәсе менә моның чаклы гына иде бит,—дип, Хисмәтулла кулы белән идәннән ярты метр чамасы күтәреп күрсәтте.

—Үстеләр инде. Кечесе, Ирекне әйтәм, гел сиңа тарткан. Олы гәүдәле булмакчы.

—Мина тарткан дисең инде... Әй рәхмәт төшкерләре... Кемгә охшасалар да охшарлар, исән генә үссеннәр,—диде Хисмәтулла, онығының үзенә тартуына бик канәгать булып.—Ходай Тәгалә исәнлек бирсен!..

—Син Ходайны да искә ала башлагансың әле, әткәй!

—Әнкән үлгәч, телгә менде шул... Бәлки, ялгызлык галәмәтедер дә. Янында ышанычлы кешең булмагач, кемгә мөрәҗәгать итәсең?.. Әллә картлык тудырган өметсезлектән шулай?..

—Әлегә син сөбханалла гына, әткәй, бирешмисең, молодец!—диде Исхак, атасының кин җилкәләренә, күлмәк җиңеннән бүртеп торган мускулларына күз төшереп.

—Көч ягыннан Ходай кимсетмәде. Мин барда яшьләр бүрәнәнең нечкә очына тотыналар әле...

—Молодец!—диде Исхак баягы сүзен кабатлап.—Ичмасам, син чирнең нәрсә икәнен белмисең...

Әтисе Исхакның уфтануын үзенчә кабул итте. Аның йөзенә сынап карады. Әйе, улы нык бирешкән, яңаклары калкып калган. Хәлсезлеге гади күзгә дә бәрелеп тора. Бу килештән, ярдәм итәм, дигән ният белән нигә кайтты икән?

—Син сынаткансың, улым,—диде Хисмәтулла, эчендәгесен яшереп кала алмыйча.

—Әзрәк бар шул, әткәй.

—Духтырларның җүнлерәгенә күренергә кирәк. Калада белдекләләре күптер бит аларның...

—Күбен күп тә,—дип сузды Исхак.—Тик кайвакыт медицина да көчсез...

—Йә, йә, хәвефкә салма әле. Беренче сүзне чир-чордан башламыйк. Әнә, аш җылынды. Бүген күңелем кемнедер көтте. Шуна ашка итне дә күп салган идем. Рәхәтләнеп ашыйк әле,—дип, Хисмәтулла өстәл әзерли башлады. Исхак та кузгалды, кулын юып, сумкасыннан кучтәнәчләрен чыгарып, өстәлгә куйды. Җиләк-җимешләр янына бер шешә аракы утыртты.

—Менә очрашу хөрмәтенә булыр, дидем, кәефең килсә инде,—диде ул, шешәгә күрсәтеп.

—Рәхмәт. Алып кайтмасаң да ярар иде. Андый зәһәр еланнан өзелгән юк. Өй саласы кешенең хәлен үзең аңлыйсың. Кучтәнәч булгач, ни... азрак тотмый ярамас,—дип ризалыгын белдерде ата.

Кайту-күрешү хөрмәтенә берне җибәргәч, сүзсез генә берәр тәлинкә ашны бушатып куйдылар.

—Бик тәмле пешергәнсең, әткәй,—дип Исхак ашны ихлас мактады.

—Ит күп эләксә, аш тәмле була,—диде ата, мактау сүзләрен үз хезмәте итеп алмыйча. Шулай да улының тәмләп ашавына эчтән сөенде. "Ашаган малда, өмет бар, диләр, хәле алга табадыр",—дип канәгатьләнеп куйды ул.

—Мал тоту бик кыен түгелме?—дип кызыксынды Исхак, сүз иткә кагылгач.

—Рәхәт түгел-түгелен. Тик авылда торып, мал да тотмагач, яшәүнең ни хасияте бар?—дип җавап кайтарды Хисмәтулла.

—Колхоздан бераз ярдәм бармы соң?

—Кайсы елны ничек... Үзеннән артса, саламын бирә. Өч кибәннең берсе исәбеннән печән чабабыз.

—Син дә катнашасыңмы?

—Кая барасың? Китереп бирмиләр бит... Гаиләсе зурларга җинел анысы...

Исхакка атасы кызганыч булып китте. Кеше шушы кадәр газаплана-газаплана һаман яшәргә омтыла, тырыша. Мал асрамаса да, ачтан үлмәс иде. Юк. Кешедән калышырга теләми, авыр булса да эшли. Шәһәргә китү турында аңа әйтеп торасы да юк: ишетәсе дә килми.

Ашап туйдылар. Хисмәтулла, өстәлне җыештырып, савыт-саба юыштыра башлады. Исхак, диванга утырып, уйга чумды...

Әнкәсе үлгәнгә елдан артты, ә әткәләренең яңа хатын алу турында сүз кузгатканы юк. Нигә суза микән? Олыгая төшкәч, ялгызлык читен бит.

Бер хатында Исхак үз фикерен әйтеп язган иде инде. "Кулай кеше тапсаң, өйлән, әткәй, гел ялгыз тора алмассың",—дип киңәш бирде. Күрәсең, башында ул кайгысы юк, өй салу хыялы белән янып йөри. Начар фикер түгел, әлбәттә. Нигә элегрәк уйламады икән? Исхак шул турыда сорыйсы итте:

—Өй кайгысына яшьрәк чакта керәсе итмәгәнсең...

—Кая кермәгән! Әнкәңнең чире генә тоткарлады. Тынгысыз иде бит, мәрхүмә, чирлелеген белмичә, эшкә кул тыгып, үзенә көч китерер иде,—дип җавап бирде Хисмәтулла, авыр көрсенеп.—Ә үзенең өйне бик салдыртасы килде. "Кулыңнан килсә, ничек тә салырга тырыш, балалар да ярдәм итәр әле",—дип васыять әйтеп калдырды.

—Өй кирәк, кәнишне, искергән,—дип куйды Исхак, атасының сүзләренә рәтле-башлы җавап таба алмыйча.

—Әнкәң, мәрхүмә: "Бер акылларына килеп, әллә балалар да кайтып килерләр",—дигән өметтә иде,—диде Хисмәтулла, баштагы фикерен дәвам итеп.—Бик көтте ул сезне...

Хисмәтулла әллә үз фикерләрен җиткерде, әллә чынлап та хатыныныкы иде, әмма Исхак шуны аңлады: ата-аналары аларны көткән. Әткәсе хәзер дә өметен өзми, Исхакны бөтенләйгә кайтыр дип көтә. Ул бердәнбер малай, кызлар—оя ташлап очкан кошлар гына. Тик Исхакның шәһәр ташлап китүне башына китерә алганы юк.

—Бик авырлык белән урнашкач , каладан баш тартасы килми шул,—диде ул үз алдына сөйләнгәндәй.

Аның сүзен җөпләгәндәй, башын селекте дә, Хисмәтулла күңелен күптән кытыклап йөргән үпкә сүзләрен түгә башлады:

—Шәһәр кешесе—тегермән эте белән бер чамага әйләнде шул. Он ялаган эт яламыйча түзә алмый, диләр бит.

Исхак, башын селкеп, көлеп куйды:

—Әй-яй, каты бәрдерәсең, әткәй!

—Улым, балаларны ил буйлап чәчү өчен табып үстермисең. "Янымда яшәр, бергә-бергә көн күрербез",—дигән өмет ата-ананы бер вакытта да ташламый...

—Өй мәшәкатенә чумуың да шул омтылыштанмы?

—Хикмәт мәшәкатьтә түгел. Ата-баба нигезенә рәтле-башлы өй дә салып калдыра алмагач, яшәүнең ни мәгънәсе бар? Алла да, бәндә дә гафу итмәс. Икенче ягы да бар: яңа өй—акча ул. Сатырсыз. Бәлки, балалар белән җыйнаулашып кайтып, җәй айларын шушында үткәрерсез. Мин исән чакта минем янга балаларны җибәрерсез. Ичмасам, рәхәтләнеп татарча сөйләшергә өйрәнеп китәрләр. Югыйсә, үз телебезне дә онытып барасыздыр әле...

—Анысы хак, дөньясы урыска әйләнеп беткәч, татарчадан тәмам бизендек.

—Начар, начар,—дип сузды, Хисмәтулла,—нинди генә тәкъдирдә дә үз телеңне онытырга ярамый. Былтыр Хәким малае Шакир ике баласы, хатыны белән Чиләбедән кайтты. Безгә калганда, эт олаккан җирдә, чи урыс арасында яшиләр. Хатыны да хохлушка диләр әле. Менә шуларның балалары чата-кама килеп татарча сөйләшәләр, әй! Авылда туып-үскәннәрдер, дип торырсың. Хатынын да әйтәсе юк. Рәхәтләндереп безнеңчә сиптерә. Менә кем ул молодец! Шакирны әйтәм...

—Бездән рәт чыкмады инде,—дип көрсенде Исхак.

—Баш бетмәле катлаулы эш түгел ул. Теләк булмады, диген.

—Уйланмаганбыз инде, әткәй. Татар мәктәбен бетереп, үзем көч-хәл белән институтка кергәч, балаларым җәфа чикмәсен, урысча әйбәт белсеннәр дигән уй белән яшәлде.

—Барыбер үз телеңне белү кирәк. Кирәк кенә түгел, мәҗбүри!—диде ата.

—Казанда тел мәсьәләсендә сүз куера башлагач, без дә өйдә татарча ешрак сөйләшә башладык анысы. Соң булмаса инде...

—Изге эш беркайчан да сонармый, әйдә, уң булсың,—дип фатиха кылды ата.

Исхак ризалык белдереп башын какты. Берара тын торгач, әңгәмәнең башланган очына кайтты:

—Безнең өчен тырышу сиңа фарыз түгел инде, әткәй. Барчабызның үз дөньясы, гаиләсе бар. Син тир түгеп тапкан мөлкәткә кайсыбызның тамгысын сузасы килсен? Аша, эч, яшә! Үз байлыгың үзеңә житә икән—без бик шат.

Хисмәтулла жавапка ашыкмады. Халисәнең сүзләрен житкерәсе килгән иде дә, тыелды, ике туган арасында низаг куптарасы килмәде. Халисәнең комсыз кыланмышы, һәрхәлдә, Исхакның күңеленә боз утыртачак. Бозылышып, дошманлашып китүләре ихтимал. Аның уйларын укыгандай, апасын Исхак үзе искә төшерде:

—Халисә апа: "Әткәйгә өй салмаска кушып килдем. Тора-бара сүрелмәс микән әле",—дип сөйләнеп алган иде.

—Син нәрсә әйттең?

—Нәрсә әйтим? Әткәй үзе ничек тели, шулай эшләсен, дидем.

—Дөрес әйткәнсең,—дип хуплады аны Хисмәтулла.

—Иртәгә эшкә тотынабызмы?—дип кызыксынды Исхак.

—Юк, улым. Ял ит. Ике көннән тотынырбыз.

—Мин ял итү өчен кайтмадым...

—Зыян итмәс. Бик таушалганга охшыйсың. Монысы—бер. Икенчедән, атна башында эшкә керешмиләр. Шундый зур шөгыльгә тотынганда, халык йоласын саклыйк инде,—дип аңлатты ашыкмауның сәбәбен Хисмәтулла.

Исхакның хәлләр дөрестән дә мөшкел иде. Озак авырып ятты. Әткәсен борчыйсы килмәгәнгә, аңа барын да әйтеп язмады. Хастаханәдән дә ныгып чыга алмады. Авылга бик кайтасы килгәч, рәте юклыкны өйдәгеләргә дә сиздермәде, зарланмады. Аягын көч-хәл белән сөйрәп чыгып китсә дә, сер бирмәде. "Юлда бик талчыктырыр",—дип хафаланган иде, киресенчә, артык йончу сизмәде. "Авыл һавасы—дәва",—диләр, әллә шуның файдасы тиде, әллә атасы белән бер рәхәтләнеп сөйләшү тәнгә жиңеллек, жанга тынычлык бирде...

Диванның икесе ике башына утырып, уйга чумдылар. Исхак атасының авылда озак калмавына икеләнмичә, аның киләчәк язмышы турында уйлап утыра. Хатын алмаса, ни өчен ул монда яшәргә тиеш? Алып китәчәк ул аны. Хатыны Алсуның бер каршылыгы булмас... Тик фатир Исхакныкы да, Алсуныкы да түгел. Фатирга әби кеше хужа... Ул нәрсә әйтер? Ай-һай!.. Исхак мәсьәләгә икенче яклап якын килде. "Әткәй нык әле. Тагын кимендә 20-25 ел яшәячәк... Минем кулга карап торырга ризалашыр дисеңме? Һич юк! Дөрес фикер йөрткән ул, аңа өй салырга кирәк. Хатын алса да, алмаса да—кирәк"...

Хисмәтулла улына сокланып утырды. Зур кеше булды. Шунысы начар: янымда түгел. Аның кебек ир-егетләр бирелә дә типтереп яшиләр. Авылда каласы килми икән, район үзәгенә урнашыр иде. Ул чагында янда гына булачак. Үзләре дә кайта-килә йөрерләр, Хисмәтулла да теләгән чагында барып кайтыр иде...

"Бу хакта иркенләп сөйләшергә булыр әле",—дигән уй белән Хисмәтулла урыныннан күтәрелде. Иске эшләпәсен баш очына ыргытып, көтү каршыларга чыгып китте.

Исхак ялгызлыкны күтәрә алмый тышка чыкты, баскычка иркенләп, яшь чагындагыча жәелеп утырды. Каршы койма буендагы өянкеләр арасыннан саркып төшкән кичке кояш нурлары Исхакның йөзенә килеп бәрелде. Көн аяз, жил дә тынып калган. Тынлыкны ярып, сыер, сарык тавышлары ишетелә. Якында гына әтәч кычкырып жибәрде, мин дә калышмыйм дигән кебек, ачы тавыш белән ата каз каңгылдады. Авылның таныш, кичке симфониясе башланды, тирә-юньне сихри моң биләп алды. Көндәлек таныш бу күренеш авыл кичесенең игътибарын читләтеп үтә,

әмма Исхак кечкенәдән күнелгә якын бу тавышларны сагынып, хисләнеп тыңлады. Йөрәк, нииндидер рәхәтлек, сөенеч мизгеле үткәреп, ашкынып тибеп куйды. Күңел төбеннән шатлыгы бәреп чыгардай тоелды. Әмма бер минуттан боларның берсе дә калмады: ямансулык, ялгызлык хисләре белән алды. Исхакка үзеннән дә бәхетсез, аннан да ятим берәү дә юктыр кебек иде... Нигә атна-ун көн көтмәде соң әле ул? Балаларның укуы бетә, Алсуга да ял алырга була иде... Җыйнаулашып кайтсалар соң? Ничек күңелле булыр иде! Әткәйнең башы күккә тияр, балалары да авыл һавасы сулап, азрак булса да татарча сөйләшеп китәрләр иде.

Әткәй яңа өй салып бетергәч, җәйлеккә балаларны кайтарам! Ата-баба нигезен күреп, белеп, ана телләрендә сөйләшеп үссеннәр...

Үзе ни өчен авылдан бизде соң әле? Аның һөнәре белән авыл җирендә эшләп булмас идемени? Әлбәттә, була... "Шәһәр гади халык өчен түгел ул. Авылга сыймастай талантың ачылса яки галимлеккә омтылсаң гына шәһәргә авышу хәерле",—дигән фикердә тора аның әтисе. Исхак аның белән бик үк килешмәсә дә, бу сүзләрнең нигездә хак булуын таный. Хисмәтулла үз гомерендә шәһәр күргән, озак кына анда яшәгән кеше. Авыл тарткан аны. Бөтенесенә кул селтәп, тоткан да кайткан. Без дә авыл балалары, әмма беребез дә туган җиребездә түгел. Авылда калсак, яши алмас идекме? Ярый, Илсөяр галим. Аңа шәһәр кирәк, ди. Халисә апага ни калган? Миңа? Авылга инженерлар кирәкмимени?..

Әнкәсе исән чакта рәхәтләндереп бер торып киткән чаклары да булмады. Үлгәндә дә үз авызыннан бәхиллеген ишетмәделәр. Әткәсе үлгәндә дә шушы хәл кабатланмас дип кем әйтә алыр? Бакалы урамыннан Гыйльмениса түти ишек тупсасына башын салып үлгән, дип сөйлиләр. Өендә беркеме булмагач, әҗәл ачысы урыныннан кузгаткандыр, ярдәм сорап, кемгәдер эндәшмәкче булгандыр. Бусагадан уза алмаган... ялгызларның язмышы шундыйрак шул инде. Баш очында авызына су салыр кешең дә юк икән, моннан да гайре ятимлекнең булуы мөмкинмени? Югыйсә, читтә аның да кызы бар. Бер мәлне алып та киткән иде, Гыйльмениса түти сагынуга чыдый алмыйча кире кайткан...

Исхакның кинәт күкрәге кысып алды, эчтән кадады. Әллә йөрәк микән? Бер чир икенчесен китереп чыгара, булуы бик ихтимал. Врачлар авыр эш эшләмәскә, дулкынланмаска, борчылмаска кушканнар иде, күрәсең, юкка булмаган. Саф һавада йөрергә, күбрәк йөрергә киңәш иткәннәр иде.

Кайтуының бер сәбәбе шуның белән дә бәйләнгән иде. Авыл һавасы кирәк иде аңа. Болын чәчәкләренең, чыклы үләннәрнең хуш исләрен күкрәк тутырып сулыйсы килеп кайтты Исхак.

"Мескен әткәйгә генә рәхәтләнеп ярдәм итә алмам. Гомер буе бәхете эштән икән",—дип, Исхак тагын үртәлә башлады.

## 4

Күзен ачуга, Исхак үзенең кайдалыгын абайламыйчарак торды. Тик сабый чактан яхшы таныш, хәтергә уелмаслык булып сеңешкән сары түшәм, бүлтләч-бүлтләч чыгып торган стена бүрәнәләре тиз аякландырдылар. Сәгатькә күз салды, дүрт тулып кына килә иде әле. Әтисенең урыны буш. "Һаман таң тишеге белән тора икән,—дип уйлады, аның йокысызлыгын исенә төшереп. Хәер, авыл кешесе шунсыз булдыра да алмый. Җәй көне аеруча. "Йокы—үлемнең юлдашы",—дип, әткәй гомергә иртә торды. Яшь чактан ук йокысыз булган. Әнкәләре мәрхүмә дә: "Атагыз йокы кешесе түгел, йокы чүмәләләрен яратмый",—ди торган иде. Без генә иртә уянуның нәрсә икәнен белми үстек. Хәзер дә йокының кирәген бирәбез. Шәһәрнең ташы йоклата торгандыр",—дип уйланып ятты да Исхак, бүген ни өчен иртә уянганлыгына гаҗәпләнде. Иртәнге дүрт тирәсендә йокысының ачылганлыгын бер дә хәтерләми. Нәрсә уятты соң аны? Ачык тәрәзәдән кергән иртәнге салкынча саф һаваны, әллә ишек алдында сыер

мөгерәгән, сарык бәэлдәгән тавыш колагына кердеме?

Тәрәзә каршындагы койма өстендә зәңгәр койрыклы кызыл әтәч сузып-сузып кычкырып җибәргәч, Исхак уятучысының кем икәнлегенә төшенде. Күзен йомды, аның тагын кычкыруын көтеп ятты. Исхакның күңеленә моң йөгерде, шатлык хисе белән алды, тәне җиңеләеп китте. Әтәч, канатларын җилпеп, тагын бер кычкырды да җиргә очып төште. "Кыт-кыт" килеп, тавыкларны үз янына чакыра башлады...

Урам башында көтүченең:"Чы-га-ры-гыз!"—дип өздереп эндәшүе Исхакның йокысын тәмам качырды. Көтү чыкканын күрү өчен генә дә иртә уяну ярый, дигән фикер белән ул урыныннан кузгалды. Урам тулы шау-шу—үзе бер сихри моң, күңелле тамаша иде. Исхак урамга күз салды. Сыер-сарыкларның зур төркемен күреп, гаҗәпкә калды: халык хәзер ныклап торып мал асрауга керешкән икән. Ул кечкенә чакта бер сыер белән өч сарык тотучы сирәк иде. Итне дә, сөтне дә колхоз бирәчәк, авыл саен ашханә салыначак, халык шунда гына туеначак, дигән буш вәгъдәләр белән малларны бетерткәннәр иде ул чакта. Авыл шул чордан ныклап саега башлады. Кулыннан эш килгәннәр, һөнәр ияләре Чаллы, Кама, Ижау, Сарапул якларына күченделәр. Ун ел эчендә район бермә-бер кимеде. Авылларда ташландык өйләр, буш ихаталар күзгә күренеп артты.

Ул чорларны Исхак яхшы хәтерли, хәзергесен дә белә. Шуңа күрә әтисенең өй салу хәстәренә керүен генә дә тәгаен үк аңлап бетерә алмый. Зур мәшәкатьле эш, күп чыгым сорый. Шуларны белә торып, олыгая барган көнендә ничек моңа җөрьәт иткән. Хәерле булсын!..

Китмәгән тәкъдирдә, Исхак шушы йорт хуҗасына әверелә иде. Кем белә, бәлки, башка да чыгар иде... Юк шул, шәһәр кызына өйләнде. Үзе теләп шәһәр кешесе булды.

Авылдан килеп укучы егетләрнең байтагы шәһәрдә төпләнү җаен эзли башлады. Кайберләренә эш табылды, икенчеләренә таныш-белеш булышты, өченчеләре шәһәр кияүләре булып киттеләр. Исхак та, мин кемнән ким дигәндәй, шәһәр кызына өйләнде. Хатынының фатирына кереп калды. Шуңа күрә курсташларын очратканда элегрәк:

—Мин өйләнмәдем, миңа өйләнделәр, ярый әле үз фамилиям калды,—дип шаярта иде.

Үкенмәде ул өйләнүенә. Алсуны яратып алды. Яратышып кавыштылар, бер-берсен аңлап яшиләр. Ун ел гомер сизелми дә үтеп китте. Бер-беренә карата кәеф кырырлык, җан рәнҗетерлек сүз әйтешкәннәре юк. Каты бәрелү гадәте Исхакның холкында электән дә булмады, тора-бара бөтенләй йомшый калды. Әби өендә яшәп үз хокукыңны дәгъвалап булмый. Исхак моны беренче көннәрдән үк ачык аңлады. Алсуның әнисе Разия кырыс табигатьле. Холкын да, телен дә тыймый, әйтәсен әйтми кала алмый. Бик кимсенгән чаклары булды Исхакның. Тешен кысып түзде, вакытлыча гына, үзебезгә аерым фатир алгач, бу битәрләүләрдән, нахакка рәнҗетелүләрдән котылырмын, дигән ышаныч белән яшәде. "Йортка кергән—утка кергән",—дип, үз башына төшкән кеше әйткәндер. Кем булса да белеп, дөресен әйткән. Мин дә ут эчендә",—дип Исхак язмыш белән килеште.

Кем гаепле иде моңа?

... Студент халкы—чуар халык. Холык-фигыль генә түгел, яшьләр дә төрле. Урта мәктәпне генә тәмамлап, Исхак кебек беренче елында ук студент булганнар арасында армиядән кайтып укучылар да, завод-фабрикаларда, колхозларда эшләп килүчеләр дә җитәрлек иде. Алар үзләрен "картлар" дип йөрттеләр. Гәүдәгә калку, нык бәләкле булгангамы, Исхак гел алар арасына кереп йөрде. "Картлар" да аны чит итмәделәр, үзләренә тиң санадылар.

Исхак үзеннән алты яшькә өлкән Инсаф исемле студент белән дуслашып китте. Ничек уртак тел тапканнардыр, карасаң—бөтенләй капма-каршы характердагы кешеләр иде. Инсафта әрсезлек тә, кыюлык та, юха теллелек тә җитәрлек. "Инсаф сабынламыйча энә күзеннән үтә ала ,—дип,

сабакташлары еш шаярталар иде. Инсафның тел бистәлелеге кайчакта файда бирсә, күп вакытта зыяны тиде. Бер көнне йөзе жимерелеп кайтып керде. Трамвайда бер хатын-кызга төчеләнгәндә элдергәннәр үзенә. Янәшәдә ире булган икән. Хатынына Инсафның бәйләнгәнен күреп торган да, тукталышта төшкәч, Инсафның күз төбенә фонарь утырткан. Акыл утыртыр инде, бу йодрык сабак булыр, дигәннәр иде, кая ул! Алтыдагы—алтмышка, ди. Күз төбендәге күге беткәнче үк иске гадәтен куарга кереште. Аның белән бергә йөрергә кыенсына да башладылар. Шулай да Исхак белән уртак тел таптылар. Ләкин, Инсаф арбасына утырдым дип, Исхак аның жырын жырламады.

... Дүртенче курста укыган чак иде. Исхакның хәтеренә ноябрь башлары сыман кереп калган. Кич кырын Инсаф тулай торакка кайтып керде дә, Исхак янына килеп, хәрби сер сөйләгәндәй, пышылдап кына тезеп китте:

—Бушлай тамак туйдырасың киләме? Теләгең бар икән—ияртәм,—диде.

—Коммунизмга алып чыгасыңмыни?,—дип шаяртты Исхак.

—Әйе,—диде Инсаф, көлемсерәп.

—Син шунда китеп югаласыңмыни соң әле?

—Шунда инде.

—Йә, мин нигә кирәк?

—Башта тыңла, аннары төпченерсең,—диде Инсаф, сүзен бүлдерүгә ачуы килеп.

—Сөйлә, тыңлыйм инде...

—Артисткалар кебек чибәр бер кыз бар. Ияләнәсең килмиме?

—Чибәрләр синнән калмас.

—Кала шул. Мин аның әнисе белән танышып өлгердем. Сине кызы белән таныштырсам, икәүләп шул йортка йөрербезме дигән идем.

—Үзең генә куркасыңмыни?

—Хикмәт куркуда түгел, бер минутка да кызы өйдән чыкмый. Ә син аны киногa алып китәр идең...

Булачак визитның отышлы чыгачагына Исхакны ышандырды Инсаф. Иртәгәсен бергәләп барырга сүз куештылар...

Икенче көнне Исхак теләмичә генә иярде. Аягы тартмаган кебек кенә барды. Ул өйгә ияләшеренә һич өмете юк иде. Кызны да ошатмас сыман иде. Килеп кергәч, эреде дә төште, телсез калды, сөйләшергә сүз тапмады, үзен ничек тотарга белмичә аптырап бетте. Кыз чыннан да чибәр иде. Матурлыкта моның белән тиңләшергә башка кызлар дөньяда юктыр кебек тоелды Исхакка. Бу кадәр гүзәллеге белән ничек ялгызы гына соң әле ул? Шәһәр егетләре аны ничек күрмиләр?

Кыз Алсу исемле иде. Кыяфәте белән житлеккән күренсә дә яшь иде әле ул. Унынчы классны гына бетереп килә. Әнисенең сөйләвенә караганда, Алсу киногa, театрга чабарга яратмый, танцыларга да йөрми икән.

—Өйгә бәйләп куйган кебек минем кызым. Китапка багынып көннәр буе утыра. Ичмасам, Мәскәү артистлары концертына да барам, дими. Аптырарсың,—дип кызы белән таныштырды Разия апа.

Исхакның күңеле бераз тынычлангандай булды. Аңа нәкъ шушындый кыз кирәк. Тыйнак булсын, яшьтән үк егетләр алдында хихи-михи килеп үсмәсен. Тик Алсуның шәһәр кызы була торып, бу чаклы иплелегенә гажәпләнде. Чирле-мазар түгелме?

Алсу сау-таза, акыллы кыз иде. Әкияттәге чибәрләр кебек, үзенә язган кияүне көтеп кенә яткан ул. Алсу да Исхакны ошатты. Аның белән ипле кыланды, киногa барырга да ялындырмады. Шулай да артыгын кыланмады.

—Син—студент, мин әле укучы гына, миллионерлар түгел, сирәгрәк йөрештерик,—дия иде ул, Исхакның кая да булса барырга өндәвенә каршы.

Икесе дә бер чорда имтиханнар тапшырдылар. Исхак институтны, Алсу урта мәктәпне тәмамлады. Инсаф, укып бетергәч, бу йортка килү юлын онытып, үз якларына эшкә кайтып китте. Исхак, кайту юлын онытып шушы өйдә торып калды. Авыл малаеның кияү булып үз янында калуына

юлын онытып, үз якларына эшкә кайтып китте. Исхак, кайту юлын онытып шушы өйдә торып калды. Авыл малаеның кияү булып үз янында калуына Алсуның әнисе Разия дә канәгать иде. "Шәһәр ялкавы түгел, эшләп үскән малай, тормыш алып барырга тәвәккәл ,—дип нәтиҗә чыгарды. Кияүнең күренекле нәселдән түгеллеге бераз кәефен кырды кыруын, әмма уныңчыны гына бетергән кызына югары белемле инженер табылу да күпмедер дәрәҗәдә бәхет инде...

* * *

Өй салуның ние бар: чутлыйсы да мүклисе!

Эш тәмамлаганнан соң болай әйтергә була. Күмәк көч белән өйне тиз арада күтәреп куйгач, иңнән тау төшкәндәй тоелды. Гадәттә, шулай була: алда торган зур мәшәкать турында көн саен уйланып, аны олы бер шөгыльгә исәпләп, ничек кенә аткарып чыгылыр икән дип баш ватып, үзеңне-үзең куркытып бетерәсең. Бер дәртләнеп тотынгач, уйлаганча ук авырга туры килмичә, башкарыла да куя. Хисмәтулланың өе дә шулайрак килеп чыкты. Ярдәм иттеләр. Рәхмәт күршеләргә! Хисмәтулланың чордашы Әүхәди малае Әхмәт белән эш төгәлләнгәнче шушында булды. Түбәне дә ябыштылар, веранданы да пыялалап бетергәнче булыштылар. Мич чыгару гына Хисмәтулла белән Исхакка калды.

Исхак бөтенләй ярдәмем тимәс инде, дип хафаланган иде, әллә авыл һавасы сихәтлек бирде—күңеле күтәрелеп, үзен сәламәтләнеп киткәндәй тойды. Әткәсенең җиң сызганып, дәртләнеп йөрүе дә тәэсир иткәндер. Хисмәтулла егетләргә хас рәвешле җилкенеп эшләде, ару-талу белән дә исәпләшмәде. Шулай кыланмаса, бәлки, барып та чыкмас иде. Ун көн дигәндә яңа өй торырлык хәлгә килде.

Авылга кайтканнан бирле Исхак җиңеллек тоеп йөри."Күзле бүкән сыман кеше эшләгәнне генә карап торырмын микән?"—дигән шикләнүләре юкка чыкты да куйды. Кулыннан эш килүен күреп, сөенде, үзен башкалар белән тигез тоя башлады.

Исхак ике хакыйкатьнең хаклыгын тәгаенләде: беренчесе—авыл һавасы сихәтлеккә чыннан да файдалы; икенчедән, авылда олы эшләрне башкару җиңелрәк, кешеләрдә бер-беренә ярдәмчеллек көчле. Ярдәмчеллек, туганлык хисләре көчле. Ата-аналар балалары өчен янып-көеп йөри, ә балалар өлкәннәрнең күңелен күрү өчен тырыша. Күршеләре Әүхәди абыйсы белән Әхмәткә генә кара—ничек матур яшиләр. Исхакка хәтта уңайсыз да булып китте. Үзе өчен кыенсынды, чөнки әткәсе белән аларның ике арасында мөнәсәбәтләр боларныкына һич тә якын килә алмый. Берсеннән икенчесе шактый читләшкәннәр алар. Эчкерсез гәпләшсәләр дә, мөһим мәсьәләләрне уртага салып киңәшсәләр дә, аларның үзара мөнәсәбәтләре ата белән бала мөнәсәбәте үк түгел. Бергә яшәмәүдән күрде моның сәбәбен Исхак. Әхмәт авылга береккән, атасы юлын дәвам итә. Аларның фикерләре дә, планнары да уртак: күп эшне бергәләп башкаралар...

Миллионлы шәһәрдә яшәп кыргыйга әйләнеп беткәнмен бугай,—дип уйлады Исхак.—Урам тулы халык, кайбер көннәрне ичмасам ник бер танышны очратсаң! Өйгә кайтасың да фатир эченә бикләнәсең. Күршеләр белән аралыш та юк. Хәтта каршы як ишекнең кем фатиры икәнен дә еллар буе белми яшисең. Андый гадәт кермәгән"...

"Мин шәһәрдә калып нәрсә оттым да, Әхмәт авылда яшәп нәрсә оттырды? Югыйсә, Әхмәткә дә шәһәргә юллар ябык түгел иде. Армиядән соң комсомол путевкасы белән зур төзелешкә киткән иде. Вакыты тулгач, авылга кайткан. Өйләнеп, шәһәр кызын алып кайткан. Кайтуы өчен үкенү хатынының ай-һаенда да юк. "Безнең авыл, безнең урам",—дип, шушында туып-үскән кеше кебек сөйләшеп тора. Колхозда эшләп, читтән торып техникум тәмамлаган. Хәзер баш бухгалтер булып эшли. Әхмәт—механик. Ул армиягә киткәнче үк тракторга утырган иде. Шул һөнәрне ташлыйсы

—Вак-төяк йомышка йөрү өчен кирәк,—дип аңлатты Әхмәт, аны тотунын сәбәбен.—Әткәй шунын белән печән чабарга йөри, күрше-тирә авылларга да барып кайта. Машина ватылган чакларда запас часть юллап чабу өчен дә бик уңай...

Көнләшеп тә куйды Исхак. Ун еллап эшләп, машина түгел, мотоцикл алырлык та рәте юк. Тапкан акча төсле телевизор, кыйммәтле тун, алтын-көмеш бизәнү әйберләренә китеп бара. Фатир тутырып келәм алдылар.

—Кыйммәтле әйбер бервакытта да бәясен югалтмый. Акчаны алыштырдыларммы—кесәгезне тотып калырсыз,—дип өйрәтә әниләре. Алалар. Исхак авыз күтәреп, каршы бер сүз әйтә алмый. Баштарак үртәлә иде, тора-бара, теләсә нишләсеннәр, дип кул селтәде. Хәзер бу хакта уйлаганы да юк. Сәламәтлеге өчен борчыла ул. Сихәтлеккә туймасан, дөнья малы күзгә чалынмый.

Кичә Әхмәт белән сөйләшеп утырдылар. Тормыш, яшәеш хакында. Әхмәт олы планнар белән яши. Көзгә хатыны белән чит илгә сәяхәткә барып кайту нияте барлыгын әйтте. Киләсе язга умарта тергезергә чамалый. Ихатада эшләү өчен кечкенә трактор сатып алырга уйлап тора.

—Тотынганда үзем дә ясар идем, безнең механизатор егетләр бәләкәй тракторны үзләре жыя. Шулай да барлык тагылма коралы белән әзерен генә аласы килә,—дип аңлатты Әхмәт киләчәк планнарын. “Бәхетле кеше Әхмәт”,—дип уйлады Исхак аңа карап.

Ул үзе бәхетлеме сон? Әлегә чаклы анын мондый сорауны куйганы юк иде. Ул хәзерге дәрәжәсеннән артыгын өмет тә итми. Анын бөтен планнарын әбисе жимерә. Акча анын кулында. Хәтта Алсуга да эләкми.

—Акчаны ничек тотасын мин яхшы беләм. Сезнең кулга карап торсаң, ачка үләрсен,—дип, беренче хезмәт хакы алган көнне үк акчаны жыеп алды. Шуннан бирле Исхак акча алып кайту белән аны әбисенә тоттыра. Санап ала әле! Бераз кимрәк чыкса, йөзе сытыла. Үз кирәк-ярагына тоту өчен, үзе кебекләр белән шабашка эшләргә мәжбүр чаклары күп Исхакның. Ир кешегә моннан да гайре нинди түбәнлек булырга мөмкин? Эшләп алган акчаңны үзең тота алма инде! Әчеп-азып йөри торган кеше булса, бер хәл иде.

Кайвакытларда Исхакның, бөтенесенә кул селтәп, башын алып чыгып китәсе килә. Чаллы якларына китеп бару турында берничә тапкыр уйга керде. Балаларны ятим итәсе килмәү хисе тотып кала килде. Алсу белән ачыктан-ачык сөйләшеп, икенче фатирга күчү хәстәренә керергәме? Хикмәт чыкмас. Алсу әнисен ялгыз калдырып, беркая да кузгалмас. Анасының да ризалыгы булмас. Исхак бер үзе генә чыгып китә калганда, исләре дә китмәячәк. Ул моны яхшы белә. Бер мәлне аз гына телгә килеп алганда Разия:

—Сине бирәү дә бәйләп тотмый. Алсуга менә дигән, яп-яшь министр яки профессор табачакбыз,—диде. Алсу бу әрепләшүне ишетмәде. Өйдә юк иде. Ул кайткач, Исхак сөйлисе итмәде, оялды.

Исхак Алсуны югалтудан да курка. Ярата ул аны. Анын күзенә башка беркем дә күренми. Бик чибәр шул анын хатыны. Гел карап кына торырлык.

Исхакның күз алдына хатыны Алсу килеп басты. Ул ачык зәңгәр төстәге жиңелчә күлмәктән. Кызу-кызу атлап Исхакка таба килә. Кулларын селтәп, нәрсәдер сөйли. Жил анын күлмәген жилпи, чәчләрен ургытып туздыра... Нинди гүзәл анын Алсуы! Буй үстереп килгән ике бала анасы дип һич кенә дә әйтмәссең... Исхакны ачулана икән ул. Ачулы чакта да чибәр үзе. Алсу үпкәләп: “Безне нигә оныттың?”—ди. “Ник онытыйм, жаным, хәзер кайтам, иртәгә үк юлга чыгам!”—дип хыялында жавап бирә аңа Исхак...

Сабыйларча хисләргә бирелеп утыруына сәерсенеп, Исхак үзеннән-үзе көлеп куйды: “Безнең ярата белүебез әллә нәселдән килә микән? Әткәй дә яшь чагында бер кызны өзелеп яраткан, армиягә алынгач, кыз кияүгә чыккан, әткәй аны оныта алмыйча, күп еллар өйләнми йөргән, дип сөйлиләр. Мин дә Алсудан башымны ала алмам. Күпме генә аерым тордык, ә ул

сагындыра да башлады. Ничек ансыз түзмәк кирәк". Алсу да аны ярата. Үзе барда Исхакка әнисеннән сүз әйттермәскә тырыша. Ике ут арасында яна аның Алсуы, тик берни кылыр хәл юк.

Авыруга сабышкач, Алсу ташламас микән, дип шикләнгән иде Исхак, бер үзгәреш тә сизелмәде. Киресенчә, Алсу тагын да игътибарлыракка әйләнде. Әби кеше генә нәрсә әйтер? Чирле кияү белән яшәргә, инвалидлык бирә калсалар, аның пенсия акчасына торырга риза булырмы?..

Әткәсенең язмышы да кызганыч. Ни өчен Халисә апасы аның өйләнүенә каршы килә? Чынлап та байлыкка кызыгуданмы? Алай уйласаң, Халисәнең үз байлыгы да оныкларына житәрлек... Ул авылдан килгәч, атасының ниндидер хатларын, язмаларын укуын сөйләде. Хәтта "роман" дип атады ул аны. "Әллә нәрсәләр язып бетергән. Безнең әткәйгә андый хис каян килгәндер?" Нинди язмалар ул? Исхак аларны табып укырга дигән фикергә килде...

Хисмәтулла кайтып керде. Өйгә жылылык үткәрү өчен торбалар табу артыннан йөри иде ул.

—Нигә монаеп утырасың, улым?—дип сорады Исхакның ямансулап утыруын сизенеп.

—Болай гына...

—Оланнар сагындырдымы әллә?

—Анысы да бардыр инде...

—Тиздән күрешерсез,—диде Хисмәтулла, кызганыч тавыш белән. Калтыранып чыккан сүзләргә сискәнеп, Исхак ирексездән күтәрелеп карады. Ата, улының карашы белән очрашмас өчен, кинәт борылды да тышка чыгып китте. Аның сүзләреннән Исхак: "Син тиздән күрешерсең, минем генә өмет юк... Иң ятим кеше мин",—дигән мәгънәне аңлады. Уңайсыз булып китте. Бу бәхетсезлектә, атасының ялгызлыгында үзенең гаебе бардай тойды. "Үзенә тиң хатын табып, өйләнсә, бер-беренә иптәш булып көн үткәрерләр иде әле",—дип уйланды.

—Әткәй,—дип сүз башлады Исхак, Хисмәтулла урап кергәч,—иске өйне берүзең генә сүтеп азапланмассың, көзгә тагын килеп китәрмен.

—Сүтү мәсьәләсе планга кермәгән әле, улым. Аңа кадәр мал өен яңартасы бар.—Хисмәтулланың: "Иске өйне әйбере-ние белән Халисә апаңа калдырам",—дип әйтәсе килгән иде дә, олы кызының юньсезлеген искә төшереп, үзенең дә, Исхакның да кәефен кырасы килмәде. Улының сораулы карашын күреп, аңлатма бирде:—Малың булгач, аларга да өй кирәк инде.

—Берүзеңә...

—Яшәгәндә кирәк... Безнең зат аяк өсте үлүчән. Бабай мәрхүм, мал ябып кергәч, тәһарәт алды да: "Мисбах мулланы тиз генә алып килегез—үләм, ясин чыгарга кирәк",—диде. Гажәпкә калдык, шулай да чакырттык. Мисбах мулла ясин чыккан арада бабакай жан бирде... Әткәй дә, эштән кайтып атын тугарган да: "Әллә нигә кәефем юк, бераз ятып алам",—дип башын мендәргә терәгән дә, китеп барган... Минем дә әжәл шулай булыр дип көтәм. Үлгәч кенә, күмелмичә озак ятмасам иде, дим.

—Өйләнергә иде, әткәй...

—Гомеремдә ике бәхетсезлеккә тарыдым. Өченчесе булмагае, дим.

Сүзнең нәрсә турында баруын сизенеп, Исхак төпченмәде. Ата кешенең нечкә хисләренә кагылуны урынсызга санады.

Көтмәгәндә, Хисмәтулла сүз агышын икенчегә борды:

—Нигәдер, улым, авылны чит иттең. Ичмасам, шушы өйләр, ихата, нигез кулдан-кулга, буыннан-буынга күчәр иде,—диде ул сагышлы тавыш белән.

—Миңа байлык кирәкми, әткәй.

—Алай димә. Яшәгәндә барысы да кирәк. Хикмәт анда гына да түгел, һәр кешегә яшәү өчен аяк астында ныклы жир кирәк. Нәселдән килгән нигез генә аяк астында ныклы нигез була ала. Шуңа күрә дә аны корытмаска кирәк. Кош балалары да ояларын онытмый, кире кайта. Уйлыйм да, гажәпкә калам: ни өчен адәм балаларының күбесе туган жирләрен

онытырлык дәрәҗәдә хәтерсез икән? Югыйсә, менә сез дә авылда туып, җирдә аунап, тузанга батып үстегез... Үстегез дә очтыгыз... Очтыгыз да оныттыгыз...

Хисмәтулла тынып калды. Әйтәсе сүзләре күп иде әле аның. Ләкин тамак төбендәге төер дәвам итәргә мөмкинлек бирмәде...

* * *

Хисмәтулла төшендә Айгөлне күрде. Тәрәзә буендагы өстәл янында беренче кыраудан бәсләнгән яфракларга карап чәй эчеп утырганда әлеге төше хәтеренә килде. Искә алган, уйлаган да юкта Айгөлнең төшенә керүенә гаҗәпләнә төшге. Өндә күрмәгәненә дә ничә еллар инде! Унбиш?.. Егерме? Тукта! Хәтере ялгышмаса, егерме алты ел узган түгелме соң?

... Умартачыларның бер айлык курсына җыйганнар иде. Хисмәтулланы да җибәрделәр. Иртәгә кайтасы көнне, күчтәнәч алу нияте белән, кибетләргә чыкты. Юл уңаендагы беренче кибеткә сугылырга борылуы булды, баскан урынында катып калды: аның каршына Айгөл чыгып килә иде. Айгөл Хисмәтуллага игътибар итмәде. Күрмичә үтеп тә китә иде, кыюсыз гына бирелгән сәламгә әйләнеп карады.

—Исәнме, Айгөл!..

—Бәй-бәй, Хисмәтулла түгелме соң?.. Исән, бик исән, Хисмәтулла,— диде кабаланып.

—Өйдәгеләр ничек?

—Әйбәт, әйбәт, үзегез ничек?..

—Сезнең хәер-фатихада...

Айгөл туктап торасы итмәде, бара-бара гына сөйләште. Элеккеләрне искә төшерүдән кыенсындымы, таныш-белешләр очраудан читенсендеме— анысы Хисмәтулла өчен караңгы булып калды. Ул үзенчә юрады: Айгөлнең ире көнчел икән, табалап кына тора икән, дип ишеткәне бар. Шуңа күрә туктап торуны урынлы санамагандыр, дип уйлады. "Бирешмәгән, һаман чибәр. Бу хатынны көнләсәң дә ярый",—дигән уфтану белән, үзенә язмаган беренче мәхәббәте артыннан сокланып карап калды Хисмәтулла.

Шуннан бирле аларның күрешкәннәре юк. Бүген Айгөл төшкә керде. "Юкка түгелдер, мөгаен, хәтергә кереп чыккандыр..."—дип исенә төшерергә тырышты Хисмәтулла, әмма берничек тә күз алдына китерә алмады. Ә төшкә яшь чактагы кыяфәте белән керде ул...

Айгөл, нинди дер яшел япма бөркәнеп, ялан аяклап, аның янынннан үтеп бара, имеш. Хисмәтулла башта аны танымый, аякларына карый икән. Яңгыр да яумый, нигә ул ялан аяк?.. Аяк йөзендәге кечкенә миңеннән танып ала, имеш: Айгөл бит бу!

—Айгөл?..

Кыз эндәшми. Хисмәтуллага борылып карый. Аның карашыннан Хисмәтулла бернәрсә дә аңламый: көләме, елыймы кыз?

—Айгөл, кая барасың?

Айгөл нидер әйтә, тик Хисмәтулла гына аның сүзләрен ишетми...

"Тикмәгә түгел. Башына хәсрәт төшкән булырга тиеш,"—дип уйлады Хисмәтулла. Аның күнеле Айгөлгә кайгы-хәсрәт килүен, аның янып-көеп йөрүен теләми иде.

Аны авыр тойгы чолгап алды. Ялгызлык ямансулатты. Айгөлнең төнлә төшкә керүе, хәзер искә төшүе Хисмәтулланың хисләрен авырайтты гына. Хатынын искә төшереп, тагын уфтанды: "Их, Асия иртәрәк китте. Бергә яшәп, бер тирәдә дөнья куудан хәерлесе юктыр. Шуңа да парлыларга тигез тормыш телиләр инде",—дип үз уйларына йомгак ясады ул.

Тагын күз алдында Айгөл чуала. Нигә алай? Ул да ялгызлыктан гаҗиз булып яши микән әллә? Үзе генә калган, дип ишеттергәннәр иде. Хәзер дә чибәр микән?.. Бирешәдер. Еллар үзенекен итә ул! Яшәвенен дә

мәгънәсе чамалы булгандыр. Ир артыннан ир алыштыра башласан, юньлелеккә түгел инде... Хисмәтулланың беренче мәхәббәтен хәтердә сакларлык бик кадерле истәлеге бар иде. Кайда ул? Исәнме?.. Иске өйнен чоланына күз саласы килде Хисмәтулланың. Исән торса, шундагы киштәдә булырга тиеш... Менә ул дәфтәр! Беренче мәхәббәт тудырган иң изге, иң саф хисләр, әчкерсез уй-хыяллар! Шуның өчен генә саклыйсы итте Хисмәтулла бу дәфтәрне. Бер гөнаһ юк анда. Укыган очракта хатыны Асия дә аны аңларга тиеш иде. Бер мәлне үзе дә Асиягә укытмакчы булды, гөнаһсыз йөрәгенә төер төйнәмим, белмәгән килеш калуы хәерле, дип, күрсәтәсе итмәде...

Шунысы гаҗәп, дәфтәр, көндәлекләр һәм хатлар салынган папкага тузан кунмаган иде. "Идәнгә төшкәндер дә, тузанын кагып алып куйганнардыр",—дигән уй йөгереп үтте Хисмәтулланың башыннан.

Чәй урынын җыештырганнан соң, өстәл артына иркенләп утырып, күзлеген рәтләп киеп, Хисмәтулла моннан кырык еллар элек язылган истәлекләрен укырга керешге—яшьлегенә кире кайтып китте...

"... Кайда дуслык бетә дә, кайдан мәхәббәт башлана—мин моның чиген билгели алмыйм. Олылар күзлегеннән караганда сабый гына тоелган малайлар да нинди генә хисләр белән янмыйлар! Гадәттә, олы мәхәббәт олы дуслыктан башлана, диләр. Минеке бу калыпка сыешмый, чын мәхәббәт булып, шунда ук кабынып китте. Кабынып китте дә уйны-фикерне, җантәнне биләп алды. Аның тозагына эләгеп, әсир калдым мин...

Нәрсәдән башланды соң әле ул? Һич хәтерләмим! Мәхәббәтнең соңы булмаган кебек, башланган ноктасы да юктыр. Тормышта үз урынынны белә башлау белән кабынып, элгәре пыскып, җае чыгу белән дөрләргә торган учак кебек түгел микән ул? Яшьлек мәхәббәте бик оялчан шул. Белдерергә базмый, оялудан читенсенеп тәкатең корый. Кешеләрдән генә түгел, хәтта үзеңнән үзең ояласың. Тышка бәреп чыга алмый, әмма эчтә ургый: сөйгәнең көндез истән чыкмый, төннәрен төшкә кереп йөдәтә.

Беренче хисләремне белдергәнче байтак вакытлар үтте. Аңа карап, алар искермәделәр, ә бәлки үсә, сафлана, ялкынлана гына төштеләр...

Баштан керешик булмаса... Мин әткәйне рәтләп хәтерләмим. Беләсең, ул дөньядан иртә китте. Ятимлектән миңа тормышның төбенә җигелергә туры килде. Безнең буын болай да балалар уенының нәрсә икәнлеген белми үсте. Миңа бөтенләй диярлек эләкмәде ул. Тормыш авырлыгы безне иртә җитлектерде, акылы да алданрак керде, ахры...

Минем җәйге каникуллар эш белән үтте. "Әнкәйгә җиңелрәккә туры килсен, аз булса да хезмәт көне эшләп калыйм",—дип тырыштым. Мәктәпне тәмамлагач та авылда калырга туры килде. Югыйсә, ярыйсы ук мактап, киләчәктә укырга киңәш итеп озатканнар иде... Хәер, андыйлар бер мин генә түгел идем. Безнең ярдәмгә мохтаҗ иде ул еллар. Хатын-кызлар ирләрне алыштырды, без аларга ярдәмгә килдек. Ни генә эшләмәдек: сабан сөрдек, урман кистек, урак урдык, ашлык суктык...

Ара ераклыгы, мәшәкатьнең күплеге сиңа карата күңелдә туган якты хисләргә сүнәргә ирек бирмәде. Каникулларга кайтуыңны зарыгып көтә идем. Син кайтып, күзгә күренсәң, минем өчен аннан да олы бәйрәм юк— кая басканымны белми йөри идем. Гүя миңа канат куйганнар!..

Бәлки, синдә дә миндәге кебек хисләр канатлангандыр? Теләсә ничек булсын, син барыбер мине тыңларга тиешсең. Тыңласаң—аңларсың, аңласаң—кызганырсың... Юк, юк, мин хисләремне кире кагып кызгануга мохтаҗ түгел. Синең кире кагу—аяз көндә яшен суптудан гайре ул...

... Тагын җәй килде. Колхозда эшләр тыгыз. Озын көннәр буе сабан артында. Арыта. Әмма син минем белән яшисең һәм ул миңа көч бирә, тормышыма дәрт өсти. Синең хатларыңны кесәмдә генә йөртәм. Җае чыккан саен, кат-кат укыйм. Ятлап бетердем инде. Шулай да аларга гел күз төшерәсе, синең нәфис бармакларың белән язылган хәрефләрне күздән кичерәсе, аларга карап сокланасы килә. Зур шәһәрдә, күпме халык арасында яшәп, мине искә алуың олы мәртәбә тоела. Кайчагында көнләшү хисе күңел

тәрәзәләренә чиртеп куйса да, бу шомлы шикләнүләрне җәһәт-җәһәт куарга тырышам. Хатларыңдагы җылы, йөрәккә ятыш сүзләрең тынычлык бирә, шикләнүләрдән арындыра.

Тормышлар рәтләнеп килә. Быел без өй сипләргә әзерләнәбез. Шуны башкарып чыксак, көзгә мин дә Казанга—әллүк! Елга техникумын тәмамлап, капитан булырга дигән хыялым торган саен көчәя бара. Укырга керсәм, бергә булабыз бит! Көн дә сине күрәчәкмен. Моннан да артык бәхетнең булуы мөмкин дә түгелдер... Болар хакында уйлаган саен, хыялларым тормышка ашып бара кебек тоела. Синең каршыңда үземне курсант киеме белән басып торгандай сизә башлыйм. Гәүдәм генә биредә, күңелем белән әллә кайчан синең яныңда инде мин...

... Безнең хисләр ничек кушылды әле? Шуны тагын бер кат исемә төшерәсем килә. Мең-мең тапкыр уйласам да, күз алдыма китерсәм дә, туймам инде мин шул чагындагы хыялларга кире кайтудан...

Шимбә көн иде. Клубта яшьләр кичәсе. Арыдык дип тормыйча, җәй көннәрендә үткәрә иделәр аны. Син анда килми калмый идең, чөнки уен-көлкеләрнең башлап йөрүчесе идең бит. Ул көнне эштән кайту белән клубка ашыктым. Мин килеп кергәндә халык аз иде әле. Барыбер килгәннәр бии тордылар. Миңа—гармун уйнау инде. Җизни сугыштан кайткач бүләк итеп биргән солдат ботинкасының табаны куба башлагач, биештерергә рәт юк иде минем. Шуңа күрә гармун тарттым да тарттым...

Яшьләр җыйнала торды, уен кыза барды. Ишек ачылган саен, менә-менә күренерсең дип, йөрәк ашкынып типте... Ниһаять, берничә кыз белән,—алар сезнең очныкылар иде,—ишектә син күрендең. Тыным кысылды, күз алдымны пәрдә каплагандай булды. Кулдан гармун ничек төшеп китмәгәндер? Якын-тирәдәгеләр белән исәнләшеп, син читкәрәк барып утырдың. Синең янга килеп күрешә башладылар. Ләкин мин урынымда кадакланганмыни! Яныма килеп, терәлеп утырсаң да, кул бирергә кыюлыгым житәр иде микән?..

Син дә уеннарга катнаштың. Шәһәрчә киенгән төз-сылу гәүдәңә, маңгай әйләнәсендә бөдрәләнеп торган шомырт кара чәчләреңә сокланып утырдым. Бөтерелеп киткән саен җилфер-җилфер килгән калын толымнарың бигрәк килешеп тора иде үзеңә. Тиңдәшсез идең син, Айгөл! Күңелемнән синең белән сөйләштем. Очрашкач әйтер сүзләрем әллә кайчан әзер иде инде минем...

Уйлаганча барып чыкмый шул! Кайтырга иртәләдең. Авыз ачып калудан куркып, гармунны Хәләфкә тоттырдым.

Киттек. Сез, бер төркем кызлар, алдан, ә мин, аерылып калган каз бәпкәсе кебек, байтакка артта калып атладык. Кызлардан аерылып, кереп китәргә җыенганда, сине туктаттым. Син минем бу эшемне мәгънәсезлек дип санамадың микән? Кыяфәтең аптыраганга охшаган иде. Мин бөтенләй каушап калдым, сүзләрем онытылды, телем тотлыккан шикелле булып китте. Әмма ашыгырга кирәк иде, үземне кулга алырга тырыштым. Егетләрнең кызларны капка төбенә чаклы озата килүләре—авылда кабул ителгән гадәт. Аның берниндн гаебе-кыегы юк. Уртак тел табалар икән, озатышу көн саенга әйләнә, килешмиләр икән, башка сөйрәлеп йөрисе дә юк. Бөтенесен беренче кич хәл итә. Мин моны сизәм һәм бүген синнән җылы сүз, өметләнерлек сүз ишетергә телим. Үзем ерактанрак башламакчы булам, ә син бүлдерәсең:

—Бүген соң. Бик арыдым...—дисең.

—Аңлыйм. Пароходтан кич кенә төшкәнсең. Ял аз тигән. Ләкин синең рәхәтләнеп йокы туйдырырлык вакытың бар. Миңа гына кояш белән эшкә китәсе.

—Безнең монда таптануның мәгънәсе юк,—дисең.

Мин бу сүзләрне көттем. Үзен ихтирам иткән нинди генә кыз минут эчендә егетләр кочагына ташлансын! Мин хисләремнең чынлыгын, синсез тора алмавымны аңлатырга тырыштым. Гүя минем сүзләр сиңа кагылмыйлар:

—Бу темага һич кенә дә сөйләшәсем килми,—дисең.

—Безнең кебек авылныкыларны санга да сукмыйсызмы? Укый башлагач, эреләнгәнсен. Шәһәр егетләре бездән әйбәтрәктер шул инде,— дип үпкә сүзләрен тезеп киттем. Бер тел ачылгач, туктата торганмыни! Әллә ниләр әйтеп бетердем бугай. Ярый әле син үзенне тыныч тоттың.

—Теләсә ничек уйла,—диден дә керергә җыендың. Сезнен өй ишеге шыгырдап ачылды. Кемдер чыга иде бугай. Миңа монда кагаеп басып торуның мәгънәсе калмады. Кузгалдым. Син кереп киттең. Бераз бардым да туктадым. Эчтә ут уйный. Кимсендем. Авылда төшеп калган егет түгел идем. Шуңа карамастан, минем белән исәпләшергә теләмәвең, санга сукмавың ачуны кабартты. Уйлар җыр булып тышка агылды... Ишеткәнсендер. Мәгънәсен дә аңлагансыңдыр. Нишләптер янадан бу хакта искә төшерергә туры килмәде. Югыйсә, ярыйсы ук төрттердем үзенә...

Җәйгә чыксаң, җилләр өчен,
Җәй келәткә урыныңны.
Миннән артыкны тапмассың,
Бик күтәрмә борыныңны!..

Менә шулай. Аңласаң аңларлыгы бар. Мин син ишеткәнсендер, тел төбен аңлагансыңдыр, дип уйладым.

Яшермә, сиңа мине мактадылар бит—кире какмаска өндәүчеләр дә булды. Сизендем. Әйтмәсәләр дә син мине белә иден инде. Бер чорда үстек. Ике урамда яшәсәк тә, бергә уйнаган чаклар күп булды. Сакка йөгергәндә, сине куып тоту өчен, җан фәрманга чаба идем. Син гел Мөшәрриф белән басарга тырыштың. Моңа мин ут яндым. Шул ачу куәт биргәндер, мин сине һәрвакыт куып тота идем. Мөшәрриф көнләшеп, мин сакка бассам, уенга керми башлады.

Җырдагыча әйткәндә: "Заманалар авыр, михнәтләр күп" булса да, дәртле идек. Күрше-тирә авылларда куелган концерт, спектакльләрдән, кичәләрдән калмадык. Иренеп тормадык, җәяүләп киттек тә бардык.

Бер көнне иптәш кызларың сине бер чакрым ераклыктагы Күнҗә авылына кичәгә барырга чакырдылар. "Риза булса ярар иде",—дип әчемнән теләп тордым. Син барсаң, мин каламмы соң! Барганда-кайтканда булса да сине күреп тору минем өчен иң зур бәхетләрнең берсе! Саф тавышың белән көлүеңне тыңлау үзе ни тора!

Без дә, бер төркем егетләр, сезнең арттан атладык. Күнҗә авылы клубының идәннәре сыгылганчы биедек, тәрәзә пыялалары чыңлаганчы җырладык бу көнне. Мине юатырга теләгәндәй, "Карабай", "Дүртле", "Сигезле" биюләрендә син гел мине сайладың. Шатлык хисләренең менә-менә тышка бәреп чыгарга торганын берәрсе сизде микән? Юктыр. Ә мин канатланып очтым, аякларымның җиргә тигәнен сизмәдем...

Кайтырга кузгалгач, көтмәгән хәл килеп чыкты. Күнҗә авылыннан Мирһади, безнең төркемгә ияреп килде дә, сезнең белән тигезләшкәч, сине беләгеңнән тотып туктатты. Син, оясыннан пырлап күтәрелгән кыр үрдәге кебек, кинәт аннан ычкындың да минем беләккә килеп ябыштың. Гәүдәм камырга әйләнде, сүзсез калдым. Култык астындагы кулыңны йөрәгемә терәлердәй итеп кыстым...

Мирһади һаман иярмәкче иде, туктаттылар:

—Күрмисеңмени? Араларына ничек итеп кермәкче буласың?—диде безнең егетләр.

... Нәрсә турында гына сөйләшмәдек без бу төнне! Әмма яратышу, сөю хакында—ләм-мим! Аңысы сүзсез дә аңлашыла икән!.. Урам саклап таң аттырдык. Тау авышлыгына салынган сезнең урам, без таптаудан, бераз турылана да төшмәде микән? Эшкә бару турында уйлаган да юк. Тоташтан әллә ничә төн керфек какмаска да риза, янымда бул!

Синең иреннәреннең кайнарлыгын, татлы тәмен мин шушы төндә татыдым: Бу бәхеткә ирешүем белән горурландым мин. Авылның иң чибәр кызы,—авылның гынамы икән әле?—синең мәхәббәтеңне кабул итсен дә, ничек тыныч кала алырсың?

... Йокысыз үткәрдем мин бу җәйне. Син киткәнче ике "смена" кудым. Ләкин уфтанмадым, сызланмадым, эштә дә сынатмадым. Мәхәббәт биргән көчнең чиге юк икән ул! Ике җәй тоташ килсә дә түзәрлек чамам бар иде...

Сиңа хат язасым бар, туктап торам. Иркенләп тагын бер утырырмын, уйларымны бәйнә-бәйнә язармын. Бик тә күп алар, чигенә чыга алсам инде. Сиңа житкерәсе килгән иң матур сүзләрем, иң жылы хисләрем һаман да тирәндә яталардыр кебек...

"Айгөл!

Байтак яза алмый тордым. Вакыты да чамалы иде, әллә нигә кәеф ягы да төшенкеләнде.

Бу араларда үзгәрешләр булып алды һәм киләчәктә дә котелә. Күптән түгел хәрби комиссариатка комиссиягә чакырдылар. Авылдан бер үзем бардым. Карасаң, минем белән авылдан армиягә китүче дә юк икән! Яшьтәшләрдән Васил, Мәгъсүм, Әсләх читтә. Мөдәррискә ак билет тоттырганнар. "Кәжә билеты" диләр аны. Армиягә бармаганнарны кимсетеп әйтүләре. Мәгъдәнурга операция ясадылар, быелга ул да калыр...

Шулай итеп, авылдан бер үземә китеп барырга туры киләчәк. Октябрь башларында ук чакыртмаслар микән? Ноябрь бәйрәмен үткәртерләр дигән өмет тә бар. Бәлки, син дә кайтып килер идең. Очраша алмый калсак, тиз генә күрешү насыйп булмас. Алда башланмаган өч ел тора. Бик күп ара ул. Көткән кешегә аеруча. Белмим, түзә алырсың—микән? Түзәрсең бит, Айгөл?

Мин көн саен хат язып торырмын. Онытa гына күрмә. Онытуын-онытмассың, хыянәт итә күрмә, диюем. Сөюләрең хак икән, көтәрсең.

Көтәреңә өмет итәм. Яшәвемнең мәгънәсе, тормышымның яме син генә. Хыянәт итә калсаң, ничекләр күтәрермен? Кеше булып йөрүнең кирәге калырмы? Син минеке булганда гына мин кеше, юк икән—мин дә юк...

Көтәрсең бит мине, Айгөл?..

Синсез нишләрмен мин?

Хисмәтең. 25 сентябрь".

"Хисмәт!

Ничә еллар синең белән бергә яшәп, синең бу чаклы тешләк, икейөзле икәнлегеңне сизенә алмаганмын. Дөрес аңла, мин бу сүзләрне һич кенә дә кире мәгънәсендә, сине битәрләп әйтергә теләмим. Кызганам мин сине. Күңелеңдә гомер буе бер кешене йөртеп, икенче кеше белән еллар үткәрү һәм аның белән дә әйбәт яши алуың синең рухи көчлелегең турында сөйли кебек, минемчә.

Күңелемә дә китермәдем, мин сөймәс кешең булганмын икән шул. Шуның белән ничә ел гомереңне үткәргәнсең. Шушы еллар буена күңелеңдә икенче кешене йөрткәнсеңдер дип башыма да китермәдем. Миңа калганда, син бик басынкы, түземле, төчеләнергә яратмый торган, хисләреңне чәчәргә ашыкмаучы кеше. Моның сәбәбе дә булган икән шул. Хәзер генә аңладым, бик соң гына... Гафу ит, мин күңелемдә сине мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңламый, сөю-сөелүнең ләззәтен белми торган кешегә исәпләп йөрдем. Әгәр миннән андый кешене атавымны сорасалар, икеләнмичә сине күрсәтер идем. "Кешене белү өчен аның белән бергә бер пот тоз ашарга кирәк",—диләр, ай-һай, центнер ук кирәкмиме микән?

Син хатын-кызларга игътибарлылык та, ихтирам да күрсәтәсең. Эчкерсез. Ясалма кылана белмисең.

Син мине ихтирам иттең, каты сүз әйтеп бер вакытта да рәнжетмәдең. Балаларга да мөнәсәбәтең әйбәт булды, какмадың, сукмадың. Синең: "Якты дөньяга китергән өчен генә дә сез әниегезне ихтирам итәргә, санга сугарга тиешсез",—дип аларга әйтеп торуың мине куандыра иде. Рәхмәт сиңа!

Уйлап-уйлап утырам да синең гел яхшы якларың гына искә төшә. Күрәсең, без бик әйбәт яшәгәнбез, тату гомер үткәргәнбез. Мине кимсеткән, кыерсыткан чагыңны бер дә хәтерләмим. Төчеләнмәдең дә, ереп төшәрлек

иркә-наз да күрсәтмәдең, ләкин бөтен кыяфәтеңнән бөркелеп торган миһербанлылык сине матурайта иде.

Өйләнешкән мәлне син мина берничә тапкыр “Айгөл” дип эндәштең. Хәтереңдәме? Мин сиңа: “Мин Айгөл түгел, Асия. Айгөл синең яшьлектә яраткан кызыңдыр. Югыйсә, мина ул исем белән дәшмәс идең,”—дия торган идем. Ә син: “Йокы аралаш саташылгандыр, бәлки яраткан исемемдер. Олы кызга шул исемне куясы килгән иде, син теләмәдең бит”,—дип җавап бирдең. Бу исемне яратуыңның сәбәбе булган икән шул. Дөресен сөйләгән булсаң, билләһи, кызыбызга ул исемне куйдыруга һич кенә дә каршы килмәгән булыр идем. Уйларыңны сиздермәдең шул. Мин дә сизенмәдем. Сизенмәдем генә түгел, мин сине гомереңдә гыйшык тотуның нәрсә икәнен белми торган зат дип уйлап йөрдем.

Хисмәтулла! Минем белән гомер кичерүеңә үкенмәгәндерсең. Мин бит сине яраттым, ихтирам иттем. Кыска гына вакытка китеп барганда да өзелеп, сагынып көттем. Хәзер дә вакытында кайтмый торсаң, тәрәзәдән күземне алмый сине көтәм. Синсез тамагымнан аш үтми, йокым йокы түгел...

Синең Айгөл белән яшь чагында чуалганың хакындагы хәбәр колакка кереп калган иде. Ләкин мин аңа игътибар бирмәдем, түбәнә төшеп уйланмадым. Яшь чакта, егетләр белән кызлар арасында шаярышулар булмый каламыни?

Рәхмәт сиңа, Хисмәтулла, утыз елдан артык мина тугрылыклы ир булдың. Синең янда мин үземне кыя ышыгындагыдай хис итеп яшәдем, бер нәрсә өчен дә хәвефләнмәдем. Серләшеп, уртак кайгы белән борчылып, бер шатлыкны урталай бүлеп яшәдек. Киләчәк кенә ничек булыр инде?..

Үз хәлемне үзем генә беләм: сыкрануымны сиңа сиздермәскә теләп, теш кысып түзгән минутларым күп. Син барыбер беләсеңдер, хәлләремне аңлыйсың кебек. Күзләреңнән сизенәм: бу араларда тирән сагышка баттың. Картлык көнеңдә ялгыз калу сиңа да җиңелдән булмас шул инде...

Синең өчен ныграк борчылам: кая сыенырсың икән? Балалар кабул итәрләрме? Картлык көнеңдә калага китеп тә торасың килмәс инде... Төпчегебезгә генә сыймасаң, башкаларына икеле... Халисәнең холкын үзең беләсең. Кемгә тарткандыр? Нәсел-нәсәптә андый кеше юк иде шикелле. Исхак үзе кеше кешесе. Әбисе янына карт атасын алып китә алмас...

Өйләнергә туры килер, Хисмәтулла. Тик кемне дә димли алмыйм. Бәлки, Хәдичә белән язмышларыгызны бәйли алырсыз? Бик яшьли ятим калып, тормышның ачысын-төчесен күп татыды. Әйбәт хатын булыр ул. Яман аты чыккан кеше түгел. Ул сиңа язса, мин бик тыныч булыр идем.

... Ярый әле, Хисмәтулла, бу язуларың кулыма элэкте. Гомеремнең соңгы көннәрендә булса да укып чыктым, сине тагын да ныграк аңладым. “Актарынган, тапкан, укыган”,—дип ачуланма, киштәнең тузаннарын сөрткәндә папкасы-ние белән килеп төште дә эчендәге кәгазьләре чәчелде. Күзем шушы дәфтәргә төште. Беренче юлларын укуга, туктала кала алмадым. Әгәр эзләнә торган гадәтем булса, утыз ел буе боларны күрми яшәмәс идем инде...

Күбесен телдән дә әйтеп бетереп булмый—кайберләрен язасың да икән. Менә мин дә сиңа ачыктан-ачык әйтергә кыймаган сүзләремне дәфтәреңдә калдырам. Бер вакыт укырсың, аңларсың, мине искә алырсың. Гаепләмә, ярыймы?

Хәер, син андый түгел...

Их! Утыз ел утыз көндәй генә кебек булып калды! Яшисе иде бит әле... Нигә Ходай елларын миннән кызганды икән? Үлгәндә дә тигезлек юк бит!

Хуш, Хисмәтулла. Урынына салып куям. Истәлек язуы, кадерле ядкарең булып саклансын. Балалар да укысын иде...

Хатының Асия. 20 октябрь.

Карале, Хисмәтулла, мине дөрес аңла: мин сине һич кенә дә битәрләргә теләмәдем. Мин язганнарны алай кабул итмә. Күпме еллар үткән, күпме

сулар аккан, көнчел кешегә дә тынычланырлык вакыт булган инде. Син беләсең, мин андыйлардан түгел.

Олыгайдың, картым! Яшь чагында омтылып карасаң, синнән язучы да чыккан булыр иде. Үз язмышыңны бәян иткәндә дә гыйбрәтле бер китап чыгар иде...

Менә шулай, Хисмәтуллам!"..

## 5

Айгөл тормышында Хисмәтуллага ишетелмәгән караңгы яклар кирәгеннән артык күп иде...

Авылга ирсез килеш авырга узып кайтты. Училищеның музыка укытучысы Рәмзидән алданды.

Үзешчән сәнгатьтә катнашу якынлаштырды аларны. Концертлар куеп, Казан тирәсе авылларында еш йөрделәр. Рәмзи хатынлы иде. Яшьли өйләнгән. Сәфәрдә чакта өйдә калган хатыннар турында кем төпләп уйлансын! Айгөл дә Рәмзине тиңдәш, егет кеше сыман итеп тоеп йөрде. Чибәрлеге, баянда оста уйнавы белән күңелен яулап алды Рәмзи.

... Язгы кичләрнең берсендә, концерт куйдылар да, калага кайту юлына чыктылар. Үч иткәндәй, автобуслар йөрми. Район үзәгенә эләксәләр, Казанга баручы берәр машина-мазарга утырырлар иде. Районга кадәр булган араны ничек узарга? Юлда сынар машина да күренми? Җәяү атлый тордылар. Байтак юл киткәч, бер җиңел автомобиль куып житте. Туктаттылар. Җиде кешенең бишесе сыйды. Шофер аларын да кагыйдә бозып алды. Икәү калырга тиеш.

—Мин калам,—диде Рәмзи.

Тынлык урнашты. Башка ризалык белдерүче юк иде.

—Мин дә калам,—диде Айгөл, тәвәккәлләп.

Машина кузгалды. Алар икәү генә торып калдылар. Тагын машина килеп чыкмас микән, дигән өмет белән атлый тордылар. Бәхетсезгә жил каршы, дигәндәй, машина түгел, жигүле ат та очрамады. Караңгы төште. Куну җаен карарга кирәк иде. Төнгә каршы, килеп кергән авылларын ташлыйсы итмәделәр, урам очындагы беренче өйгә сугылдылар.

—Өем кечкенә, урын юк, берегез идәнгә ятсагыз гына инде,—диде карчык.

Ризалаштылар. Айгөл караватка ятты, Рәмзи идәнгә сузылды...

Төн урталары иде. Битенә кайнар кул кагылудан Айгөл күзләрен ачты. Кечкенә тәрәзәдән сизелер-сизелмәс кенә төшкән таң яктысында, каршында Рәмзи басып торганын абайлап алды.

—Тс-с!—диде Рәмзи.

Айгөлнең тавыш чыгаруда исәбе юк иде. Рәмзи, бер кулын муен астыннан, икенчесен тез астыннан тыгып, Айгөлне күтәреп алды да күкрәгенә кысып идәндәге үз урынына китереп салды. Айгөл аның муеныннан кысып кочаклаган иде, яткач та ычкындырмый торды. Еш-еш алган кайнар сулышы белән Рәмзинең муенын җылытты. Камыр кебек изрәгән гәүдәсен тотарга Айгөлнең көченнән килми иде. Ул эреде дә төште, бу мәлҗерәүнең соңы ни белән бетәчәген уйларлык чамасы калмаган иде. Минутлык рәхәттән тыела алмыйча, гомерлек бәхетсезлеккә тару ихтималлыгын кисәтергә бу мизгелләрдә аның акылы сәләтсез иде.

Как идәнгә салынган мендәр өстендә Айгөл беренче мәхәббәтенә, сафлыгына хыянәт итте...

И, язмыш! Алда нинди сынаулар, абыну-сөртенүләр көтә?

Шунысы гаҗәп: әллә бөтен тирәнлеге белән аңлап бетермәде, әллә үзе турында югары фикердә йөреп, чибәрлеге белән масаеп, Айгөл алдануы өчен бик артык борчылмады. Ничәмә-ничә еллар буена өзгәләнеп, саф сөю хисләрендә янып йөргән, аның белән кавышу минутларын тыны белән тартып алырдай булып көткән Хисмәтулла да аңа кызганыч түгел иде.

Шулай да күнелен бераз тынычландырырдай сәбәп тапты. "Хисмәтул-лага барсаң, гомерең буе авыл хатыны булып калачаксың. Шәһәрдә калуны уйлыйсы да юк".—Шулай итеп үзен юатырга теләде Айгөл.

Алдануына җиңелрәк карауның икенче ягы да бар: мондый хәл бер аның башыннан гына үтмәгән. Иргә баралар әле, менә дигәннәрен табалар, хәзер заманы шул...

Хилаф эш кылуын аңлый ул. Соны хәтта фаҗига белән бетәрен дә чамалый. Ләкин Рәмзи белән элемтәсен өзми һәм теләге дә юк кебек. Чыгарылыш имтиханнары алдыннан кара кайгыга батты Айгөл. Ул авырга узган иде...

Нишләргә?

Рәмзи белән икесе дә эш узгач кына ныклап торып баш вата башладылар. Хәсрәткә чумып, Айгөл имтиханнарына рәтле-башлы әзерләнә дә алмады. Рәмзи ярдәмгә килде, укытучыларның Айгөл өчен ташлама ясауларына сорап, кайда ялварып, кайда хәйләләп дигәндәй йөрде. Айгөлне тизрәк озатып, тизрәк аннан котыласы килә иде аның.

Айгөлдә тагын икенче кайгы: ишелгән корсак белән кайтып, авылда ничек йөрерсең? Кешеләргә, туганнарга нәрсә диярсең? Ярый Хисмәтулла армиядә. Ичмасам, аның белән очрашмаячак...

Башка әмәлен уйлап таба алмагач, шулай килештеләр: Айгөл кайта, иргә чыктым дигән сүз тарата, тиздән кайтып алачагына ышандыра. Ир булып Рәмзи кайта һәм Айгөлне алып китә. Шәһәргә килгәч, Айгөлгә үз язмышы турында үзенә уйланырга калачак. Рәмзинең гаиләсен ташлау уе юк иде.

Рәмзи сүзендә торды, Айгөлне алырга кайтты. Озату мәҗлесе оештырдылар, кызу эш вакыты булуына карамастан, кунак күп җыелган иде. Бик күп җылы сүзләр, теләкләр әйтелде яшь парларга. Тигез тормыш, мәхәббәт-бәхет, күп балалар үстерү һәр кешенең сүзендә кабатланды. Айгөлнең әти-әнисе дә бик куанышты: аларның чибәр кызлары килде-китте егет сайламас, юк-бар кешегә абынмас, диделәр...

Айгөл шәһәргә килеп яши башлады, балалар бакчасына тәрбияче булып урнашты. Бердәгеләргә тормыш юлын икенче төрлерәк аңлатты: "Өйләнешү белән ирем армиягә китте, хезмәтен тутыргач, укырга кайта. Шуңа күрә шәһәргә урнашасы иттем",—дип сөйләде.

... Баласы үле туды. Айгөлнең аяк-кулы бераз чишелеп киткәндәй булды. Ялгыз башының кайда да сыенырга мөмкинлеге бар. Сынар канат белән бала тәрбияләп үстерүне Айгөл мең бәлагә исәпләп йөри иде. Шуңадыр, бала үле тугач, аны кызганмады, киресенчә, җанында җиңеллек тойды.

Төрлесен уйлады Айгөл. Бөтенесен бәйнә-бәйнә сөйләп, Хисмәтул-лага хат язу уена да кергән иде. Аның өзелеп яратканын белә. Гафу үтенер, кичерүен түбәнчелек белән сорар. Хисмәтулла киң күңелле, Айгөлнең хәленә керер, бәлки, кичерер? Тик бу Хисмәтулланың эчкерсез мәхәббәтеннән оятсыз рәвештә көлү булачак лабаса!

Хисмәтулла үзенә тиң табар, күркәм тормыш корыр. Бәхетле хатын әләгәчәк ана. Чөнки Хисмәтулла олы җанлы, башкалар турында кайгырта белә, якыны өчен бөтенесен кылырга риза, ихтирамлы ир заты. Мондый кеше янәшәсендә Айгөлгә урын юк. Бу бәхетне башка хатын татыячак...

—Их, ничек хыянәт итә алдым мин аның мәхәббәтенә!—дип беренче тапкыр чын йөрәктән уфтанды, өзгәләнде Айгөл.—Оятсыз мин! Хисмәтул-ланың яше сугар, Ходайның каһәре төшәр...

Күңеле дөрес сизенде: бәхетсезлек Айгөлнең юлдашына әверелде. Һәрбер абынган саен сәбәбен язмышка сылтады, кемнедер гаеплисе килде. Үз гамәлләренә нәтиҗә ясаудан ерак йөрде ул. Күңеле көтте, ана да шатлыклы көннәр килер сыман иде, ләкин аны якынайту, каршы алу өчен күңел ишегең ачмады, ихлас күңелдән бәхетенә омтылмады.

Баладан котылып бер ел узгач, Айгөл өстенә ябырылган хәсрәттән бераз җиңеләеп калгандай хис итте. Кешеләр арасына керәсе, үзен башкалар

белән тигез сизәсе килү омтылышы җинде. Яшьлек тә үзенекен иткәндер. Аның яшьтәшләреннән бик күпләр әлегә яшь-җилкенчәк булып, Айгөл күргән хәсрәтләрнең нәрсә икәнлеген белми яшиләр. Унтугызы гына тулып киткән иде бит әле...

Сабантуй көннәрендә, шәһәр паркында Айгөл бер егет белән танышты. Валерий исемле. Егет ыспай киенгән, тотышы ипле, сүзгә кесәгә керә торган түгел. Танышып, ярты сәгать үтүгә үзе турында бөтенесен сөйләп бетерде. Заводта эшли икән. Кичен институтта укый. Инженер булырга җыена. Утызны кырлап килсә дә өйләнмәгән. Айгөл дә кыскача гына кемлеген аңлатты, хәзер кайда эшләвен әйтте. “Ирем үлде”,—димәкче иде, тыелып калды, “Әле генә танышкан кешегә ул чаклысын сөйләп торуның ни хаҗәте бар?”—дигән фикергә килде.

Айгөл белән Валерий арасындагы элемтә торган саен тыгызлана барды. Алышу-барышу турында да сүз кузгалды. Валерийга завод менә-менә фатир бирергә тиеш икән. Егет өйләнү өчен шуны гына көтә, имеш. Бу көн якынлашкан саен Айгөлнең күңелендә буран уйный. Валерийны алдап йөртә бит ул. Ничек чишелергә? Дөресен әйтергәме?

Айгөл сиздермәскә уйлады. “Ни булса да булыр...”—дип, язмыш хөкеменә тапшырды. Әлбәттә, ярату көчле булса, күп нәрсә гафу ителә. Күрәсең, Айгөл Валерийның гомерендә беренче мәртәбә ихлас яраткан кызы булып чыкты. Өйләнештеләр, яратышып, ихтирам итешеп яшәделәр.

Валерийның хезмәте командировкага еш йөрү белән бәйле иде. Озакка китеп барган чаклары күп була. Мондый вакытларда Айгөл үзен кая куярга белми. Ялгызы өйдә калу яшь хатынга бик ямансу. Вакыт үткәрү һәм ялгызлыктан арынып тору өчен, үзләреннән ерак түгел генә кинотеатрга йөрештерә. Өйдә үзенә урын тапмагач, бүген дә барасы итте. Кино тәмамлангач, ашыкмый гына кайту ягына чыкты. Март аеның саф һавасын ташлап, таш өй эченә кереп бикләнәсе килми иде.

Үз уйларына чумып атлаган Айгөлне туктаттылар.

—Карап торам да, аптырап куям: ябь-яшь кыз ялгызы гына кинога йөри, әллә иптәш булыймммы, дим? Ничә көн күзәтәм үзегезне—һаман бер ялгызыгыз,—диде туктатучы егет.

—Ирем командировкада,—дип теләр-теләмәс кенә җавап бирде Айгөл.

—Ай-һай, чибәр хатынны ялгыз калдырып югалучы ирнең эчендә җаны юктыр,—диде егет башын чайкап.

—Эше шундый. Ни хәл кыласың?—дип җавап кайтарды да, Айгөл урыныннан кузгалды.

—Ашыкмагыз әле, танышыйк, исемегез ничек?—дип чат ябышты егет.

Айгөл аңа беренче тапкыр күтәрелеп карады һәм бер мәлгә каушап калды: егет төс-кыяфәте белән коеп куйган Хисмәтулла иде. Нәкъ Хисмәтулланың яшь чагы! Булса да булыр икән шул чаклы охшашлык! Бертуганы диярсең!

—Исемегез ничек?—дип кабатлады егет.

—Очрашкан берәү белән таныша башласаң,—дип сүзне өзү ягын карады Айгөл, әмма исемен әйтергә ашыкмаса да, аның бу егет белән тиз генә аерылышасы килми иде. Сөйләшү тансык иде аңа. Хисмәтуллага охшаган егет белән сөйләшү тәмле иде.

—Мин—Рамил, сез кем?—дип үҗәтләнде егет.

—Айгөл...

—Матур исем. Апамның кызы Айгөл исемле иде. Җиденче класста укыганда Агыйделгә су коенырга барып, батып үлде,—диде Рамил көрсенеп. “Агыйдел” сүзен ишеткәч, Айгөлдә кызыксыну тагын да артты:

—Сез кайсы яктан?

Алар бер районнан булып чыктылар. Хәтта авыллары да артык ерак түгел икән.

—Сез безнең авылдан бер егеткә бик нык охшагансыз. Өзеп куйган шул инде,—диде Айгөл, һаман да Хисмәтулла турында уйлавын дәвам итеп.

—Юньле кешеме? Әллә кемгә охшатмыйсызмы?

—Кирәгеннән артык юньле ул. Әүлияләр кебек... Хәзер генә кайда йөри торгандыр?—Айгөл көрсенеп куйды. Анның хәлен Рамил дә сизенде:

—Якыныгыз идемени?

—Әйе...

Тынлык урнашты. Башына тәвәккәл фикер килгән кыяфәт белән, Рамил Айгөлгә мөрәҗәгать итте:

—Бу очрашуны билгеләп үтәргә кирәк. Әйдәгез ресторанга?

—Соң инде...

—Рәхәтләнеп ике сәгать утырырлык вакыт бар. Бүген премия дә алдым. Киттек!

Ирләр затына артык каршылык күрсәтү гадәте булмаган Айгөл бу юлы да баш тарта алмады. Керделәр. Утырдылар. Ике сәгать сизелми дә калды. Биегән кыланып бөтерелеп тә алдылар. Айгөл һаман хыялыннан арына алмый иде: Рамил гел Хисмәтулла инде. Озын, кара куе чәчле, ак йөзле. Инсаләре дә шуныкы кебек кин, көч-куәте сизелеп тора...

Бу төнне Рамил Айгөл янында үткәрде...

... Валерий ышыгында Айгөл бер ел жил-янгыр күрми яшәде. Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, дигән кебек, бозык күңелне яхшылык белән генә төзәтеп булмый икән. Үзе теләмәсә—нишләсән дә юк. Айгөл Рамил белән очрашуын дәвам итте, ире өйдә юкта фатирына да алып кайткалады. Без капчыкта ятмаган кебек, Айгөлнең кырын эшләрен дә Валерий сизенде һәм, төпченеп тә тормастан, аны куып чыгарды. Айгөл урамда калды. Ярый әле эше бар. Тотанаксызлыгын сизенсәләр, бакчада, балалар арасында тотулары да икеле иде.

Кая барып сугылырга? Сонгы ышаныч—Рәмзигә ялыну. Ул фатир табышуда ярдәм итә алыр. Бәлки, тулай торакка урнашырга булышыр. Айгөл аның эш урынына килде, чакырып чыгарып, озаклап сөйләште. Рәмзи аның тетмәсен тетте:

—Сабыйлыктан чыгарга вакыт! Нинди иргә эләккән идең шунын да кадерен белмәдең! Сиңа тагын ни кирәк?

—Гел командировкада бит... Минем дә тәнем-жаным бар...

—Түзәргә иде! Сиңа гына каян килгән ул кадәр тыелмас нәфес!—диде Рәмзи, ачуын яшерә алмыйча.

—Ялгызым нишләргә тиеш? Мин әби түгел лә!—диде Айгөл акланып.

—Син һаман бер нәрсә дә аңламагансың һәм аңларга да теләмисен. Үз кырыгын кырык! Теләсә нишлә, мин сиңа ярдәм итә алмыйм,—диде дә Рәмзи кузгалу ягын карады.

—Минем бу көнгә калуыма син гаепле,—дип Айгөл Рәмзинен каршына төште. Аны тиз генә ычкындырырга уйламый иде ул. Актык өмете шушында. Әгәр Рәмзи баш тарта калганда, ана кем ярдәм кулы сузсын!

—Син шуны аңла: безнең мөнәсәбәт ризалык белән булды. Минем урында башка берәү булса да син карышмас идең. Син минем хатыным барлыгын белеп тордың...

Айгөлнең тамагына төер утырды. Рәмзине дә, үзен дә күрәсе килми иде аның бу минутта. Бик саллы сүзләр белән Рәмзинен тетмәсен тетәсе килде. Ләкин гәүдәсен хәлсезлек биләп алды, аяклары камырга әйләнде.

—Оятсыз, жир бит син, хәсис!—дип, теленә беренче килгән сүзләрне тезде дә, китеп барырга тырышты...

... Ничә еллардан сондыр, Айгөлне тагын иргә барган дип сөйләделәр. Үзеннән байтакка өлкән икән, көнли икән, дигән сүзләр авылга да кайтып ишетелде. Хисмәтулла белән кибет алдында очрашкан вакытта ул шушы ире белән тора иде.

Ире каты булды аның, тезгенне нык тотты. Имгәнгәнче кыйнап ташлаган чаклары да булгалады. Айгөл түзде. Ике бүлмәле фатирны ташлап урамга чыгып китәр хәле юк иде. Тукмалуы да үзеннән. Бозыклык гадәтен һаман тыя алмый... Ирләр дигәндә эри дә төшә иде...

Иллесе тулганда гына ипкә-сапка килде ул. Күзләрен шинә торган гөл кебек, аны да матурлык ташлады. Гомер жил куып, мәгънәсез яшәү

белән үтте. Башка балалары да булмады. Хәзер аңлаган да кебек, әмма соң инде. Ничә ир кулыннан үтеп, нык таушалды, вакытыннан элек картайды. Артка әйләнеп карарлык, искә алырлык бер эше-гамәле дә юк. Картлык көнендә бер ялгызы...

Пенсиягә чыкты. Җитмеш биш яшьлек картын җирләп, ике бүлмәле фатирда япа-ялгызы калды. Картаюдан йөннары саргайган ата песи белән сөйләшеп көн үткәрә. Берәүгә дә кергәне юк, башкалар да аның хәлен белмиләр...

Хисмәтулланың төшенә кергән көнне Айгөлне паралич суккан иде...

Иртәнге чәйне эчте дә, башы гөжләүгә чыдый алмыйча, диванга ятты. Уң аягын күтәреп салды, икенчесе идәндә калды, аны күтәрерлек чама юк иде—потлы таш асканнармыни! Сул кулы да асылынып төште. Бите тартышты, авызы кыйгайды, башы томанланды. "Үләм, ярдәм итегез!"—дип кычкырырга авызы ачылмады, нindидер хәлсез мыгырдану гына килеп чыкты. Һушы бар чакта ишекне ачып, күршеләргә хәбәр саласы иде... Айгөл соңгы көчен туплап, кузгалмакчы булды, ләкин селкенә дә алмады, тәне диванга кадаклап куйгандай иде...

## 6

Исхак киткәч, Алсуга да фатир эчендә урын тарайды. Әни кеше кызының һәр адымына бәйләнергә кереште. Разия электән үк, башкалар фикеренә каршы килеп сүз әйтмәсә, үзеннән канәгать була алмый иде. Кызы Алсу, анасының бу гадәтен яхшы белгәнгә, күп очракта аңа җавап кайтармыйча, әләгешеп китүдән үзен-үзе тыеп торды. Разиягә кияү дә ярамый—чирләш, кызы да ул дигәнчә яшәми, балалар бөтенләй бозылып үсәләр... Оныклары Әнис белән Фәнис бераз шаулаша төштеләрме, Разиягә җитә кала, үзен-үзе тыя алмыйча ярсырга керешә:

—Тый балаларыңны—дип Алсуга ябырыла.

—Әни, минеке генә түгел, синеке дә алар. Оныкларың,—ди Алсу аптырап.

—Хулиганнар үстерәсең!—дип үзенекен тукуын дәвам итә ана.

—Китеп дөрес эшләде Исхак. Ике яклап талауга ничек түзмәк кирәк! Сиңа кушылып, мин дә аның күпме йөрәк итен ашыйм. Әле дә безгә чыдап яшәде. Авылдан килмәсә дә сүз әйтер урыныбыз юк,—диде Алсу, үз алдына сөйләшкәндәй.

—Кая талау! Аз әләкте әле ул мокытка. Минем өемдә яшәп, минем белән исәпләшми кыланган була тагын! Авыл бәрәне! Менә аңа!—Разия ике бармагы арасыннан баш бармагын чыгарып, Алсуга таба сузды.

Дүрт ай авырып йөргәннән соң, Исхак комиссия узды. Икенче группа билгеләделәр аңа. Эшләүдә исәбе булса, өченче белән калдыралар иде.

—Хәвефләнер урын юк, буын чиреннән котылу өчен вакыт кирәк. Аннары күп нәрсә үзеңнән дә тора: хәрәкәт кирәк. Саф һавада йөрү, үзеңне тыныч тоту таләп ителә,—диде аңа комиссиядә утырган табиб. Киләсе елда группасы киметелергә яки бөтенләй алынырга мөмкинлеген дә аңлатты.

Исхак өйгә башын иеп кайтып керде.

—Нәрсә булды?—дип хәвефләнде Алсу.

—Икенче группа бирделәр...

—Хәерчегә җил каршы! Әле генә рәтле акча алып эшли башлаган иден,—дип сыкранды Разия.

—Борчылма, әни, озак түгел, терелгәч тагын эшләр. Әйе бит, Исхак?

Исхак "әйе" дигән мәгънә белдереп, башын селекте, ә Разия кабынып китте:

—Терелерлек кешегә икенче группа бирмиләр...

Өй эче авыр тынлыкка чумды. Агуын чәчеп качкан елан сыман, әйтәсе сүзен әйтте дә, Разия кухня ягына чыгып китте. Алсу башта агарынды, аннары кызарынды, әйтергә сүз таба алмыйча, хәлсезләнеп, диванга

шуып төште. Укның агулысы Исхакка эләкте. Ул мона әзер иде һәм шуна күрә, бик читен булса да, ирләрчә кабул итте. Сүз куертуны, эче бушаганчы ачу чыгаруны кирәк санамыйча, тын гына утырды да, йокы бүлмәсенә кереп, тәрәзә янына барып басты. Июнь кояшы баеп килә иде. "Авылда кояш матур байый",—дип уйлап, Исхак былтыр авылда баскыч төбендә утырып кояш баюын карап торуын исенә төшерде һәм ямансулап, туган авылын сагынып куйды. "Димәк, кадер эшләгәндә генә. Хәзер мин әби өчен беркем түгел... Ичмасам фатир да бирмәделәр. Алсу чыкмаган тәкъдирдә үзем күчәр идем, аннары ул да килер иде. Юк! Килмәве дә бик мөмкин. Анасы җибәрмәс. Җибәрсә, барыбер килеп, җаннарын игәр. Әлегә котылуның бердәнбер дөрес юлы—авылга китеп тору. Мин дә уйланыйм, алар да уйлансыннар,"—дигән карарга килде Исхак. Авылны искә төшерү аңа бераз җиңеллек бирде. Кайтса тәмам сихәтләнердәй тоелды.

Аяк очларына гына басып, Алсу керде, Исхакка якынлашты, аркасына кулын салды:

—Чишен, Исхак, ашыйбыз,—дип, костюм төймәләрен ычкындыра башлады. Исхак сүзсез генә Алсу артыннан иярде. Кулын чайкап, кухня ягына керде. Разия анда юк иде. Алсу әйтеп куйды:

—Әни Маһира апаларга китте. Кунмакчы...

Кәефне тәмам кырып чыгып китеп, Разияның бер кич кунып кайтуы гына Исхакка ниндидер шатлык өстәми иде.

—Иртәгә авылга китәм. Алмаш киемнәр әзерлә. Балалар да миңа иярсәләр яхшырак булмасмы?—дип, Исхак уен хатынына белдерде.

—Авылга китүең әйбәт булыр. Тизрәк савыгырсың. Балаларны ияртми тор әле. Бәлки, бергәләп тә барып чыгарбыз. Миңа ял бирмәсәләр, самолетка утыртып озатырмын. Каршы алырсың,—диде Алсу иренен фикерен куәтләп һәм ризалашып.

—Кайтсагыз, начар булмас. Яна өйне дә күргәнегез юк бит әле,—диде Исхак, хатынының күзләренә туры карап. Алсуның күзләрендә бер нинди ясалмалылык сизелмәде: әвәлгечә сөйкемлеләр, тутырып, эчкерсез карап торалар.

—Балалар укып бетерү белән кузгалырбыз,—диде Алсу.

Исхак еракка күз текәп, офык өстендәге ак болытларга карап уйга чумды. Алсу аңа берничә тапкыр эндәшеп карады, ләкин Исхак хатынының сүзләрен ишетмәде. Иренең авыр хисләр кичерүен чамалап, Алсу аны башка мазасызлыйсы итмәде, акрын гына атлап килеп, янәшә басты.

—Минем бу өйдән артыр көннәрем дә килеп житте,—диде Исхак, үз алдына сөйләнгәндәй көрсенеп.

—Юкны сөйләмә! Мин булганда син артмаячаксың...

—Сезгә дә килер бу көн,—диде Исхак карашын болытлардан алмыйча.

—Син иртәгә ничек китмәкче буласың соң әле? Самолетка билетың да алынмаган,—диде Алсу, сүзне башкага күчерергә теләп.

—Поезд белән китәрмен...

—Озата барырмын.

—Ә эшен?

—Иртәгә ял.

—Ә-ә,—дип сузды Исхак.—Эшләмәгәч, мин хәзер көннәр исәбен дә онытып бетердем инде...

... Өйләдән соң вокзалга юл тоттылар. Исхак үзе утырасы вагонга кечкенә чемоданын куеп, Алсуны озата чыкты.

—Кайт син, мин китәрмен. Балаларны каршылыйсың бар,—дип хатынын җибәрү ягын карады.

—Житешермен. Сине озатмый китмим,—диде Алсу.

Сүзсез калдылар. Исхак Алсуны кулыннан алды һәм аны ике кулы белән кысып, йөрәк турысына китерде.

—Алсу, бәлки, син минсез дә яшәрсен. Мин—гарип. Минем аркада бәхетсез булма... Кулдан килгән кадәр балаларга ярдәм итәрмен,—диде Исхак, хатынының күзләренә карамаска тырышып.

—Ни дигән сүз инде бу, Исхак?..

—Яшермә, әниең сиңа миннән аерылырга куша бит?...

Алсу елап җибәрде. Исхакка хатынының күз яшьләрен күрү авыр иде. Нигә бу хакта сүз куерттым икән, дигән көнгә төште, Алсуны юатырлык сүзләр таба алмады.

—Алсу, безнең сөйләшенмәгән бик күп сүзләребез кала. Авылга кайт. Рәхәтләнеп эчләрне бушатырбыз,—диде Исхак һәм вагон баскычына басты.

—Кайтам, кайтам... Әлбәттә, сөйләшербез,—диде Алсу, елавын басарга теләп.

Поезд кузгалды. Исхак тәрәзәдән башын тыгып караганда, Алсу урынында басып тора иде. Ирен күреп, кулын болгый-болгый, поезд артыннан йөгерде...

Иртәгесен Алсу эштән кайтып кергәндә, диванда таныш түгел бер ир утыра иде. Алсу чишенүгә, ир киенә башлады. Алсу аңа "исәнмесез"дән башка сүз катмады. Әнисе бөтерелеп, "кызым", "кызым", дип үрсәләнсә дә, ишетмәмешкә, күрмәмешкә салынды. Алсуның кәефсезлеген сизеп булса кирәк, ир китәргә ашыкты.

—Зариф абыең бу. Безнең хәлне белергә килгән...

Алсу үз гомерендә әнисе янына бик күп "абый"ларның килгәнен күреп үсте. Бу юлы да аның күңеле шик сизде. Шулай да, белмәмешкә салынып:

—Кайсы Зариф?—дип сорады.

—Әтиеннең авылдашы... Ераграк туганы.

—Алай икән,—диде Алсу сузып кына.—Моңа чаклы бер дә килеп хәл белгәне юк иде...

Шимбә көнне Алсу, ял булудан файдаланып, өй җыештырды, келәмнәрне чыгарып какты. Балалар мәктәптә иделәр, соңгы көннәрен йөриләр. Соңгы келәмне кагып бетергәч, шунда эскәмиядә утырган Фатыйма карчык янына килде.

—Утыр, Алсу кызым, күп эшләден, бераз тын ал,—диде Фатыйма, утырырга үз яныннан урын күрсәтеп.

—Утырып ук торып булмас инде, Фатыйма апа, эш күп.

—Эшнең бер чакта да беткәне юк. Үзең үлгәч тә өч көнлек эш кала, диләр бит.

—Бетми инде ул бетүен... Балаларны юлга җыендырасы бар, диюем.

—Кая китәләр?

—Әтисе янына...

—Алай икән! Бик әйбәт... Кызым, ачуланмый гына әйт әле, кеше сүзе инде, шулай да сорыйм.

—Сора, сора, Фатыйма апа.

—"Әниең йортка ир кертә икән. Исхак фатир юллап чыгып киткән икән",—дигән сүз йөри, хак түгелдер бит, кызым?—диде Фатыйма, пышылдый ук төшеп.

—Юк, Фатыйма апа, Исхак авылга кайтып китте. Әни турында кем чыгаргандыр—белмим. Андый сүз ишеткәнем юк,—диде Алсу, үзе дә гаҗәпләнеп.

—Һи-и, кызым, бөтен подъезд сөйли. Көн саен килә бит Зариф дигән бер нәмәстәкәй...

"Өендәгесен күршеңнән сора",—диләр, хак икән. Килгән кешенең исеменә кадәр беләләр! Утсыз төтен чыкмый, Разияның бу арада кинәт кенә үзгәрүе сәбәпсез түгел. Йортка кертү теләге бар икән, нигә ачыктан-ачык әйтми? Алсу да, Исхак та, балалар да бирегә ябышып ятмыйлар. "Ачык авыз ачка үлмәс",—диләр, эшләп торабыз, Исхакның да пенсиясе ярыйсы гына. Фатирын да юнәтербез. Әллә биреп тә куярлар. Исхакның чираты житеп килә иде бит. Бәлки, инвалид буларак, беренчеләр рәтендә эләгер",—дип уйланды Алсу.

Әнисе белән Алсу арасында сөйләшү кыска булды.

—Әни, син Зариф абыйны йортка кертәсеңмени?—диде Алсу, сүз

иярә сүз чыккан кебек кенә итеп. Разия бер мәл телсез калды, кызарынды, ык-мык килде һәм, ниһаять:

—Кем чыгарган сүз?—дип әйтә алды. Тавышы акрын чыкты. Нахактан ишеткәне булса, күзгә-башка ябышыр иде. Алсу да шулай анлады һәм, бер дә исе китмәгәндәй:

—Өй тирәсендә генә түгел, урам буйлап сөйли башлаганнар инде,—диде.

—Гайбәт тиз тарала...

—Дөресен әйт, әни, хак эш икән, тел яшереп торуның мәгънәсе юк.

—Мәгънә юк дип, мин дә кортка түгел бит әле. Кырык бишем генә тулып китте. Синең ир белән торасы килгәнне минеке килми дисеңмени? Әле дә ялгызым ничә еллар яшәдем...

Әнисенең күп ирләр кулыннан үтүен яхшы белсә дә, Алсу бу хакта сүз куертеп торуны кирәк санамады.

—Әни, теләгәнеңне эшлә. Сиңа бер сүзем юк. Әгәр йортка кертү уең бар икән, керт кенә. Без үз җаебызны җайларбыз...

—Чирле ир беләнме?—Разия керпеләнеп маташты.

—Чирле ир белән дә... Авылга китәбез без!

—Анда нишләрсез?

—Исхак—төзүче-инженер. Аңа авыл ни, шәһәр ни! Район үзәгенә урнашырбыз. Җае чыгар әле,—диде Алсу.

Башта Разия кызы шаяртыбрак сөйләшәдер, дигән фикердәрәк иде, соңгы сүзеннән эшнең алай түгеллеген төшенде.

—Авыл хәерчесе буласың киләмени?

—Шәһәрнекеннән ни аермасы?—диде Алсу.

Балалар кайтып керде. Разия аларга дәште:

—Әнә, әниегез сезне авылга алып китә!

—Ура!—дип дәррәү кычкырдылар балалар.

—Ашыкмагыз әле! Бөтенләйгә алып китә, татарча укырга,—диде Разия, оныкларын куркытырга уйлап.

—Укыйбыз!—диделәр Фәнис белән Әнис.

Разия хәлсезләнеп диванга шуып төште. Ир кертсә дә, аның өмете кызын шәһәрдә калдыру, яңа шәп кияү табуда иде.

Балаларының куанычы Алсуны тынычландырды. Ничектер, ул үзен элек-электән авылда яшәгән кешедәй, аннан вакытлыча гына аерылып торгандай хис итте.

* * *

Хисмәтулла, нәсел тамырының нигезгә ныклап торып ябышуын күреп, ирексездән бәреп чыккан шатлык яшьләрен тыярга да теләмичә, рәхәтләнеп елады. Моннан да олы бәхет бармыни аның өчен?

—Рәхмәт, оланнар, аеруча сиңа рәхмәт, килен,—дип, кабатлап туймады Хисмәтулла.

Әтиләрен ике яклап кочаклаган малайлар бабаларының сабыйларча сеңеп, елап утыруына гаҗәпләнеп карап тордылар...

# ШИГЪРИЯТ

## ПАР АККОШЛАР АРАСЫНДА...



*Гаҗәеп дәрәҗәдә тынгысыз җанлы шагыйрә Нәҗибә Сафинаның иҗаты, әлбәттә, чын игътибарга лаеклы иҗат. Туган ягы Башкортстанда иҗади гына түгел, сәяси даулар уртасында кайнап, Казан дөньясына чумганына байтак инде аның.*

*Саҗидә Сөләймановага багышлап язган шигырендә шагыйрә үзенең туган ягы—Яңавыл төбәге хакында болай ди:*

Яңа авыл түгел, ян авыл да.
Җан авыл ул, дуслар, җан авыл!
Туып үсү түгел, бер күрсәң дә
Мәңгелеккә җанда кала ул.

*Нәҗибәнең шигъриятенә нәкъ шушы моң һәм моңны раслау-яклау дәрте хас.*

*Тоташ иҗат белән яши ул. 1997 елда шагыйрә безгә "Таң кошы" исемле китабын бүләк итте. "Аккош күле" исемлесе дә нәшрият "табасыннан" төшеп килә икән.*

*Шагыйрә балалар өчен дә бик тә яратып яза. 1996 елда аның "Кош теле" дигән китабы нәниләр кулына барып иреште. Һәм, иншалла, дөньялар бераз рәтләнсә, балалар аның "Мәче фәлсәфәсе", "Кырмыска ник очмаган?" "Камка һәм яфрак капка", "Вакыт һәм Вахит", "Әнисенең әнисенең әнисе" һәм "Таң алдыннан" исемле китапларын да укып сөенер дип өметләник.*

*"Таң кошы" китабына исем биргәндә Нәҗибә татарның туып килгән таңын күздә тоткан. Шул таң өчен җанын ярып бирергә әзер булып яши ул.*

*Нәҗибәнең әнкәсе үлем түшәгендә ятканда шигырь әйтеп бәхилләшкән:*

Килдем, инде китеп барам—
Барасым бар!—
Җирнең минем белән ямар
Ярасы бар!

*Нәҗибә татар шигъриятенә очраклы рәвештә генә килеп кермәде— аны үз урыны көтә иде. Шигъриятнең вазифасы да шул—җаннардагы яраларны сихәтләү, аңарга шифа кылу...*

*Менә шул изге сукмактан читкә атлатмасын сине, язмыш, Шагыйрь!*

*Һәр көне шигырьле булсын шагыйрьнең! Үз шигырендә әйтелгәнне үзенә теләк итеп телик бүген:*

... Ялган назлар миңа тимәсен.
Пар аккошлар арасында булсын
Язмышымның ялгыз көймәсе!

ЗӨЛФӘТ

# Нәҗибә Сафина

## Җанавылда туып үскән без

*Сәҗидә Сөләймановань*
*искә алу кичәсендә*

Кай җирләрдә туып үскән диләр,
Нинди җир ул диләр, Яңавыл?
Яңамы ул, әллә ян авылмы?
Шигырь булып җанда яна ул!

Һәр адымы белән яңа ул!

Галим-голәмәләр, баш ватмагыз!
Ян диеп тә, яңа диеп тә.
Җаныбызны яшереп яшәдек без,
Моңга салып, янып, көеп тә.

Ул эндәште безне биеккә!

Яңа авыл түгел, ян авыл да.
Җан авыл ул, дуслар, җан авыл!
Туып үсү түгел, бер күрсәң дә,
Мәңгелеккә җанда кала ул...

Аксакал ул, сабый бала ул!

Инде бүген килеп сер чишәбез:
Җанавылы туып үскән без.
Сәҗидәләр, Нәҗибәләр булып
Шигырь дөньясына күчкәнбез.

Моң касәсен чумырып эчкән без!

Ишмораты, Гайнан Әмирие,
Нуриханы, Илдар Юзие!—
Җанавылда булган кешеләргә
Шәһре Казан һәрчак үз өе.

Җанавылның анда үз көе!

Һәр татарга кадерле ул Казан,
Дошман гына аны алганмы?!
Үз баласы итеп каршылый ул
Җанавылдан килгән җаннарны...

## Пар аккошлар арасында

Ташла да кит әйтми-нитми генә,
Ялган назлар миңа тимәсен.
Суын түгеп, ялгызым да ишәм
Язмышымның ярык көймәсен.

Диңгезләргә таба омтылгандай,
Мәңгелек яр эзләп тукталам.
Үз ярымны тапмый укталудан
Мин туктамам сыман, туктамам.

Хыялымда моңсу күл өсләре...
Төнбоеклар чәчәк аталар.
Дулкыннарда һаман толым чайкый
Яшел камыш, зифа ак таллар.

Күңел күгем өсләрендә йөзә
Ак аккошлар, кара аккошлар.
Күңелемнең төпләрендә йөзгән
Үземнән дә яшерен аккош бар.

... Ташла да кит, әйтми-нитми генә—
Ялган назлар миңа тимәсен.
Пар аккошлар арасында булсын
Язмышымның ялгыз көймәсе.

## Мәхәббәткә күз йому

Очрашабыз, хушлашабыз,
Аерылышып китәбез.
Китәбез дә тагын шулай
Очрашуны көтәбез.

Юкса, бар бит, бар бит инде
Аралашу чарасы.
Хатлар бара, якын—дәшсәң,
Телефоннар арасы.

Әмма ләм-мим без дәшмибез,
Чөнки юк әйтер сүзләр.
Китәбез дә көтәбез без—
Кайчан очрашыр күзләр.

Шулкадәрле мәхәббәтне
Сер итеп саклыйбыз бит.
Бер-беребезгә сиздермәүне
Ничектер аклыйбыз бит.

Без аклыйбыз, ә мәхәббәт
Булалмый икейөзле.
Берчак җанны ярачак та
Ачачак эле күзне.
Фаш итәчәк ул безне.

## Төшләр...

Төшләр...
Искәртеп торалар:
Сөю калган үткәндә.

Тирәнәя яра, Сөю
Җәрәхәтләп киткәнгә.

Төшләр...
Кабатлап торалар:
Кабатлама хатаны,
Чын булса, сөю югалмый,
Эзлә, эзлә, тап аны.

Төшләр...
Юатып торалар:
Табылыр, елама, дип.
Үткәннәргә хатлар бармый,
Хатларың юллама, дип.

Төшләрне
Тыңламый хисләр.
Кабатлый хаталарны.
Үткәннәргә хатлар язам,
Табачак хат ул ярны.

Төшләрдә
Хаклык бар барын.
Чын мәхәббәт югалмый.
Язны үзең яса икән,
Язсыз ташкын юл алмый.

Ә без
Күзләргә керәбез.
Язда кызыл алма юк:
Күкләргә аша күңелләр,
Имеш, җирдә Алла юк.

Төшләрдә
Алма бирәсең.
Алмалар пешкән дә бит.
Алма исләрен китерә
Җилләре искәндә тик.

## Синең күзләр

Көзнең сары яфрак яңгырыдай
Түгел әле, сагыш, җанымнан!
Сагышлардан бераз бушап калсам,
Мәхәббәткә шулай ялынмам.

Кышның ап-ак бураннары кебек
Ак җилләргә салыйм уйларны.
Юк та диеп белим дөньялыкта
Була алмый калган туйларны.

Язның ярсу ташкыннары булып
Ник кайтасыз, хисләр, тагын да?
Мәхәббәтне инкарь итеп кара
Дөнья чәчәк аткан чагында.

Күзнең сары сагышларын чабып,
Эскерт-эскерт өям җаныма.
Зәңгәр гөлләр кереп оялаган
Сары сагышларга, йа Хода...

Синең күзләр...

## Зәңгәр юрган

Җәй иде бит,
Нидән өшедек без?—
Юрган эзләп киттек ябынырга.
Җаныбызда әллә сүнгән булган
Сөю дигән учак, табынырга?

Көз иде бит,
Инде аерылдык,
Башкаларга киттек яр булырга.
Агачларда сары яфраклар тик
Пышылдашып калды: "Зар булырга..."

Кыш иде бит...
Нигә ябынмыйбыз
Шуып төшкән зәңгәр юрганны без?
Ничек җиңел генә җимергәнбез
Сөю кадәр сөю корганны без...

... Читтә ята
Зәңгәр боздан сырган юрганыбыз!

---


# Игътибар: льготалы подписка!

***Кадерле әбунәчеләребез, укучыларыбыз!***

***"Татарстан почтасы" идарәсе һәм "Казан утлары" редакциясе 1999 елның икенче яртысы (июль-декабрь айлары) өчен льготалы подписка игълан итте. Ул шушы елның 10 февраленнән башланып, 31 марткача дәвам итәчәк. Журналыбызга язылу бәһасе - 1999 елның беренче яртыеллыгындагыча - 6 айга нибары 24 сум. Каталогтагы индексыбыз - 73210. "Казан утлары" сезне яңадан үз яктысына, үз җылысына чакыра, мөхтәрәм милләттәшләр!***

Чәчмә әсәрләр

# ПАР КАНАТЛАР ТАЛМАСЫН

*Миргалим Харисов белән танышып китүем алтмышынчы еллар башында булды. Ул Мәскәүдә театраль югары белем алып кайтканнан соң, милләтебезнең баш сәхнәсендә—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйный башлагач.*

*Студент елларында ук каләм тибрәтә башлаган егет, балачактан канында уйнаган иҗат чаткысын сүндермичә, әдәбият мәйданына килде.*

*Язучы буларак, укучы хозурында беренче имтиханын ул бик гади, мәгәр бик чынлыклы "Тәзкирә" хикәясе белән тотты. Бу хәл аның беренче китабына (1966) исем табуга сәбәп булды.*

*Журналистлык стажы да шул еллардан башланды. Әйтергә генә ансат: утыз ике ел редакциядә! Әдәби хезмәткәр, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, баш редактор урынбасары.*

*Әдәби хәзинәсе күркәм Миргалим Харисовның. Алда телгә алынган китабыннан соң ул "Кызыл планетага сәяхәт" дигән маҗаралы повестен бастырып чыгарды (1967), "Сабыйлар хакына" дип исемләнгән пьесалар җыентыгын (1969), "Ватан нидән башлана" дигән хикәяләр тупланмасын укучыларга бүләк итте (1971). Шунысын да әйтик, "Кызыл планетага сәяхәт" повесте үзбәк һәм болгар телләрендә дә басылып чыкты.*

*Миргалим Харисов—пар канатлы каләм иясе. Бер канаты—үзе иҗат иткән драмалар, повесть, хикәяләр булса, икенче канаты—тәрҗемәләгән әсәрләр. Бу җәһәттән аның тырышлыгы күпләрне сокландырырлык.*

*Сәхнә әсәрләре оста язылганнар. Ул театр кануннарын теоретик яктан да, гамәли тарафтан да әйбәт белә. Аның бер пәрдәлек пьесалары—"Сабыйлар хакына", "Бабай", "Ачык авыз", "Тук башак җиргә иелә", "Чәчмәгәнне урмыйлар"—башлыча мәктәп сәхнәсенә атап язылганнар.*

*Миргалим Харисовның прозасы чынбарлыкны иннек-кершәнсез, бизәмичә, нәкъ тормыштагыча тасвирлавы белән күңелгә ятышлы. Ул үзенең персонажларын мөнбәргә дә күтәрми, түбәнсетми дә, аларны гайре табигый шөгыльләр белән дә изаламый, сөйләшүләрендә дә ясалмалык юк. Персонажлар теле күп очракта индивидуаль, автор сурәтләве геройлар сөйләшеннән сизелерлек аерыла.*

*Авторның һәммә хикәяләренә диярлек халыкчан җорлык хас.*

*Хикәяләрдә кызыл җеп булып сузылган бер фикер ачык абайлана: теләсә нинди шартларда да адәм баласы КЕШЕ булып калырга тиеш, дигән фикерне үткәрә язучы. Безнең заманда моннан да кыйммәтлерәк сыйфат юк, чөнки тормышыбызда тискәре гадәтләр нык баш калкытты, әхлаксызлык канат җәя. Матди хәл иртәме-соңмы яхшырыр, акча девальвациясе узар, ә менә әхлак девальвациясенең озакка сузылуы бик ихтимал.*

*Бер җөмләгә сыйдырып әйткәндә, Миргалим Харисов прозасы—сугышчан проза, мораль югарылык өчен көрәшче проза.*

*Юбилярның пар канатларыннан янә берсе—тәрҗемәче буларак кылган эшләре. Аның каләме аша татарча яңгыраган әсәрләрне тиз генә санап чыгуы да ансат түгел.*

*Иң әүвәле үтә җитди темаларга язылган әсәрләрне атыйк.*

*Миргалим-каләмдәш тарихи- публицистик "Д.И.Ульянов" (С.Я.Чикин әсәре), "Ленин турында хикәяләр" (авторлар коллективы), "Зинин" (Л.*

*Гумилевский), "Гафурлар гаиләсе" (Г. Шәрипова) дигән китапларны, "Дуслык аланы" (авторлар коллективы) җыентыгындагы берничә хикәяне туган телебезгә күчерде.*

*Тәрҗемәләүче Миргалим Харисов активына тагын Николай Чуковскийның "Кыю капитаннар" (русча исеме—"Водители фрегатов") әсәрен, Нодар Думбадзеның "Мин кояшны күрәм" повестен, Диас Вәлиевнең "Тормыш бүләк итәм", "1887 яки тәңребез бер—Хәрлек" драмаларын да кертсәк, аның колачы матур мәгънәсендә көнләшерлек булуына ышанырбыз. Чыны шул: Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Миргалим Харисовның эшчәнлеге алда тасвир кылганнар белән генә дә чикләнми. Әсәрләре дә алда атаганнар гына түгел. Ул бик күп киносценарийлар тәрҗемә итте. Агитбригадалар өчен дистәдән артык сценарий язды. Шунысын да өстик: Миргалим Харисов өлкән һәм замандаш каләмдәшләре Г. Бәширов, М. Галәү, Ә. Еники, К. Нәҗми, Г. Әпсәләмов,А. Гыйләҗев, А. Расих, Р. Мөхәммәдиев һәм башка әдипләребез әсәрләре буенча радио-телевизион инсценировкалар да иҗат итте.*

*Пар канатлы язучыбыз Миргалим Харисов бүген дә каләмен кулында нык тота. Ул каләмнең күгәрмәсенә ышаныйк.*

*Түбәндә "Казан утлары" журналы укучыларына Миргалим Харисов тәрҗемәсендә Җәүдәт Ильясовның "Тынлык манарасы" әсәреннән өзек тәкъдим ителә.*

**Барлас КАМАЛОВ**

**

# Җәүдәт Ильясов

# ТЫНЛЫК МАНАРАСЫ

БӘХЕТСЕЗ ШӘЕХ, ШАГЫЙРЬ, ГАЛИМ ӘБЕЛФАТЫЙХ ГОМӘР ХӘЙЯМНЫҢ УҢЫШЛАРЫ ҺӘМ УҢЫШСЫЗЛЫКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ ХИКӘЯТ

## Сагыш китабы

*"Бу дөньяда син акыллы,—соң шуннан?*
*Чәчәсең фикер дә киңәш,—соң шуннан?*
*Йөзгә кадәр яшәрсеңме? Яшә соң.*
*Бәлкем ике йөзгә җитәрсең. Соң, шуннан?.."*

—Саксаулмы ул?—дип сорады кәрванны озата баручы.

—Әйе, шул бугай. Корыган ике ботак бер-берсенә береккән. Вак ботаклары юк, аларын җил сындырган. Карале, моннан бит ул гелдә шәрә хатын кебек күренә.

—Була бит дөньяда могҗиза! Кәрван озатып күпме йөрим инде, моңдыйны күргәнем юк иде әле...

Җәүдәт Хәсән улы ИЛЬЯСОВ (1929) *Урта Азиядә эшләгән татар язучыларыннан берсе. Үзбәкстан нәшриятларында урыс телендә басылып чыккан "Согдиана", "Ук һәм кояш", "Тимгелле үлем" һ. б. китаплар, киносценарийлар авторы, тәрҗемәче. Җәүдәт Ильясов иҗатында дөнья әдәбияты классигы, шагыйрь һәм галим Гомәр Хәйямның тормышына багышланган "Еланнар әфсенләүче" һәм "Тынлык манарасы" повестьлары аерым урын алып тора.*

Исең китәр: корыган ике ботак бәләкәй гәүдәле шәрә хатынга шундый охшаган, әйтерсең лә, башын иеп, тынып калган да кәрванның бакыр шөлдерләре чылавын тынлый. Хәтта чәче дә бар—куе, куппы, хорафатларга ышанучы кемдер корыган ботакка сарык тиресе элеп киткән диярсең. Юл тирәсендәге куаклыкларга һәрвакыт ни дә булса эленгән була... Җирле әрвахларга бүләккә...

Шулчак Гомәрнең башы шаулый башлады, аяклары калтыранды. Бер кара таш, күкрәктән тамакка менеп, тын юлын каплады. Теге... корыган ботак... дигән нәмәрсә кинәт сулыш алды, бер аягыннан икенчесенә басты һәм... күзләрен ачты. Гомәр күрде: бернинди дә, корып, бер-берсенә ябышкан ике ботак түгел, нәкъ менә шәрә хатын-кыз иде бу!

—Син кем?—дип, башка ни әйтергә дә белмичә, коты очып фарсыча сорады Гомәр һәм аңа кулын сузды.

Куркынган мизгелле карашта ул үзенә карата булган кечкенә генә кызыксыну очкынын тойды. Хатын, очлы азау тешләрен күрсәтеп, карлыккан тавыш белән кычкырып җибәрде, аннары кинәт кенә борылды һәм түбәнгә—ком өеме итәгенә очты.

—Ул соң... ялгыш, күземә генә күренде ме?!—дип мыгырданды аптырашта калган Гомәр, әлеге шәүлә көньякка—ерактагы бархан артына китеп югалгач.

—Юк, син ялгышмадың. Мин дә күрдем аны. Нас-нас ул—чүлдәге кыргый хатын. Ишеткәнең бар идеме?

—Бар иде. Әмма әкият дип уйлыйдыр идем.

—Менә хәзер инде үз күзләрең белән күрдең. Син, туганкай, аны онытырга тырыш. Юкса гомерең буе эзәрлекләр ул сине.

Ул аны тупас яңгыраган Нас-нас урынына Зәнге Сәхра—сәхра кыңгыравы дип атады.

Хыялмы?

Һәркемнең чыңга ашмаган Зәнге Сәхрасы була.

Куптәннән булды инде бу. Моннан егерме дүрт ел элек. Яшүсмер Гомәр туган шәһәре Нишапурны ташлап, бәхет эзләп, данлыклы Сәмәркандка барганда.

Тик кайда соң ул бәхет?

"Дөнья Аристотельдән дә акыллырак башка берәүне белмәде. Аның тирән акылы борынгыда кабул итә алырлык барлык гыйлемнәрне колачлады һәм бергә туплады. Афинаның Ликея мәктәбендә укыган нотыкларын ул йөз илле томга җыйды. Алар арасында фәлсәфи "Метафизика" һәм логика, физика, зоология, психология буенча трактатлар: "Категорияләр", "Аңлатулар турында", "Аналитика", "Топика", "Физика", "Килеп чыгу һәм юк ителү турында", "Күк турында", "Хайваннар тарихы", "Хайваннарның барлыкка килүе турында", "Метеорологик сораулар турында", "Хайваннарның хәрәкәтләнүе турында", "Җан турында трактат" бар. Галим аларда шулай ук этика һәм поэтика, риторика, сәясәт мәсьәләләрен дә читләтеп үтми".

Көнләшерлек! Күңелдә—әрнүле газап. Ул бөек грек ирешкән биеклекләргә беркайчан да менеп җитә алмаячагына кайгыра. Бәлки менә дә алган булыр иде. Тормышы башкачарак юлдан киткән булса...

Җәйге иртә. Таңда сайрашып, шәүләгән, майн, миләш чыпчыклары азык эзләп таралыштылар.

Торды. Әлмирраның җылысын саклаган урын-җирне җыештырырга дип ятагы янына килде. Ул кызыл беренче урман күгәрченe гөрли башлагач ук тәрәзәдән чыгып шылды. Гомәр япманы җинел генә селкеп куйды—аннан йомшак, нәфис ис бөркелде. Төрек кызыннан чыннан да мирра[1] исе аңкый иде шул.

Юк, урынын җыймасын әле. Әйтерсең лә, ул әле дә биредә, аның янында. Яратып, Гомәрнең ничек язганын карап ята шикелле.

Тиздән чынлыкта да шулай булса иде. Ул инде аңсыз яши алмый. Дәшмәсә дә, аның янында булсын. Төнлә генә түгел, көндезен дә. Иртә, кичен, җәен, кышын—һәрвакыт янында булсын ул аның. Ичмасам картлык көнендә җан тынычлыгы булыр иде.

[1]Мирра—хуш исле сумала.

Юньлерәк бер кеше табарга да яучыларга Әлмирраның апасына җибәрергә. Яшерен эшләр беленгәнче...

Көн саен эшләргә җыена инде ул моны. Төн уртасында Әлмирра баскычтан аның янына төшкән, аннары, чак яктыра башлагач, шул ук баскычтан сак кына өскә менеп киткән минутларда ул үзен сорау алырга чакырылган җинаятьче кебек каушап, бөкерәеп кала, агарына.

Аны кем дә булса күрсә ни булыр? Әйе, җитте! Мөнәсәбәтләрне канунлаштырырга вакыт.

Әмма кыз китү белән үк Гомәрнең күңелендә, әкияттәге ач елан сыман, инде әллә кайчан яза башлаган "Голәмалар турында китап" гаме уяна. Уяна да, шул китап турындагы бетмәс-төкәнмәс уйлар әлеге борчылуларны каплап китә. Бу уйлар аны, теш сызлагандай,—хәер, ул бу хакта ишетеп кенә белә,—көн буе җибәрмиләр. Шулай булгач, бөтенесенә кул селтәп, яучы эзләргә чыгып китү җаен таба алмый.

Ә төнлә, Әлмирра белән бергә булганда, куркү хисе бөтенләй бетә. Өлгерер әле! Моның бит бернинди әһәмияте юк. Барыбер аныкы бит инде ул кызый.

Гаҗәеп халәт иде бу. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. "Әй картлач, әй дивана картлач..."

Нидән курка соң әле ул? Үз намусы каршында чиста лабаса Гомәр. Бербесен яраттылар алар. Язмыш дип әйтергә була. Икәвесенә бергә чакта бик тә яхшы, шулай булгач, нигә әллә нинди кануннар турында баш ватарга? Җирдә мәхәббәт дигән хис беренче дини ышануларга кадәр үк, әллә кайчан барлыкка килгән. Шуңа күрәдер ул хәтта дингә дә буйсынмый.

Бер килгәндә Әлмирраның йөзе-бите күгәргән-кабарган иде.

—Ни булды сиңа?—Күкрәгенә кысар өчен биленнән тотканда Гомәрнең иреннәре һәм куллары калтыранды.—Караңгыда баскычтан егылдыңмы әллә?

Төрек кызы кинәт аннан аерылып, сәкегә барып утырды.

—Баскыч үз урынында. Апам шулай "иркәләде". Сине сихерче диләр бит, шуны терелә алмаслык берәр авыруга сабыштыр әле.

—Ә ни өчен җәберли ул сине?

—Күралмый. Хәерчелектән микән әллә? Ашаган ипиемне кызгана, мине артык кашыкка саный. "Синең аркада икенче тапкыр кияүгә чыга алмадым",—ди. Мин аның белән бергә ул тол калгач яши башладым. Ятим мин. Булышмыймыни соң инде мин аңа? Менә кулларым йөк ташучыныкы кебек сөялләнеп бетте бит инде!

Әлмирра Гомәргә балаларныкыдай кечкенә кулларын күрсәтте.

Гомәр, кызганып, аның күпергән иреннәренә карады.

—Синең апаң терелерлек түгел инде. Нык кыйныймы?

—Кызганып тормый ул убырлы.

—Ә бит сездә гел тыныч, тын-тавыш ишетелми ич.

—Әй! Хәйләкәр ул. Бөтенесен тавышсыз гына эшли. Күршеләрдән курка. Мин дәшмим—ачудан. Ул әкренләп мине чыгырымнан чыгара, ә мин—аны. Шулай итеп, тавышланмыйча гына бер-беребезнең җанын кыйныйбыз. Апам инде акылдан шашты, озакламый мин шашачакмын. Өйлән миңа, коткар!

Кызның шигырьләре аңа күп нәрсәне аңлатты:

> "Түз һәм тыңла. Ела, каршы әйтмә...
> Бар дөньясы тулы төрмә, җәтмә;
> Әллә инде шайтан кочагына ташланырга,
> Әллә тәмугка тыгасы башларымны?!"

Әйе, бөтенләй дә өметсезлеккә бирелгән бичара. Холык та инде үзендә! Хәлдән котылуның мондый юлын теләсә кем таба алмый шул! Ярый, шайтаннан мин кай җирем белән ким? Бүген үк чыгып китәм яучы эзләргә. Менә шушы битне генә язып бетерәм дә китәм.

Гомәр өстәл янына утырды һәм каләмен карага манды.

Шулай итеп, Аристотель...

"Соң, шуннан? Замандашлары бу даһины соңыннан аның акылдан язган шәкерте—Искәндәр Зөлкарнәйн патшаны зурлагандай зурлаганнардыр. Алла

урынына кургәннәрдер, ана баш игәннәрдер, күтәреп кенә йөрткәннәрдер, дип уйлыйсызмы? Алай булмый торсын әле! Аны денсезлектә гаепләделәр, Аристотельгә качарга туры килде. Ул читтә, Халкидта, электән үк килгән ашказаны җәрәхәтеннән вафат булды..."

Даһиларның да була ул ашказаны. Юкса, бер уйласаң, аларга һич керәге юк аның. Артык бер мәшәкать кенә. Даһиларның эше—уйлау. Аристотель алтмыш ике яшендә үлде. Безгә әле нибары кырык алты. Ашказаны авыртудан үлмәбез, шәт. Чөнки андый авыруыбыз юк. Булмас та. Кем әйтмешли, Алла боерса, әлбәттә. Ә менә качарга... бәлкем, тагын туры киләчәктер. Яшь вакыттагы кебек.

Ярый, күз күрер әле тагын.

Хәзер инде Фирдәүси хакында. Шул нисбәттә без галимнәр белән шагыйрьләрнең тормышын сурәтләүне аралаштырып барырбыз. Шагыйрь кай ягы белән галим түгел? Ул әле югарырак та. "Поэзия тарихтан фәлсәфирәк һәм житдиерәк,—дип язды акыл иясе Аристотель, чөнки поэзия күбрәк гомуми төшенчәләр, образлы фикерләү аша эш итә, ә тарих конкрет нәрсәләр турында яза".

Соң, алайга калса, конкрет дигәне гомуминең бер өлеше түгелмени инде?

"Әбелкасыйм Фирдәүси күпләгән сугышчы бирердәй зур Бадж авылыннан, бай диһканнар—Тус игенчеләре нәселеннән чыккан.

Киң сөрү җирләре, җиләк-җимеш һәм йөзем бакчаларыннан алынган керем аркасында ул муллыкта яши, кемнеңдер акчалата ярдәменә мохтаж булмый".

"Менә безнең хакта болай дип әйтеп булмый инде",—дип көлемсерәп уйлады Гомәр Хәйям.

"Ул үзенең даһи "Шаһнамә"сен утыз биш ел буе яза. Фирдәүсинең бер кызы була. Китабы өчен тиешле бүләккә кызына әйбәт калым әзерләргә уйлый ул. Гали Дайлам кульязманы сигез данәдә күчереп яза, һәм Фирдәүси шулар белән Газнага, солтан Мәхмүт сараена килә.

Катыйб исемле гыйлемле, акыллы вәзир шагыйрьне ачык йөз белән каршы ала, солтанга аның килүен хәбәр итә.

Фирдәүси белән бергә аның әсәрен укучы Әбудулаф та була. Ул солтан алдында "Шаһнамә"нең багышлавын укый, солтан аннан да, үзенең вәзирләреннән дә канәгать калган кебек була. Әмма сарайда вәзирнең дошманнары—аның абруена һәрвакыт тоз сибеп торучылар да була. Солтан Мәхмүт шулар белән киңәшләшә: "Фирдәүси белән нишлибез?"—ди. Ә тегеләре, шагыйрьне һәм аның китабын гамьнәренә дә алмыйча, фәкать вәзир Катыйбтан үч алырга гына тырышалар һәм:

—Фирдәүси—кяфер, язмыш турындагы тәгълиматны кире кагучы. Менә бу юллар аның денсезлегенең мисалы түгелмени?—дип укыйлар:

"Юкка талдырмагыз күзегезне мәңге—
Кем күргән дә, кайда соң ул Тәңре?"

Кемнеңдер утыз биш ел буе бөтен җанын салып эшләгән эшен фәкать егерме биш минут эчендә бик җиңел генә сызып та ата ала кайберәүләр. Шунысы тынычландыра: тар карашлы әлеге явыз кешеләрнең исемнәрен кем хәтерли? Без дә алар турында "Шаһнамә"гә бәйле рәвештә генә әйтеп үтәбез. Ә бөек китап һәм аны иҗат итүченең исеме җирдә мәңгелеккә калачак...

—Ә менә мине вафатымнан соң беркем дә искә алмас,—дип, күңелсез генә мыгырданып куйды Гомәр.—Мин—барлык чорлар өчен дә җайсыз кеше. Мин—албасты!—Ул ябык-арык йөзен шамакай кебек ямьсез итеп чытты.—Фирдәүси солтаннарны мактый, ә мин фаш итәм. Җирдә кемдер икенче берәү өстеннән хакимлек иткәндә, минем исемем һәркайда комачаулаячак. Шайтаныма олаксыннар ла! Мәрхүмгә бит барыбер.

"Солтан Мәхмүт, мәгълүм булганча, фанатик булган, якын яраннарының Фирдәүси турындагы тискәре фикере анда шик-шөбһә уяткан. Һәм ул шагыйрьгә фәкать егерме мең биргән, анысы да алтын динар түгел, ә көмеш дирһәм генә.

Шундый китап өчен шаккатмалы аз! Тиеннәр генә. Көлке. Бик нык рәнҗегән Фирдәүси мунчага бара, анда җимеш суы эчә һәм барлык көмешне мунчачы белән тәмле "фук" сатучыга бүлеп бирә..."

Күңеле булып, Гомәр көлеп җибәрде. Шагыйрь, фәкать чын шагыйрь

генә эшли ала моны! Ә күгәргән бер дирһәм өчен күршесен суярга торган саранга кая инде мондый егетлек!

Без—хикмәтле кешеләр. Гадәттән тыш кешеләрнең сәер гадәтләре аның күңелен күтәреп җибәрде. Һәм камыш каләм, гарәп язуының челтәрле бизәкләрен төшереп, ак кәгазь өстендә тизрәк йөри башлады:

"Бу хакта Мәхмүткә җиткерәләр. Рәнҗетелгән солтан шагыйрьне кулга алырга боера. Әмма Фирдәүси Гератка, Исмәгыйль Варрак кибетенә кача. Мәхмүтнең кешеләре аны таба алмыйча кире кайтып киткәнчегә кадәр—ярты ел яши ул качкан урынында.

Куркыныч янамый башлагач, Фирдәүси Хәзәрнең[1] көньяк ярындагы Табаристанга, хаким Шәһрияр янына китә. Шәһрияр үзе дә шигырь чыгарырга, фәлсәфи уйларга бирелергә ярата, хәтта "Марзбаннамә"—"Кенәзләр китабы"н яза. Сасанид Анушрван әйткән: "Аллаһы кайсы да булса халыкка игелек эшләргә теләсә, ул аның патшаларына—белем, ә патша хакимиятен аның голәмаларына бирер",—дигән.

Шәһрияр солтан Мәхмүткә бәйле була, шулай да җәзага дучар ителгән шагыйрьне кабул итәргә һәм чит күзләрдән яшерергә курыкмый.

—Элек шагыйрьләр һәм шигърият сөючеләр бер-берсенә булышканнар, ичмасам,—дип авыр сулап куйды Гомәр, инде арыганлыгын тоеп. Өстәл өстенә иелгән иңбашлары сызлап авырта башлады. Начар. Картаябыз инде әллә? Туктарга кирәк. Арылды, юньле бер нәрсә дә язып булмаячак. Әмма шундый эш инде бу: бөтенләй корып каласың, ә каләмеңне ташлый алмыйсың. Әйтерсең лә, ул кулыңа ябышып үскән.—Ә хәзер шагыйрь шагыйрьдән читләшә. Шаһка, солтанга, ханга, әмиргә, хакимгә, сипаһиларга[2] һәм башка аксөякләргә—җәһәннәмгә олаксыннар иде үзләре—нәрсәседер белән ярамаган кешегә яхшы мөнәсәбәт күрсәтеп, югарыдагыларның ачуын чыгарудан куркалар. Вакландылар шигырь чыгаручы туганнар...

Табаристанда бөек шагыйрь Мәхмүткә багышлап йөз бәеттән торган икеюллык усал сатира яза. Шәһрияр, Фирдәүси башы өчен дә, үз башы өчен дә куркып, Фирдәүсинең бу сатирасын йөз мең дирһәмгә, ягъни һәр бәетне меңәр дирһәмгә сатып ала да утка яга. Чөнки белә: сатира солтан кулына барып эләксә, ул шагыйрьне дә, аны үз канаты астына алган Шәһриярны да юк итү юлын табачак.

Шәһрияр Фирдәүсигә бик зур яхшылык эшли. Шул ук вакытта Мәхмүткә дә. Юкса солтан бөтен Көнчыгышта оятка калачак иде...

"Һиндстандагы яуларыннан соң өенә кайтып барганда,—дип дәвам иттерә аннары арыган Гомәр,—бер ныгытмага кереп урнашкан фетнәчеләр бастыру өчен туктагач, Мәхмүт шушы уңай белән әйтелгән бәет ишетә:

Дорфа булса синең җавап,
Ишетегез кайда да:
"Минем гөрзи эзләп табар
Афросиабны мәйданда".

Солтан: "Кемнеке бу шундый камил, батырлыкка өнди торган бәет?"—дип сорый. "Утыз биш ел буе интегеп "Шаһнамә"сен язган, әмма аның өчен лаеклы бүләк ала алмаган бәхетсез Әбелкасыйм Фирдәүсинеке",—дип җавап бирә вәзир Катыйб.

Мәхмүт үкенү хисе кичерә һәм Фирдәүсигә алтмыш мең динарлык төрле кыйммәтле бүләк җибәрергә боера.

Солтанның бүләкләре төялгән кәрван игелекле Туска җитеп, дөяләр Рудбар капкасыннан кергән бер вакытта шагыйрьнең гәүдәсен, җиргә иңдерү өчен Разан капкасыннан алып чыгалар". Үзенең күзләрне сукырайтырлык бүләкләре белән солтан соңга кала. "Әйе-е. Гомәрнең яңа хезмәтенә "Голәмалар китабы" дип исем кую, мөгаен, туры килеп бетмәстер. Бу, барыннан да элек, "Сагыш китабы".

Туста ул вакытта бер дин белгече яши. Кырыс холыклы, башбирмәс ошбу

[1]Хәзәр—Каспий диңгезе.

[2]Сипаһи—гаскәри.

кеше: "Мин Фирдәүсинең гәүдәсен мөселман зиратына күмдерергә ирек куймаячакмын, чөнки ул денсез кеше иде",—дип белдерә. Кешеләр күпме генә бәхәсләшсәләр дә, ул үзенекен итә. Капка тышында Фирдәүсинең зур бакчасы үсә. Аны шунда күмәләр".

Көнчыгышның Гомерга тиң даһи шагыйренә мөнәсәбәт әнә шундый була.

Ул борынгы баһадирлар, күптән тынган вакыйгалар турында язсын һәм әлеге вакыйгаларның, бер караганда, безнең заманга бернинди кагылышы да булмасын, тоелсын ди. Әмма бар кагылышы! Аның образлы фикерләү рәвеше шундый булуы аңлашылмыймыни? Чөнки без бит хайваннар кешеләр кебек үк гамәл кылган, сөйләшкән иске мәсәлләрне, искитмәле хәлләргә бай булган борынгы әкиятләрне игътибар белән һәм рәхәтләнеп укыйбыз, алардан үзебез өчен, бүген яшәүчеләр өчен гыйбрәтле мәгънәләр алабыз...

Алга таба... "Солтанның бүләкләрен мәрхүм шагыйрьнең кызына бирергә телиләр. Әмма ул: "Миңа сездән берни дә кирәкми",—дип, аларны ачу белән кире кага".

Гомәр Хәйям учлары белән яшьләрен сөртте. Уйларга да куркыныч: шагыйрьнең тормышы һәм үлеме, аның әсәрләренең язмышы ниндидер бер явыз ихтыяр кулында булып, әлеге ангыра ихтыярның бөтенесен бер мизгелдә юкка чыгарып ташлавы ихтимал...

"Шаһнамә" белән булган очракның иң шаккатыргычы шунда—Мәхмүт таныганчы ук инде ул тулысынча тәмамланган була. Шагыйрьне шактый интектереп, ниһаять, китапны танудан анда бер генә бит тә, бер генә юл да, бер генә сүз дә артмый. Ул бөек "Шаһнамә"—"Китаплар шаһы" булды һәм булып кала бирә.

Болар нәрсә турында сөйли соң?

Чын китап, аны язган кеше исәнме яки мәрхүмме икәнлегенә, аны аксөякләрдән кем дә булса тануына яки танымавына карамастан, халык күңелендә урын таба, шунда яши.

Поэзия ул—мөстәкыйль күренеш.

Әди ибне Зәет әйткән:

"Күпме жайдак шәраб эчте
Бездә—тузанлы юл чатында!
Кайда алар хәзер,—әйтегезче?
Алар—усал язмыш катында".

Язмыш Әди ибне Зәетне дә аямаган. Көнчеләр әләге буенча патша Ән-Нуман аны зинданга ябарга һәм буып үтерергә боерган. Әмма шигырьләре, күргәнегезчә, юкка чыкмаганнар...

## Беренче бүлек

## Суфый һәм җилкуар

—Бу китабың өчен сиңа нәрсә бирәләр инде?—дип сорады Әлмирра яткан килеш, өстәлдә тонык шәм яктысында шәйләнгән кәгазьләргә ымлап.

Халаты ачык. Ботлары нык кысылган. Карашы сынаулы. Кыяфәте үзенә якын китерердәй түгел.

—Белмим,—диде Гомәр, авыр сулап. Әкрен сөйләштеләр. Ул тәрәзәнең бизәкле капкачларын алдан ук ябып куйган иде.—Берни дә бирмәсләрдер. Йә булмаса, гарәп шагыйре Бәшәр Әбумөәзне суктырган кебек, житмеш камчы бирерләр.—Гомәр идәндә ашъяулык янында утыра һәм туңган итне вак кисәкләргә турый.—һәр нәрсә турында үзенчә уйлаганы өчен аны Алласыз дип белдергәннәр һәм үтергәнче кыйнаганнар. Өч йөз дә ничәдер ел элек, хәлиф Мәһди вакытында булган бу...

Хәтта ярым караңгыда да Гомәр кызның матур күзләрендә ул әйткәннәрне аңламау белән бергә хайвани дәрт кузгалуын күрде.

—Ә нигә язасың син мондый китапны?—дип сорады кыз, чак карлыккан тавыш белән акрын гына.

—Ә син ник шигырьләр язасың соң?—Шагыйрь җамыякка кара җимеш, чия салды, көлчәне кисәкләргә сындырды.

—Болай гына.—Әлмирра җилкәләрен җыерып куйды.—Күнел ачу өчен.

Тәкәбберлегеннән әйтә ул моны. Шигырьләрне күңелен тынычландыру өчен яза ул. Гомәр үзе дә шулай. Аларда халыкның моңсу җырларына охшарга тырыша. Шул ук вакытта Гомәргә дә. Аларның барысы да бертигез, бер дәрәҗәдәге хис кайнарлыгында түгел. Шигырьләрендә—холкындагы ук кырыслык, усаллык. Һәм тагын берничек тә аңлап бетереп булмый торган яшеренлек, серлелек бар.

Менә, мәсәлән:

"Гонаһмы бу?
Көн—шатлыксыз, төн—йокысыз.
Караңгыда ялгызкаем
Ниләр уйлаганны белсә,
Кызганудан сүнәр иде мескен Аем".

—Нәрсә турында уйлыйсың син?—диде Гомәр.

Җавап та шундый ук серле иде:

—Үзең бел...

—Мин китап язуны күңел ачу итеп кенә карамыйм,—дип караңгы чырай белән әйтте Гомәр, чынаякларга кызыл шәраб агызып. Ул—хезмәт, тормышымның мәгънәсе. Бурычым.

Әлмирра, авыр сулап, гаҗәпләнеп сорады:

—Сез, шагыйрьләр, ничек түзәсез боларның бөтенесенә? Сезне асалар, учакта яндыралар, чылбырга богаулап куялар. Ә сезнең һаман үз туксаныгыз туксан.

—Шуңа күрә шагыйрь дә инде без.

—Әй, сезне!—Ул күңелсез генә кулын селтәде. Гомәр күреп тора: хәзер кызны шигырь белән китап артык кызыксындырмый.

—Төш монда,—дип чакырды ул аны.

—Төшмим. Куркам. Кичә түти миңа карап әйтә: "Матурланасыңмы? Сине кияүгә бирергә вакыт инде. Төнге каравылчыга бирәм мин сине, юкса юньле кеше ата-анасыз кызны алмас",—ди. Әгәр ул белсә...

—Белергә өлгермәс, иртәгә үк яучы җибәрермен.

—Төн саен шулай дисең инде.

—Күрәсең бит, китап белән мәшгульмен. Әмма иртәгә барыбер җибәрәм.—Ә эчтән янадан шом үзенең кара канатын җилпеде. Чынаягын бушатып, Гомәр кара уйларып куып җибәрде:

"Әтәчкә ник кирәктер атуы таңның,
Беләмсен, борчулы ник тавышы аның?
Ди ул: "Күрдем тагын таң көзгесеннән
Гомердән бер төн үтте, сизми калдың!"

(Н. Арсланов тәрҗемәсе).

Әлмирра чишмә челтерәгән тавыш белән көлде һәм аның янына төште.

Гомәр газаплы ыңгырашып куйды. Бу шигырьне ул кайчандыр Рәйханга укыган иде. Анысы да шушылайрак көлгән иде.

—Сиңа ни булды, Гомәр?—дип, куркып сорады Әлмирра.

Гомәр, вәсвәсәләрне куып, башын селкеп куйды:

—Кайбер нәрсәләр искә төште.

Төрек кызы аңламады:

—Берәр җирең авыртамы әллә?

—Вөҗданым.—Ул аңа үзенең соңарган үкенүеннән еш ыңгырашуын, ахылдавын-ухылдавын әйтергә теләмәде. Күп еллар элек Гомәр рәнҗеткән кешеләр, бәлкем, бу хакта оныткannардыр да инде, әмма ул оныта алмый...

—Эч,—диде Гомәр күңелсез генә. Ул тырышып елмайды һәм, аңа ярарга

тырышып, шул мизгелдә үк шигырь чыгарды:

"Янмаган да көймәгән йөрәктән мескене юк,
Шашып-ярсып сөймәгәч, яшәүнең дә яме юк.
Көнлендә булмаса татлы сөю-сәгадәт,
Аннан шыксыз, күнелсез һичбер нинди көн юк".

Искитәрлек шигырь килеп чыкмады-чыгуын. Алсу төтен. Буш сүз. Әмма ул Әлмиррага жан өргәндәй булды:

—Ай, картлач! Ай, тиле картлач...

Хайвани дәрт. Тәкатсез кызыксыну. Ирләр кебек хырылдап йоклаучы саңгырау түтәсеннән качып, һәр төнне ул үзе өчен янадан-яна табышлар таләп итә.

Бәлкем, аның табышмагы да әнә шундадыр?

Бу юлы алар танны йоклап үткәрделәр.

Гомәр йортының артында, билгеле булганча, ипи пешерүче яши. Шагыйрь кайчакларда аңа урам аша кайнар көлчәләр алырга керә. Ул көлчәләрне эче уттай кызганчы ягылган зур түгәрәк мичтә пешерәләр һәм аннары йомшак, хуш исле, кызарып торган көлчәләрне дистәләп, йөзәрләп сатарга алып чыгалар.

Ул көнне ипи пешерүченең хатыны иртә торды да түбәгә күтәрелде. Гадәти булмаган авырлыктан баскыч ыңгырашып, шыгырдап куйды. Кичә алар гаилә әгъзалары белән бакчаларындагы өч өрек агачын селкеттеләр, шунда коелган жимешләрне жыеп, киптерер өчен ишегалдында һәм түбәдә чыптага таратып салдылар.

Бер төн эчендә генә, әлбәттә, алар кибәргә өлгермәгәннәр иде. Урлаулары да мөмкин түгел, чөнки бу якларда күршеләр бер-берсенең әйберенә тимиләр. Әшулай да... Кошларның чукуы ихтимал. Ә инде дөресен генә әйткәндә, гадәттән тыш юан бу ханымны иртә таңнан түбәгә менәргә үзен мал иясе итеп сизү, хосусыйлык тойгысы мәжбүр итте. Һәм шуларга бәйле тынгысызлык. Ул чын ләззәт табып, үзенең байлыгына карап торды һәм, тыны кысылып, аннан кышын күпме дирһәм эшләп булачагын исәпләп карады.

Көчкә иелеп, аз гына бөрешә башлаган гәрәбәдәй өрекне кулына алды.

Без—сакчыл, исәп-хисап ярата торган халык. Без яши беләбез. Әнә теге, әллә ничә көннәр буе күренми торган, йә хәрчәүнәдән кызмача кайта торган яңа күрше, арык, эшлексез шагыйрь түгел инде. Тик менә күршеләрдән генә бәхет чамалы. Мәрхүм рәссам бераз ычкынганрак иде, монысы тагын да диванарак. Мәчеткә йөрми, күршеләрне үзенә кертми, аларның тормыш мәшәкатьләренә катнашмый.

Ул өрекне аңа ябышкан кечкенә кырмыскасы белән бергә авызына капты. Күрмәде. Әле бик иртә булуына һәм кичтән бик әйбәтләп тәгам жыюларына карамастан, аның инде ашыйсы килә иде. Хәлбуки, аның өчен яшәүнең төп мәгънәсе—тамак туклыгы. Күп итеп, бертуктаусыз ашау. Кеше никадәр зуррак гәүдәле булса, ул үз ишләре янында шулкадәр хөрмәтлерәк санала бит бу дөньяда.

Һәм кинәт...

Ул гажәпләнүдән аһ итеп куйды һәм өрек төше тамагына китеп, чак кына тончыкмады.

Йә Ходаl

Бу кыз!

Бу инсафлы жан!

Бу чибәркәй!

Бу Әлмирра... Хәйямның ишегалдыннан үзләренең түбәләренә сикереп менде дә, тирә-ягына карангалап, аска, үз өйләренә шылды.

Күршесен ул күрмәде, чөнки тегесе, юан булуына карамастан, яндагы чинар ябалдашы куелыгына яшеренде. Өстәвенә—туры килүен кара әле син аның,—бүген соры чәчәкле иске яшел күлмәген кигән иде. Ашыкканда ничек күрәсең ди инде?!

"Алай икә-ән! Ә мин, юләр, чәнчелеп киткере бу Әлмирраны олы улыма ярәшергәме әллә, дип уйлап йөри идем. Ата-анасы юк, калымны күп сорамаслар, дип". Күзләре тоныкланды. Беренче уе—үз толымнарына тотынып, бөтен мәхәлләгә

"Әй, мөселманнар, күрегез әле безнең мәхәлләдәниләр эшләнгәнен!"—дип кычкырасы килде.

Әмма ире ни әйтер? Ул кырыс, басынкы кеше, хатын-кыз чырылдавына түзә алмый. Кыйнавы да бар. "Кычкырырга кирәкмәс, җайлап кына уятыйм әле үзен".

Ул баскычка басты һәм, аска, еракка-еракка алып төшүче мескен, нәзек, черек һәм кәкре-бөкре басмаларга карап, йөрәге жу итте. Мескен хатын аптырашта калды. Анда баскыч, монда баскыч. Башында томанлы истәлекләр пәйда булды. Ерак еллар офыгында калган, күптән-күптән булган тагын бер баскыч хәтерендә янарды. Кайчандыр, яшьлегендә, ул үзе дә түбәгә менеп, посып кына күрше ишегалдындагы ир-егетләрне күзли торган иде бит...

Тәвәккәллеге бетте. Хатынны ниндидер газаплану тойгысы биләп алды. Ул әкрен генә җиде-сигез басма аска төште дә, борылып, аларның берсенә утырды. Чак сыйды.

Күптән инде мүкләнгән җанда кинәт үзен сиздергән онытылган хис хатынны йомыкыйлык һәм саклык кочагына этәрде.

"Хәзер бит Әлмирраны юк бәягә дә алып була,—дип фикер йөртте ул.— Без горур тирекләр түгел, без тыйнак фарсылар, безгә андый кыз да ярый. Шаушу күтәрү кирәкмәс. Әлегә иремә дә әйтми торыйм. Соңрак тегүче күршемә керермен, карармын, төшенермен. Беркем берни белмәсен өчен бөтенесен тавышсыз гына эшләргә кирәк".

Хәзер ул барлык күршеләреннән дә баерак! Чөнки читләр серен белә. Ни әйтсәң дә, без бит шәһәр кешеләре. Үз акылыбыз үзебездә булган, эшлекле һәм хәйләкәр халык. Ул, булачак файдалы алыш-бирешне уйлап, үзалдына елмаеп куйды. Күңеле үк күтәрелеп китте. Ишегалдына шундый ук зар-интизарлык белән төште дә симез һәм авыру ире йоклап яткан айван[1] янында туктап калды.

Аның ире янына, җылы, йомшак юрган астына чумасы килде. Күптәннән күргәне юк моңдый ләззәтне. Ире исә ипи пешерә торган мичнең кара авызына охшаган авызын зур итеп ачып иснәде дә бәхетсезкәйне үз кочагына алды. Зар-интизар хатынның теләге канәгатьләндерелде. Аңа көлне генә түгәсе калды.

Шайтан! Нинди дә булса эшкә хатын-кыз килеп кысылдымы, ул эшне бетте дип исәплә инде. Юкка гына тәмуг кисәве дип атамаганнардыр аны.

Гомәр әчке бер сиземләве белән яза торган китабының: "Эшлә!"—дип ялваруын ишетә. Ә югыйсә, имеш, тот та, бөтен эшенне ташлап, яучы эзләп чыгып кит. Кайдан тапсын ул аны? Гомәрнең ул тел бистәсе-әрсезләргә гомергә дә ялынганы булмады. Алардан башка да яшәр әле.

Өйләнмәгез, шагыйрьләр! Гомәр өстәл өстендәге бәхетсез кульязмаларын сыпырып төшерде. Боегып, кәгазь битләре очты, рәнҗеп һәм кайгыга батып, кара савыты ауды. Язгы болын төсле зәбәрҗәт-яшел төрек келәме өстендә явызларча кара матәм табы җәелде. Өйләнүнең тагын бер файдасы. Гаилә бәхете хәбәрчесе.

Әмма шулай да әлеге юеш тап үзенең игелекле эшен эшләде. Ул Гомәрне ачулы уйлардан арындырды, ничек кенә гаҗәп булмасын, аны тынычландырды һәм аек акыл белән уйлау сәләтен кире кайтарды.

Их! Төннәрен дә иртәнге кебек аек фикер йөртә алсаң икән ул...

Өйләнергә туры киләчәк. "Ахыр чиктә бу бит мөселманнарның бурычы,— дип көлемсерәде Гомәр.—Дин алдындагы бурычы. Өйләнергә һәм ишле балалар үстерергә тиеш".

Коръән һәр мөэмин мөселманга дүрт хатынга өйләнергә рөхсәт итә. Тик ул аларны асрарлык хәлдә булырга һәм "үзенең ирлек назын алар арасында тигез бүләргә тиеш".

Хәлле егет чәчәк аткан 18-20 яшендә беренче тапкыр өйләнә. Әгәр малы булса, 30 яшендә—икенче хатын, 40 та -өченче, 50 дә дүртенче хатын ала. Бу аңа картлык көннәренә кадәр яңа шатлыклар кичерү өчен кирәк. Әйткәннәр бит: "Өстәл дә дүрт аякта тора",—дигәннәр.

Бездә барысы да башкачарак килеп чыкты, дип яңадан көлемсерәде Гомәр.

[1]Айван—терраса.

Безнең өстәл озын, һәм ул кырык аяклыга охшаган...

Ярый соң! Төзәтербез. Әлмирра ожмахка эләгәме-юкмы, барыбер ул үзе үк ожмах.

Яше ул түгелме? Көнчыгышта моның әһәмияте юк. Рәхим ит, туксан яшендә кыз балага өйләнә аласың. Шундый теләгең һәм, әлбәттә инде, акчаң булса.

Шулай итеп, биредәге никах йолалары турында ниләр беләбез әле? Кайчандыр шәригать кануннарын укыган идек бит... Сөнниләр белән шигыйлар бергә яшәгән бу якларда күп йолалар, телисеңме-юкмы, уртакка әверелгән. Кияүгә бирердәй кыз үсеп житкән өйгә өйләнмәгән ир-ат булган өйдән берничә хатын-кыз килә.

"Өйләнмәгән ир-ат безнең күз алдында,—дип күңелсез генә көлемсерәп куйды Гомәр.—Әмма бу гаиләдә хатын-кызны табып булмас".

Дөрес, биредә, Нишапурда, аның сеңлесе Гөлмохтар бар. Мөгаллим әл-Багдадида кияүдә. Әмма алар диндар кешеләр, мондый жилбәзәк белән аралашмыйлар. Мөселман жәмәгатьчелеге күз алдында үз абруйларын төшермәс өчен, әлбәттә. Ярар соң! Яшәсеннәр шулай, бер сүз юк...

Бизәнеп-ясанып, кәләш кунаклар янына чыга, үзенең уңганлыгын күрсәтергә тырышып, өстәл әзерли. Үзенең, мескенкәй, куллары калтырый, иреннәре дерелди: ошатмый китмәсәләр ярый инде, дип курка.

Күзәткән-сынаганнан соң, кәләшнең әтисе янына нишан—кияүнең әтисе зур булмаган бүләк тотып килә.

"Каян алыйм мин аны? -дип, күңелсез генә сорады Гомәр бушлыктан.— Бүләкне димим, әтиемне, авыр туфрагы жиңел булсын. Һәм аны Әлмирра каян алсын? Гадәттән тыш очрак.

Калым турында килешәләр дә, никахлашу турында белдерәләр. Бик тә мәшәкатьле эш! Гомәр ачу белән өстәлне тибеп аударды. Аннары, мәхәлләдә яшәүче бар кешене чакыртып, туй ясыйлар. Сорнайлар чыелдавы, барабаннар гөрелтесе. Шау-шу, ыгы-зыгы. Бөтенесен сыйларга, бөтенесенә ярарга тырышырга, кемнәргәдер бүләк бирергә туры киләчәк...

Әйтерсең лә, тир исе килеп торган оятсыз ирләр өере белән аерым күңел ачучы, май чүлмәгенә әверелгән, юан муенлы, күкрәкләре асылынып төшкән, үз-үзләрен әллә кемгә куючы тинтәк хатыннарның кәләш белән кияүдә ниндидер хокуклары бар. Мөэмин мөселманнар кәләшнең "сафлыгына" үз күзләре белән күреп ышансыннар өчен иртән ак жәймәне кичекмәстән тышка чыгарып эләргә кирәк. Шулай булмыйча, башкача ярамый!

Әмма мәхәббәт бит—интим, шәхси эш.

Әле иң хәтәре шунда—берничә көн дәвамында мәхәлләдә һәм базарда гайбәт чыганагына әйләнәсең. Көтмә—юньле бер нәрсә дә әйтмәячәкләр. Хәтта алар өчен иң соңгы фельсыны[1] тотып бетерсәң дә. Гайбәтенне сатар өчен яна бер сәбәп кенә булачак.

Аһ, Әлмирра! Әлмирра! Каян килеп чыктың син минем бәхетсез башыма?

Әйе, әкияттәгедәй булды бу. Ул үзе өчен гадәти елмаю—дөресрәге, һәрвакыттагыча күңелле көлемсерәү белән моның ничек булганын исенә төшерде.

Гомәр үзенең ишегалдында, инеш янындагы эскәмиядә яңа китабы турында авыр уйларга бирелеп утыра иде.

Сул яктагы күршенең койма астыннан агып чыккан инеш суын балчык торба эченә керткәннәр. Торба исә матур итеп, юри тәртипсез рәвештә табигый таш белән тышланган кечерәк кенә, түгәрәк коега килеп тоташа. Әйтерсең лә, ул табигый чишмә: аның суы тау чишмәләренеке кебек челтери, бытырдый, чупылдый, аның өстенә өянке ботаклары салынып төшкән.

Шагыйрь, ияген ике йодрыгына терәгән дә, дөнья гамьнәрен онытып, жанлы кебек челтерәгән суга карап тора.

Кинәт чишмә төбеннән, аның салкын тирәнлегеннән, бер кызыл нәрсә калкып чыкты. Тирбәлеп килеп чыкты да суда бөтерелә башлады. Гомәр аңа аңсыздан озак карап торды. Аннары кинәт исенә килде: роза ич бу! Тотты, суын

---

[1]Фельс—вак акча берәмлеге.

селекте. Әле яңа гына өзелгән тере чәчәк иде бу. Ул аны иреннәренә тидерде, үпте.

Инештән икенче, өченче розалар килеп чыкты. Могҗиза! Мөгаен, каяндыр, югарыдан агып киләдер болар.

—Әй!

Гомәр каранды, ишегалды буш иде.

—Мин монда,—дип әкрен генә пышылдап әйткәннәре ишетелде.

Ул югарыга карады. Кыз... Күрше тол хатынның өй түбәсендә чинар күләгәсендә ята. Күзләренә үк төшеп торучы, аерым төрек сурәтле куе чәч, хәтта кашлары да күренми. Борынын сизелер-сизелмәс сипкелләр бизәгән. Бит алмалары уттай яна.

Әнә каян килә икән ул розалар. Туп-туры шул бит алмаларыннан өзелгәннәр диярсең.

—Бер сәгатьләп күзәтәм инде мин сине. Төшкән идем, кире мендем. Сине шагыйрь, диләр, дөресме шул?—диде кыз.

—Әлбәттә.

—Талантлымы? Танылган шагыйрьме?

—Шик тә юк.

—Буйдакмы?

—Әлбәттә...—Гомәр көрсенеп куйды: "Хәзер акчам күпмелеген сораячак".

Юк, сорамады. Аңа күптәннән таныш, якын карашының якты назын сирпеп, тау күгәрченедәй тыныч һәм тыйнак кына көлеп куйды.

—Мин дә бит шигырьләр язам,—диде ул кыенсынып кына.

—Һо! Кәгазьгә язып барасыңмы? Алып кил әле, күрсәт.

—Юк, мин яза белмим. Хәтеремдә генә чыгарам да истә калдырам.

—Яза белмисең? Анысына өйрәнергә була. Исемең кем синең?—дип йомшабрак сорады Гомәр.

—Әлмирра. Әмма исемемнең ни аңлатканын мин үзем белмим.

—Гарәбстанның эссе якларында тәмле сумала исле шундый үсемлек бар,—диде шагыйрь, ни өчендер башын аска иеп.—Мин... Рәйхан дигән берәүне белә идем. Аннан чыннан да рәйхан исе килә иде. Төш.—Ул торды, диварга баскыч сөяде.—Карыйк әле, синнән нинди ис килә икән.

—Юк, төшмим.

—Алайса, кит.

—Китмим! Түбә безнеке.

—Алайса, утыр шунда картайганчыга кадәр.

—Мин куркам, биек.

—Тотармын, курыкма.

Кечерәк кенә, нәфис гәүдәле, әле генә тулган күкрәкле, алсу күлмәк, кызыл ыштан кигән, битләре янып торган кыз, арты белән борылырга кыенсынып һәм оялып кына көлеп, күктән төшкән алиһә кебек төшә башлады. Кайнар җил аның күлмәк итәген ялкын кебек җилфердәтте. Аның нечкә ак аягы Гомәрнең бите белән тигезләшкәч, ул бу аякны сак кына кулы белән тотты һәм нәзек бармакларыннан үпте.

Юк, тиресеннән мирра исе килми. Аның исе мең тапкыр яхшырак: аннан иртәнге сафлык һәм эчкерсез кызлар мәхәббәте бөркелә иде.

Гомәр тешләрен шыгырдатып куйды. Кайнар хыял-хисләргә бирелүче таза яшь кыз тәҗрибәле, өлгергән һәм көчле иргә ирексездән тартыла икән, бу бик табигый. Табигать үзенең ни эшләгәнен белә.

Табигый булмаган нәрсә, ул да булса—аларның матур, чиста мәхәббәтләре тирәсендәге өйләнешүгә бернинди катнашы булмаган һәм аны сәүдә алыш-биреше дип кенә кузаллый торган аңгыра һәм тупас кешеләрнең ыгы-зыгысы.

Йә, әйтегезче, Гомәр белән Әлмирраның бер-берсенә булган көчле мәхәббәтләрен, Әлмирраның өмсендергеч тыныч елмаюын, ягымлы күзләренең тәэсирле яктылыгын, фәкать икесенә генә аңлаешлы кул хәрәкәтләрен шәригатьнең кайсы маддәсенә кертеп була?

Мәхәллә мәчете имамы? Үзенең алыштыргысыз Коръәнен дә әлле-мәлле

генә белүче надан бер кеше. Гомәр ана мөрәҗәгать итәргә һәм мөхтәрәм дин башлыгының үзенең хәләл җефете аша Гомәр өчен яучылар табуын үтенергә тиеш. Ә аңгыра яучысы тагын? Ни өчен ул үз күңеленең тылсымлы дөньясына әлеге ят, ана бөтенләй дә кирәкмәс бәндә кисәкләрен кертергә тиеш?

Мөселман мәхкәмә[1] кануннарының берсендә дә, хәтта никах, гаилә турындагы өлешләрендә дә, "мәхәббәт" дигән сүз бер генә тапкыр да искә алынмаган. Бөтенесе күздә тотылган: ничек өйләнергә, ничек аерылышырга, мөлкәтне һәм балаларны ничек бүләргә. Кемгә һәм ни өчен күпме бүләргә. Ә мәхәббәт турында ләм-мим.

Ул үз артында ниндидер җиңелчә генә тыпырчыну ишетте. Борылып карады: тәрәзә төбендә, канатларын салындырып, чыпчык тора һәм селкенә. Нидер булган үзенә. Гомәр ана якын килде.

Шагыйрь һәрвакыттагыча киң тәрәзә төбенә сибә торган кипкән валчыкларның берсе чыпчыкның авызына тыгылган икән. Йота да, чыгарып ташлый да алмый мескенем. Тыпырчына, канатларын бәргәли, күз алдында һарап булуы ихтимал. Хәтта очып та китә алмый.

—Әй, син, үләргә җыендыңмы әллә?—Гомәр сак кына аның калтыранган аркасына сукты.

Валчык төште. Чыпчык очып китте, күрше чинары ботагына барып кунды, шатланып чыркылдап куйды.

Гомәрнең кәефе күтәрелеп китте. Ул өстәлне урынына утыртты, кәгазьләрне тәртибе белән тезде, шунда ук каләм белән кара савытын алып куйды. Юеш чүпрәк белән келәмдәге тапны сөртте. Әмма чиста келәмдә пычрак кара табы калды барыбер.

—Йә, ярар ла! Кайчан булса бер янасын алырбыз әле. Әгәр кирәге чыкса...

Ул ефәк базарына, йолдызлар буенча күрәзәлек иткән иске танышы Мозаффар янына китте.

—Миңа иң яхшы яшел ефәктән бер чапанлык бир.

—Өйләнергә уйладыңмы әллә?

—Охшаганмыни?

—Яшәргәнсең, чибәрләнгәнсең. Гадәттә син ни туры килде, шуны киеп йөри идең. Ә бүген—яңа чапан, җитмәсә әле ефәктән. Ходай кушсын! Бәлкем, акылга утырырсың.

Булмастыр... Бөтенесе мине тәрбияләргә тырыша. Нигә? Барыбер файдасыз бит. Ничек булсам, үлгәнче шулай калачакмын. Тагын егерме биш-утыз ел түзә алмыйсызмыни соң сез?

Култык астына ефәк тукыма кыстырып, ул күрше хатынның ишеген какты. Хатын-кызлар гына яши торган өйгә ир-атка керергә ярамый-яравын да, нишләмәк кирәк, сәбәбе бар бит.

Ишекне Әлмирра ачты. Куркып китте. "Ah",—диде дә йөгереп качты. Гомәр янына хуҗабикә үзе чыкты.

—Гафу итегез,—дип кыенсынып кына әйтте Гомәр, аның тирән җыерчыклы битенә карамаска тырышып. Кайчандыр ул чибәр булгандыр, мөгаен. Төрекләр гомумән чибәр халык. Бигрәк тә Елга аръягыныкылар.

—Зарар юк!—диде хуҗабикә, кырыс кына.—Мин үзем дә оныттым инде хатын-кыз икәнлегемне. Гомерем буе ирләр йөген тартам. Үзем теккән чапаннарны сатучы арадашчым белән базар тел бистәсе кебек сатулашам. Әйдә, уз, күрше.

—Йомыш белән килдем,—диде Гомәр, ефәк кисәген җәеп күрсәтеп.—Гафу итегез инде, өемдә хатын-кыз юк, шуңа үзем килдем.

—Өйлән соң!—дип дорфа гына әйтте тегүче хатын.—Ah!—Ул ялтырап торган тукыманы бер ләззәт белән селкеп карады.—Төсе белән туры килә торган эчлекне үзем табармын. Искитмәле чапан булачак бу. Әмма ялгызак кешегә ник кирәге бар аның?

—Ялгызак булудан туктар өчен,—дип көлемсерәп җавап бирде Гомәр.

—Өйләнергә уйладыңмы әллә? Бик хуп. Күптән кирәк иде. Әллә... безгә кыз сорарга кердеңме?—дип кисәк кенә әйтеп куйды ул.—Ха-ха! Баштук уйлаган

[1]Мәхкәмә—суд.

идем аны, юкка гына кермәгәндер бу дип. Чапан кирәк булса, синең акчага базардан әзерен дә алып булыр иде. Кайсыбызга төште соң күзең?—Ул күз кырые белән генә Әлмиррага карап куйды.—Иң яхшысы—миңа өйлән. Миң өлкән, житди кеше. Нәкъ сиңа тиң. Оттырмассың.

Аның тупас турылыгыннан Гомәр гажәпкә калды, әмма, үпкәләтмәс өчен, тыныч кына әйтте:

—Мин... каршы түгел дә, тик һөнәрегез артык тавышлы.—Мин өйдә шакылдаганны һәм тавышланганны бер дә яратмыйм.

—Берни эшләр хәл юк!—диде тегүче, ачу белән.—Үземне һәм менә бу әрәмтамакны туендырам. Шакылдавыңнан тукта, тинтәк!—диде ул Әлмиррага.

Әлмирра тукмагын читкә куйды, сүзсез генә башын иде.

Кем белән эш итүен аңлап, Гомәр туп-туры:

—Мин сезне артык кашыктан коткара алыр идем,—диде.

—Шулаймыни?! Баштук әйтәләр аны!—Карчыкның тупас иреннәрендә әрсез елмаю барлыкка килде.—Күпме бирәсең?

Әйтерсең лә, чапан сата...

Гомәр дә ирексездән тупасланды:

—Күпме сорыйсың соң?

Ул Әлмирраның кызганыч карашын тойды, аны жәлләп, жаны әрнеде. Мескенкәйнең менә хәзер кулыннан тотасы иде дә, күкрәккә кысасы иде...

—Биш йөз алтын,—диде күршесе, катгый итеп.—Аннары миңа ат белән арба һәм дә яшь хезмәтче алып бирәсең.

—Биш йөзне бирә алмыйм,—диде Гомәр, күпме акчасы калганын хәтерендә исәпләп.—Ике йөз динар бирәм. Ат алырга, хезмәтче ялларга риза. Ә нәрсәгә кирәге бар соң аларның сиңа? Ярый, яшь хезмәтчене берәр нәрсәдә файдаланырга да булсын, ди,—диде ул киная белән,—ә ат нигә?

—Гомерем буе атлы булырга хыялландым. Ике йөз, дисеңме? Риза. Ике йорт арасында керү-чыгу юлы эшләрсен.

—Юк, анысы булмастыр.

—Йә, ярар. Кул бирешәбезме?

Мондый бәхет хатынның төшенә дә кергәне юк иде.

Бирешәбез.

Шапылдатып, кул бирештеләр.

—Ә чапанны нишләтәбез?—дип сорады карчык, исенә төшереп.—Тегәбезме?

—Кирәкми,—дип кул селтәде Гомәр.—Тукыманы үзегезгә алыгыз. Бүләк итәм.

—Менә рәхмәт!—Карчык ефәк кисәген шундук сандыгына тыкты.

Әлмирра кыйммәтле тукыманы маңгае астыннан бүре карашы белән озатты, аннары апасына текәлде. Моны күреп, Гомәр нык гажәпләнде.

Бернинди яучының да кирәге булмады! Әлмирра аны кече капкага кадәр озатты һәм апасы күрмәсен өчен, ашыкмыйча, шатланып, муеныннан кочаклап алды.

—Төнлә килермен,—дип пышылдады ул, дәртләнеп.—Миңа да шундый тукыма алырсыңмы?

"Юньсез шагыйрь! Каһәр суккан юлдан яздыручы. Күр әле ничек жинел генә кулга төшерде тутый кошны. Ә нигә, күрекле ир ул, сүз әйтерлек түгел. Тинтәк кызга ни кирәк тагын?

Юк инде, башка күрә алмаячаксың син аны!"

Сирәк кенә булганча, ипи пешерүче хатыны юынды, кызыл кершән сөртте, күзләренә сөрмә тартты, иң әйбәт күлмәген киде. Чиста яулыкка көлчәләр төрде дә, аһ-уһлап, күршесенә керде.

"Ни хикмәттән икән бу?—дип усал гына уйлап куйды тегүче, көлчә өемен күргәч.—Гадәттә берне бурычка ала алмаганда, кинәт шундый юмартлык. Нидер кирәк бездән юан бу әрсезгә".

Аның мескен акылында шик туды.

Ипи пешерүче хатынның үз уйлары:

"Хәерчеләр!—Өйгә бер күз ташлауга әнә шундый бәя бирде ул.—Идәндә

искереп беткән киез, арзан савыт-саба, юрганнары тишек-тошык. Таптым да соң үземә туганлашыр кешеләр!

Кыргый. Кунакны да юньләп каршы ала белми. Сабыр итегез әле. Сенлесен кулга төшерсәм, апасын бусагамны да атлатмам. Ә телендә башка сүзләр иде:

—Кыз һәйбәт әвәләнгән!—дип мактады ул Әлмирраны.—Әйбәт кисеп тегелгән,—дип "тегүчеләр" теленә күчте аннары.—Кызыктырырлык кәләш. Ышанасыңмы-юкмы, балакай, әмма мин синең яшьтә тагын да нәфисрәк идем. Хи-хи...

Ул моны Әлмирра елмаймыйсын һәм тешләрен күрсәтсен өчен әйтте. Тигез ак тешләр—сәламәтлек билгесе.

"Аңлашыла,—дип уйлады тегүче,—монысы да яучыларга килгән. Минем тинтәгемә шулай исләре киттеме? Бәлкем, кичкә әле кем дә булса тагын берәү килер? Арзан сорап, алданып куймагаем.

—Балам, эшеңне куеп тор, бөтенесен себер, җый,—диде ул Әлмиррага, төчеләнеп.—Нишләп болай торабыз әле? Гомергә бер күршебез кергән, ә бездә аны утыртыр урын да юк.

Булачак күңелсезлекләрне күңеле белән сизенеп, боегып калган Әлмирра себеркесен су белән чылатты да тиз генә киезне себереп алды, юрганны икегә бөкләп куйды, ашъяулык җәйде.

Кечкенә матур кулларында эш уйнап кына торды. Күрше моны күрми калмады.

"Картлык көннәребездә әйбәт булышчы, терәк булачак бу".

—Өйдә эч пошып китте,—диде күрше хатын. Авыр сулап, йомшак юрганга утырды.—Иртәдән бирле гел мич янында. Әле бит җыештыр да, ашарына да әзерлә... Их, булышыр кешем юк шул минем! Олы улымны башлы-күзле итәргә ниятләп торам әле. Шуннан, Ходай кичерсен, шуны уйлап куйдым: күрше йортта, койма аша гына җиткән кыз барында, нигә дип әле безгә кәләшне әллә кайдан ерактан эзләп йөрергә? Менә, карарга, белешергә, сүз катарга дип керүем иде әле...

—Кыз яучыланды инде,—дип төксе генә әйтеп куйды тегүче.

—Ничек? Кемгә?

—Шагыйрь аның өчен ике йөз динар тәкъдим итә,—диде төрек хатыны.—Арбасы белән ат, ялчы алачак мина. Искитмәле ефәк бүләк итте. Менә...

Ефәкне алды, ачты—бөтен өй эче йомшак яшел төскә күмелде. Әйтерсең лә, өй эчендә искиткеч зур зөбәрҗәт кисәге балкыды.

—Ә син ризалаштыңмы?—дип кара көеп сорады пешекче хатыны, әйтерсең лә, зөбәрҗәт кисәге белән аның башына бәрделәр.

Тегүче иңбашларын җыерды:

—Ә ник ризалашмаска? Аның белән туганлашуны үземә мәртәбә саныйм мин. Күренекле, могтәбәр кеше. Үзе юмарт.

Күршенең иреннәрендә яшел күбекләр күренде:

—Ул бит сәрхүш!

—Булса соң! Барыбер күренекле кеше ул! Ни дисәң дә, падишаһлар белән эш иткән адәм.

—Әй, кайчан булган инде ул!—дип кычкырды пешекче хатыны, табышның үз кулыннан ычкыну ихтималыннан куркып.—Булган-беткән! Хәзер инде ул каһәрләнгән бәндә. Шагыйрь, имеш! Харап икән. Ә минем улым—бөркет! Эшчән, тырыш. Югары үрмәләячәк. Әлмиррага аның янында таш дивар артындагыдай тыныч булачак.

—Менә шул-шул!—дип үртәп әйтте Әлмирра.—Әле апаның таш дивары уртасында яшәвем житмәгән, хәзер сездә шул ук хәлгә калыргамы?! Бөркет түгел, күсе ул синең улың!..

Оһо! Кызның тешләре үткен икән.

—Олылар янында дәшмә син!—диде аңа карчык.—Без... тормыш турында кайбер нәрсәләрне беләбез. Кайбер диварларда ярыклар да була.

Әлмирра шундук күңелсезләнеп калды. Әллә?.. Нәрсә булыр инде хәзер?

—Йә, нәрсә әйтерсең, кадерлем?—диде пешекче хатыны тегүчегә, аңа кинаянең мәгънәсенә төшенергә ирек бирмичә.

—Белмим,—диде тегүче, авыр сулап.—Кемне теләвен Әлмирра үзе әйтсен.
—Мин фәкать Гомәргә генә кияүгә чыгачакмын,—диде кыз.

Пешекче хатыны, юанкай, кичен икенче бер юанкай—мәхәллә мәчете имамы хатыны белән килде.

Мөхтәрәм ханымны тут агачлары астындагы салкынча ишегалдындагы урыныннан кузгату җиңел булмады аңа. Өстәвенә, мәчет һәм имамның йорты мәхәлләнең ерак, теге очында ук. Монда килеп җиткәнче калын пәрәнҗә астында шактый тирләргә туры килде.

Бер өем көлчә белән генә эш пешмәде. Тагын ике өем көлчә, өч дистә йомырка, биш дирһәм өстәргә туры килде.

Кызыкты! Чөнки мәхәллә ярлы. Нишапурның зур утарлары, киң бакчалары, бассейннары, биек мәчетләре һәм мәдрәсәләре белән аерылып торган үзәге белән чагыштырганда, монда күңелсезлек һәм фәкыйрьлек хөкем сөрә. Мондагы хәлләр турында бер гарәп географы болай дип язган: "Кешеләре... дорфа, башларында—җиңел акыллылык; нәфислек һәм әдәплелек юк, матур мәчетләр юк. Урамнары чүп-чар белән тулган, базарлары ташландык хәлдә. Мунчалары пычрак, кибетләре ярлы, диварлары тигезле-тигезсез.

Шәһәрнең бу өлешендә һәрвакыт бәхетсезлекләр булып тора, биредә кыйммәтчелек хакимлек итә. Җиләк-җимеш һәм яшелчә аз, утын өчен агач житми. Эшләп акча табу читен, тапканы да яшәү өчен җитәрлек түгел. Биредә яшәүчеләр арасындагы ызгыш-талаш йөрәкне борчый, алар арасындагы дошманлык күкрәкне яралый. Дин әһелләре алар белән бергә хәерчелеккә һәм бозыклыкка кереп батканнар. Әмир шәһәрдән киткән чакларда Нишапурның бу өлеше чыгырыннан чыга. Әгәр кем дә булса дәшсә һәм чакырса, гади халык шундук аңа иярә; анда кыргый үч алыш һәм кабахәт әхлаксызлык хөкем сөрә".

Әйе, ташландык мәхәллә. Имам хатынының кешелеккә кия торган күлмәген, әйтик, сәүдәгәр Мозаффарның хатыны өйдә кияргә дә оялыр иде.

Алар, хуҗабикәне диварга кысрыклап, кечкенә өй эчен үзләренең кайнар гәүдәләре һәм әче тир исләре белән тутырдылар.

Шул ук тузган юрганнар. Шул ук пычрак ашъяулык. Андагы көлчәләр дә шул ук, әмма инде катканнар. Әчегән каймаклы җамаяк. Могтәбәр кунаклар хөрмәтенә бөләргә туры килде. Бусаганны атлап чыкмыйча да зыян күрәсең бит. Бөтен тормышы зыяннан гына тора...

—Әлмирра әйтте бит инде, бары тик Гомәргә генә чыгам, диде.—Тегүче арыган кыяфәттә авыр сулады.—Мин үз туганыма дошман түгел. Бәлкем, чәпчимдер дә, бәлкем, кычкырамдыр да, холкым шундый, әмма барыбер минем аннан да якынрак туганым юк. Гомәр ошады аңа.

"Шайтан йөртә үзегезне,—дип ачуланды ул эченнән.—Көн буена эшемнән аердыгыз".

—Кяфер ул,—диде кырыс кына галимә-хатын. Галимә дип аны ире имам аркасында гына йөртәләр, ә үзе укый да, яза да белми. Әмма хәтере яхшы. Ансыз яшәп булмый. "Ә бәлкем сез,—дип көйләп Коръәннән аять укый башлады ул,—нәрсәне дә булса яратмыйсыздыр, ә ул сезнең өчен файдалыдыр; ә бәлкем сез ни дә булса яратасыздыр, ә ул сезнең өчен явызлыктыр. Тәхкыйк, Аллаһы барысын да белә, ә сез берни дә белмисез". Гомәр Хәйям сезнең өчен явызлык ул, сеңлем. Мөэмин мөселманга андый кеше белән туганлашырга ярамый. Бөтенләй кеше дә түгел әле ул! Шайтанның үзе, кяфер, юлдан язган шагыйрь ул! Аңа кияүгә чыксаң, мәхәлләнең бер генә хатын-кызы да исәнләшмәячәк сезнең белән.

—Исәнләшмәсә соң?!—дип ябык иңбашларын җыерып куйды тегүче.—Миңа нигә кирәге бар аларның? Алар хәзер дә мине күргәч шатлыкларыннан егылып китәргә тормыйлар.

—Ә ул чакта бөтенләй башкача булачак: алар сез теккән нәрсәләрне алмаячак. Сез ипилек акча табу мөмкинлегеннән мәхрүм калачаксыз.

Тегүче үпкәләгәндәй итте:

—Минем күлмәк-халатларымны кулымнан тартып алалар, чөнки мин аларны тегә беләм. Бүтән базарда сатармын. Шәһәр зур.

—Юлдан язган киявен һәм тинтәк сеңлең белән бергә сезне мәхәлләдән үк себереп чыгарачаклар. Яшәр урынны башка җирдән эзләргә туры киләчәк.

Тегүче шиңеп калды. Әйе-е. Алар моны эшли ала. Кансызлар яши монда.

Гомәрдән башка кияү кирәкмәс иде ана. Ул шундый да мөлаем, яхшы күңелле. Аның үзен дә, Әлмирраны да беркайчан да җәберләмәс иде ул. Денсез икән—монысы аның шәхси эше. Ул үзе дә дингә алай ук бирелгән кеше түгел. Теге дөньяда ни булыр, кайчан булыр һәм булырмы әле ул? Тегүче үзенең энә белән тишкәләнеп беткән ябык кулларына карады. Шәригать кайгысы түгел әле монда... Әмма бит болар безне барыбер тынычлыкта калдырмаячаклар.

—Йә, ярый.—Ул чигенүгә таба бер адым ясады.—Әгәр Әлмирраны бу хөрмәтле ханымның улына бирсәм, безгә тимәячәкләрме?

—Шөбһәсез. Һәм хөрмәт итәрләр. Чөнки сез намуслы, әдәпле кешеләр белән туганлашасыз бит. Алар сезгә авыр вакытларыгызда ярдәм итәчәкләр.

"Сабыр ит әле, мин сиңа шундый да итеп ярдәм итәчәкмен!"—дип зәһәрләнеп уйлады пешекче хатыны.

—Алайса, эшкә күчик,—диде тол хатын коры гына.—Гомәр Әлмирра өчен ике йөз динар бирә. Ә сез нинди калым тәкъдим итәсез?

—Калым?—дип гаҗәпләнде пешекче хатыны.—Бернинди дә калым булмаячак, туй чыгымнары да җиткән.

Төрек карчыгы гаҗәпкә калды:

—Ничек инде алай?

—Менә шулай.—Һәм күрше хатын мәкерле төстә ахыргача саклаган төп дәлилен ачып салды:—Көлчәң бит янган.—Һәм аңлаешлырак булсын өчен төзәтеп өстәде:—Халатың... тишек... Сиңа төннәрен ул кадәр каты йокламаска, сеңлеңнең түбә аша чыгып, кая баруын күзәтергә иде.

—Алаймыни?—Тегүче муенын сузды һәм кобрага охшап калды.—Дөресме бу?—дип сорады ул зәһәрлек белән каршыда ашъяулык артында утыручы Әлмиррадан.

—Әйе!—дип кискен генә җавап бирде тегесе.

—Кем... Гомәр беләнме?

—Әйе!

—Йә Хода!

—Белдем... белдем мин синең кайчан да булса башыма бәла китерәчәгеңне,—дип мыгырданды тегүче, ни эшләргә белмичә һәм сукыр кебек тирә-ягында нидер эзләнеп.—Оятымнан кая барыйм инде мин хәзер?

—Аны Хәкимгә бирергә риза булсагыз, бернинди дә оят булмас,—дип, коры гына әйтте "галимә" хатын.—Бөтенесе кирәгенчә һәм шәригать кушканча булыр. Шулай эшләрбез. Риза булмыйсыз икән—бөтен мәхәлләгә мәсхәрә итәчәкбез.

—Бөтен шәһәргә!—дип төзәтте күрше хатын.

—Йә Аллам! Ни өченнәр бу кадәрле җәфалыйсың мине? Ничәмә-ничә еллар ашатып-эчерттем, бактым, карт көнемдә терәгем булыр, дип уйладым, һәм менә мә, ал бүләгеңне! Белдем мин... күңелем сизде...—Ул эзләгән әйберен артыннан, дивардан тапты. Һәм, ашъяулык өстеннән үрелеп, кинәт ташланган кобрадай, агач тукмак белән Әлмирраның маңгаена тондырды. Кызның тишелгән башыннан чәчрәп чыккан кан ашъяулыкны кызылга буяды, ипигә тамды. Әлмирра аңын җуеп күчтәнәч көлчәләр өстенә ауды.

Бу төнне Гомәр Әлмирраны озак көтте, ләкин ул килмәде. Югыйсә бит вәгъдә биргән иде. Килә алмаганда, гадәттә, алдан ук кисәтеп куя иде ул. Бу юлы кисәтмәде дә югыйсә.

Ана дип алынган алсу ефәк төргәге җәелмәгән килеш шүрлектә ята бирде.

Ни булды икән? Мөгаен, берни дә булмагандыр ла. Апасы белән бик тә дулкынланганнардыр. Туйны ничек итеп әйбәтрәк итеп үткәрү турында киңәштабыш корганнардыр да, хәлдән таеп егылганнардыр. Әллә тегүче хатын, акылына килеп, буй җиткән туганын сакларга булганмы?

"Ярар ла!—дип гамьсез генә кул селтәде Гомәр.—Үземнең дә ничә көн инде йоклаганым юк. Мәхәббәттән дә ял итәргә кирәк. Әлмирра беркая да китмәс, иртәгә килер..."

Шик-шөбһәләрне куып, йокларга ятты. Әмма бик теләде ул аны. Төшендә кайнар кулы белән ятакның гадәттә Әлмирра ята торган ягын сыпырып карады һәм, өч-дүрт тапкыр сыпырып та таба алмагач, төзәтеп булмаслык хата эшләгәндәй куркып уянды.

Гадәттәгечә, ул иртә торды. Башка көннәрдә ялт итеп, саф баш һәм ныклы куллар белән тора иде. Бүген исә кәефе төшенке иде.

Гомәр фәкать иртә белән ач карынга, саф баш белән, кәефне ачучы кытай чәе, яисә ямән боны, ягъни кофесы эчеп кенә яза ала. Ашаса, шундук эш сәләтен югалта. Көннең икенче яртысында укый яки йоклый.

Авыр сулап, эшенә утырды.

“Бөек Әбурәйхан Беруни Газнада үзенең ике томлык “Йолдызлар кануны”н тәмамлагач, ул вакытта хакимлек итүче солтан Мәсүд, явыз Мәхмүтнең улы, галимнәрнең яклаучысы булып күренергә тырышып, аңа ике дөя илтә алырлык көмеш бирергә куша. Әмма галим патша бүләген кире кага:

—Минем баш өстемдә—түбәм, өстемдә—киемем, алдымда җитәрлек азыгым бар, болардан тыш миңа берни дә кирәкми,—ди ул һәм көмеш төялгән дөяләрне кире борып җибәрә.

Ачуы чыккан Мәсүд аны зинданга яба.

Әррахиб әл-Исфахани әйткән: “Әмирләрнең иң начары—галимнәрдән ераграк торганы, ә галимнәрнең иң начары -әмирләргә якынрак торганы”. Хәтта иң тыныч холыклы әл-Газали да болай ди: “Әгәр дә син һәрвакыт сарайда булган галимне күрәсең икән, бел: ул—карак”.

Кызык: күрешәсе иде Газали белән, карыйсы иде үзенә, Багдадта кемгә әверелде икән...

Тәрәзә артында тыныч, эшләр өчен моннан да яхшырак вакыт юк. Әмма гадәттә аңа шатлык китерә торган тынлык бүген никтер эчен пошыра башлады. Әкренләп бу түзеп тормаслык хәлгә әверелде.

Моның ни өчен икәнен ул башта аңламый торды. Әмма инде бүтән яза алмады.

Аптырашта калып, каләмен куйды, келәм өстендә арлы-бирле йөренә башлады һәм, кинәт уянгандай, башын күтәрде.

Әлмирра тукмагының тавышы ишетелми бит! Аның өчен гадәтигә һәм, әйтергә мөмкин, күп мәгънәгә әверелгән тавыш.

Ул үзе турында хәбәр бирми.

Бәлкем, әле иртәдер? Юк, инде кояш чыккан. Ниндидер бер хәл булгандыр бәлкем. Ул моны шундук сизенде. Кабаланып, җиңелчә халатын киде, кесәсендәге акчасын капшап карады, яланаякларына башмакларын эләктерде дә урамга чыгып китте.

Кулларының, аякларының, ә иң мөһиме, йөрәгенең калтыравын туктатырга тырышып, капка төбендәге эскәмиягә утырды. Азрак тынычлангач, коточкыч гөнаһларда тотылгандай, качып-посып кына күршесенең кече капкасы янына килде, әкрен генә шакыды...

Ишегалдында җиңел, әмма акрын адымнар тавышы... Әлмирра түгел. Ул очкын кебек йөри. Гомәр ярыктан карады. Карчык. Килеп җитте дә ул да ярыкка иелде. Гомәр артка тайпылды. Тегүче хатын, елан кебек, аңа ялтыраган зәһәр күзләре белән карап алды да, усал итеп нидер мыгырданып, китеп барды.

—Апакай!—дип тыныч кына дәште Гомәр ярыктан.

—Каһәр суксын үзеңне! Уйнашчы, хәсис азгын!

Ала-ай. Башы миңгерәүләнгән Гомәр, кая юл тотуын да белмичә, урам буйлап китте. Үтүче-сүтүче юк: ком катламын аяклар туздырырга өлгермәгән әле.

Ул тупас, кытыршы ташлардан ничек кирәк алай өелгән кәкре коймалар буйлап озак йөрде. Фәкыйрь урам. Фәкыйрь мәхәллә. Фәкыйрь дөнья. Анда фәкать бер хуш исле матур чәчәк—Әлмирра бар, әмма, мөгаен, анысын да харап итәрләр...

“Кая барам мин? Шайтаныма олагыргамы!”

Кече капка ачык калды. Кем дә булса кереп, аның яңа китабын мәсхәрәләмәсен тагын.

Тегүче хатынның еланныкыдай карашына янадан эләкмәс өчен ул йортны икенче яктан әйләнергә булды. Ана ул көне буе капка ярыгыннан карап торыр кебек тоелды...

Тәмле булып пешкән ипи исе килә. Бу йортта кече капка иртәдән үк ачык, сатып алучылар өчен кирәк һәрчак ирекле. Яңа пешкән көлчәләр алырга инде әллә? Бүген эшнең дә, ашап-эчүнең дә рәте булмас, ахры.

Инде бушап калган түгәрәк зур мичтән дулкын булып кайнар һава һәм күңелне чеметтерә торган, якын, җылы көл исе чыга. Бик тә зур яссы кәрзиндә—кайнарлык бөркеп торучы, алтынсу төстәге көлчәләр. Ни генә әйтмә, кешеләрне тәмле икмәк белән сыйлау игелекле эш инде ул.

Гомәрне икмәк пешерүченең олы улы каршы алды. Көлчә кебек алсу, шома битле, таза яшүсмер.

Башка вакытта Гомәрнең фельсын баш иеп ала торган яшь хуҗа бүген ни өчендер караңгы чырайлы.

—Синең кебекләргә бездә ипи юк!

—Ә-ә?—Гомәр башта аптырабрак калды. Аннары, боларның да Әлмирра белән аның мөнәсәбәтләренә кагылышы барлыгына төшенеп, ачу белән каты итеп тешен кысты. Бер сугуда бу оятсызның буш чүлмәктәй башын яра алыр иде дә, их, ярамый! Үзен көчкә тыеп әйтте:—Ярый, базарга барам да өч фельслык көлчәгә юри бер динар түлим.—Ул тәнкәсен үсмернең борын төбенә китерде.—Һәм син керемнән колак кагачаксың, ишәк. Алтын динар! Синең мондыйны кулыңа да тотып караганың юк. Ә мин аларны йөз меңләп туздырдым инде...

Борылып чыгып китте.

Башланды... Хәзер алар аның тенкәсенә тиячәк.

Ярый соң, ишегалдына зур чокыр казып, аңа су тутырырга да, утарны тире эшкәртүчегә сатаргамы? Бөтен мәхәлләне чыланган тиреләрнең коточкыч сасы исенә күмәргәме?

Әй, бик кирәгегез бар иде...

Әбелатахия әйткән:

> О! Җир йөзендә күпме кеше!
> Тик бик азы Кеше өше...

Гомәр капканы бикләде, идән астыннан бер кувшин чиста кызыл шәраб алды. Арпа аракысын күптәннән авызына алганы юк инде.

"Дөньядагы җиде могҗизаның барысы да йөзем тәлгәшенә табынучы халыклар тарафыннан уйлап чыгарылган",—дип көлемсерәде Гомәр, касәсен шәраб белән тутырып.

Ул үзенең "Нәүрүзнамә"сендәге риваятьне исенә төшерде.

... Бервакыт Шамиран патша тәрәзә янында утыра икән. Янәшәсендә бик яхшы мәргән улы Бадам да бар. Кинәт алар алдына җиргә, кычкырып, феникс-кош килеп төшә. Муенына юан елан уралган. Елан матур кошны чагарга әзерләнгән. Әтисе әмерен тыңлап, Бадам үзенең искитмәле ялтыравык җәясен киерә дә угы белән еланны җиргә кадый. Бәхетсез финикска бернинди дә зыян тими кала. Ул рәхмәтле тавыш чыгарып, очып китә.

Бер елдан соң алар аны шул ук көнне шул ук урында янадан күрәләр. Феникс җиргә нәрсәдер куя да, берничә тапкыр кычкырып, күккә күтәрелә.

—Карагыз әле, нәрсә калдырды икән ул,—ди патша үзенең яраннарына.

Тегеләр кечкенә генә каты өч орлык алып килә. Патша әлеге орлыкларны бакчага утыртырга куша. Алардан язын нечкә генә үсенте чыга. Ул әкренләп киң һәм очлы яфраклы озын, сыгылмалы сабакка әверелә.

Кешеләрнең мондый үсемлекне моңарчы күргәннәре булмый. Бакчада иң матуры була ул. Кәләштәге бизәнү әйберләре кебек, анда куе булып тәлгәшләр асылынып тора. Көзгә таба җимешләр карала башлыйлар, аннары яшелдән ахак кебек чем карага әвереләләр, тәлгәштән җиргә коела башлыйлар.

—Аларны сык та сүлен кисмәккә сал, нәрсә килеп чыгар икән,—дип куша бакчачыга Шамиран патша.

Берничә көн үткәч, бакчачы аңа әйтә:

—Сүл утсыз-нисез казандагы су кебек кайный.

Кайнаудан туктагач, сүл якут кебек ачыклана, үтә күренмәлегә әверелә.

"Үсемлек шуның өчен үсә икән,—дип уйлый патша.—Әмма без аның файдалымы, әллә зарарлымы икәнлеген белмибез".

Зинданнан үлемгә хөкем ителгән бер мәхбүсне китерәләр һәм, ни булыр икән, дип, аңа бер касә әчегән сүл бирәләр.

Шуны эчкәч, тоткын йөзен чыта: "Әче!"—ди. "Тагын эчәсеңме?" "Эчәм". Икенче касәдән соң күнеле күтәрелә моның, җырлый һәм бии башлый. Өченче касәне сорап ала. Шуннан соң куак төбенә ята да тирән йокыга тала. Уянгач, аны патша янына китерәләр.

—Моны эчкәч, ниләр хис иттең син?—дип сорый Шамиран.

—Мин үземне патша итеп хис иттем,—ди тоткын.

Патша аның гаебен кичерә. Шуннан соң үзе дә әлеге шәрабны эчә башлый. Башкаларга да рөхсәт итә...

Төн көмешсыман ак. Мондый зур ак айлы төндә күзне талчыктырмыйча да укырга була. Агачлардагы һәр яфрак, ишегалдындагы һәр таш кисәге аерым-ачык күренә. Инеш өстендә дә ап-ак сыек томан агыла.

Үзенең ачык киң тәрәзәсе янында Гомәр күрше йорт диварына карап тора. Анда—дар агачыннан төшкән кебек, басмаларның кәкре кара күләгәләре. Ә баскыч үзе ятим кебек ачык, онытылган, бәс каплагандай, якты ай астында салкын булып агарып тора.

Бөтенесе коточкыч үзгәрде! Әле кичә генә бу басмалардан Әлмирраның житез, матур аяклары атлаган иде.

Һәм Гомәр бөтенесен тиешенчә кабул иткән иде. Бөтенесе тәртиптә иде. Бәхеткә бик тиз күнегәбез шул без, аның башлангыч рәхәтлеген, сафлыгын саклый алмыйбыз. Кыскасы, бәһалене бәяли белмибез.

Ә бәяләргә кирәк иде. Һәр мизгелдә. Язмышның көтелмәгән бер борылышы—һәм бөтенесе юкка чыга. Бушлык. Утыр да, хет айга карап, эт кебек ула.

Югалту әчесе күкрәкне кара агу белән тутырып, башка кайнар дулкын булып килеп бәрелде һәм Гомәрнең күзләреннән яшь тамчылары сытылып чыкты.

Аның көрсенү-аһларын ишеткәндәй, күрше йорт түбәсендә, чинарның кара-яшел күләгәсендә ак шәүлә пәйда булды. Ул баскычтан аска төште, ак өермә булып, якты ишегалдына узды һәм күпмедер мизгелдән бүлмәгә атылып килеп керде. Ай яктысы чагылышыннан Әлмирраның башындагы ак бәйләвеч—аның тирәсендәге нурлы алка, ә бәйләвечтәге тап—канлы йолдыз булып тоелды.

Талчыккан Гомәр, бу бәхеткә ышанып ук бетмичә, юеш маңгае белән Әлмирраның яланаякларына терәлде һәм аларны күз яшьләре белән юды.

Соңгы шатлыклар.

Соңгы көрешү...

—Качыйк моннан!—диде Әлмирра капыл гына, инде алар икәүләшеп елап, бераз тынычлана төшкәч.

Һәм моның белән Гомәрне тирән аптырашта калдырды.

Ул, бәлкем, аның белән качып китәр дә иде. Үзенең гаепле икәнен белсә, әлбәттә. Әмма бит мәхәббәт җинаять түгел. Әгәр җинаять түгел икән, нишләп соң без мең еллар буе, мәхәббәт ул—байлык, муллык, дип кычкырабыз? Кысаларга кертелгән мәхәббәт мәхәббәт түгел инде ул.

Өстәвенә—аның китабы. Аны әле язып бетерәсе бар. Ул—язучы. Ул язарга тиеш! Аңлашылмыймыни соң инде бу? Качкынлыкта, шау-шулы кәрвансарайларның хөҗрәләрендә күп эшли алмассың. Мондый китапны, ул үзе күзаллаган китапны язу өчен күңел тынычлыгы, җан рәхәтлеге, бимазасызлык кирәк.

Ә инде үзеңне теләсә кайсы мизгелдә качкын җинаятьче итеп тоясың икән, нинди күңел тынычлыгы, җан рәхәтлеге ди ул?!

Дөресен генә әйткәндә, яше дә бар бит инде, күпме генә әтәчләнсәң дә, арыганлык үзен барыбер сиздерә, кеше теләсә нинди тетрәнү һәм мәҗаралардан курка башлый торган чиккә житеп килә. Гомумән, ул балачактан ук тыныч, ипле тормышка омтылучан. Тормыш исә аны, үз ихтыярына каршы, әрле-бирле бөтерелдереп йөретте.

—Ә минем язасы китабым нишләр?—диде ул, ниһаять.

—Дөресен әйт,—дип кинәт кенә урыныннан калыкты Әлмирра һәм шундук, ыңгырашып, кан таплы тукыма уралган башын тотты,—синең өчен кайсы кадерлерәк: китабынмы, әллә минем мәхәббәтемме?

Кара син бу шайтанны, яшенә караганда да акыллырак! Әмма соравы—ахмак һәм мәкерле сорау. Әйтерсең лә, китапны тормыштан аерып була. Алайга калса, хатын-кызның логикасы шундыйдыр инде. Йә тегеләй, йә болай. Ә син, ир-ат, теләсә ничек боргалан.

—Китап,—диде Гомәр, йөрәген кысып.—Ни әйтсәң дә, минем исемем—Шагыйрь, ә Кияү түгел. Мин бит синеке генә түгел. Һәм үземнеке генә дә түгел. Мин—үземнең китапларымны укучыларныкы да. Ягъни—халыкныкы.

—Халык укый белми!—диде тегесе, ярсып.

—Аның каравы хәтере яхшы. Нишапурда, юк, Нишапурда гына түгел, бөтен Иранда һәм Туранда минем шигырьләремне яттан белмәгән кеше юк. Хәтта көйгә салалар аларны.

—Ә! Ярый соң... алай булгач...—Әлмирра торды, матур гәүдәсенә төнге ак күлмәген киде, сәке кырына утырып, үз уйларына батты.

Ишегалдында—кинәт гөрселдәү. Кемнеңдер карлыккан тавышы. Баскычтан егылып төшкән, аксаган, чәче-башы тузган, коточкыч кыяфәтле, кулына агач тукмак тоткан карчык аларның бүлмәсенә атылып килеп керде.

—Ләззәтләнәсезме? Караклар!—Ул, мескенкәй, кардәш сеңлесе белән Гомәр бергәләп үзен талыйлар дип уйлады. Ул кычкырмый, ә фәкать булачак карендәшләрен уятмас өчен акрын гына ырылдый иде.—Үтерәм мин сине, себерке!—Өстәлне аударып, ул тукмагы белән Әлмиррага ташланды.

Гомәр аның кулыннан тотты, тукмагын алды. Үз-үзен онытып, карчык бар көченә акыра башлады. Гомәр учы белән аның авызын каплады. Хәзер бирегә бөтен мәхәллә җыелачак.

Тегүче аның сакалына ябышты. Хатын-кызның шундый явыз җанвар икәнен башына да китермәгән иде. Акылын җуеп, үз явызлыгыннан ләззәт табып, теләсә кемне үтерә ала ул. Канәчкеч убырлылар турында сөйләнүләр, мөгаен, юкка түгелдер.

Ул аны почмакка селтәп җибәрде. Карчык дивар янына авып, җан өшеткеч тавыш белән үкерә башлады. Һәм Гомәр, коты очып, шуны күрде: Әлмирра инде аның белән түгел, ә апасы белән, өстәлнең бу ягында түгел, ә теге ягында апасы янәшәсендә кайнаша. Бәхетсез шагыйрь!

—Шушы булдымы өйләнешү бәхете?—дип кычкырды Гомәр.—Булды! Шайтаныма олагыгыз. Алайга калса, мин өйләнмим. Моннан соң да беркайчан да өйләнмәячәкмен. Гомерем буе бер сынга да табынмадым, хатын-кызга бигрәк тә табынмам. Дөньяда мөһимрәк нәрсәләр дә бар. Мә!—Ул ал ефәк төргәген Әлмиррага ыргытты.—Туеңа миннән бүләк булсын!

—Кирәге юк!—Әлмирра, гарьләнеп, ишеккә таба юнәлде. Апасы—аның артыннан. Әмма анысы барган уңайга ефәк төргәген әләктерергә онытмады.

Бүген Гомәрнең эшлисе килмәде. Шулай булмыйча! Күңелең урыныннан кузгалып, башында мең төрле фикер чуалганда иҗат итеп була димени?! Кәефен юкта аш та пешерәсе килми хәтта.

Төрекмән Ораз әйткәндәй, кешеләр йә ачыктан-ачык, сугышта, йә яшерен төстә, көнкүрештә бер-берсен юк итәр өчен яратылганнар микәнни? Мәсәлән, ир-ат белән хатын-кыз аерым яши алмыйлар, әмма бергә яши торгач, "мәхәббәт" белән шундый сугарылалар ки, ире—хатынын суярга, хатыны ирен агуларга әзер. Тьфу!

Кояш чыкканда Гомәр инешнең теге ягындагы кечкенә, әмма бик уңайлы бакчасына керде. Ясмин һәм лаләләр үсеп утырган, эшкәртелгән җир янәшәсендә ул беркөн зур гына кырмыска оясы күргән иде. Дөньяда кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә тәртип юк икән инде, игелекле бөҗәкләрнең тәртипкә салынган тормышын күзәтик, ичмасам...

"Тапканнар урын!—дип кызганып уйлап куйды Гомәр.—Канауга су керә башлау белән үк бата башлаячаклар бит болар. Ыгы-зыгы килә, чабыша, йомыркаларын коткара, аларны өскә ташый башлаячаклар. Әмма су китеп, тишек кипкәч, тагын шул ук тишектән аска төшәчәкләр. Кырмыскаларның шуны истә

тота алмаулары аларның акылы белән һич тә сыешмый. Ә соң кешеләрдә дә шул ук хәл түгелмени? Җир тетрәп, аларның йортларын җимерә. Вулканнар лава белән каплый, су юып алып китә. Ә алар һаман-һаман шул ук үзәнлеккә әйләнеп кайталар. Үҗәтлекме, кыюлыкмы яки гади күнегүме бу? Ни генә булмасын, бу үҗәтлек кешеләргә бик кыйммәткә төшә. Меңнәр һәлак була..."

Әйе-е. Әгәр кешеләр һәм кырмыскалар арасында ниндидер охшашлык бар икән, нәкъ менә шушы мәгънәсез ыгы-зыгыда, дип боегып уйлады Гомәр. Ни хакына? Бөтенесе шул байлык җыю, саранлык, бер үк омтылыш—туйганчы ашау һәм үрчү, нәсел калдыру хакына...

Юк, Кырмысканы Кеше белән чагыштырырга ярамый. Һәм Кешене Кырмыска белән дә. Оят. Кешеләр кырмыскаларга охшаган икән—бу бик начар.

—Ат абзарың синең, әлбәттә, юк инде. Атларны кая куярбыз икән соң без?

—Монда кунарга җыенмыйсыз икән, урамда торсыннар.

... Хатыны Гомәр белән Әлмирра турында сөйләгәч, мәхәллә мәчете имамы аптырап калды. Гомәр тегенди-мондый кеше генә түгел, аңа болай гына якын килә алмыйсың. Аерым очрак бу. Берни дә уйлап таба алмагач, имам, дер калтырап, шәһәр казые Хөсәен бине Гали бине Микаль янына китте.

—Минем генә көчем җитми аңа! Чөнки бик үк гыйлемле түгелмен. Ә ул, әйтүләренә караганда, Коръәнне яттан белә икән.

Казыйның күңелендә элеккеге вәзир Гыйззелмөлек вакытында Гомәр тарафыннан ясалган ике мең динарлык зыяннан калган тирән җәрәхәт әле дә булса сызлый иде. Ниһаять, үч алыр вакыт җитте! Әмма бөтенесен яхшылап уйлап, тавыш-тынсыз, үлчәп эшләргә кирәк. Гомәр кебекләр белән сак булуың яхшы. Кем белгән аны: ул әле иң түбәндә, әле иң биектә...

Хөсәен үз ялчысына атларны иярләргә кушты. Имамга ялчысының атын тәкъдим итте. Ялчысына җәяү барырга туры килде. Юлда барганда аның күңеленә әллә ничә тапкыр хәлсез картны аягыннан өстерәп төшерү уе килде...

Шулай итеп алар, казый белән шагыйрь, тагын очраштылар.

Гомәр кунаклар алдына узган елгы анарларны куйды—салкынча базда алар бик әйбәт сакланган иде.

Хөсәен бине Гали бине Микаль гадәттә булмаганча ачык йөзле, Гомәргә карата ачык мөнәсәбәттә.

—Яхшы,—диде ул, әкияти ишегалдына нурлы караш ташлап. Аннары табактан иң эре, иң өлгергән, куе кызыл төстәге, сары тимгелле анарны алды.

—Биредә шагыйрь яшәгәнлеге шундук сизелә.—Тагын өстәп куйды:—Зур шагыйрь. Хисләргә бай шагыйрь.

"Бәлкем, бу кеше буларак алай начар да түгелдер,—дип уйлады Гомәр, аның мондый мөгамәләсенә күңеле булып.—Хәсис һөнәре генә бозгандыр үзен".

—Тик,—дип авыр сулады казый, кулындагы авыр җимешне ничек ашарга белмәгәндәй әйләндереп,—ничектер, күңелсез, димим, ә саран яшисең, ат алып җибәрәсең бар, димме...

Яшьлек—гамьсез һәм әрәм-шәрәм итүчән.

Өлгереп җитү сатып алу омтылышы уята.

Картлык—байлык җыюга. Ягъни кешегә инде ул вакытта кәфенлек белән зиратта кечкенә җир кисәгеннән башка нәрсә кирәкми.

Бик сәер ул кеше дигәнең!

Әмма аларның күз алдында Нишапурда иң сәер кеше—Гомәр Хәйям.

—Ә ник кирәге бар ул атның?—дип, гаҗәпләнеп сорады Гомәр.

—Соң... кирәк урынга тизрәк барып җитү өчен.—Кабыгын вакытыннан алда ертмас өчен казый анарны каты итеп, әмма сак кына учлап тотты да баш бармагы белән кабык аша каты төшләргә басты.

—Ә нигә ашыгырга?

—"Ни өчен әфәнде" дип юкка гына атамаганнар икән сине,—дип елмайды Хөсәен.—Нигә булсын—тормыш юлны кыскартуны таләп итә.

—Ә юл үзе үк тормыш түгелмени?—Гомәр инсәләрен җыерып куйды.—Тормыш үзе юл инде ул. Ашыгу, юлны кыскарту, димәк, тормышны кыскарту дигән сүз. Беркайчан да ашыкма—беркайчан да соңга калмассың. Ат өстендә

бөтенесен дә күреп бетереп булмый. Нинди рәхәт бит: ашыкмыйча гына җәяү барасың, һәр инеш янында тукталасың, аның челтерәвен тыңлыйсың, аның өстенә ничек матур булып күләгәле куаклар асылынып торуын, аларда пыр-пыр килеп кошлар очуын күрәсең. Күк йөзе, басу, калкулыклар—күз алдында. Су янында иелеп торган тирәк алдындагы хәрчәүнәдә утыру үзе бер хозурлык бит. Ә юлда күпме кызыклы очрашулар көтә. Ат өстендә чапканда юлда очраган кешенең күзенә карап, аның белән бер-ике сүз алмашып буламы соң?! Әнә шул инде ул тормыш дигәнең... Аннан кая ашыгырга, ди?! Тыныч кына, ашыкмый-кабаланмый гына яшәсәң, гомерең озынрак булыр. Барыбер бит кабердән дә ераграк китә алмыйсың.

Гомәр Хәйям сүзен шигырь белән йомгаклап куйды:

Шөкер ит, тишек булмаса чикмәнең,
Ашарына булса бер сынык икмәгең;
Бушка да кирәкми байлыгы-даны,
Тормыш кадерле. Шул—дөньяның яме...

*(Н. Арсланов тәрҗемәсе)*

—Анысы шулай,—дип көрсенеп куйды Хөсәен.—Әмма дә ләкин ат кешегә олпатлык та өсти бит әле.

—Кешене ат яки ишәк кенә олпат итеп күрсәтә икән, аннан ни мәгънә?

—Аһ, бу шагыйрьләр!—Хөсәеннең ябык, әмма көчле куллары белән изелгән анар чүпрәк янчык кебек асылынып калды.—Сүзләрең һич кенә дә аста калдырмаслар. Әмма без бирегә аның өчен килмәдек. Ни өчен икәнен беләсеңме, әфәндем?

Бу икәүнең ник килгәнен Гомәр, әлбәттә, сизенде. Ә шулай да:

—Юк,—диде.—Башыма һич кенә дә сыйдыра алмыйм. Болай гына, хәл белергә килгәнсездер, дисәм...

—Казый кешеләргә болай, тиктомалдан гына керми.—Хөсәен тырнагы белән анарның кабыгын ертып, чынаякка аның якуттай сүлен сыгып агызды. Анары зур иде—чынаяк тула язды.—Бик тә мөһим эш белән килдек без. Мәхәлләгез кешеләреннән синең өстән шикаять бар.—Хөсәен чынаякны авызына якын китерде.—Сөйләгез, хөрмәтлем,—дип ым какты ул имамга.

Монарчы читтәрәк тыйнак кына утырган имам вәкарь белән генә йөткергәләп куйды, аннары мәчеттә вәгазь укыгандай тантаналы төстә башлап китте:

—Сез галиҗәнапләре... э-э... күршебездә яшәүче кызны көчләгәнсез икән...

—Көчләгәнмен? Ха-ха! Иске бер мәзәкне ишеткәнегез бармы? Берәү сораган: "Ир кеше хатын-кызны көчли аламы?"—дигән. "Көчли ала,—дигән икенчесе,—әгәр дә ул теге хатыннан качып котыла алмаса". Кем кемне көчли бит.

—Барыбер. Никахсыз яшәү—уйнаш кылу. Уйнаш кылу—гөнаһ. Ә гөнаһ шәригать буенча—җинаять.

—Җинаять,—дип раслады казый һәм чынаяктагы сүлне эчеп бетерде.—Мондый җинаять өчен мөселманнар, бергә җыелып, гаепле кешене таш атып кыйный алалар.

—Әмма дә ләкин үз гөнаһымны юу өчен мин өйләнергә әзер! Ә нигә әле сезгә Әлмирраны нәкъ менә шул тинтәккә бирергә кирәк? Харап булачак ул аның белән. Миңа бирегез, мин әйбәт түләрмен, шуның белән эш тә җайланыр. Кай җирем белән пар түгел мин аңа?..

—Ярамый,—дип, башын селекте имам.—Хәким тәртипле гаиләдән. Ә сез—таплы. Әлмирраны ул алачак, шулай дөрес булыр. Сез алсагыз, кешеләр аңында фетнә башланачак, ә менә юл куярга ярамый.

—Миндә кай җиремдә һәм нинди тап күрдегез әле сез, мөхтәрәм имам?—дип кызуланып сорады Гомәр.

Имам ярдәм сорагандай казыйга ялварулы караш ташлады.

—Син,—дип йомшак кына, түземлелек белән генә аңлата башлады казый, икенче анарга тотынып,—ислам тормышын белеп бетермисең. Кирпеч суга торган калыпны күргәнең бармы? Кирпечләр күп, ә калып бер генә. Менә шулай, мәхәлләдә әнә гомуми калыпка сыймаган, кыскасы, гадәти булмаган бар нәрсә—

шикле һәм шунлыктан куркыныч. Ә син ислам кануннарын санга сукмыйсың, бөтенесен үзеңчә эшлисең. Син мәхәлләдә махау авырулы кебек...

—Аңлашыла,—дип күңелсез генә баш какты Гомәр.

—Бәс, шулай икән, син монда ят кеше,—дип өстәде Хөсәен.

—Бик тә сәер!—дип кычкырып җибәрде Гомәр.—Үземдә, үз туган илемдә нишләп ят булыйм мин? Мин аның сәламәтлеге белән сәламәт, аның авыруы белән авыру. Ә шулай да—гарәпләр өчен ят, иранлылар өчен ят. Төрекләр өчен инде әйтеп тә торасы түгел. Патшалар өчен, түрәләр өчен дә ят. Шайтаным белсенме моның ни икәнен! Әйтегез әле, бәлкем шигырьләремдә мин үтерергә, алдарга, таларга өйрәтәмдер? Кешене кимсетергә өндимдер? Кеше фикерен басарга, кеше шәхесен кимсетергә чакырамдыр? Әллә соң мин хыянәткә һәм дошманлыкка, түбән аңлылыкка һәм ялагайлыкка өйрәтәмме? Киресенчә! Мин һәр дүртьюллык шигырем белән кешегә: “Гадел бул, киң күңелле бул, акыллы, горур, бәйсез һәм намуслы бул, куркуга һәм хорафатларга бирелмә, башкаларны кимсетмә һәм үзең дә кимсенмә, үзеңнең һәм башкаларның кешелек дәрәҗәсен хөрмәт ит”,—дип өйрәтәм. Әгәр кешеләрне тәнкыйтьлим икән, бу бит кешене күралмаганнан түгел, аларның дөньяга күзләрен ачу һәм фикерләүче җан ияләре дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм итү өчен.

—Менә шуның өчен дә ятсың син безнең өчен,—диде казый.

—Боларның бөтенесе юләрлек.—Гомәр, арып, кулын селтәде.—Мин бөтен Көнчыгышка үз кеше. Бөтен Көнбатышка да. Бөтен дөньяга! Сез ул хәтта үз-үзегезгә дә ят кешеләр!

—Без сине мәчеттә бөтен кеше алдында мәсхәрәгә калдырып, мәхәлләдән куа алабыз,—диде имам кырыс кына. Казыйның теләктәшлеген тойгач, ул кыюлана төште.

—Куарга?—Гомәр тешләрен ыржайтты. Әлеге ахмак әңгәмәдән аның инде күңеле болгана башлаган иде.—Тырышып карагыз! Мин базарда ике мең ярым алтынга җаванмарлар шайкасын яллап, өемне сакларга кушачакмын. Ишеткәнегез бармы шундыйлар турында?

—Пычаклары ике терсәк озынлыктагы башкисәрләрме инде ул?—дип агарынып сорады казый.

—Нәкъ үзләре. Шуннан да кыска түгел.—Гомәр линейка, себерке алды һәм аның сабында җаванмарларның корыч пычагының нинди озынлыкта икәнен күрсәтте.—Ябык ике казыйны берьюлы тишеп чыгарлык. Өстәвенә мәхәллә мәчетенең шыксыз имамына да җитәрлек. Казый белән бер хәйләкәр турындагы мәзәкне беләсеңме? Бер изге кеше хәйләкәр алдакчыны казыйга алып килгән дә әйтә икән: “Менә бу миңа өч йөз динар бурычлы, шуны түләми”,—дигән. Теге хәйләкәр алдакчы кулын куенында тота, чапаны кабарып тора, эчтә нидер бар икән. Ә бәлкем алтын кисәгедер. Казый, миңа хәйләкәрдән файда күбрәк булыр, дип уйлаган да аның файдасына карар чыгарган.

Кимсетелгән изге кеше киткәч, хәйләкәр казыйга әйтә икән: “Ярый әле карарны минем файдага чыгардың, юкса башыңны ярган булыр идем”,—ди һәм куеныннан авыр таш чыгарып күрсәтә...

—Нигә инде алай... мәрхәмәтсез рәвештә...—диде Хөсәен, тыныч булырга тырышып.—Шул ук ике мең ярымга син каза күрүчеләрнең күңелен күреп котыла аласың.

—Каза күрүче ул мин түгелмени?

—Менең без бәхетсез корбанның апасына бирербез.

—Бәхетсез? Һе. Хәер, чыннан да корбан ул. Әмма минеке түгел, сезнеке. Сезнең рәхимсез гадәтләрегез корбаны.

—Икенче менне—кияүнең әнисенә. Чөнки ул сезнең гөнаһларны яшерергә ризалык бирә.

—Әйе-е. Бик тә “тәүфикълы” гаилә икән...

—Хезмәтебез өчен ике йөз иллешәрен үзебезгә алырбыз.

—Башымны катырмагызсана! Әйтерсең лә, мин сезне белмим. Меңәрне сез,—шагыйрь мулла ягына ым какты,—аның белән үзегезгә алачаксыз, ә тегеләргә ике йөз иллешәрне бирәчәксез. Бирсәгез әле. Әмма бу миңа

кагылмый. Теләгәнегезчә бүлешегез. Ин мөһиме—түләсәм, сез мине тынычлыкта калдырачаксызмы? Сез һәм сезнен имин мәхәлләгез? Мина эшләргә кирәк, язарга!

—Рәхәтләнеп эшлә. Мәмләкәткә дә файда булыр.

—Акча алуын турында кәгазенне әзерлә. Анар суын түгел, минем канымны эчәсен. Шушында, ишегалдында утырып торыгыз, мин акча ваклаучыга—саррафка барып киләм. Акчаларымны мин шунда тотам. Өйдә тоту куркыныч. Беләм мин сезне. Кубәү сез...

Саррафка киткәнче ул башта өйне әйбәтләп бикләде. Агач булса да, нык һәм хәйләле йозак ул. Эчке биге бар. Ана ачкыч яратырлык түгел.

Тәрәзә капкачларын да эчтән элмәккә эләктереп, ябып куйган иде. Әлеге канун кортларынын анын "Сагыш китабы"нда актарынулары житмәгән тагын! Сәмәркандтә чакта хезмәтче Юныснын тик торганда анын кульязмаларын юк итәргә теләвен онытмады әле Гомәр.

Юл унаеннан, түзә алмыйча, хәрчәүнәгә кереп чыкты. Жаны кисәкләргә аерылды, әлеге кисәкләрдән куе төтен чыкты. Аларны шәраб белән сүндерергә кирәк иде.

Ерткычлар! Чәнчелеп китегез үзегезнен андый мәхәббәтегез белән.

Ул юләрләр үзләре тавис койрыкларын кем алдында ачарга белми эзләнәләр. Кая сон элеккеге кызлык тыйнаклыгы? Үзләре сасыйлар да, син жавап бир. Килеп карасын хәзер анын янына розалы бирәр хатын-кыз...

И Ходаем, кызган минем мескен йөрәгемне,
Уттай янган һәм кысылган күкрәгемне;
Күтәрелгән кулларымда шәраб белән касә тулсын,
Һәркем белә: акыллылык—түгел кимлек.
Шыр дивана—язмыш өчен сөйкемле жан.
Куй гаменне. Әйдә без дә тинтәкләник:
Китерегез исертергә шәраб тулы касә, йә жам...

Куе кызгылт-көрән япма, яшел яулык белән уратылган яшел фәс кигән казый, бизәкле чаршау корылган ишек янына вәкарьле генә килеп, тамак кырып куйды һәм бармаклары белән ишек янагына суккалады.

—Кули, наам, анта вәкили!—дип ачык итеп гарәпчә әйтте шартлы жөмләне. Һәм ашыкмыйча гына аны фарсычага тәржемәләде:—Әйе, син минем вәкилем", дип әйт,—диде.

Бөек гарәп телен кем белә монда? Казыйнын шул телдә башлавы да мөһимрәк булып күренү өчен генә иде. Һәм тагын барысынын да казый Хөсәен бине Гали бине Микальнын Гомәр Хәйямнын ваз кичкән өчен биргән акчасыннан үз өлешен тикмәгә генә алмавына ышансыннар, үзенен никахлашу йоласында катнашуы белән бу ике гаиләне нинди дә булса мәхәллә йолкышы түгел, ә шәһәр казые үзе, зур кеше бәхетле иткәненә горурлык хисләре кичерсеннәр өчен иде.

Тегүче хатын өенен айванында бу очрак унаеннан сатып алынган яна киез өстендә, ашъяулык артында кияү, имам, кияүнен әтисе, шаһит-күршеләр утыра.

Бизәкле чаршау корылган ишек артында хатын-кызлар яшеренгән. Ипи пешерүченен хатыны Әлмирранын аркасына зур йодрыгы белән китереп төртте, һәм кыз әкрен генә:

—Әйе, син минем вәкилем,—диде.

Бу исә: кияүгә чыгарга ризалык бирәм, минем исемнән никахлашуны казыйга ышанып тапшырам, дигәнне анлата.

—Әйт: "Әйе, син минем вәкилем",—диген.

—Әйе... син минем... вәкилем.

Әлеге йола мыскыл итүгәрәк охшаган. Бернинди дә шик калмасын өчен казый шәригатьнен бу сорау сүзләрен ундүрт тапкыр кабатларга һәм кәләш ундүрт тапкыр ачык, анлаешлы итеп ана унай жавап бирергә тиеш.

Әлмирраның кискен төстә: "Юк!"—дип җавап бирү мөмкинлеге бар иде. Әмма тегүче апасы тукмак тотып басып тора. Ипи пешерүче хатынның да кулы йодрыкланган. Имам хатынының агулы теле дә әзер. Арыды Әлмирра! Бөтенесе шатлыклы, тыныч, җайлы, рәхәт иде—кинәт кенә акылдан язарлык буталчык, шау-шулы тормыш башланды. Тизрәк бетсен иде бу хәлләр. Хәкимгә чыгарга икән инде, Хәкимгә. Ходай шулай язгандыр...

Һәм Әлмирра, әле кычкырып, әле пышылдап, әле карлыгып, йә күз яшенә тыгылып, ундүрт тапкыр:

—Әйе, син минем вәкилем,—дип әйтергә мәҗбүр булды.

Шулай итеп. Гомәргә юл бөтенләй ябылды.

Ә аның Гомәр берничек тә чишә алмаган сере дә шунда яшеренмәгән микән әле? Дөньяның үзе кебек карт, сантый-шагыйрьдән башкаларның һәммәсенә билгеле "сер"—шик-шөбһәләрдән, борчылулардан, мышкылдап елаулардан, үкерү-бакырулардан, ә кайчак акыл ярлылыгы сәбәпле аз гына уйланулардан соң, читенне җинелгә алыштыру сере. Күңел тынычлыгы һәм яшәү унайлыгы бәрабәренә мәхәббәтне сата алу сәләте.

Хәер, ул нишли ала соң? Унике яшьтә кемнең муеныннан жиргә күмелеп, үткән бер кешенең йөзенә төкерүен, үзенә пычрак, таш атуын теләсен?

Әйе, көчсез бу чыпчыкның тамагы өчен Гомәр артык зур, чәнечкеле һәм кытыршы "кисәк" булды, күрәсең...

Нишапур—зур һәм шау-шулы шәһәр. Бай, сәүдә, һөнәрчелек шәһәре. Гомәр Хәйям ярата үзенең шәһәрен. Яшь вакытында ук ул моннан каядыр, булмаган могҗизалар дөньясына ашкынды, әмма менә хәзер, картайгач, үзенең зәнгәр Нишапурыннан башка беркайда да яши алмас иде.

Ә шәһәр аны яратмый. Ул Гомәрне үзенең мәгънәсез корылмалары, ыгы-зыгысы, кешеләренең дорфалыгы белән җәзалый. Кырык мәхәллә, эреле-ваклы шул кадәр үк базар, дистәләрчә кәрвансарай. Кара кытайлар—Ерак Көнчыгышта Цинь—Алтын империясенә нигез салган чжурчженьнәр турында беркем дә белми әле. Алар кулыннан сәлҗүкләр дәүләте җимерелә, аны тар-мар итү эшен Балх тирәсендәге огузлар тәмамлый. Нишапур алар тарафыннан тәмам таланачак һәм яндырылачак. Һәм җимерелгән шәһәр, вакытлар үтү белән, ташландык бер торакка әвереләчәк. Бөтенесе эзсез югалачак, бөтенесе бетәчәк.

> Элек монда горур шаһлар утырган,
> Хәзер бу җир тузан-туфракка тулган;
> Саный моңлы кәккүк: "Кем бар да кем юк!.."—
> Хәрабә өстенә кунган урыннан.
>
> *(Н. Арсланов тәрҗемәсе)*

Янәсе, бөтенесе кая юкка чыккан? Дөрес, бу әле тиз генә булмаячак, аңарчы озын-озак алты дистә ел үтәчәк. Гәрчә тарих күзлегеннән караганда, бу бик аз вакыт инде. Дәверләр, гасырлар белән эш итүче тарих өчен күз ачып йомганчы үтә торган ярты гасыр күпмени соң ул?!

Әмма әлегә беркемгә дә бернәрсә дә билгеле түгел. Әлегә вилаять[1] хакиме, төрек әмире-сипаһдар—хәрби түрә Нишапурның иң зиннәтле сараенда, рәшәткәләре алебастр бизәкле тәрәзәләр һәм айваннар артында тук, рәхәт тормышта яши. Ул үз кулына үзәнлектәге иң ундырышлы җирләрне һәм күрше таулардагы үләнгә бай болынлыкларны алды.

Аның белән янәшә хәрбиләр катлавыннан күренекле төркиләр тәмле ашыйлар, татлы эчләр. Иктадарлар, ягъни патша хакимияте тарафыннан аларга бүләк ителгән авыл җир биләмәләре, шәһәр корылмалары һәм һөнәрчелек биналарының хуҗалары да шулай ук рәхәттә яши. Аларның хезмәтчеләренә һәм, билгеле инде, сугышчыларына да күпмедер тама.

Сарайда аз гына түбәнрәк хаким—җирле диһканнардан, бай җирбиләүчеләрдән чыккан шәһәр башлыгы да кәеф-сафа кора. Ул төрекләргә бөтен

[1] Вилаять—өлкә.

жаны-тәне белән бирелеп хезмәт итә. Чөнки бу ана файдалы. Хаким янына жирле укымышлы кешеләрдән булган барлык дәрәҗәдәге түрәләр елыша. Шулай ук аларнын туймас тамак хезмәтчеләре, кучереп язучылары, йомышка чабучылары өере дә.

Җамигъ һәм мәхәллә мәчетләрендә сәетләр—"пәйгамбәрнен нәселдәшләре" һәм хажилар—беренче хак дүрт хәлифнең "варислары", шулай ук дәрәҗәләре белән түбәнрәк тагын бик күп дин әһелләре—шәехләр, имам һәм башкалар хакимнәрнең, аларнын яраннарынын һәм бөтен Сәлҗүк ил-дәүләтенең рәхәттә яшәвен теләп, дога кылалар.

Күк тә аларга юмарт кул белән вакыфлардан, ягъни мәчетләргә, мәдрәсә һәм монастырьларга бирелгән төрле һәм шактый зур милекләрдән керемнәр җибәрә.

Мәчетләрдән ишетелгән сузынкы һәм ашкынулы дога авазлары астында алтын белән каймаланган сәхтиян чекларны алганда кемнәрнең куллары калтырый ул? Болар—эре сәүдәгәрләр. Алар, мангайларындагы тирләрен сөртеп, әмма әдәплелек дустанә мөгамәлә күрсәтеп, тавышларын күтәрмичә, үзара йөзләрчә мең динарлык килешү төзиләр. Шулай ук ваграк алыпсатарлар да шулай ук калтыранып, әмма кычкырып һәм сүгенеп, вак акчаларын чылтыратып, күзләрен ялтыратып, вак сату-алу эше белән шөгыльләнәләр.

Һәм кайдадыр аларның астында, төтенле, тузанлы тар остаханәләрдә алны-ялны белмичә, көне-төне төрле һөнәр иясе тир түгә.

Болары, барыннан да бигрәк, тимерчеләр.

Кою остаханәләрендә, кайнар җәһәннәмдә, бакыр һәм бронзадан казан һәм тазлар, табалар, мангаллар, кара савытлары ясыйлар. Кыңгыраулар һәм өзәңгеләр. Ювелирлар, билләрен дә турайтмыйча, кечкенә сандалларда алкалар, йөзекләр, беләзекләр, кувшин, табак, тәлинкә һәм чынаяклар ясыйлар. Алар белән янәшә тигезләүчеләр һәм шомартучылар төсле ташларны эшкәртәләр. Ә арырак, күзләрен сукырлар кебек кысып, ару-талуны белмәс дирбиячеләр зур энәләре белән эш итәләр.

Эрләүчеләр эрли, тукучылар тукый, тегүчеләр тегә, тиречеләр тире или. Кешегә хуҗалыкта күп нәрсә кирәк. Иләк һәм уклаудан башка ничек яшисең? Ясап бирәләр аларны сина. Май язучылар, итчеләр һәм тегерманчеләр бар. Су ташучылар, аш пешерүчеләр, тәм-томчылар, хәтта чикләвек һәм пестә җимешен ватучылар да бар...

Ягъни болар—өстән алып аска кадәр бөтен Нишапурга кирәкле хезмәт кешеләре. Алардан башка шәһәр яшәүдән туктар иде. Чөнки хаким—беркемнән дә салым ала алмас, дин әһеле—беркемгә дә вәгазь укый алмас, сәүдәгәр сәүдә итә алмас иде. Ә каракларга урлар әйтер булмас иде.

Әмма югарыдагыларнын барысы өчен дә бу эш халкы—фукаро—гади халык...

Гомәр бер дивардан икенчесенә йөрүдән туктады. Рудакиның "Картлыкка мәдхия" китабын алды, битләрен актарды һәм, гайрәте чигеп, кире уемтыктагы киштәгә куйды. Шул чак шагыйрь уң кулының бармак сөякләрен бизәкле агач ишекнең бер кырыена нык кына бәрде һәм йөзен чытты. Чәнчелгерләре! Китап кайгысымыни! Һәм ул янадан да бер дивардан икенчесенә булган очсыз-кырыйсыз юлын кабатлый башлады. Дивардан диварга. Дивардан диварга...

Шуңа игътибар иткәннәр: кеше, уйларына чумып, ял итеп, игътибарын туплап комачауламасыннар өчен кулларын артка куеп, бер алга, бер артка йөри. Ул уйлый. Ул шулай сәгатьләр буе йөри ала.

Уйсыз кеше, ни эшләргә белми аптырап, нәрсәнедер вата, ерта, изә, ваклап ыргыта. Моны ул башындагы бушлыкны ни белән булса да тутыру өчен эшли. Бу бушлык куркыныч. Ул адәм баласындагы хайвани башлангычларны тизгеннән ычкындыра...

Бәхетсез колларны алыйк. Нишапурда күп алар. Дөрес, язмышлары төрлечә анысы. Таза егетләрне башкалага сакчылар булып хезмәт итәргә җибәрәләр. Аларның тормышын кызыгырлык дип әйтергә мөмкин. Алар патша яки патшабикәгә якын кешеләр, сарайда шактый зур дәрәҗәгә ирешә

алалар, аерым шәхесләр ихтыярында булган ирексезләрдән нык аерылып торалар.

Ә соңгылары хурлыклы эшләр башкара—төзелештә тир түгә, рудникларда казына, кабер казый. Атлар һәм ау этләре карый, аш пешерә, бакча-ишегалды караучы-себерүчеләре була, хуҗаны саклый, аның байлыгын карвыллый алар. Араларында музыкантлар, җырчылар бар. Акыллы кол язу-сызу эше белән шөгыльләнә, укырга-язарга өйрәтә, әфәнделәр казнасында исәп-хисап эшләре алып бара.

Сатып алганда колларны ничек сайлау, аларның холкы, сәләте турында нинди тышкы сыйфатлары аша хөкем йөртү, алар белән мөгамәлә турында аерым кинәш-үгет язулары бар. Мәсәлән, татар, кучмә ягма һәм алан коллары батырлыклары белән аерылып торалар. Византиялеләр—әдәпле, эшлекле, сабыр холыклы. Әрмәннәр—тәкәббер һәм качарга гына торалар. Ә инде кол хатын-кызны, аеруча яшь һәм чибәрләрен ни өчен тотканнары һәркемгә билгеле...

Күрер күзгә зур көнчыгыш шәһәренең тормышы шундый. Әмма Нишапурда яшерен тормыш та бар. Зимагур һәм уйнашчылар, ялланып үтерүчеләр һәм ялган шаһитлар тормышы. Ә алары инде үзләренең тоткан урыннары буенча коллардан да түбәнрәк. Тегеләренең исә куну урыннары, хуҗалары һәм, такы-токы булса да, көнлек ризыклары бар...

Шәһәрдә янчык кисүчеләрнең, биючеләрнең, хәерчеләрнең үз кануннары һәм йолалары буенча һәртөрле җәмгыятьләре-ширкәтләре бар. Алар арасында җаванмарлар ширкәте аерым урын алып тора.

Раслауларынча, җаванмар—көчле, кыю, бөтен эштә чыдам, вәгъдәләренә тугрылыклы, максатка омтылучан, чиста күңелле, беркемгә дә зыян салмый, файда хакына дусларын кабул итә, әсирләргә кул сузмый, ярлыларга ярдәм итә, явызларны әшәке эшләреннән тыеп кала, фәкать дөресен генә сөйли, хаклыкны тыңлый, тиешле бәясен бирә, ипи ашаган өстәле янында явызлык эшләми, яхшылыкка явызлык белән җавап кайтармый, күңелгә ятышлы әңгәмә кора...

Һм... Ә нишләп соң, алайса, аларга ике терсәк озынлыгындагы пычак кирәк?

Әлеге серле тормыш турында дөресен кем генә белә икән?! Белсә дә шул тормышта яшәүчеләр үзләре генә беләдер. Ә инде шәһәрнең хәерче бер өлешендә, бушлыкта, чүплек өемендә Әлмирра кебек зөбәрҗәтләр яшеренеп ятуын Гомәрдән башка һичкем белми. Инде белгән хәлдә дә шундук коточкыч шау-шу куптарачак һәм диндәш туганнары белән берлектә аны таптап, кире чүп өеменә илтеп ташлаячак. Өлгереп җитә алмаган андый шагыйрьләр күпме әрәм булды инде.

Их сагыш! Үзен кая куярга белмичә, Гомәр башланмаган бер кувшин шәраб алды да уң яктагы күршесе, рәссам-миниатюрачы Сәфәр янына кереп китте. Алар еш кына хәрчәүнәдә очрашалар, кайчакларда бер-берсенең өенә керәләр, берәр касә шәраб эчәләр.

Рәссам—огуз төреге, әмма шигыйлар ягыннан, исламның бу өлеше тере җаннарны рәсемгә төшерергә рөхсәт итә.

Ул гадәти өйләрдә, гадәти кешеләрдә булмый торган зур һәм биек өстәл янында утыра иде. Алдында, болындагы чәчәкләр кебек, ак, сары, зәңгәр, яшел, кызыл һәм кара буяулар салынган бакыр чынаяклар. Вазалардан туры ботаклар сыман нечкә пумалалар тырпаеп тора.

Сулда—сулы кувшин, унда, бронза пресс астында, тыгыз кәгазь битләре өеме. Кул астында—әле яңа гына башланган соры рәсем.

Бер якта кечкенә өстәлдә әзер миниатюралар кибә. Шүрлекләрдә, идәндә, дивардагы кадакларда—төрле-төрле рәсемнәр, караламалар, иске миниатюралар.

Монда якты, күңелле, җанга рәхәт. Яфраклары коелган көзге бакча кебек.

—Нинди очрак белән әле бу?—Рәссам Гомәр алып кергән кувшинга ымлап күрсәтте. Үзе, сыйланырга әзер булып, башлаган эшен бер читкә куйды.

—Күршемне, туганымны кияүгә бирәм,—диде Гомәр күңелсез генә.

—Ишеттем. Туйга да чакырулы. Әмма бит ул төрек кызы. Ә син—фарсы.

—Ә кайда күргәнең бар синең Иранда яки Туранда чиста канлы төрекләрне? Андыйлар еракта, Алтайда. Ә мондагылары кушылып беткән. Хәрәзмнәр, согдилылар, фарсы, һинд, гарәпләр белән. Алла белсен, тагын кемнәр беләндер. Чуар халык. Кыскасы, кишмиш. Мин аңа уникенче буын абый туры киләм.

—Нигә соң, алайса, бик күңелсез?

—Хәзер.—Гомәр киштәдән яндырылган балчыктан бизәкләп эшләнгән чынаяклар алды, аларга шәраб салды.

—Ярый, Алла үзенең ярдәменнән ташламасын ул кызны!—Рәссам чынаякны бушатып куйды.

—Ташламасын.

—Бик әйбәт булды әле бу.—Рәссам кувшинны яратып, хатын-кыз билен сыйпагандай сыйпап куйды.—Арыдым. Ялыктыргыч эш. Мәшәкате күп.—Гомәр карасын өчен ул, кулларын махсус болгап, кәгазь битләренә күрсәтте.

Шагыйрь ачык төстәге, алтынсу-ялтыравык бер кәгазьне кулына алды.

Кызгылтрак сөзәк ярда, сирәк кенә үлән, кызыл һәм ак чәчәкләр үскән сыек-яшел бер кыяташта, аякларын бөкләп, кулларын көнчыгыштагыча җиң эченә тыгып, ак чалмалы, зәңгәр халатлы уйчан бер карт утыра. Янәшәсендә—яшел киемле әңгәмәдәше. Астарак, су янында, кызыл кафтанлы икәү, кулларына кәйләләр тотып, кыя-ташны ваталар. Сыннар бик уйлап урнаштырылган: өстәге икесе бер яссылыкта, җир казучыларның берсе—нәкъ алар астында, икенчесе беренчесеннән читтәрәк—ундарак һәм югарырак. Бик тә тәэсирле асимметрия.

Кызгылт-көрән калкулыклар өстендәге күк йөзе—куе зәңгәр, кара диярлек, бераз куе яшел сызыклар бар. Ул әлеге түгәрәгрәк калкулыкларның якты бушлыгын нык аерып күрсәтә һәм карт белән аның әңгәмәдәше утырган бик үк ачык булмаган яшел кыяташ белән бик тә шәп яраша.

Җир казучыларның алсу кафтаннары сөзәк ярның эссе көн төсмере фонына бик туры килә. Унда, читтәрәк торганының яшел күлмәге акыллы карт әңгәмәдәшенең киеме белән бер төстә, аның зәңгәр штаны акыл иясенең зәңгәр чапанына төстәш. Рәсемдәге ак һәм кызыл чәчәкләр ак баш бәйләвечләрне һәм кафтаннарның ачык кызыл төсен тулыландыралар. Барлык төсле таплар үзара бик тә шәп, тигез дәрәҗәдә бәйләнгән. Рәсем һәр яктан искиткеч камил.

Оста! Башка сүз таба алмыйсың.

—Кем бу?—дип сорады Гомәр.

Ак чалмалы, зәңгәр чапанлы карт бик тә мөлаем, күңелдә ышаныч тудыра, үзенә тартып тора.

—Искәндәр Зөлкарнәйн,—дип җавап бирде Сәфәр, юри исе китмәгәнрәк кенә.—Сәйхунны[1] кичәргә җыена. "Шаһнамә"дәге аның батырлыклары турындагы өлешен вилаять акиме Аргуш үзенең улы—күчереп язучы-каллиграф Госман өчен аерым бер китап итеп эшләргә кушкан.

—Һәр пешка улын Искәндәр итеп күрәсе килә, шуннан һич тә ким түгел,—дип көлемсерәп куйды Гомәр.—Менә күрәсеңме, безнең якларда тагын бер Икемөгез пәйда булачак.

—Анысы инде аларның эше! Госман миннән китабын рәсемнәр белән бизәвемне сорады. Мин ясыйм.

—Искәндәрнеме?—дип инсәләрен җыерып куйды Гомәр. Тагын шул ук хәл. Бөтенесе якынча, бөтенесе чагыштырмача. Якын, әмма дөрес түгел. Томанлы гына охшаган яки бөтенләй дә охшамаган...—"Шаһнамә"нең ин унышлы өлеше түгел,—диде Гомәр коры гына.

—Ничек? Бу бит—Фирдәүси!

—Булса соң? Бәхәссез китап булмый. Хәтта Фирдәүсидә дә бөтенесе дә бәхәссез түгел. Һәм хәтта Әмид Камалида да,—дип, төрттереп әйтеп куйды

[1]Сәйхун—Сыр-дәрья.

Гомәр.—Ишеткәнең бармы аның турында? Ишетмәгәнсең. Ә бит ул сәлҗүкләрдә—"шагыйрьләр әмире". Ә монда нәрсә?—Шагыйрь икенче бер бизәлгән битне алды.

Сары чүл, кызгылтрак күк фондында озын чапан, очлы башлы биек очлымнар кигән сугышчылар тора. Уртада кемдер, тезләренә чүгәләп, җирдә яткан берәү өстенә кайгылы төстә иелгән.

—Монда Искәндәр үзенең якыннары тарафыннан үтерелгән патша Дарийны таба,—дип аңлатты Сәфәр, бик үк теләмичә генә.

—Юк, туганкай,—диде Гомәр.—Бу Искәндәр Зөлкарнәйн түгел. Александр Македонский түгел. Бу—уйлап чыгарылган Искәндәр. Беркайчан да изге карт булмаган ул. Ул бит пәйгамбәребезгә кадәр бик күп еллар элек яшәгән.

—Ничек инде—пәйгамбәргә кадәр?

—Пәйгамбәр әле ул вакытта булмаган.

—Ничек инде—булмаган?

Остаханәдә караңгы, күңелсез, салкын булып китте,—нәкъ яңгырдан каралган һәм юешләнгән ботаклар тырпаеп торган кышкы бакчадагы кебек.

—Булмаган әле ул. Мөселманнар да булмаган әле ул чакта.

—Ышанмыйм.

—Бик беләсең килсә, пәйгамбәр Искәндәр Зөлкарнәйннән соң мең ел чамасы соңрак туган.

—Әмма дә ләкин... Искәндәр Зөлкарнәйн бит... бу дөньяга Мөхәммәткә кадәр җибәрелгән пәйгамбәр булган!—дип кычкырды ачуы чыккан рәссам.

—Юк! Фирдәүси сурәтләгәнчә, ул пәйгамбәр дә, хакыйкатьне яклаучы да, канунналарны саклаучы да түгел. Җимерүче, басып алучы ул. Чалма да йөретмәгән. Утыз яшендә үлгән яшь, кызыл битле, җирән һәм сәрхуш бер мәҗүси. Ә син аны ак сакаллы, зәңгәр чапанлы итеп күрсәтәсең. Моның берсе дә дөрес түгел. Шуны исеңдә тот: китаплардагы һәм картиналардагы дөреслеккә детальләрнең һичшиксез төгәллеге белән ирешелә. Сөйләүләренчә, император Траянның Рим колонналарындагы рәсемнәре буенча шул чорның кием-салымын, коралын һәм хәрби көнкүрешен иң вак нечкәлекләренә кадәр өйрәнеп була икән.

Гомәр янадан беренче кәгазьне алды. Кызганыч. Бик шәп эшләнгән! Әмма күпме көч юкка сарыф ителгән...

Гомәр кулларын артка куйды да янадан үзенең дивардан диварга кадәр булган гадәти юлын таптый башлады.

—Бөек Искәндәрне мөселман итеп сурәтләү күңелле, әлбәттә. Ә аның мөгаллиме Аристотельне Шаш төреге итеп, ә? Шул рәвешле төрек халкын югары күтәрү өчен. Әмма тарих алдаганны яратмый! Тарих катгый! Ул канлы. Аны төгәл белергә кирәк. Аны, шундый ук катгый һәм канлы безнең дәвергә яраклаштырып, яхшыртырга, бизәргә, матурларга ярамый. Төрекләрнең, туганкаем, болай да горурланыр нәрсәләре күп. Аларның бай үз тарихлары бар,—диде Гомәр, акыл өйрәткәндәй.

—Әмма патша Искәндәрне яланаяклы, тезгә кадәр итәкле, әтәч кикригенекедәй очлымлы итеп ясасам, әмир Аргуш миннән көләчәк кенә бит.

—Соң, инде алайса, Аргушның күңелен күтәрәсең һәм акча эшлисең килә икән, Искәндәрне башына тузгыган төрекмән бүреген кигергән хәлдә яса.

—Булган-булган икән...—Сәфәр, ачуланып, кәгазь битләрен җыйды да шүрлеккә ташлады.

Сәфәр күршесен җен ачулары чыгып озатты.

Гәпләштеләр... Сәфәр белән ачыктан-ачык сүз куертуына Гомәр үкенеп тә куйды. Үз фикерләрен яшерергә күптәннән өйрәнде бит инде, югыйсә. Ә монда түзә алмады. Шәраб эчкәнгәме? Юк, аңа түгел. Кешенең тел бистәсе, ахмак яки җинаятьче булуына шәраб гаепле түгел. Ул фәкать анда тумыштан яки тәрбиядән эчтә утырган нәрсәләрне генә кузгата, шуны ачыклый. Мәсәлән, оятсызда—оятсызны, хәсистә—хәсисне, тыйнакта—тыйнакны, акыллыда—акыллыны, усал телледә—усал теллене...

"Әйе, жайсыз, зарарлы кеше мин! Нигә дип бәйләнәм инде кешеләргә?— дип битәрләде ул үзен өенә кайтышлый.—Нигә дип үземнен урынсыз кинәшләрем белән тыгылам? Мескенгә бит яшәргә кирәк. Акча өчен ул Александрны изге карт кыяфәтендә генә түгел, ә бәлки алиһә Астартаның каһинәсе—тулы күкрәкле кыз кыяфәтендә дә сурәтләргә әзер. Өстәвенә патша әлеге сүрия алиһәсенә багышланган мистерияләрдә[1] бик теләп хатын-кыз киеме кигән.

Буясын шунда! Мина ясыймы әллә?! Кушкан кешесенә генә ошасын. Шулаен ул шулай да, әмма бит бу якты дөньядагы барлык буталчыклар да шул аз белемле болгаткычлардан!—Шагыйрь тешләрен шыгырдатып куйды.— Бөтенесен астын өскә әйләндерәчәкләр. Әнә шулар кешеләр аңында тормыш, дөнья, вакыйгалар турында бөтенләй ялгыш күзаллаулар тудыралар. Шундый тәтен жибәрәләр ки, нәрсә алда, нәрсә артта икәнен күрергә Ходай үзе ярдәм бирсен. Еланнар тулы чокырга килеп төшүеннә дә сизми калуың бар.

Инде бер темага алынасың икән, рәхим итеп, аны жентекләп өйрән. Базарда борчакның ни хак торганын белмә. Сәләмә киемдә яланаяк йөр. Каткан ипи ашап, кайнамаган су, шәраб, инде килеп, шайтаныма олак, арпа аракысы эч—әмма эшеңне намус белән башкар. Иренмә, укы. Менә, мәсәлән, сарай кешеләре арасыннан бер такмакчы үзенең бер мәдхиясендә сабынның хуш исен күкләргә чөеп мактый. Янәсе, чисталык-пөхтәлек символы. Ул аны гомергә дә иснәмәгән, күрәсен. Ишетеп кенә белә. Ә безнең иснәгән бар".

Теге вакыттагы кебек, Гомәр чыраен сытты. Борынында остаханәнен сасысы һаман да бетмәгәндәй тоелды. Ул тенкәгә тигән күршеләренә үч итеп сабын кайнатучыга иске өен сатуын исенә төшерде. Һәм бөтен нәрсәгә, шул исәптән Искәндәр белән рәссам Сәфәргә дә исе китмичә кул селтәп, көлемсерәп куйды. Шайтаныма олагыгыз! Мактышыгыз шунда, дан һәм хөрмәт сезгә. Бөтенесе үтте, монысы да үтәр...

Фирдәүси "Шаһнамә"сендә Искәндәр турындагы өлеш нәрсәсе белән яхшы? Ул шунын белән яхшы, анда: бернинди ыгы-зыгы, яулар да, басып алулар да, жирдәге бернинди рәхәтлек, байлык һәм һич күрелмәгән хакимлек тә кешегә билгеләнгән үлем сәгатен чигерә алмый, дигән фикер үткәрелә. Әмма әмир Аргуш моны аңламастыр шул...

Шыгырдавык капканы ачып керү белән үк Гомәрнен күзе койма буендагы чәчәкләргә төште һәм ул аһ итте.

Лаләләрнең нәзек сабаклары саргайган, шиңгән, корыган чәчәкләрнең кыңгыраучыклары гажизләнеп, асылынып төшкән. Ясминнәрнең галәттә калын, тыгыз яфраклары сәлперәйгән, бөрешкән. Күптәннән су сипкәне юк иде шул. Су сипсәң, кырмыска оясын коендырасың. Тьфу! Шул хәсис тә безнең бәла бит.

Гомәр кырмыска оясы өстенә иелде. Монда нидер үзгәргән. Кырмыскалар инде жирдәге кара тишек тирәли арлы-бирле чабышмыйлар. Алар каядыр шуышалар. Максатка омтылучан төстә каядыр баралар. Аннан уң якта сугару канавына таба кара тасма сузыла. Гомәр иелгән килеш кенә шул тасма буйлап китте, бераз баргач, жирдә башка бер кара тишек күрде.

Күченәләрме әллә?

Ул жанлы кара тасманың икәү икәнлеген абайлады: берсе иске оядан яңасына, икенчесе аңа каршы—иске ояга ашыга. Иске оядан яңасына чабучыларның кайберләре,—барысы да түгел,—ниндидер кечкенә генә чүпләр ташый. Ә киредән буш килеш кайталар.

Күрәсең, бу гомуми күченүдер. Тулган иске ояда кысынкы була башлагач, бер өлеше яңа ояга күчәдер. Кирәк бит, урынны тагын түбәндә, су күтәрелә торган урыннан сайлаганнар...

Кара-каршы юлдан килүче кырмыскалар еш кына бер-берсе белән маңгайга-маңгай бәрелешәләр һәм, мизгелгә генә аптырап калганнан соң, тагын йөгерешә башлыйлар. Әллә соң мыеклары белән тәрәшеп, бер-берсенә

[1] Мистерия—урта гасырдагы дини тамаша.

ни дә булса хәбәр итәләрме? Бу мәрәкәдә нинди дә булса мәгънә булырга тиештер бит инде?

Ул иелгән килеш бер сәгатьләп торды һәм аларның эш-гамәлләрендә үзенә аңлаешлы бер генә мәгънә дә тапмады. Әлеге туктаусыз ике яклы хәрәкәт ун-унбиш кырмыска күтәргән мескен ике-өч чүп өчен кирәк микәнни соң?

Эссе капты бугай, башы авырта башлады. Йөзе кызарып чыкты. Шулай итеп коткарасызмы чәчәкләрне? Әгәр су сипмәсәм, алар чынлап та сулачаклар.

Әмма Гомәр һаман да шул рәвешендә—тезләренә таянып, гаҗәпләнеп, әйтерсең лә, күрер күзгә эшлекле, әмма чынлыкта исә тинтәк, йокылы бу тормыштан әсәрләнеп карап торуында булды.

Соң, шуннан? Ярый, җирдә яңа бер ярыкка урнаштыгыз ди инде. Үрчеп, тагын башкасын эзләп китәрсез. Ишегалдын, шәһәрне, вилаятьне, бөтен илне, дөньяны басып алырсыз! Сөйләүләренчә, кара Африкада исәпсез-хисапсыз кырмыскалар өере, бер урыннан икенчесенә күчеп, урман һәм далаларны басып ала, юлында очраган барча тереклекне юк итә, ди. Алардан җанварлар да, кешеләр дә котыла алмый, хәтта гигант филләр дә нишләргә белми кача, ди. Җирдәге бөтен нәрсәне ашап бетергәч, нәрсә ашарсыз соң? Бер-берегезнеме?

... Шул вакыт бер әрсез кырмыска штаны астыннан аның аягына менде һәм "нечкә җирен" тешләп алды. Гомәр авыртудан йөзен җыерды, кәтмәнне алды һәм, Сәфәрнең рәсемендәге җир казучы кебек, киң итеп кизәнеп, бер бәрүдә инеш белән коры сугару канавы арасындагы өемне алып ташлады.

Су комсызланып канауга акты, чыжылдап, ярыкларга керде, ашкынып, ахыргача йөгерде һәм, тынычланып, әкрен генә күтәрелә, иңкүлекне тутыра башлады. Өстә пычрак соры күбек, коелган коры яфраклар белән бергә кырмыскалар бөтерелә, чәбәләнә башлады.

Тавышсыз гына ярдәм сорап кычкыруларга Гомәр битараф калды. Әмма ул сизгер күңеле белән җирдәге тамырларның нинди ләззәт кичерүен тойды. Чәчәкләр сискәнеп киттеләр, башта аңа аптырап, аннары рәхмәт хисләре белән карадылар. Шунда ул кинәт үсемлекләрнең дә тоя белү сәләтенә ия булуларын төшенде. Ә бәлкем әле уйлыйлардыр да. Үзләренчә, әлбәттә...

Ашыкмыйча гына атлаган адымнар, ипле генә сөйләшү. Һәм капкадан кергәндә кычкырып сәламләү. Аннары быргы, сорнай чәрелди, барабан дөпелди башлады. Күршеләрдә туй...

Ул үзенең барлык язуларын киштәгә куйды, өстәлгә җыйнак кына ашъяулык җәйде, аңа шәраб һәм су тулы ике кувшин, кытыршы чынаяк, ашамлыклар белән тәлинкә куйды да, бөтенесе тарафыннан онытылган, ялгызы хәлендә, тын гына үз күңелен үзе күрү эшенә кереште.

Музыка тынгач, ул ипи пешерүченең ишегалдында ир-атның канәгать төстә гүләшүен, тегүченең ишегалдында хатын-кызның нидер пышылдашуын ишетте. Тәмле булып шашлык, башка ризыклар исе килә. Ипи пешерүче белән аның хатыны бүген кунакларны сыйлый инде. Гомәр акчасына...

Инде карангыланды. Ул берьюлы ун шәм яндырды—әйдә, өйдә якты һәм күңелле булсын!

Музыкантлар бию көе уйный башладылар. Гомәр канатланып китте. Өйдә кия торган башмакларын салды да келәмдә яланаяк бии башлады. Шәп бии ул! Тумыштан ук ритмны тоя. Төз гәүдәсен тигез тотып, төгәл ритмга аякларын алыштырып, иңсәләрен сикертеп биеде ул. Кайберәүләр кебек түгәрәк ясап йөрмәде, сикеренмәде, иелмәде-бөгелмәде, мәтәлчек атмады. Болар бит—биюгә бернинди мөнәсәбәте булмаган акробатика. Чын бию ул—күңелдәге давыллы хәрәкәтләрне аяк, кул һәм иңсәнең саран һәм төгәл хәрәкәтләре белән белдерү. Һәм тыйнак кына елмаю белән. Аның өчен өч терсәк киңлектәге урын да житә.

Кызганыч, кул чабар кеше генә юк.

Салмыш башта шук, мәкерлерәк бер уй туды: бер кувшин шәраб алып, туйга барып керсәң ни булыр икән? Ипи пешерүчене котларга, кияү егетен үбәргә. Һәм, кунаклар күңелен күреп, биергә. Ул инде иң яхшы чапанын

кигән дә иде, әмма үз-үзен тыеп калды: "Ярамый! Җәнҗал кубачак. Соңыннан түләп котылыр нәрсә юк. Акча бик аз калды".

Чапанын салды, сәкегә утырды. Ә бәлкем үлә белмәс Гайшә карчык янына барыргадыр? Бу юлы алтын динар табарбыз. Күпме телисең, шулкадәр әзер кыз, тулы бер чәчәк түтәле! Һәм алар төрлечә аңкый. Якшәмбе көнне—муксус, дүшәмбедә гамбәр сөртәләр. Сишәмбедә—мирра, чәршәмбедә—яран. Кичатнада—лалә, җомгада роза белән ышкыналар. Шимбә көнне, кагыйдә буларак, нәркәс белән. Әйе, ул йорттагы кызлар тәмле исләрне сайлый беләләр.

Бүген сишәмбе бугай. Шәп! Бүген Әлмирра булачак...

Юк, соң инде. Төнлә урамда йөрү куркыныч. Чыкма. Юкса карак талар яки шул ук эшне сакчы эшләр. Гомумән дә, шайтаныма олаксыннар ла үзләренең тәмле исләре белән. Чынлыкта нинди ис чыгаруларын беләбез без аларның.

Барабан тавышы астында үзенең җитди, саллы китабын яза алмый ул. Кәефе андый түгел. Йокларгамы? Барыбер ирек бирмәсләр. Нишләргә соң? Их, әйбәт түгел. Бер дә әйбәт түгел бу.

Ул шәрабен күз алдыннан ераккарак алып куйды. Һәм янадан—дивардан диварга. Дивардан диварга...

Күршеләрдә тынлык. Һәм кинәт койма артында ачык, чак кына калтыравыклы, ашкынулы яшүсмер тавышы ишетелде.

Таныш тавыш түгел. Таныш та кебек. Әлмирра җырлый кебек тә, ул түгел дә сыман. Әллә тавышы үзгәргәнме соң? Нишләп икән? Ә-ә, җырлаганда бит тавыш үзгәрә. Җыр тавышы сөйләм тавышына охшамый.

Дарича җырлый. Ул таҗик-фарсы телен яхшы белә. Шигырьләрен дә шул телдә яза. Төрекчә апасы белән генә сөйләшә. Кайвакытта аның белән, Гомәр белән дә...

Әмма бу туй җыры түгел. Мәет җирләгәндәге елау. Матәм робагыйларының берсе. Ислам әле ныклап урнашмаган таулы урыннарда ирен зиратка озатканда, тол хатын юлда кайгырып биеп, шулай җырлый:

Чыгам да утырам ташка, уйлыйм сине,
Өнемдә дә, төшемдә дә куймыйм сине;
Аяк баскан эзләреңдә сине күрәм,
Шул эзләрдән туфрак алып, кат-кат үбәм.

Әллә нинди катлаулы мәгънәләр юк, әмма хәсрәтле ул җыр. Гаҗизлек! Әнә нәрсә үзгәрткән Әлмирраның тавышын. Шуңа ул, күңелгә якын булып калуына карамастан, ят яңгырый.

Нигә дип әле син май гөбесе янындагы камыт кигән ишәк кебек һаман йөрисең дә йөрисең? Бар, чап! Гомереңдә бер игелекле эш эшлә. Ал да үзен, тауларга, Баге-Сангка кач...

Ишеккә таба атлаган иде, тез буыннары кинәт йомшады, хәле бетеп, бусага янында егылды.Биек, йолдызларга кадәр җиткән бусага бу. Куркыныч бусага. Үтеп булмый торган бусага...

Аһ! Йөгерергә соң инде. Яше ул түгел...

"Ул бит миңа хыянәт итте",—дип әрнеп уйлады Гомәр, үзен аклап.

Тыныч кына өйләнергә ирек бирсәләр, ул аның белән әйбәт һәм озак яшәр иде. Әмма бүтән каңгырып, күченеп йөри алмый инде. Арыды. Фәкать дивардан диварга гына йөрергә кала. Дивардан диварга...

*Яшьләр иҗаты*



# Луиза Янсуар

## ЯЗ ТӨСЕНДӘ ЗӘҢГӘР ӘКИЯТ

### Минем серем үземнән дә гади...

"Серләреңне ничек белим?—дисең,—
Күңеләңә каян табыйм ачкыч?.."
Минем серем үземнән дә гади,
Юлы гына серле—баскыч-баскыч.

Юлы гына аның—урау-урау,
Әкияттәге таулы сукмак төсле...
Сәйләннәрдәй тезелеп сүзләр ята—
Иң кыйммәтле асылташлар төсле.

Сүзләр ята һәм иҗекләр ята
Ап-ак кәгазь тузанында аунап.
Күз салмыйча узма! Бара-бара
Өелерләр әле алар таулап.

Сусаганда—саф чишмәгә иел,—
Сусавыңны басыр дулкын-хисем,
Учларыңа мөлдерәмә тулып.
Тәнеңә—ял, җаныңа—наз бирсен.

... Юл ахыры... Иң-иң соңгы битен
Дәфтәремнең инде атлап үттең.
Карашыңда—таныш түгел бер хис...
Ә син нәрсә... могҗизамы көттең?

"Серләреңне белсәм иде..."—диеп
Әйткән идең беркөн назлы итеп...
Минем серем үземнән дә гади—
Шигъри юллар тулы дәфтәр бите.

### Язгы әкият

Кояш миңа күзен кысты,
Бәллүр Тамчы тамды учка—
Һәм биеде зәңгәр бию
Бөтерелеп минем учта.

Гөрләвекләр йөгерeште
Корабымны алга әйдәп.
Умырзая күзен ачты,
Ут йөрәген язга бәйләп.

Күтәрелде бөтен Хәят!..

... Карый-карый тәрәзәмнән
Мин төшердем кәгаземә—
Яз төседәй зәңгәр әкият,
Язгы әкият!..

## Күңел учагы

Күңел учагымда—хисләр дөрли,
Күккә сибеп очкын тузанын.
Мәңгелеккә сузылган бу яну!
Һәр мизгеле якын, үз аның.

Күңел учагында—җырлар туа,—
Йолдызларга аша, Галәмгә.
Утлы йолдыз булып җиргә кайта,
Әверелә назлы сәламгә.

Күңел учагымда—хис ялкыны
Дөрли генә! Әгәр сүрелсә,
Ап-ак көлдән утлы ялкын булып,
Янар коштай янә терелә!

## Сер

Төнге күктә ниндидер бер якты йолдыз
Күзен кысып уйнамакчы минем белән.
Күзләремә көлтә-көлтә нурын сибеп,
Пышылдый ул: “Серләреңне беләм.
Беләм!”

Карашымны яшерәмен оялудан.
Кара инде!
Уйларымны хәтта нәни йолдыз белгән.
“Яратам” дип пышылдадым эчтән генә,
Ә ишеткән бөтен Галәм!..

* * *

Китәрмен дә... Онытырсың төсле.
Суынырсың төсле, сүнәрсең.
Кочагыңа атылганда кабат
Маңгаемнан бары үбәрсең.

Китәрмен дә... җуелырмын төсле
Уйларыңнан синең, җаныңнан
Эзләремне каплар сары яфрак,
Томаннарда мәңге табылмам.

Китәрмен дә... кайтыр сукмагымны
Күмәр төсле иртә бураннар...
Юк, китмимен! Әгәр синсез калсам,
Мин үзем дә инде булалмам.

## Төш

Гаҗәеп бер төш күрдем бүген, илаһи төш,
Төшемдә: мин—шаһ кызы,
ә син—солтан, имеш.
Гөлбакчада җитәкләшеп йөрибез икән,
Син дәшәсең: "Күзләреңә йолдызмы иңгән?..

Чәчләрең—төнгә, ә үзең—көнгә тиң...
Гүзәл Яр! Кояшым да, Аем да—Син..."
"Алсу гөл өзеп бирче миңа, хаким",—
Оялчан гына сиңа эндәшәм мин.

Гаҗәеп матур гөлне өзеп алдың,
Чәчемә кадап, сокланып елмайдың:
"Гүзәлем, Син үзең дә гөлләргә тиң,
Йөрер юлыңда туфрак булсамчы мин..."

... Уяндым... Син, диеп, мендәремне кочып...
Гүзәл төш югалды, очып...

## Күңел кылы

Айкалдыра, чайпалдыра җанны—
Моң агыла, моң сирпелә. Каян?
Әллә күңел кылы өзелгәнме?
... Нур сирпелә тәрәз аша айдан...

Уелыплар куям, сискәнәмен,
Пәрдәләрем җилдә җилпенсә дә.
Ургылыплар моң агыла җанга,
Моң агыла... хисләр җилкенсә дә.

Өзелепләр киткән күңел кылы,
Юлы ачык хәзер һәркем өчен.
Дусмы, дошман?.. Карашлары гына
Ялкын өсти... Сыный илһам көчен.

Минем күңел—уен кыры түгел,
Урын тапмас анда иблис затлар.
Саклагандай оҗмах ишекләрен,
Минем җанны ак фәрештә саклар.

Айкалдыра, чайпалдыра җанны,
Моң агыла—тирә-юнем тулы.
Өзелепләр киткән, өзелепләр
Күңелемнең җиденче кат кылы...

## Кичерегез!

Кичерегез мине—бүген ташып киткән
Һәм җыр булып әверелгән хисләр өчен.
Кичерегез мине сәер холкым өчен,
Кичерегез, хәтта изгелегем өчен.

Кичерегез мине! Торам башым иеп,—
Булалмадым җир-туфракка алтын орлык.
Кичерегез! Мин дә, бәлки, гаепледер,
Бу дөньяда әле һаман—тарлык, коллык.

Кичерегез минем изге күңелемне,
Кешелектә чын "кеше"ләр бик аз калган...
... Кичерегез!.. Йөрәгемнән—соңгы аваз:
Кичер, Җирем! Кичер, Дөнья!
Кичер, Аллам!..

*1997—1998*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

### Наис Гамбәр:

—Сөенечләр һәм көенечләр уртасында яшим. Әйбәт әсәрләр укысам—сөенәм, начарраклары кулга эләксә—көенәм...

Әле күптән түгел генә миңа Г. Исхакыйның "Г. Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә" дигән мәкаләсе белән (ул 1938 елда Берлинда Г. Исхакый мөхәррирлегендә чыгарылган "Яңа безнең юл" журналында басылган булган) танышып чыгарга туры килде. Әйтергә кирәк, беренче җөмләләрен укый башлауга ук йөзем яктырып китте (менә кайда ята икән ул бүген язарыма эзләгән тел ачкычы!), шушы яктылык җавапларымны язып утырганда каләмем очына да нур булып тамсын иде (менә кайда ул фикерләремә терәк-баскыч!).

Шагыйрьләр һәм шигырьләр...

—Әйе, "Кем ул Шагыйрь?", "Нәрсә ул Шигърият?" дигән мәңгелек сорауга борынгыдан алып, хәзергегә чаклы йөзләрчә халыкларның меңнәрчә фикер ияләре төрледән-төрле кимәлдә җаваплар биргәннәр, җаваплар эзләгәннәр һәм әле дә булса эзлиләр... Менә тагын шундый җавапларның берсе—Гаяз Исхакыйныкы. "Үзләренең шәхси кабилиятләре берлә бер-берсенә охшау-охшамауларына карамастан шагыйрьләр...икегә бүленәләр,—дигән ул.—Бер төрлесе үз-үзен тирә-юньнән аерып алып, үзен чорнаган мохиттән рухан аерым була ала торган, үзенең төшенчәләре, хиссиятләре эчендә генә тәҗәрред итә (ялгыз яши) ала торган, вә бу вакытта гына шигырь ярата (тудыра.—Н. Г.) ала торган шагыйрьләрдер. Икенчесе үзен тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шул шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь ярат учылардыр... Икенчедән, туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитенең

шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәржеманы булып, шул халыкның шатлыгы, кайгысын, өметен сөйләүче, аның үзенең мохитенең иҗтимагый омтылышларын төрләндереп эшләүче, җәмгыять эшләренең һич берсе яныннан күз йомып, колагын тыгып үтә алмаучы, җәмәгатьче шагыйрьләрдер. Бу төрлесе үзенең көче, сәләтенең зурлыгы, кечкенәлеге, тирәнлеге, сайлыгына карап, яшәгән мохитенең термометры ролен уйнап килеп, үзенең шул термометр дәрәҗәсенең нечкәлек-тупаслыгына карап, халыкның күзеннән кан-яшь агуын, йөрәк тибүен җырлап торалар. Бездә Сәгыйть Рәми беренче груһтан булса, Габдулла Тукай мeнә соңгы төстәге шагыйрьдер".

Бөекләр кайда да—бер-ике кәлимә сүздә дә—бөек булып кала шул: никадәрле төгәл күзәтүләр, никадәрле хакыйкый бәяләмәләр.

Сүземне яшьтәшләремнән башлыйсым килә.

Икенче төрле шагыйрьләр рәтенә мин, беренче чиратта, Мөдәррис Әгъләмовны кертер идем. Гаяз Исхакый әйтмешли, ул "үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәртен шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр". Мөдәррис барлык вөҗүде белән, эче-тышы белән, бары-югы белән, чыны-ялганы белән халыкчан шагыйрь. Аның иҗаты буеннан-буена шундый да халыкчан тирән моң, саф сагышлар, ихлас әрнү, киная катыш усаллык вә үҗәтлек белән сугарылган ки, әдәбиятны аңлау-аңламавы, дөньяга карашы төрле булуга да карамастан, аны төрле социаль катламнар—гыйлем иясе дә, гади халык та, яше дә, карты да—үз шагыйре итеп кабул итә. Мөдәррис шигърият "сабантуе мәйданына" яшь булса да ольыларча зирәклек белән (бу юллар бүген дә актуаль булып яңгырыйлар):

Дошманнар таптаса жиренне,
Сорамый: "Син батыр иденме?"
Мәйдан кук кысыла бар халык:
—Бирмә иленне!
—Бирмә!—

дип чаң кагып килеп керде һәм бүген дә, менә утыз елдан артык инде, сулкылдый-сулкылдый "Акмулла арбасы"нда безнең бүгенге буынга мирас булып ирешкән "Тукайдан хатлар"ны укый. Укый дигәннән, бездә шигырьне үзәкләргә үткәрерлек итеп укучылар бик сирәк, ә менә Мөдәррис шул сирәкләрнең берсе; ул шигырь укыганда тәннәр кымырҗып китә, сулыш алу кыенлаша башлый, тамак төбенә төер утыра... Әнә, ике ел элек, үзенең иҗат кичәсендә шигырь укып киңәндерде генә шагыйрь, артистларың да тоныкланып калды: тавыш гөбедән чыккан кебек ярсып чыга, күзләр ут кебек яна, борын яфраклары киңәйгән, сул кул кылычтай башөсте күтәрелгән—шагыйрь яньчә генә; ул гади дә, интим дә хисләрен мәңгелек хакыйкатьләр ефәгенә төреп болай ди:

Илләр бәхетенә житкән хәтле
Саклармы Жир затлы хакыйкатьне
Ялган матурлыкка төрмичә?
... Киләчәккә бара алмый шагыйрь,
Бара алмый шуны белмичә!

Әйе, Мөдәррис—чичән шагыйрь; егетләр мәйданнарда ат уйнаткан кебек, шигырьдә саллы сүз уйната белә:

Юридик яктан шагыйрь юк,
Юридик яктан—патша юк.
Әкияттә калган алар:
Калыкса—бар,
Батса—юк!

Мөдәррис турында сүз чыкканда еш кына "анда өйрәнчеклек чоры булмады, шигырь аңа болыты белән ишелеп кенә төште", диләр. Хаклык юк түгел монда (йөрәкләргә ничек кан савылуын шагыйрь үзе генә беләдер), шөкер, баскан урыны тар булса да, ул әйтәсе сүзен әйтеп, күкрәк киереп җырлап тора—Тукайчарак итеп:

Сүз жибәрдем... Гаебем зур.
Яратмыймын болгануны.
Күкне—балык,
Илне халык болгатачак;
Мин—ил улы.

Ил улы булып яши алу ул олуг шагыйрьләргә генә бирелә. Ә Мөдәррис—олуг шагыйрь!

Татар шигъриятендә Зөлфәт белән Мөдәррис, бер нигездән бергә калыккан манаралар кебек, бергәлектә янәшә басып баралар. Зөлфәт Зөлфәтчә, үзенчә олуг шагыйрь. Менә кайда ул көч, жегәр, биек очыш; менә кемдә ул галәми киңлекләргә инрәп таралган гасабилы тавыш. Ул үтә дә шәхси тоелган хисләрне дөньяви орбитага чыгара алу кодрәтенә ия; ул көндәлектәге гадәти кичерешләрне дә галәми биеклеккә күтәрә ала; вакытлыча туган омтылышларны да мәңгелек белән бәйли:

Мин бит монда бер яшәгән идем!—
Гафу ит син берүк Дөньялык!
Тагын менә чыклар ярып йөрим,
Мәңгелектән капылт уянып.

Тирәннән, метафорик төпкелләрдән, "патша булып утырган бушлыклардан", урман араларыннан, "яшеннәр оясыннан" ургып-ургып чыккан Зөлфәт шигъриятендә Хиражча дуамаллык та ("килде ижатчылар янына ул шактый гына "ижадиланып"; килеп китә иде ул бер көнгә, ун ел кыйланасын кыйланып"), Хозыр Ильяс кебек хозурлык та бар ("Хозыр Ильяс идем. Мин идем"). Зөлфәтнең шигъри гомер елгасыннан Ут белән Боз бергә агып бара. Әйе, Зөлфәт антитезалар остасы: аның "күнел кошы", бер карасаң, күкләрдә талпына, икенче карасаң, "кайнар кәлтә эзләреннән" мәңгелеккә үтеп бара. Менә шулай бер чикләрдән икенче чикләргә барып тоташа аның авазы; шуның нәтижәсе буларак, ул Галәм, Жир, Күк һәм башка шундый "һавалырак" сүзләрне дә еш куллана, әмма бу "шапырыну" Зөлфәткә шундый килешеп тора ки, аны тыйнаксызлыкта гаепләргә һич кенә дә тел әйләнми... Әйләнми, чөнки алар очышның ("Күкнең һәр йолдызы эри-эри тамган ут сыман") фәлсәфи сурәтнең тәңгәл кайтавазы буларак яратылганнар. Шулай, Зөлфәт белән Мөдәррис шигъриятендә хис, фикер, тойгы, сурәт элмәкләнә-элмәкләнә, бөтерелә-бөтерелә бергә укмашып, тоташ агыш булып агылалар. Алар бер тотып алынган детальне, сурәтне кулдан ычкындырмыйлар, шигырь ахырында кабат, әмма яна сыйфатларда тергезеп, уятып вә уйнатып жибәрәләр. Алар безне менә шулай "алдыйлар".

Берара Зөлфәт, кайнар Зөлфәт бераз сүлпәнәя башлаган да кебек тоелган иде (хәер, И. Тургенев билгеләп үткәнчә, заманында Пушкин булып Пушкинны да "бирешә башлады" дип битәрләүчеләр табылган); баксаң, бу тын алу гына булган икән. Әнә, Зөлфәт соңгы араларда гына 15—16 табаклык, ягъни ун-унбер мең юллар чамасы өр-яңа шигырьләр тәгәрәтеп атты. Бер әңгәмәсендә күренекле рус шагыйре Е. Евтушенко "өч-дүрт ай эчендә 80 ләп шигырь яздым" дигәч, вәт "продуктивность" бу, ичмасам, дип шаккатып торган идем, мондый женлелеккә безнең егетләр дә сәләтле икән ләбаса.

Шигырьләр арасыннан үзенең сурәтлелеге белән берсе аеруча сискәндерде. "Дала уртасында ак теплоход"... дип атала ул *("Казан утлары", 1998, № 2)*:

Күз алдыма гел килә дә баса:
Без яшәгән сәер бу заман—
Дала уртасында ак теплоход!

... "Титаник"ка никтер охшаган...

Аклык һәм һәлакәт!.. Һәлакәткә таба йөзеп баручы ак теплоход!.. Житмәсә, ул дала уртасыннан йөзеп бара бит әле—моннан да зуррак хата, мәгънәсезлекнең, чынбарлык белән хакыйкать арасындагы аңлашылмаучылыкның булуы мөмкинме соң? Әмма бу—бүгенге чор, бүгенге заман сурәте. Ирексездән Чыңгыз Айтматовның "Ак пароход" повестендагы мотивлар күз алдына килеп баса: шундый ук гажизлек, шундый ук өметсезлек.

Зиннур Мансуров артык күзгә ташланмыйча гына, яфрак-үләннәр арасыннан үзенә азык эзләп чыккан керпе шикелле, кыштыр да кыштыр иҗат итә бирә. Аның шигырьләрендә ниндидер үзгә, фәлсәфи, парлакъ моң, җилбәзәк шом бар. Ул яши-яши акыл җыйган авыл карты кебек тирән уйга чума, мәҗүсиләрчә матурлыкка табына, тын сагышка бата, шунадырмы, аның шигырьләрендә әүлиялык чаткылары да чагылып киткәндәй була:

Нигә әле шаһит булдым
Туган чакта могҗиза?
"Бөтнек исе! Бөтнек исе..."—
Эчтән кылдым мең нида.

Гаяз Исхакыйча бүленештә Рәдиф Гаташны беренче төр шагыйрьләр рәтенә кертеп карарга мөмкин булыр иде. Рәдиф Гаташ—романтик шагыйрь; ул дөньяны йөрәге аша күрә. Гаташ иҗатының башлангыч чорында татар шигъриятенә Александр Гринның "Ак җилкәннәр" әсәрендәге Ассоль кебек садә, саф, романтик рухлы героиняларны алып керде, аннары гомере буе мәхәббәткә мәдхия җырлады. Зөлфәт аның турында болай дип язып чыккан иде: "Әгәр чынлап, "Мәхәббәтнең мәҗнүн исемендәге премиясе" булдырылса һәм ул премиягә Рәдиф Гатауллин кандидаты тәкъдим ителсә, мин аны яклап чыгыш ясаудан тыелып кала алмас идем һәм ул күпләрнең күнел тавышы белән Мәҗнүн дигән ат алды да. Дөрес, бервакыт, иҗатының урта бер чорындарак, ул башка темалар белән дә мавыгып алды (шагыйрь хәзер бу хакта "йөргәнмен шунда саташып", дип искә ала), әмма тора-бара тагын үз ярларына кайтып төште. Бөтенләй башка сыйфатта, акыл утырткан, акыл иясе сыйфатында кайтып төште ул. Гаташ гаҗәеп эрудицияле шагыйрь, ул Көнбатыш поэзиясен дә, Көнчыгыш-Шәрекъ поэзиясен дә яхшы белә. Баштарак, Байрон, Гете, Берне, Вийон, Рансар, Бодлер, Лорка шигърияте белән женләнеп йөргәннән соң, соңрак Шәрекъ шигъриятенә кереп чумды. Нәтиҗәдә, бу гауваслык бушка китмәде, Гаташ әдәбият дингезе төбеннән робагыйчы, газәлче булып калкып чыкты. Шагыйрьнең борынгы шәрекъ поэзиясе жанрларына, аеруча газәл жанрына мөрәҗәгать итүе бер дә гаҗәп түгел, бу жанр аның поэтик фикерләвенә ярашып, ятып тора. Газәлләр—Гаташ иҗатында гүзәллек символы ул.

... Үкенмәм дим, Гаташ исемен бәеттә,
Гыйбрәт итеп, авылың, нәселең сөйләсен!

Бәлки әйтерсең үзең дә, син Гүзәл:
—Милли йолдыз саклар, ышан—үлмәссең!

Мондый алым, лирик геройның кемгә булса да эндәшү алымы, эчке импульслар аша гүзәллек объектына мөрәҗәгать итүе Гаташ иҗатына элегрәк тә хас күренеш иде. Газәлләрдә исә бу алым, жанр хасиятләреннән чыгып, тагын да кинрәк урын ала; чөнки, безгә калса, ул күнел кичерешләре аша олы дөньяга эндәшә—борчыла, шатлана, оча, очына... Аннары тагын шунысын да искәртеп үтик: Гаташның шигырьләре ритмик төзелеш, структура ягыннан элек тә катлаулы, күп катлы, күп чылбырлы, динамикалы иде, шушы сыйфатның газәлләрдә дә саклануы һәм тулаем әсәрнең, һәм аерым бәетләрнең экспрессив яңгырашын, тәэссоратлы аһәңен көчәйтеп җибәрәләр.

Кыскасы, татар шагыйрьләре арасында Шәрекъ классик шигъриятен яхшы белүчеләрнең берсе буларак, Гаташ иҗатында әледән-әле борынгылык чалымнары төсмерләнеп китә, аның шигырьләрендә борынгы диварларга сенеп калган илаһи тавышлар ишетелгәндәй була. Шушының белән ул 90 еллар шигъриятенә янача калоритлы рух, эстетик янарыш алып килде. "Бу—сиңа калган догам..." китабы (Казан, 1997) шуның ачык мисалы.

Равил Фәйзуллин соңгы елларда азрак язды кебек, аның каравы 4 томлык "Сайланма әсәрләр" сыйфатында күпьеллык хезмәт җимешен гавәм кулына тапшырып зур егетлек эшләде. Хәтердә ич, шагыйрьләрдән Хәсән ага Туфан белән Сибгат ага Хәким генә үзләре исән чагында ике томлык әсәрләр җыентыгын чыгарып кала алганнар иде һәм бу ул чагында хаклы рәвештә олы вакыйга итеп кабул ителгән иде. Менә тагын шуларга тиң тантана, иҗат тантанасы. Шәхсән

бу минем өчен аеруча истәлекле, чөнки томнар туу процессында мина әдәби редактор буларак катнашырга туры килде. Җаваплы да, борчулы да, шатлыклы да көннәр иде ул. Равил Фәйзуллин никадәрле генә катлаулы шәхес булмасын, аның белән эшләве үзе бер сабак икән: беренчедән, үзенә дә, редакторга да таләпчән; икенчедән—үзе дә эшли белә, кешене дә эшләтә белә. Кыскасы, ярты сүздән аңлашып эшләдек кебек. Аннары, зур иҗатка күнелең белән орынуын, аның эчендә кайнап яшәп алуын, автор белән бергә шатлануын вә борчылуын үзе бер бәхет бит ул. Редактор булуның, гади укучылар белән чагыштырганда, өстенлекләре менә шуннан гыйбарәт, минемчә.

Равил Фәйзуллин иҗатына багышлап йөзләргә мәкаләләр язылды, мин фәкыйрегез дә, кодрәтеннән килгәнчә, мона үзеннән өлеш кертте (Р. Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр. 3 том, 269—306 бб.), шуңа күрә дә язылганнарга өстәп әллә нәрсә әйтә алмам, шулай да сөземтә рәвешендә генә кайбер күзәтүләрем белән уртаклашып китим әле.

Р. Фәйзуллин—хәзер дә үз стихиясендә, ул метафорик ассоциацияләр аша зур дөньяның асыл сурәтен эзләвен дәвам итә, эмоциональ-психологик, метафорик—ассоциацияләргә корылган шигырьләр аның төп кредосы. Әйе, ул вакыт агышына, дөнья барышына чын фәйләсүфләрчә карый, хис-фикернең сүлен—сыга, түбен—түгә. Кайчакта соңгы-баш хөкемдар булып хөкем чыгарып куярга да ярата. Әйтик, "Казан утлары" журналында басылган шигырьләре (1998, 12 сан) тулаем шундый рух белән сугарылганнар.

> Һәм, ниһаять, бусы да булды!
> Яптык бер сәхифә!
> "Ах! Ялгыштым!.." була алмый
> Кичә үткән кичә!

Шагыйрьләр әдәбиятка төркем-төркем булып та, аерым-аерым да киләләр. Роберт Әхмәтҗанов исә Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслановлар буыны белән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Р. Мингалим, Г. Рәхимнәр буынын тоташтырып торучы иҗатчы—"җәяүле күбәләк" булып килеп керде. Батулла әйтмешли, ул буыннар алмашында барлыкка килгән бушлыкны, упкынны яулаган шәхес; нәселдәнлек чылбыры өзелде дигәндә, күпер булып ике ярны тоташтырган шагыйрь ул—Роберт Әхмәтҗанов. Әйе, әнә шул "җәяүле күбәләк"леге ана күп вакыт кыенлыклар да китергәндер, әмма Роберт Әхмәтҗановның күнел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, ахыр чиктә, эстетик карашларын, поэтик идеалларын шушы метафорик образдан төгәлрәк әйтеп бирү мөмкинме соң? Берникадәр миститиклыгы, шашкын хыялыйлыгы, бәлки, табигатькә үтә якын булуыннан, "Җил һәм Кояш Республикасы кочагында" эреп бетә алуыннан киләдер? Шундый шагыйрь генә (башкаларга килешмәс тә иде):

> Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
> Баш очымда шаулый тупыллар.
> Баш очымда Идел әкият сөйли.
> Йөрәгемне юа дулкыннар,—

дип әйтә ала. Ул тормышны "тургай тәрәзәсе" аша тоя, "пыяласы аның күк фирүзә", аны "якты җилләр, якты яңгырлар юа", әмма тирәндә нәзберек моң ята:

Күрдем: кунган очар кошларның гел Җилгә каршы карап торуларын.

Тормышта "җәяүле күбәләк" булып та, шигырьдә шоңкар булу шушыдыр инде ул!

Хатын-кыз шагыйрьләрдән өч буын вәкиленең—Лена Шагыйрьҗан, Илсөяр Иксанова һәм әле бөтенләй яшь Луиза Янсуарның авазлары башкаларныкыннан аермалы булып, ачык ишетелеп торалар.

Дөрес, мин бу җавабымда бик күпләрнең иҗатына күз салып үтәргә тиеш идем дә бит, күнел тарлыктан түгел, урын тарлыктан шушы урында нокта куеп торырга мәҗбүрмен.

Ә гомумән алганда, соңгы дәвер шигърияте иманга кайту, иман яңарту шигърияте булды.

Лена
Шагыйрьҗан

# СҮЗЛӘР, СҮЗЛӘР...

ШАГЫЙРЬ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

*Иң әүвәле Сүз булды...*

Тәүрат китабыннан.

*Сүзне ничек яратам мин!..*

Пабло Неруда.

Сүзләр... Сүзләр!... Яши-яши мин сезне чын-чынлап аңлый башладым, ахрысы... Чын күңелдән аңлый һәм ярата. Элегрәк мин сезне ишетә, әйтә, уйлый һәм яза гына белә идем. Ә хәзер мин сезне бөтен күзәнәкләрем белән тоям, күрәм, хәтта ки төсләрегез вә исләрегезне аера башладым шикелле... Алай гына да түгел: учыма алып сыйпый, иркәли, үлчәп тә карый алам сыман... Сезнең белән тәмам туганлашып беттем мин, Сүзләр!.. Сез—тере, сезнең үз дөньягыз, үз үлчәнешегез, үз кануннарыгыз һәм кагыйдәләрегез, үз холкыгыз һәм язмышыгыз да бар икән... Хәтта ки—үз дәүләтегез...

... Минем туган телемдә—дөньяда тәүге тапкыр "Әннә", "Әттә" дип әйттергән газизләрдән газиз Ана телемдә—нинди генә сүзләр юк... Тамырлы һәм тәлгәшле, ялгызак һәм парлы, карт һәм яшь, чит һәм кардәш сүзләр... Йомры яки яссы, авыр яисә җиңел, озын вә кыска сүзләр, зур һәм вак сүзләр... Шома яки кытыршы, нурлы яки төссез, катлы-катлы яки гап-гади, бөртекле яисә кантарлы—тагын әллә нинди, әллә нинди сүзләр... Санап китсәң, очы-кырые күренми...

Кояш кебек балкып торган нурлы сүзләрне күргәнегез бармы?.. Алар—балачак һәм мәхәббәт иленнән... Ә менә кайбер сүзләр караңгыда гына яши—яктыдан курка... Кайбер сүзләр татлы һәм баллы, бәлзәм кебек сихәтле һәм шифалы—кашыкка салып кына йотарлык. Ә кайберләрен сеңгер сыман чәйнәп-чәйнәп тә йотып җибәрер хәл юк... Косасыны китергеч төче сүзләр күбәйсә, миләш кебек ачы сүзләрне дә тансыклый башлыйсың... Яңа гына өзеп алган түтәл кыяры сыман сусыл, яисә кызган казан төбендәге талкан кебек коры сүзләрне дә очратырга мөмкин... Тимер чүкеч белән төеп-төеп тә ватылмый да, яньчелми дә торган каты сүзләр булган кебек, аз гына саксыз орынсаң да, бәллүр сыман уалырга гына торганнары да бар... Дөньяда "ачкыч" сүзләр бар—"йозак" сүзләр... Тылсымлы һәм гап-гади, үлчәүле һәм үлчәүсез, вакытлыча сүзләр һәм мәңгелек сүзләр...

Күтәреп булмаслык авыр, шыксыз һәм иләмсез сүзләр булган кебек, куенда гына йөртә торган җиңел, иплә һәм җыйнак сүзләр дә була... Керпе кебек чәнечкеле, песи кебек йомшак, елан сыман чагып ала торган сүзләр дә яши... Шулай ук туп шикелле тәгәрәтеп җибәрерлек йомры сүзләр дә аз түгел... Ә менә тутык калай сыман салкын һәм кытыршы сүзләрне шагыйрьләр бер дә өнәми...

Кайбер сүзләр оча, кайберләре йөзә, ә кайберләре... аксап йөри... Аксак-туксак сүзләр кайвакыт әрсезләнеп шигырь яки җырга кереп калырга тырышалар. Нәтиҗәдә, шигырь—туганчы ук һәлак була яисә гарип булып туа... Ара-тирә—шуышып яки сөйрәлеп кенә йөрүче ялкау һәм иренчәк сүзләргә дә "абынып сөртенгән" чаклар була... Аның каравы, вакыты-вакыты белән бары тик һавада гына очып йөри торган канатлы сүзләрне дә эләктереп алу бәхетенә ирешәсең...

Сүзләр гаҗәеп сыйфатларга ия. Ефәк җеп булып энә күзеннән үтә алырлыгы да, гигант корабларны якорь сыман ярда тотып торырдайлары да бар аларның... Сүз авыздан чыпчык булып очып чыга да, кире әйләнеп кайтмый... Нәкъ менә җәядән атылган ук шикелле... Аларның кайсылары балта белән дә кырып бетермәслек эз калдыра, кайсылары

иртәнге чык тамчысыдай, кояш нурларында кибеп, парга әйләнә... "Әйткән сүз—аткан ук" дисәләр дә, тормышта бумеранг шикелле, усал сүзләр—явызлык булып, ә изге, яхшы сүзләр игелек булып кире кайтучан. Шуңа күрә дә халык "Яхшы сүз—җан азыгы, яман сүз—баш казыгы" дип юкка гына әйтмәгән.

Сүзнең кеше күзенә бәрелеп торырлык зур-зур хәрефләр белән диварларга яки капкаларга язып куела торганнары да, йә булмаса, күз карасыдай саклап, чит-ят күздән бик нык яшереп, йөрәк түрендә генә йөртә торганнары да була.

Бер-берсенә ут белән су, яшәү белән үлем, көн белән төн шикелле капма-каршы сүзләр дә, яки, киресенчә, бер-берсенә ярдәм итеп, көч-куәт биреп торганнары да шактый.

Сүзләр тәмам бер могҗиза... Аларның төсе дә, исе дә, тәме дә, хәтта ки җаны да бар бугай... Кемдер бәлки: "Йә, арттырма инде ул кадәр, сүзнең нинди җаны булсын?!"— дияр... Юк шул, һич тә арттыру түгел, аны шагыйрьләр бик шәп беләләр... Дөрес, бөтен кешегә дә аны сизү сәләте бирелмәгән... Дөньяда бит яңа пешкән арыш ипиенең исен тоя белмәүчеләр дә очрый... Яисә аллы-гөлле салават күпере төсләрен аера белмәүчеләр дә...

Сүзләрнең кайберләре—урамда, ә кайсыберләре өйләрдә генә яши. Дөресен генә әйткәндә, аларның яшәмәгән җире дә юк. Бәгъзе сүзләр фәкать ташка гына уела. Әүвәл заманнарда Сүз бик кадерле булган, шуңа күрә ташка уелган. Хәзер исә кайбер сүзләр кәгазьгә дә ятмый, телгә дә, колакка да, йөрәккә дә. Ә менә кайбер сүзләр күзләргә генә язылa... Күргәнегез бардыр, кайчак кешеләр күзләр белән генә сөйләшә... Шул ук вакытта кесәдә генә йөртә торган сүзләр дә була. Алар "сүз эзләп, кесәгә кергәндә", әзер булып торсын өчен кирәк.

Сүзләр җиде кат җир астына да үтеп керә, җиде кат күкләргә дә барып җитә. Әмма бик күп сүзләр бүгенге көндә хәле беткән карт-корыдай, архивларда—калын-калын китаплар һәм кульязмалар, борынгы басмалар эчендә йокымсырап яталар... Төрледән-төрле сүзлекләргә кереп яшеренгәннәре дә хәтсез... Ихтимал, әле без белмәгән бик күп сүзләр тирән җир асларында, тузанлы чормаларда, хәтта ки ерак әби-бабаларыбызның инде эзе дә калмаган каберләрендә дә әрәм булып яталардыр. Бар, син аларны табып кара!.. Шулай да, югалган, онытылган сүзләр әледән-әле табылып та тора. Хәтер сандыкларында бик озак ятып, күксеп-күгәреп беткән сүзләрне кояшлы җилгә чыгарып элсәң, алар кабаттан яңарып, сафланып һәм яшәреп китәләр. Телгә, җырга, тарихка кереп калган сүзләр барыбер үлми, юкка чыкмый... Аларны каен суыдай тамчылап, яисә энҗе кебек бөртекләп җыярга да, җыярга кирәк...

Күзнең явын алырлык, хәтта ки яңа ел чыршысын бизәрлек уенчык сүзләр дә була... Алар, гадәттә, бәйрәмнәрдә бик тә кирәк булып чыгалар. Балаларга ялтыравыклы шарлар ничек кадерле булса, өлкән кешеләргә дә шундый уенчык сүзләр бик тә кирәк, бик тә тансык... Без һәммәбез дә күңелне күтәрә торган уенчык сүзләргә мохтаҗбыз. Аларны вата күрмик, кирәк чагында—сәбәпсезгә боегып, эчебез пошкан көннәрдә бер-беребезне шундый сүзләр белән юатыйк...

Ә менә энҗе-мәрҗән, җәүһәр-якут, зөбәрҗәт-фирүзә сыман асылташларны хәтерләтеп торган кыйммәтле, затлы сүзләрне кая куярга?! Андый сүзләрне, ихтимал, муенса итеп тезеп, иң кадерле кешеңә—әниеңә, сөйгән ярыңа, сөекле туташлар һәм ханымнарга бүләк итү—буыннан-буынга күчеп килгән күркәм гадәттер... Андый сүзләрне борчак кебек сибәргә дә, чиләкләп түгәргә дә мөмкин түгел... Андый асыл сүзләрнең урыны—патша сарайлары, затлы мәҗлесләр, искиткеч бай даирәләр, дип кенә уйлый күрмәгез... Һич тә алай түгел! Андый сүзләр мәңге-бакый шагыйрьләр йөрәгенә төпләнеп калган... Әмма җирдә тупас, яман сүзләр дә бертуктаусыз үрчи, арта бара. Гадәттә алар караңгы һәм тынчу йортларда, чүп баскан тузанлы тыкрыкларда, яисә тимер рәшәткәле шомлы тәрәзәләр артында, канлы сугыш кырларында азалар, нәфис һәм гүзәл сүзләргә каршы көрәш ачарга көч туплыйлар, йогышлы чир сыман бөтен дөньяга таралырга ният коралар... Кызганыч, Җирдә илаһи сүзләрнең дошманнары бик күп. Шуңа күрә дә якты, нурлы сүзләр әшәке һәм явыз-яман сүзләр белән гасырлар буе көрәшеп яшиләр. Җирдә бик күп шагыйрьләр изге, гадел сүзләр хакына үз гомерләрен дә корбан иткәннәр...

Әйе, серле дә, хикмәтле дә ул сүзләр... Кайсылары бик тирәннән чишмә кебек саркып чыгалар, ә бер ишеләре язгы ташкын кебек ургып агалар.

Кешенең гомере буена хыялында гына йөрткән, еллар буе кызыктырып, үкендереп-әрнетеп торган, әмма бер генә тапкыр да иреннәренә килеп куналмаган, бер генә тапкыр да әйтеп тә, ишетеп тә карамаган изге-тансык сүзләр дә була. Тумыштан ата-ана йөзен күрмәгән ятимнәр, яисә үз гомерендә бер генә тапкыр да мәхәббәт тәмен

татып карамаган бәндәләр нәкъ менә шундый сүзләргә мохтаҗ булып яшиләрдер...

Безнең арабызда ашап туймаслык тәмле ризыклар пешерә белә торган затлы кешеләр—ашбазлар яши. Аларның тәм тою сәләте искиткеч көчле була. Һәм—чама хисе... Шундый асыл кешеләр белән сөйләшеп тә, сыйланып та утырганым булгалады.. Кызык хәл, алар сүзгә дә бик оста, җор телле булып чыгалар. Сүзнең тәмен беләләр, зәвыгын аңлыйлар... Ә бит шул ук дөньяда тозлы яки тозсыз сүз сөйләп йөрүчеләр дә бик күп. Әйләнә-тирәдә сүз боткасы пешерүчеләр дә җитәрлек. Күбегезнең "ашап" та караганы бардыр: ул бик тиз туйдыра, өстәвенә тәмсез дә... Андыйларны тыңлап торсаң,—туры килә бит—яки укый башласаң (укып бетерергә, әлбәттә инде түземлегең җитмәячәк...), камыры уңмаган, чиле-пешле бәлеш ашаган кебек буласың. Аш-су дигәннән, сүзләрдән аш та, пәрәмәч тә пешереп булмый, әлбәттә. Аның каравы, халыкта "Сыйламага сыең булмаса—сыйпамага телең булсын",—ягъни сүзең булсын дигән бик зирәк әйтем дә йөри. Әйе шул: сүзләр ризык кебек татлы да, ачы да, төче дә була. Шифалы сүз—тәнеңә дә, җаныңа да бер дәва. Ә тәмсез сүзләр каныңа тоз сала, агулый, ачу-таш булып бәгыреңә утыра... Гомумән, хикмәтле сүзләр хакында да, тел турында да гыйбрәтле мәкальләр һәм әйтемнәр бик күп безнең татарда. Алар кырда да, өйдә дә, базарда да, юлда да, сугышта да, тынычта да туып кына торганнар.. Аларны әлеге дә баягы сүз тәмен белгән бай телле затлы кешеләр чыгарган. Безгә аларның исемнәре, ияләре дә билгеле түгел. Хәер, бүген инде моның әһәмияте дә юк...

Әйе, ияле сүзләр дә, иясез сүзләр дә йөри халык арасында. "Сүз иясе белән йөрми" дип акланучылар да була әле... Киресенчә, иясеннән башка бер адым да атламый торган сүзләр дә юк түгел... Әмма, барыбер, аерым сүзләр беркемнеке дә түгел. Алар үзеннән-үзе йөри торган Киплинг мәчеседәй, үзләренә үзләре генә хуҗа булып, үз иркенә яши бирәләр... Ияләштерә аласың икән, ияләштер! Буйсындыра алсаң, буйсындыр!—Әнә шул "үзирекле" сүзләр кем йөрәгенә килеп керә, шуңа охшый башлый да инде... Гомумән, сүзләр кешеләргә бик тә охшаш. Холыклары һәм асылы белән. Ипле, рәхәт сүзләр белән атлавы да җиңел. Ә кырыс, тупас сүзләр сине богаулый, адымыңны авырайта, эшеңне артка җибәрә, хәтта ки аяктан ега... Кешеләр бәхетле һәм ачык йөзле сүзләрне кунак көткәндәй, зарыгып көтеп алалар. Әмма, кайбер кунаклар кебек, бәхетле сүзләрнең дә килми калган очраклары була...

Сүзләр кеше теленә килеп керү белән, "коры сүз"булудан туктыйлар. Һәрбер сүзнең үз энергиясе була. Мин үзем, фәнни тел белән әйткәндә, сүзләрдә семантик, фонетик һәм график энергия тупланган, дип саныйм. Сүзнең энергиясе, әлеге дә баягы, сүзләрнең шул тылсымлы куәте, аларга таш-таулар җимерергә сәләтле көч-җегәр бирсә, шул ук энергия аларны нечкә гөлләр һәм тук башакларны гына тибрәтерлек йомшак җилдәй назга да әверелдерә.

Сүзләр нәкъ менә адәм балалары шикелле, төркем-төркем булып та, ялгызак булып та яшиләр. Бер гаилә булып яшәүче сүзләр дә була. Алай гына да түгел, Җиһандагы барча-барча сүзләр, Җир шарының төрле кыйтгаларына төпләнеп, милләт-милләт, халык-халык булып та яшиләр. Хәер, кайбер сүзләр үз милләтләре белән генә чикләнмичә, бик тә аралашучан һәм актив булулары сәбәпле, еш кына бүтән халыкларга да үтеп керәләр һәм аларга да хезмәт итә башлыйлар. Ул гынамы: кайда күбрәк файда китерүләренә карап, сүзләр төрле сыйныфларга, касталарга һәм төркемнәргә дә бүленеп бетәләр... Бал кортлары кебек күче-күче белән оешып яшәгән сүзләрдән аермалы буларак, бер ялгызы, мөстәкыйль рәвештә көн иткән сүзләр дә бар... Аның каравы, бөтен җирдә гел янәшә, бары тик парлап кына йөри торган сүзләр дә аз түгел. Андыйларны бер-берсеннән аерсаң, рәнҗи, үпкәли, хәтта сүз булудан туктый... Ә кайбер сүзләр, киресенчә, бер-берсен яратмыйча, бер-береннән читләшеп качып ук китәләр. Аларны янәшә куйсаң, һич кенә дә килешмиләр, үзләренең ялгыш кына бергә туры килүләренә көч-хәл түзеп торалар. Кайвакыт үзара ярашмаган сүзләр адашып шигыреңә килеп керәләр дә, юка нәфис тукымадан тегелгән җиңел күлмәккә калын җеп белән тагып куелган иләмсез һәм тупас төймә шикелле, чекерәеп күзгә бәрелеп тора башлыйлар. Аларны җәһәт кенә өзеп атасы килә.

Ә кайбер сүзләр нәкъ киресе: әйтерсең лә, бер-берсенә гашыйк егет белән кыз диярсең. Алар бер-берсен эзләп йөри, бер-берсеннән башка яши алмый башлый. Үзара гармониягә сусап, ул сүзләр җыр-шигырьләрдә кавышалар, бер-берсен эзләп табышуларына мәңге канәгать һәм разый булып, һәркемнең җанын иркәлиләр, күңеленә хуш киләләр һәм телдән-телгә күчеп гомер итәләр. Андый сүзләр яшел үлән арасыннан

күзне кызыктырып җемелдәп торган кып-кызыл каен җиләкләре сыман, яисә яшькелт-зәңгәр диңгез дулкыннарына орынып-орынып очкан акчарлаклар кебек, үзара бик тә камил, зәвыклы булып ярашалар, тәңгәлләшәләр, мәңге аерылмаслык булып берегәләр. Шуңа күрә сүзләрнең холкын-фигылен өйрәнергә, белергә кирәк...

Әйтәсе дә юк, сүзләр гаҗәеп серле вә четрекле "халык". Алар белән бик сак эш итсәң генә... Югыйсә алар синнән үч алырга да күп сорамый.

Дөньяда бернинди авызга да, бер генә каләмгә дә буйсынырга теләмәгән артык горур һәм бәйсез сүзләр дә очраштыргалый. Әлеге азат һәм хөр сүзләр нигәдер кешеләрдән ераграк торырга яраталар. Аларны читлекләргә бикләп тә, сандыкта яткырып та булмый. Кызганыч, шундый хөр сүзләрнең дә, заманына карап тоткынга, әсиргә әйләнүе ихтимал. Яшәү шартлары, тормыш кануннары үзгәреп тора, һәм сүзләр дә, нәкъ кешеләр кебек, моны бик тиз сизеп алалар. Дөньяларның асты-өскә килгән дәверләрдә кайбер сүзләр дә "кулга алына", йозакка бикләнә, җиргә күмелә, утка ягыла, беркем яшәми торган бушлыкларга—сөргенгә сөрелә, зинданнарга ябыла... Андый чакларда хөр сүзләр палачлардан куркып, изге һәм батыр йөрәкләргә кереп яшеренәләр һәм дөньяга нәфрәтле, сагышлы күзләр аша карап тора башлыйлар... Әмма, барыбер, беркөн килеп, алар иреккә чыгалар, язгы ярсу кар сулары шикелле, иркен болыннарга ургылалар, мәйданнарга, урамнарга ашыгалар, ярларыннан ташып агалар. Аларны тоткынлыкта озак тотып булмый! Хөр вә Чын сүзләр, бөтен киртәләрне ватып-җимереп, тимер пәрдәләрне кубарып, биек коймаларны аударып, ниһаять, ирекка чыгалар һәм үз урыннарына әйләнеп кайтып, өр-яңадан үз эшләренә керешәләр. Патшалар алмашынса да, әлифбалар, акчалар үзгәреп торса да, чын сүзләр үзгәрмиләр, алар мәңге үзләре булып калалар...

Шулай да вакытына карап, үзенең төп асылын бик тиз үзгәртүчән, тотрыксыз һәм умырткасыз сүзләр дә яши бирә. Алар гүя җил уңаена гына хәрәкәт итәләр. Шулай ук аларны базарларда сатарга һәм сатып алырга да мөмкин. Сатлык сүзләр бигрәк тә төрле фиркаләрне, аеруча сәясәтчеләрне үз итәләр, инде килеп кайбер гәҗит битләрен яратучан булалар. Аларның бәясе дә әледән-әле үзгәреп тора. Сүз җегәрен, сүз тәмен ифрат нечкә тоючы сүз "дегустаторлары" гына аларны бер ишетүдә танып ала.

Безнең арабызда яңа туган "бала" сүзләр һәм меңьяшәр "карт" сүзләр дә яши. "Аксакал" сүзләр нарасый сүзләрне тәрбияли, дөнья белән таныштыра, кешеләр теленә кертеп, сыный, утка-суга салып чыныктыра. Әлбәттә, яңа сүзләр көн саен туып тормый... Мөгаен, җирдә менә шушы мизгелдә дә, туам-туам дип торган сүзләр бардыр... Әлегә аларның авазлары да, формасы да, кем әйтмешли, "исе" дә юк. Әмма алар, һичшиксез, Телебез карынында яралып ята...

Күп кенә сүзләр сине дус итә, ярата, кирәк чакта эзләп интекмәсен дигәндәй, гел яныңда булырга тырыша. Ә кайберләре исә бик тә ялындыручан һәм киребеткән, иң кирәк чагында табылмыйча йөдәтә, эзләтә, тәмам аптыратып-тинтерәтеп бетерә. Ә үзләре соңыннан, кирәге беткәч кенә, әллә кайдан "ялт" итеп килеп чыгалар да, әрсез чебен күк, тирәңдә безелдәп очарга тотыналар! Ачуны китерәләр хәтта. Ләкин мин аларны кумыйм, кыерсытмыйм—йөрсеннәр шунда, алар да сүз ич... Бөтен сүзләргә дә кадерле һәм кыйммәтле генә булып бетәргә димәгән лә... Нишлисең бит, тормышта кеше гомерене тиң бәһасез сүзләр белән беррәттән, кайчак сукыр бер тиенгә тормаслык сүзләргә дә урын табыла. Хәлбуки, сүзнең бәясе күбесенчә аның иясе, урыны һәм вакыты белән билгеләнә.

Кайбер сүзләрдән шулкадәр туясың ки, хәтта качып китәр дәрәҗәгә җитәсең. Сатып та, бүләк итеп тә, бушка биреп җибәреп тә булмый үзләрен. Алар сиңа чат ябышкан. Урлап китүче дә юк ичмасам... Ә менә сирәк очрый торган асыл сүзләреңне урлап-йолкып китүчеләр бик тиз табыла. Ат карагы Шәкүрне ишетеп белмәгән кеше юктыр. Энә карагы дигән бик матур бөҗәкләрне дә күреп беләсездер. Ә кесә карагына очрарга язмасын... Сүз карагы да булуын гади кешеләр белеп тә бетерми торгандыр әле... Аны сүзләр белән "эш итүчеләр" бик яхшы белә... Дөньда сүз караклары ай-һай күп... Ярый әле, урланган сүзләр дә, сатылган сүзләр шикелле үк, үзләренең чын хуҗалары турында әллә кайдан кычкырып торалар. Малның да бит урланганы, үз хәлә көчең белән табылмаганы әллә кайдан күзгә бәрелеп тора...

Сүзләрне, әлбәттә, саклык кассаларына салып булмый. Әмма аларның да бәясе нәкъ менә акча шикелле әледән-әле үзгәреп тора, ягъни инфляциягә дучар була. Әле ярый, кешеләр сүзләрне саклык кассаларында тотмыйлар. Юкса көтмәгәндә, бер көн килеп, аларның бит бер сүзсез калулары да бик мөмкин... Хәер, без саклык акчаларыбыз

эреп югалгач та, бер сүзсез калдык... Күрәсез, акча белән сүзләр арасында да охшашлык бар бугай... Акчасыз калсаң да, телсез калсаң да, күп нәрсәләрдән коры каласың... Шуңа күрә без сүзләрнең бәясен арттыру әмәлен табарга тиешбез. Валюта булып йөрерлек алтын сүзләр кирәк!!!

Акчаны бурычка алып торган кебек, кайвакыт кешеләр сүзләрне бүтәннәрдән әҗәткә дә алып торалар. Ләкин соңыннан инде шул сүзләрне чын хуҗаларына кайтарып бирергә "онысталар". Сүзләрне бурычка биреп тору да, үзең әҗәткә алып тору да, шулай ук алар белән сату итү дә затсыз кешеләргә хас сыйфат...

Сүзләрне саклык кассаларында саклау мөмкин булмаса да, "сүзләр банкы"н булдыру гаять зарур. Мин үзем төрледән-төрле сүзлекләрне әнә шундый сүзләр банкы дип саныйм. Яисә—компьютерлар... Дөрес, соңгыларына килеп эләккән сүзләрнең язмышы нәрсә белән бетәр—киләчәк күрсәтер... Әмма ләкин компьютер ярдәмендә шигырь язучыларны мин аңлый алмыйм инде. Чөнки чын хисләр белән сугарылмаган җансыз сүзләрне бер-бер артлы тезеп кенә кеше күңелен дулкынландырып була микән?! Мәгълүм ки, "ут белән шаярма", дигәндәй, сүз белән шаяру да беркайчан да юньлегә алып бармаган... Сүзләр алар бик шәпләп үч алырга да сәләтле: интернетка теркәлгән "ясалма акылың" да коткармас...

... Без менә шулай гомер буе сүзләр белән аралашып яшибез. Сүзләр безне бәхетле дә, бәхетсез дә итә ала... Сүзләр әйтерсең лә кояш: алар һәркемнеке һәм һәммәбезнеке дә. Һәркемнең үз кояшы булган кебек, һәркемнең үз сүзе, үз язмышы...

Бу дөньяда изге, якты сүзләр белән дус-тату булып яшәсәң иде! Кайвакыт минем салават күпере төсле аллы-гөлле сүзләр уртасында каласым килә. Алар мине җитәкләшеп уртага алсыннар иде дә, ямьсез, төссез, салкын һәм сатлык сүзләрдән ышыклап, саклап торсыннар иде. Миңа гомерем буе бары тик тере сүзләр арасында гына яшәргә насыйп булса иде... Моның өчен мин шул гүзәл сүзләрне эзләргә, табарга һәм бүтәннәр өчен дә саклап калырга тиеш... Югалтмаска! Аларны кадерләп тотарга, хисләр бишегенә салып тирбәтергә, ефәк яулыкларга, ак сөлгеләргә, саф күңелләргә шигырь итеп чигеп калдырырга кирәк. Урманнан да, болыннан да, базардан да, диңгез төпләреннән дә, йолдызлы күктән дә, кешеләр күңеленнән дә энҗе кебек бөртекләп, тамчысын да, валчыгын да әрәм итмичә, җыярга да, җыярга!.. Бу дөньяда адәм балаларын сүзләр каршы ала һәм соңгы юлга да сүзләр озатып бара... Сүзләрдән башка дога укып та, изге теләкләр теләп тә булмый. Сүзсез шигырь дә язылмый...

Сүзләр кешегә һава белән су, икмәк белән тоз, Кояш белән Мәхәббәт кебек кирәк!.. Сүздән башка Тел дә, халык та юк. Сүзләр миңа әби-бабаларымнан мирас булып калган. Рәхәттә дә, михнәттә дә Сүзгә мохтаҗ без, Сүз ул Ата-Анага да, Балага да бер үк дәрәҗәдә кадерле. Сүзләр игенчегә дә, фәйләсуфка да хезмәт итә. Яхшы сүзләр бөтен кешегә дә кирәк, яман сүзләр беркемгә дә кирәкми... Сүзләр әле кешеләргә генә түгел, кошларга да, җәнлек-хайваннарга да, чәчәкләргә дә кирәк...

Кереш сүзләр булган шикелле, йомгак сүзләр дә була. Тәүге сүзләр булган кебек, соңгы сүзләр дә көтеп тора... Алар гадәттә соңгы сулышта яисә хөкем алдыннан әйтеләләр... Әмма мин әле бүген соңгы сүземне әйтергә җыенмыйм... Бары тик йөрәгемнән чыккан шушы хисләремә, язганнарыма йомгак ясарга гына җыенам. Минем әле ишетер сүзләрем дә, әйтер сүзләрем дә бетмәсен иде... Телемдәге изге, хак сүзләрдән мәхрүм итмә мине, Ходаем! Минемчә, иң әүвәле Сүз булган кебек, иң соңыннан да Сүз калыр...

Сүзләр... Сүзләр... Сез—минем Мәхәббәтем... Сез—бөтенесе дә... Сез—миннән башка да яшисез, ә мин сездән башка яши алмам. Ләкин мин дә сезгә кирәк! Чөнки мин дә—сезне саклаучыларның берсе... Сезнең хакта язучылар бик үк күп түгел, ә менә сездән башка беркем дә берни дә яза алмый...

Сүзләр үзләре турында үзләре сөйләп тора, әлбәттә. Әмма аларның да бездән яшерен серләре бар. Без гомер буе шул серләрне ачарга омтылып яшибез...

Сүзләр, мин сезне ничек яратам!.. Мин сезгә бурычлы. Минем телем дә, каләмем дә гомерем буе сезнең кануннарыгызга итагатьле булып калыр... Сез мине үз кадерегезне дә, тормыш кадерен дә аңларга өйрәттегез. Рәхмәт сезгә, сүзләр!

Дөньядагы барлык-барлык сүзләр арасында минем дә үз сүзләрем бар... Газизләрдән газиз Әткәм-Әнкәм теле—Бөек Татар телендәге сүзләрем—Җир шары буйлап кояш нурлары кебек таралсын иде дә, җиһандагы барлык кешеләрне бары тик гүзәллеккә һәм изгелеккә генә өндәп торсыннар иде!..

*1988—1998*

*Фән һәм дин*

Адлер Тимергалин

# ПӘЙГӘМБӘР

Әүвәлгеләр Коръәнне яттан белгәннәр. Кайчагында искә төшерүне җиңеләйтү өчен пальма ботакларына, куйларның калак сөягенә, ташка, пергаментка Коръән сүзләрен язып куя торган булганнар.

Пәйгамбәрнең вафатыннан соң, аның сәхабәләре газаватларда һәлак булып, Коръәнне яттан белүчеләр (кариэләр) сирәгәя барган саен, Коръән мәтенен (текстын) язма рәвештә саклау зарурлыгы үзен ныграк сиздерә. Инде беренче хәлифә Әбүбәкер чорында ук (632—634) Коръәнне яхшы белүчеләр хәтерләрендә сакланган Коръән аятьләрен әйтеп яздыра башлаганнар. Бу эшне Пәйгамбәрнең сәркатибе булып хезмәт иткән Зәед ибне Сабитка йөкләгәннәр.632 ел ахырларына Коръән мәтене барлыкка килгән. Бу мәтенне Сухуф дип атаганнар.

Тиздән язмалар һәм телдән сөйләнә торган сүрәләр арасында күп кенә мөһим һәм вак детальләрдә аерма барлыгы күренә. Өченче хәлифә Госман (644—656) Зәед ибне Сабитка барлык язмаларны берләштереп, Коръәннең абруйлы мәтенен төзергә әмер бирә. Төрле вариантларны өйрәнеп һәм сайлап алып, 651 нче елда төзелгән бу җыентык бердәнбер дөрес мәтен (текст) дип игълан ителә, калган барлык башка вариантлар, шул исәптән Сухуф та юк ителергә тиеш була. Яна җыентык "Мосхәф" ("Мосхәф шәриф") яки "Госман мосхәфе" ("Мосхәф Госмани") дип атала. Коръәннең борынгы кульязмалары барысы да Госман хәлифә редакциясен чагылдыралар.Коръән Кәримнең Ислам дөньясында файдаланыла торган бүгенге тексты да әлеге мәтенне кабатлый.

Госман Коръәненең, читләтебрәк булса да, татарга да мөнәсәбәте бар. Сәмәркандта Урта Азия мөселманнарының Дини идарәсе китапханәсендә борынгы Коръән кульязмасы саклана.Аның мәтене Рәсүлуллаһның тол хатыны Хафизадагы китап буенча төзелгән. Ул берничә гасыр буена Сәмәркандта Хуҗа Әхрар мәчетендә сакланган һәм Госман хәлифә кушуы буенча язылган кануни Коръән күчермәләренең берсе дип исәпләнгән. 1869 елда Төркестан төбәге генерал-губернаторы аны юк кына бәягә сатып алган да Петербургтагы Император китапханәсенә бүләк иткән. 1891 елда ориенталист А. Ф. Шебунин кульязма Коръәнне палеографик яктан тасвирлый һәм бу күчермәнең төзелү вакыты VIII гасырдан да иртә түгел диган нәтиҗәгә килә. Петроград милли округының төбәк мөселманнары үтенече буенча "Госман Коръәне" 1917 ел азагында Владимир Ульянов (Ленин) фәрманы белән Уфага җибәрелә һәм Мөселманнарның Дини идарәсе мөфтие Галимҗан хәзрәт Барудига тапшырыла. Ул анда 1923 елның 19 июненә кадәр саклана.Ватандашлар сугышы тәмамланганнан соң ук Урта Азия дини җәмәгатьчелеге Коръәнне Сәмәркандка кайтаруны таләп итә. Ләкин аны башта Ташкентка җибәрәләр (Ташкент Диния нәзарәтенә "Мосхәф Госмани"ны Ризаэддин Фәхреддин хәзрәт үзе илтә) һәм изге китапның язмышын урында хәл итәргә диган компромисслы карар чыгаралар. 1926 елдан ул Үзбәкстан халыклары тарихы музеенда саклана. 1989 елның 14 нче мартында Урта Азия мөселманнарының Дүртенче корылтаенда тарихи ядкяр Урта Азия мөселманнарының Дини идарәсе китапханәсе—"Мавәраэннәһер"гә тантаналы төстә тапшырылды.

---

*Ахыры. Башы 2 санда.*

Шиһабетдин Мәрҗани 1790 елларда Сәмәркандта булган вакытында бик искергән кулъязманың татар суфи шагыйре Утыз Имәни тарафыннан төзәтелүе, югалган битләренең тутырылуы турында яза. Аның фикеренчә дә бу Коръән күчермәсенең Госманныкы булуы шикле.

Билгеле булганча, Коръән текстын укудагы төрлелектән котылу өчен аңа гарәп язуына хас билгеләр куеп чыгалар (VII гасырның ахырларына кадәр). Ләкин кыска сузык авазларның язуда чагылмавы аркасында, сүзләрне укуда төрлелек саклана.Хәзерге вакытта җиде төрле уку варианты кануни булып санала, шуларның икесе—Гасим һәм Нәфи системалары гамәлдә кулланыла.

1919, 1923 һәм 1928 елларда Каһирәдә басылган Коръәндә изге китапның орфографиясе, мәтеннең төзелеше һәм аны уку кагыйдәләре тәмам канунлаштырыла.

Коръән Кәрим төрле озынлыктагы 114 сүрәдән тора. Гыйльме Коръәниядә кабул ителгән традиция буенча, сүрәләрне, кайда иңгән булуларына карап, Мәккә сүрәләренә (610—622 еллар, 90 сүрә) һәм Мәдинә сүрәләренә (622—632 еллар, 24 сүрә) бүләләр. Күпчелек очракта Мәдинә сүрәләре Мәккә сүрәләреннән озынрак. Мәккә сүрәләрен дә беренче (шигъри), икенче (рәхмани) һәм өченче (рәсүли) чор сүрәләренә бүлеп карыйлар. Беренче чор сүрәләре күтәренке рухлы һәм хис белән сугарылган, икенче чор сүрәләре тынычрак, аларда бер аллалыкны вәгазьләү төп урынны алып тора. Рахмани—Алланыкы дигәнне аңлата. Өченче чор сүрәләрендә пәйгамбәрләр турында риваятьләр күп, шуңа күрә алар рәсүли дип аталганнар да. Мәдинә сүрәләренә килгәндә, аларында мәрасим (рәсмиләшкән йолалар, гадәтләр), хокук һәм әхлакка нисбәтле күрсәтмәләр күбрәк туплан-ган. Гыйльме Коръәниядә "Бәкарә"сүрәсенең 280 нче аяте Пәйгамбәргә иң ахырда иңгән дип исәпләнелә. Бу аятьнең мәгънәсе бик мөһим булганга, аның "Тәфсир Ногмани" буенча мәгънәсен китерик: "Әгәр сездән бурычка алган кешеләр бурычларын түли алмаслык фәкыйрь булсалар, бурычларын түләргә мал тапканнарына чаклы кичектерү сезгә лязимдыр. Әгәр бурычларын түләргә көче җитмәгән кешеләргә, бурычларын үзләренә сәдака кылсагыз, сезнең өчен бик тә хәерледер, әгәр белсәгез!"

Сүрәләрнең һәрберсенә исем бирелгән һәм кайбер сүрәләр икешәр, өчәр исем белән атап йөртелә. Мәсәлән, "Та һа" сүрәсе (20) беренче аять алдында торган хәрефләре буенча аталган.

9 нчы һәм 12 нче сүрәләрне исәпләмәгәндә, алар бер-берсеннән бисмилля гыйбарәсе белән аерылганнар. Үз нәүбәтендә һәр сүрә аятьләргә бүленә. Аять—аерым җөмләдән яки җөмләнең бер өлешеннән гыйбарәт. Иң озын сүрәдә (2 нче сүрә) 286 аять, иң кыскасында (112 нче сүрәдә) 4 кенә аять бар. Аятьләр 1 дән алып 68 гә кадәр сүздән торалар.Коръәндә барлыгы 6204 тән алып 6236 яки 6238 гә кадәр аять (төрле исәпләү вариантлары буенча) һәм 77934 сүз. Хәрефләр исә 323 621. Хәзерге заман басмаларында аятьләрнең тәртип номерлары ике төрле: европача һәм яңа мисырча булырга мөмкин. Урысча басмаларда алар янәшә сугыла. Бездә (мәсәлән, Ногмани тәфсирендә) кабул ителгән нумерация урысча басмаларда җәя эчендә бирелгән.

Коръәннең шактый өлеше арадашчылар (рух, Җәбраил) аркылы беренче яки өченче заттан "сөйләүче" Аллаһы белән Пәйгамбәрнең дошманы арасындагы бәхәстән яки Аллаһы тәгаләнең Мөхәммәд галәйһиссәлам тарафдарларына вәгазь һәм күрсәтмәләр белән мөрәҗәгатеннән гыйбарәт.

Коръәндә Мөхәммәд пәйгамбәр нотыкларының төп идеясе—бер Аллалыкка күчүнең зарурлыгын аңлату. Коръән буенча Аллаһы—дөньяны хәлык итүче (бар итүче) һәм бөтен хаятнең башлангыч сәбәбе. Коръән Кәримдә кыямәт көне турында кисәтүләр, җәһәннәм һәм оҗмахны тасвир иткән сүрәләр, гарәби фольклорга һәм йәһүди-христиан риваятьләренә дә барып тоташа торган кыйссалар зур урын алып тора.

Еш кына европалылар, Коръән белән таныша башлауга ук, андагы күп кенә шәхесләрнең Библия һәм Инҗилдән үзләренә мәгълүм булган затларга тәңгәллегенә игътибар итәләр дә, Коръәннең әлеге китаплардан шактый соңрак туганлыгын искә алып, аның икенчеллеге турында нәтиҗә ясыйлар, ягъни Библия китабы Коръән өчен нигез булып хезмәт иткән дип уйлыйлар.А. Гейгернын

"Йәһүдилектән Мөхәммәд нәрсә алган" (1902), В. Рудольфның "Коръәннең йәһүдилеккә һәм христианлыкка бәйлелеге"(1922) кебек китапларында нәкъ менә шундый караш чагыла. Чынлыкта исә мәсьәләнең мондый куелышы тарихи картинаны боза гына. Коръән дә Библия һәм Инҗил туган мохиттә барлыкка килгән һәм аның йәһүдилек һәм христианлык белән генетик элемтәләре—бердәм мәдәни дөньяның чагылышы гына.Мәсәлән, Х. Шпеерның "Коръәндә Библиядәге тарихлар" дигән китабында Коръәндәге кыйссаларның турыдан-туры Библиядән яки башка чыганактан алынганлыгын дәлилләп күрсәтү мөмкин түгел дигән фикер үткәрелә. Бу мәсьәләдә күренекле материалист һәм үзе дә еврей чыгышлы Фридрих Энгельс фикерен искә төшерү урынлы булыр:"... еврейләрнең изге китабы борынгы гарәпләрнең дини һәм кабиләи традицияләре язмасыннан башка нәрсә түгел, алар еврейләрнең үзләренә кардәш булган, ләкин күчмә кабиләләр килеш калган күршеләреннән бик иртә аерылуы аркасында үзгәргәннәр генә",—дип яза ул. Шуна күрә Коръәнне өйрәнү юлы белән әлеге бердәм мәдәни һәм рухи дөньяның күп кенә үзенчәлекләрен анларга һәм аны тулырак күзалларга мөмкинлек туа.

Коръәндә мәгънәсе анык ачылмаган урыннар бар. Бу хакта Гимран (3) сүрәсенең 7 нче аятендә дә әйтелә:"Коръәндә күбрәге мәгънәсе ачык, анлаешлы аятьләр, ул аятьләр Коръәннең төп нигезе. Шулай ук Коръәндә мәгънәсе яки тәэвиле (юравы, анлатуы) ачык беленмәгән аятьләр дә бар, ләкин андый аятьләргә тәэвил ясаудан, ягъни мәгънә чыгарудан Аллаһ тыйды. Әмма күнелләре хактан батыйльгә авышкан яман кешеләр мәгънәсе ачык булмаган аятьләргә ияреләр, кяфер булуны эстәп яки мөселманнар арасына фетнә салуны теләп һәм нәфесләренә муафыйк мәгънәләр бирмәкне теләп тәэвил ясарлар. Бу мәгънәсе ачык беленмәгән аятьләргә тәэвил ясап, мәгънә бирергә һичкем белмәс, мәгәр Аллаһ үзе генә белер." ("Тәфсир Ногмани" буенча.) Шуна күрә сонгырак аятьләр алдарак ингәннәрен гамәлдән чыгаралар. "Бәкарә" сүрәсенең (2) 106 нчы аятендә аермачык әйтелгән:"Әгәр кайбер аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртсәк яки онытсак, ул аятьләргә охшашлы аятьләрне яки яхшыракны бирербез."

Бу турыда махсус гыйлем бар, ул "гыйлем ән-насих вә-л-мәнсух" дип атала (юкка чыгаручы һәм гамәлдән чыккан нәрсәләр турында).Ул бер-берсенә каршы килә торган аятьләрне тикшерә. Алар арасында гамәлдән чыгарылган һәм Коръәннән төшереп калдырылган аятьләр,үзгәртелгән аятьләр һәм хөкеме бетерелгән, ләкин Коръән мәтенендә сакланган аятьләр аерып карала.

Кыскасы, мөселманнар белән бәхәскә кереп, Коръәндә капма-каршылыклар булуына басым ясарга тырышу нәтиҗә бирә алмый, чөнки Ислам галимнәре боларны бик яхшы беләләр һәм мәгънәсе ачык беленмәгән аятьләрне (алар мөтәшәбихат дип атала, андыйларның саны 200 гә җитә) өйрәнәләр. Гадәттә алар мәрасимнәргә һәм хокук мәсьәләләренә кагыла. Бу темага караган иң абруйлы хезмәтләрнең авторларыннан Ибн Сәламаны (1019 елда вафат) һәм Ибн Таһирны (1039 елда вафат) күрсәтергә мөмкин.

Исламияттә Коръәннең эчтәлеге һәм формасы ягыннан могҗизалы булуын, аны бераүнең дә кабатлый алмавын анлаткан махсус термин бар: Игъҗаз әл-Коръән (Коръән могҗизасы). 620—622 елларда ингән сүрәләрдә Мөхәммәд пәйгамбәр "Коръән—Аллаһ сүзе түгел" дигән кешеләргә:"Алайса Коръән сүзләренә охшашлы бер сүрә китерегез",—дигән таләп куя (2:23).Коръәнне башка телләргә тәрҗемә итү мөмкин түгеллеге игъҗаз әл-Коръән концепциясенә нигезләнгән.

Коръәннең төп нөсхәсе, башка изге китаплар белән бергә, оҗмахта саклана дип исәпләнелә.

"Заруратган ипигә басарга ярый, Коръәнгә басарга ярамый" дигән сүз бар.

Безнең гасырның утызынчы елларында Коръән X—XI гасырларда гына барлыкка килгән, ә язма рәвештә XIV гасырда,солтан Госман заманында теркәлгән дип исбат итәргә омтылышлар (Н. Морозов) белгечләр тарафыннан бик тиз кире кагылды. Кайбер Мәскәү галимнәренең Коръәнне күмәк мистификация дип игълан итүләре дә уңышсызлыкка очрады, чөнки борынгы документлар, әйтик, Гайсә пәйгамбәрдән аермалы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тарихи шәхес булганлыгын кире каккысыз итеп раслыйлар.

Билгеле булганча, Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафатыннан соң Гарәбстанда

Исламнан күпләп кире чигенүләр күзәтелә. Әмма Әбү-Бәкер белән Гомәр Исламны кабат торгызалар һәм җәелдерәләр.

Коръән идеяләре һәм гомумән Ислам дине турында рус философы Владимир Соловьевның бер чагыштыруын китерәсем килә. Ислам мәҗүси бал белән христианнарның исерткеч шәрабы арасында тора торган сәламәт һәм аек сөт кебек, ди ул. Үзен кабул иткән гарәбләр өчен Ислам бер үк вакытта кануннар җыелмасы һәм тормыш философиясе дә булган. Гарәпләрдә һәртөрле фәннәрнең (бигрәк тә математиканың, астрономиянең, химиянең, медицинаның, диңгездә йөзүчелекнең һ. б.) һәм философиянең кинәт үсеп китүе, Европа өчен дә остазга әйләнүе алар арасында нәкъ менә Ислам диненең тантанасына бәйле.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең нәселеннән ир баласы калмый. Югарыда әйтелгәнчә, һиҗрәтнең сигезенче елында җариясе Мария тапкан Ибраһим исемле угыл ике яше тулганчы ук вафат була.

Пәйгамбәрнең төпчек кызы Фатыйма уналты яшендә әтисенең туганнан туганы Гали ибн Әбү Талибка кияүгә чыккан. Аларның Хәсән һәм Хөсәен исемле игезәк уллары булып, бүгенге көндә Ислам дөньясындагы шактый күпсанлы сәетләр һәм шәрифләрнең нәсел җебе Хәсән белән Хөсәенгә барып тоташа. Пәйгамбәрнең үз оныкларын бик нык яратканлыгы билгеле.

Рәсүлулланың өлкән кызы Зәйнәп Һалт исемле кеше никахында булып, һиҗрәтнең сигезенче елында вафат булган.

Рокыя башта Әбү Ләһәбнең Готбә исемле угылында булган, ләкин Пәйгамбәрнең канкардәше һәм кандошманы Әбү Ләһәб, туй үткәрелгәнче үк, аларны аеруга ирешкән. Соныннан Рокыя Госман хәзрәтләре белән никахлана һәм Бәдер сугышы вакытында вафат була.

Пәйгамбәрнең өченче кызы Өммөгелсем, Рокыя вафатыннан соң, хәзрәти Госманның җефете була. Вафаты—һиҗрәтнең тугызынчы елында. Рәсми әдәбиятчылар тарафыннан алласызлар сафына кертеп йөртелгән һәм 1915 елда укыган дәһри шигыре өчен чыннан да ләгънәтләнгән татар-башкорт әдибе Мәҗит Гафуриның "Хәзрәти Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһиссәлам вә дүрт хәлифә" дигән элегрәк язган иманлы китабында (1912) Мөхәммәд пәйгамбәргә түбәндәге бәяләмә бирелә.

"Хәзрәти Рәсүлнең тавышы күркәм, сөйләшүе мөлаем вә йомшак, сүзе гаять фәсыйх вә ачык булып, сүзне кирәк вакытта гына сөйли торган иде. Уйнап сөйләшми, начар вә ярамас сүзләр әйтми, һичкемне гайбәт кылмый, сүз сөйләгәндә сүзләрен санап торырга мөмкин иде. Сүз сөйләргә керешсә, бөтен мәҗлес тып-тын булып, бик ихлас белән тыңлыйлар иде.

Хәзрәти Рәсүл һәркемгә—хәтта дошманнарына да—ачык йөзле, татлы сүзле булып, һичкемгә чытык йөз белән тормый иде. Кешеләргә әүвәл үзе сәлам биреп, күрешкәндә башлап кулын суза, сөйләшә башласа, теге кеше сүзен бетергәнче тыңлап тора, ягъни аны ташлап китми иде.

Мәҗлестә кайда урын булса, шунда утыра, сүз сөйләгәндә бер генә кешегә карап сөйләми иде. Нинди гаҗәп нәрсә күрсә дә кычкырып көлми, елмаеп кына көлә, берәр кеше начар сүз ычкындырса, илтифат кылмый яки иплә кенә ярамаганлыкны аңлата иде. Хәзрәти Рәсүл һәркемгә түбәнчелекле булып,үзен һичкемнән артык күрми иде...

Хәзрәти Рәсүл гаять киң холыклы, сабырлы булып, һичкемгә ачуланмый, бирәүдән дә үч алырга теләми, үзенә усаллык кылган, зарар китергән кешеләрне дә гафу итә иде. Рәсүлебез бик юмарт булып, кулында булганда һичкемне буш җибәрми, малын кызганмый биреп җибәрүчән иде...

Хәзрәти Рәсүлнең искиткеч гүзәл сыйфатларын күреп, Ислам динен кабул итүчеләр булды."

Рәсүлулла чәчен колак йомшагыннан, хәтта аннан да түбән төшәрлек озын итеп йөрткән. Мәҗит Гафури китабында ул:"Йөзе түгәрәк булып, бик матур вә нурлы, зур кара күзле, нечкә озын кашлы, уртасы калкурак борынлы, тешләре саф вә энҗе кеби ак вә сирәк иде. Чәч вә сакалы чем кара булып, чәче бөдрәләнеп тора иде,"—дип тасвир итэлә. Чыганакларга караганда, "Ул чәч вә

сакалын тарыйдыр, майлый вә хушбуйлыйдыр, көзгесе хәтта сәфәрдә дә яныннан калмыйдыр иде." Мөхәммәд пәйгамбәр абайяга төренеп (кайбер чыганакларда озын киез кием кигән дип сөйләнә), чалма сарып йөргән. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Лейпцигта Гедан тарафыннан гравюра итеп эшләнгән рәсеме, тулаем алганда, әлеге тасвирга каршы килми, ләкин гравюрада ул чалмасыз,сакалы да куерак итеп күрсәтелгән кебек тәэсир кала. Европа кешесе эшләгән портретта Пәйгамбәр артык мәгърүр кыяфәтле, хәлбуки бусы аның табигатенә хилафлык була...

Дин галиме Абызгилдин Җиһангир Пәйгамбәрнең сүз сөйләү тәртибе һәм әдәбе турында:"Сүзен уйлап-фикерләп, һәркемгә аңлашылырлык ачык итеп, акрынлык белән сөйли, әйткән сүзләрен анлап яки санап торырга мөмкин булган, тәмам төшендереп бирү өчен кайбер сүзләрне өчәр мәртәбә кабатлап әйтә, сүз сөйли башласа, бөтен мәҗлесне мәхәббәт басып, һәммәсе тукталып, ихлас белән тынлыйлар иде. Сөйләгәндә аз гына елмая, артык кычкырып сөйләми, вәгазь-хөтбә, кыямәт хәленнән хәбәр бирсә, күзе кызара,тавышы күтәрелә, сүзне гайрәт белән әсәрле итеп сөйли торган була...",—дип яза.

Хәзрәти Рәсүл Әкрәм үзенә очраган адәмнән әүвәлрәк сәлам биргән, көрешергә теләп кулын суза торган булган, көрешкән адәм белән ул адәм үзе кулын алмыйча кулын алмаган. Аның ни дәрәҗәдә сизгер кеше булганлыгын "Гәбәсә" ("Чытты") сүрәсеннән дә күрәбез. Сүрәдә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең үзенә мөрәҗәгать иткән сукыр ибне өммү Мәктүмнән читкә борылуы, йөзен чытуы һәм моның өчен Аллаһудан шелтә алуы турында сүз бара.

Рәсүлулла беркайчан да "Мин пәйгамбәр,"—дип эреләнмәгән, үз эшләрен кешедән эшләтергә яратмаган, базарда алган нәрсәләрне үзе күтәреп кайткан, киемнәренең ертык җирләрен үзе тегеп куя, хайваннарны үзе ашата-эчертә торган булган.

Мал җыю, байлык туплау дигән нәрсә аның өчен ят була, артык малын ул юксылларга өләшеп бетерә, вафатыннан соң хәтта бер киеме закладта булган дип сөйлиләр.

Әл-Газәли яза: "Пәйгамбәр әйткән: Өч нәрсәдән—шикчеллектән, сүи заннан (кеше турында начар уйлаудан, явызлык уйлаудан) һәм көнләшүдән берәү дә котыла алмый.Ләкин мин сезне алардан ничек арынырга икәнен аңлатыйм: әгәр шикләнәсең икән—төпченмә, әгәр уеңа явызлык килсә—ераграк кит, әгәр көнлисең икән—кызыкма."

Рәсүлулланың шигырьне хурлау сүзләре генә түгел, мәдех кылган, ягъни мактаган сүзләре дә бар. Мәсәлән, "Бакый сәгадәт" касыйдәсен укыган вакытта Рәсүлулла мәҗлестә булганнарга "Тынлагыз" дип боерган. Аның шагыйрь Кәгаб ибн Зохаергә Пәйгамбәр хөрмәтенә чыгарган мәдхиясе өчен ябынча—"бурда" бүләк иткәнлеге мәгълүм. Бу ябынча Исламның кадерле ядкярләреннән берсе хисаплана.

Коръәндә музыка коралында уйнау һәм аны тынлау хәрам булу хакында ачык бәян ителгән сүз юк. Рәсүлулла хәзрәтләренең гает көннәрендә, туй вакытларында уен уйнаудан тыймаганлыгы билгеле.

Хәдисләрдә "аның сабырлыгы вә ныклыгы һәркемгә үрнәк булды" диелә.Мөхәммәд галәйһиссәлам бик бирелеп гыйбадәт кыла торган булган, хәтта озак рәкәгатьләре сәбәпле аяклары шешенгән булуы турында хәбәрләр бар. Пәйгамбәр төнлә белән намаз укырга тору, ә рамазан аенда ураза тоту җиңелрәк булсын өчен көндез төш вакытында йоклап алырга киңәш иткән:"Төш вакытында йоклап алыгыз, чөнки көндезләрен шайтан гына йокламый", —дигән.

Рәсүлулла Мәдинәдә 9 мәртәбә Рамазан рузәсе үткәргән дип хисап кылына.

"Сәхих Мөслим" мәҗмугасы Пәйгамбәрнең үз анасының каберенә зиярәт кылганда бик тәэсирләнеп елаганлыгы турында хәбәр итә. Рәсүлулла зиярәт кылуны хатыннар өчен дә дөрес гамәл дип санаган һәм каберләргә баргач укыр өчен хәзрәти Гайшәгә дога өйрәткән.

Әнәс бин Малик: "Аллаһыдан берәр нәрсә сорап ялварганда Пәйгамбәр (с.г.в.—салаллаһу галәйһивәссәлам, ягъни "Аңа Алланың хәер догасы һәм сәламләве булсын!") беркайчан да кулларын югары күтәрми иде, мәгәр яңгыр теләп ялварганда гына кулларын күтәрер, хәтта култык астындагы ак җирләре күренер иде,"—дип сөйләгән.

Әнәс бин Малик: "Бервакыт Пәйгамбәр (с.г.в. ) мәчеткә кергәч, ике багана арасына сузылган бауны күргән дә:"Бу бау нигә кирәк?—дип сораган.Мәчеттәгеләр:"Аны Зәйнәб бәйләп куйды, басып тора-тора аргач, ул шуна ябыша, "—дигәннәр". Пәйгамбәр (с.г.в. ): "Болай эшләмәгез, бауны чишеп алыгыз, һәркайсыгыз хәленнән килгәнчә гыйбадәт кылсын, арый башлагач—утырсын!"—дигән." (Хәдис. )

Мөхәммәд пәйгамбәр: "Әгәр дә берәү исерткеч эчемлек эчсә, анардан иман нуры качар,"—дигән. Исламның хәмер эчүгә мөнәсәбәте турында сөйләгәндә шушыннан да саллырак сүз табылмас.Билгеле булганча, Һиҗрәттән соң өченче елда (Өхөд сугышы булган ел) мөселманнарга хәмер эчү хәрам исәпләнә башлый.

Кайбер чыганакларга караганда, Пәйгамбәр унбер хәләл җефет белән никахлашып, шуларның тугызы вафатыннан соң да исән булган.Татарча "Тәфсир Ногмани"да "Әхзаб" сүрәсенең (33) 52 нче аятендә: "И Мөхәммәд г-м, ошбу тугыз хатыннан соң хатын алмак сиңа хәләл түгел, һәм бер хатыныңны талак итеп аның урынына икенче хатын алмак та сиңа хәләл түгелдер, гәрчә ул икенче хатын чибәрлеге белән сине сокландырса да, мәгәр кулыңда үз тәрбияңдә булган кәнизәк хатын сиңа хәләлдер.Аллаһ һәрнәрсәне күзәтеп саклаучы булды",— диелә. Коръәннең үзендә бернинди сан да атап күрсәтелмәгән.

Хәзрәти Хәдичәнең вафатыннан соң, Госман бине Мәзгунянең хатыны Хәүлә Мөхәммәд галәйһиссәламнең өен карап җыештырып йөргән. Ниһаять, ул Мөхәммәд Пәйгамбәрне өйләнергә күндереп, аңа Сәүда исемле бер тол хатынны һәм сигез яшьләрдәге Гайшәне яучылаган.

Пәйгамбәрнең яраткан хатыны Гайшә (Рәсүлулланың сәхабәсе Әбү Бәкернең кызы) аның васыятьләрен саклаучы һәм аңлатучы буларак сәясәттә дә катнашкан. Никахлашканда Гайшәгә сигез яшь була. Дөрес, бу никахка каршылык та килеп туган, чөнки Гайшә Моттгыйм бине Гуданың улы белән ярәштереп куелган була. Ләкин Моттгыйм кяфер булган һәм Әбү Бәкернең иманга димләвенә каршы торган, шунлыктан аларның Гайшәне бирү турындагы килешүе таркала. Пәйгамбәр хатыны булырлык дәрәҗәдә гыйлем бирергә теләп, Гайшәне укырга-язарга өйрәткәннәр. Аның белән ярәшкәннән соң Пәйгамбәр, тормыш уңайлыкларын күздә тотып, Сәүда белән никахлаша. Соңрак ул аны аерып җибәрмәкче дә була, әмма шул көннәрдә Пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә ирешеп, аңа Аллаһының: "Сәүда синең хатының булсын!" дигән әмерен житкерә.Пәйгамбәрнең Һиндә исемле хатынының үлгән иреннән Салма атлы улы булганлыгы мәгълүм. Ә Зәйнәб исемле хатынына Пәйгамбәр үзенең тәрбиягә алган улы Зәед аны талак кылганннан соң өйләнә (бу хакта "Әхзаб" сүрәсенең 37 нче аятен карагыз). Сугышта әсир төшкән Сафия исемле хатын исә (Сафия бинт Хөйя) әле беренче ире исән чакта ук төшендә кояшның күктән төшеп үзенең корсагына кереп югалуын күргән булып чыга. Ире үлемгә хөкем ителгәч, Сафия Пәйгамбәр белән никахлаша һәм аның вафатыннан соң тол килеш кырык ел яши. Риваятьләргә караганда, Сафияне йәһүдә дип атаганнар һәм "Бүлмәләр" сүрәсенең (49) 11 нче аятендә бер-береңне кимсетү һәм кушым исем тагуны тыйганда Сафия күздә тотыла.Хәндак янындагы сугыштан соң, Мәдинәдәге соңгы йәһүд кабиләсе дә, дошманга сатылганы өчен, аяусыз рәвештә кырып бетерелә, хатын-кызлар һәм балалары бәдәви гарәпләргә коллыкка сатыла, ә чибәр Рәйханәне Мөхәммәд пәйгамбәр үзенә хатынлыкка алып коткарып кала. Рәсүлуллаһның кайбер никахлары ачыктан-ачык сәяси максатларны күздә тоткан.Мәсәлән,Өмми-Хәбибә исемле бер тол хатынга ул аның әтисе Әбү-Суфиян белән үзара дошманлыкка чик кую нияте белән өйләнә.Пәйгамбәрнең унсигез яшьлек тол Хафизага (Гомәрнең кызы) өйләнүе дә аның тарафдарларын арттыру максатына хезмәт иткән.Гайшәдән кала, Хафиза Пәйгамбәрнең иң яраткан җефете булган.Аллаһы тәгаләдән ингән яңа вәхи язмалары саклый торган сандыгын Мөхәммәд Пәйгамбәр Хафизага ышанып тапшыра. Коръән Кәримнең Госман редакциясе дә Хафизада сакланган китап буенча эшләнгән. Чыганакларга караганда, Маймүнә исемле илле бер яшьлек тол хатынга да Мөхәммәд Пәйгамбәр сәяси сәбәпләр аркасында өйләнгән.Маймүнә Пәйгамбәрнең башка хатыннары үлеп беткәнче яшәгән дип сөйлиләр. Мария исемле җариясе Мөхәммәд пәйгамбәрдән угыл таба, аңа Ибраһим исеме кушалар, тик бала озак яшәми.

“Хатыннар” сүрәсенең 3 нче аятендә:”Үзегезнең күңелегез тарткан хатыннар белән—ике булсын, өч булсын, дүрт булсын—никахланыгыз. Ә инде гадел булмам дип куркасыз икән, берсе белән никахланыгыз”,—диелгән. Ягъни Аллаһыдан инеп, Рәсүл тарафыннан игълям ителгән Коръән күп хатын алуны тыймый һәм дүрт хатын белән никахлашу мөмкинлеге асылда Ислам таралган заманда ирләр һәм хатын-кызлар саны арасындагы диспропорциядән, кануни һәм нәшәргый (шәригатьне бозып, зинадан туган) балалар булу аркасында килеп туган проблемалардан котылуны,ирнең хатынына хыянәт итү ихтималын кисәтүне—ахыргы исәптә гаиләдәге гаделлекне һәм иминлекне күздә тота. Бу чикләүне Мөхәммәд пәйгамбәр миляди 625 елда керткән дип исәпләнелә.

Никахны дүрт хатын белән чикләү таләбе мөселман дөньясында катгый үтәлеп килгән. Бу шартны Пәйгамбәр нәселеннән булган идарәчеләр дә үзгәртә алмаганнар. Мәсәлән, Пәйгамбәрнең өлкән оныгы, игезәкләрнең берсе—Хәсән Мәдинә шәһәрендә сафа сөрүе белән билгеле. Шәригать рөхсәт иткән дүрт хатынының әле берсен, әле икенчесен алмаш-тилмәш талак кылып, ягъни “хәйләи шәргый” дип атала торган алдау юлына басып, йөздән артык яна хатыннар белән никахка кергәне өчен, ана Митлак (“Талак кылучы”) дигән кушамат та такканнар. Ләкин хәтта шушындый йөгәнсезлеге дә аның абруен төшерә алмаган кебек. Шулай да хатын-кызга, аналарга мөнәсәбәттә Пәйгамбәрнең сәясәтенә хас булган тигезлек, гаделлек һәм ихтирам принцибының анардан соңгы хакимнәр арасында бик тиз йомшарганын күрмичә калу мөмкин түгел. Ләкин монысы инде кеше табигатендәге гомуми кимчелекләрдән килә һәм Ислам нәкъ менә шулардан котылуны, үзеннең “кан тамырларында булган” Иблис-ләгыйнь коткысыннан арынып камиллеккә ирешүне күздә тота да. Бүгенге ислам никах мәсьәләсенә, әлбәттә, башкачарак карый. Йәмән халык җөмһүриятендә, мәсәлән, никахта фәкать ике хатын белән генә торырга рөхсәт ителә, ә Туниста полигамия бөтенләй тыелган. Хәзерге вакытта Иракта да күп никахлылык сирәк очрый. Кияү белән кәләш арасындагы яшь аермасы да кими.

Пәйгамбәр Мәчете янында һәр хатыны өчен аерым йорт төзетә һәм нәүбәт буенча аларның һәркайсы янында була. Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәләл җефетләре хиҗаб, ягъни пәрәнҗә киеп йөриләр, соныннан бу барлык иреклe мөслимәләр өчен мәҗбүри булып китә.

Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгында Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны Гайшә бүлмәсендә намаз укыганда тәрәзәдәге пәрдәгә кош сурәте төшерелгән булуын күреп, бу пәрдәне алып куярга кушканлыгы турында сөйләнә. Гайшә пәрдәне ала да, анардан түгәрәк мендәр тышы тегә. Мөхәммәд Пәйгамбәр сурәтле мендәр тышына каршы килмәгән.

Төрек галиме Мәхмүт Шөкрү Сөзер моны түбәндәгечә аңлата:“Мөселман өчен иң мөһиме—гыйбадәт кылган вакытта күз алдында җан ияләренең сурәте тормавы,”—ди ул.

Хәзрәти Гайшә Рәсүлулланың никахындагылардан башка хатыннарга куллары белән кагылмаганлыгын сөйли.

Гайшә:”Чирләп киткәч Рәсүлуллаһ бик авыр чакларында:”Мин бүген кайда? Иртәгә кайда булам?”—дип сорый һәм нәүбәт буенча минем көнем җиткәнне түземсезлек белән көтә иде. Минем көнем җиткәч, ул кулларымда җан бирде һәм өемдә җирләнде, ”—дип сөйли.

Җаһилият чорында гарәпләрдә яңа туган кыз баланы, әгәр ата-анасы аны товар сыйфатында тәрбияләп үстерергә теләмәсә, тере килеш җиргә күмү гадәте булган. Мөхәммәд пәйгамбәр мондый вәхшилеккә каршы көрәшкән (бу “Тәквир” сүрәсенең 8, 9 нчы аятьләре белән раслана).

Түбәндәге аятьләр Пәйгамбәр гаиләсендә хөкем сөргән низам һәм тәртип турында мәгълүмат бирәләр (“Коръән тәфсире” буенча).

“Әхзаб” сүрәсе, 28 нче аять: “Мөхәммәд галәйһиссәламнең хатыннары яхшы киемнәр һәм яхшы зиннәтләр таләп иттеләр. Шул чакта Аллаһ әйтте: ”И пәйгамбәр,хатыннарына әйт, әгәр сез дөнья байлыгын вә аның зиннәтен теләсәгез, килегез, мин сезгә сез сораган дөнья нәрсәләрен бирермен, вә һич зарар тимичә яхшылык белән талак итәрмен,”—дип.

Шул ук сүрәдән 30 нчы аять:”И пәйгамбәр хатыннары, әгәр сезләрдән

берегез фәхешлек кылса яки пәйгамбәргә итагать итмәсә, ул хатынга башка хатыннарга булачак газапның ике өлеше тияр, бу—Аллаһуга бик җиңел."

32 һәм 33 нче аятьләр дә шул турыда.

"И пәйгамбәр хатыннары, сез башка хатыннар кеби түгелсез, әгәр гөнаһлардан саклансагыз, ят ирләргә җавап биргәндә тавышларыгызны йомшартып сөйләмәгез, чөнки йомшак тавыш белән сөйләсәгез, күңелләрендә шәһвәт яки яманлык чире булган ирләр сездән өметләнерләр, вә аларга тавышыгызны нечкәртмичә яхшы сүз әйтегез. "

"Вә өйләрегездә торыгыз, вә җаһилия заманындагы хатыннар кеби бизәкләнгән зиннәтләрегезне ят ирләргә күрсәтмәгез, намазларыгызны укыгыз, зәкятләрегезне бирегез, вә Аллаһуга вә Аның рәсүленә итәгатя итегез, и сез, рәсүл галәйһиссәламнең өй әһелләре, Аллаһ сездән гөнаһларны күтәрүне вә сезне кимчелекләрдән пакъләүне телидер. "

Бу аятьләргә заманында Александр Пушкин да игътибар иткән һәм үзенең Коръәнгә ияреп язылган шигырьләрендә аларның эчтәлеген бирергә тырышкан.

Пәйгамбәр икеләтә бүләкләнәчәк кешеләр хисабына җариясенә белем бирүче, аны иреккә җибәрүче һәм аңа өйләнүче мөселманны да кертә. Монда аның кәнизәге Мария күздә тотылган дип уйлау табигый.

Кәй-Кавус үзенең "Кабуснамә" китабында Пәйгамбәрнең хатыны хәзрәти Гайшә өендәге бер карчыкның Рәсүлдән:"И Рәсүлуллаһ, минем йөзем җәннәттә торучыларныкымы, әллә тәмугта булучыларныкымы?"—дип соравы турында яза. Пәйгамбәр исә шаяртып: "Ул дөньяда җәннәттә бер генә карчык та булмас, "—дип җавап биргән. Карчык кайгысыннан җылап ук җибәргән.Шунда Рәсүлулла елмаеп болай дигән:"Җылама, минем сүзем синең теләгеңә каршы килми бит. Мин җәннәттә карт-коры булмас дип дөресен әйттем, чөнки кыямәт көнендә адәмнәр каберләреннән яшь килеш кубарылып торырлар." Моны ишеткәч карчык тәмам тынычланган.

Хатын-кызларга вәгазь уку өчен Пәйгамбәр аерым көнен билгеләгән.

Рамазан аенда Рәсүлуллаһ гыйбадәттә булган һәм айның соңгы ун көнендә Аллаһыны зикер итүдә аеруча тырышлык күрсәткән. Ул төн буе йокламаган, гаиләсе дә төнне гыйбадәт кылып үткәрә торган булган. Бу хакта хәзрәти Гайшә түбәндәгечә сөйли:"Рамазанның соңгы ун көнендә Рәсүлуллаһ (с.г.в.) ыштанын ныклап буып куя иде, төн буе йокламас иде вә гыйбадәт кылу өчен гаиләсен уята иде". Бу сүзләрдән Пәйгамбәр ул көннәрдә хатыннары белән якынлык кылудан тыелган дип аңларга кирәк.

Бервакыт Гайшә барында ир-атлар намазга нәрсә комачау итүе турында сүз куерта башлап: "Намазны эт, ишәк вә хатын-кыз бозарга мөмкин,"—диешкәннәр. Моны ишеткәч, Гайшә болай дигән: "Сез безне эт белән тиңлисез, ә Пәйгамбәр (с.г.в.) мин аның каршында ятып торганда да намаз укый иде, һәм әгәр хаҗәт туып мин аның катында кала алмасам, әкрен генә торып чыгып китә идем." (Хәдис. )

"Әхзаб" сүрәсенең 53 нче аяте Пәйгамбәр өенә килүчеләргә кагыла (И. Ю. Крачковский бу аять Зәйнәбнең икенче туенда озаклап утырган кунакларга нисбәтле дип уйлый): "И мөэминнәр, Пәйгамбәр галәйһиссәлам өйләренә аш мәҗлесенә барганда ашның өлгергәнен көтеп тормыйча рөхсәтсез кермәгез, мәгәр керегез дип дәшкәндә генә керегез, ашау-эчү тәмам булгач китегез, бер-берегезнең хәлләрен сорашып озак вакыт утырмагыз, сезнең шулай озак утыруыгыз Пәйгамбәрне борчыйдыр, ул сезгә инде кайтыгыз дип әйтергә сездән оялалыр, әмма Аллаһ хакны әйтергә оялмыйдыр. Әгәр Пәйгамбәр хатыннарыннан бер-бер нәрсә сорасагыз, пәрдә аркылы сөйләшегез, әнә шулай сөйләшүегез сезнең күңелләрегезгә дә, аларның күңелләренә дә пакълектер. Вә сезгә лаек булмады Пәйгамбәрне бернәрсә белән рәнҗетмәк, дәхи Пәйгамбәрнең хатыннары үзеннән соң сезгә мәңге хәләл булмады. Тәхкыйк Пәйгамбәрне рәнҗетү, вә аның хатыннарына никахлану Аллаһ хозурында сезгә бик олугъ гөнаһ эш булды. "Александр Пушкинның игътибарын бу аять тә җәлеп иткән.

Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими үзенең "Тәварихы Болгария" дигән китабында: "Пәйгамбәребез, хода аңа рәхмәт кылсын, Габдеррахман бине Зөбәер, Тальха бине Госман һәм Зөбәер бине Җәгъдә дигән өч сәхабәне Болгарга җибәрде,"—дип яза. Зөбәер бине Җәгъдә Айдар хан кызы Туйбикәне паралич авыруыннан терелтеп, соңыннан аңа өйләнгән һәм Болгарда торып калган, шунда

25 ел яшәп вафат булган, имеш. Ләкин бу хәбәрләр ышанычлы чыганаклар белән расланмый. Шулай да Шиһабетдин Мәрҗани Болгарга дингә өндәү өчен табиб сурәтендә гарәп илчеләре килгәнлеккә дәлил булырлык Беркадәр риваятьләр бар дип саный. Алардан анлашылганча, Мөхәммәд пәйгамбәр янында төрки телен белүче кеше булган һәм ул ниндидер бер халыкка төрки телендә хат язган. "Ул заманда гарәп, Шам илләрендә, Рум мәмләкәтләрендә төрки телендә сөйләшә торган халык юк иде,—дип дәвам итә Ш. Мәрҗани.—Кытайга чаклы бик күп мәмләкәтләр, күп тоткарлыклар, озын юллар булу сәбәпле, бу хатның аларга да язылмыйча,бәлки якындагы, бер-берсе белән аралашып йөргән Болгар һәм Хәзәр халкына язылган булуы ихтимал... Аларның (гарәпләрнең—*А. Т.*) бу өлкәдә көмеш ятмасы табып, зур бер елганы һәм мәгълүм бер өлкәне гарәп телендә "Нократ елгасы" һәм ул өлкә халкын "Нократ болгарлары" дип атаган булулары шуны күрсәтә... Шуңа күрә дә Болгар халкы телендә бик күп гарәп сүзләре табыла... Аларга гарәп теле керүе сәүдә эше аркасында аралашу нәтиҗәсендә булмаска кирәк. Алай булса, фарсы теле дә шулай ук нык кереп урнашкан булыр иде. Дөрес, фарсы сүзләре дә кергән, ләкин алар бик аз."

Боларга өстәп тагын түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. "Пәйгамбәр" сүзе чуваш һәм мари телләренә дә кергән, дөрес,ул аларда мәҗүси мәгънәләргә тарта: чуваш телендә—илаһ, бүреләр иясе; мари телендә—илаһ, пәйгамбәр, ярдәмче. Тагы шунысы игътибарны җәлеп итә: чувашлар үзләрен "көмеш болгарлар" дип атыйлар. Хәер, бу күркәм атаманың соңгы чорларда, чувашларны Идел буе болгарларының бердәнбер варислары дип игълан иткән "болгар-чуваш теориясе" туып, гади халык аңында шуны ныгыту өчен генә әйләнешкә кертелгән булуы да ихтимал. Әгәр чувашлар, гарәпләргә ияреп, үзләрен электән үк "көмеш болгарлар" дип атый башлаган булсалар, шөбһәсез, Ислам динен дә кабул иткән булырлар иде. Ә бәлки мәсьәлә катлаулырактыр да, монысы миңа караңгы.

Татарстандагы Иске Салман авылы оешуы турындагы риваятьтә түбәндәгеләр сөйләнә. Мөхәммәд пәйгамбәр исән чагында Мәккә шәһәреннән бер зур галим кеше Идел буена дин өйрәтергә җибәрелгән икән. Сөләйман атлы бу кешене, галим булганга күрә, Сөләйман Хуҗа дип йөрткәннәр.

Шәһри Болгар ханы Хуҗаны үзенең сараенда тотып, соңыннан илне агартыр өчен, хәзерге Салман авылы якларына җибәргән. Сөләйман Хуҗа бу төбәктә зур мәдрәсә ачып, белемле муллалар укытып чыгарган. Сөләйман Хуҗа Болгар илен бик яраткан, шуның өчен кире Мәккәгә кайтып китмәгән.Сөләйман Хуҗа әйтә торган булган:"Шәһри Болгар җире бик бәрәкәтле җир, ул җиргә ислам кылыч көче белән таралмаган. Болгар илендәге халык ислам динен үзе теләп кабул иткән, шуның өчен җомга намазында хотбәләр агач таяк тотып кына укыла", —дип.

Менә шушы Сөләйман Хуҗа—Иске Салман авылының беренче карты вә изге бабасы. Халык аны Салман бабай дип йөрткән. Аннары авыл һәм елга исеме дә Салман дип атала башлаган...

Татар мөнәҗәтләрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын тасвирлауга багышланганнары шактый. "Әминә ханым—Мөхәммәд анасы" исемле мөнәҗәттә Пәйгамбәр туар алдыннан хәзрәти Әминә бар җиһанның нурга күмелүен, өй тирәли фәрештәләрнең Кәгъбәне тәваф кылган кебек әйләнеп йөрүләрен күргән дип сөйләнә.

Халык риваятенә караганда, Мөхәммәд пәйгамбәрнең гәүдәсе җәннәттәге Тәсним чишмәсе суында чылатылган җәннәт туфрагыннан яратыла.

"Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхия" дигән татар мөнәҗәте салават әйтү рәвешендә күмәк башкарылган:

Йә, Мөхәммәд Мостафа,
Атаң-анаң вафаты
Сәне ятим калдырды.
Сәне Аллаһ үстерде,
Йә, Мөхәммәд Мостафа!

Мөнәҗәтләрдә Рәсүлулланың кешелеклелегенә дан җырлана. "Мөхәммәд пәйгамбәрнең ятим баланы җәлләве" дигән мөнәҗәттә мондый юллар бар:

Бисмиллаһир рәхманир рәхим!

Рәсүлулла ятим үзе,
ятимнәрдә ике күзе.
Әгәр күрсә ятимнәрне,
барып сөяр иде үзе.
Васыятьләрем өммәтемә—
ятимнәрне күрсәгез гәр,
Минем кебек тәбрикләп ки
хәлен белегез сезләр.

XV—XVI гасырларда яшәгән татар шагыйре Әхмәтбиккә нисбәт ителә торган бәеттә Пәйгамбәрнең һәр җан иясенә гуманлы мөнәсәбәте сурәтләнә.Кяфер сунарчылар бер газәлне тотып алалар, шунда Пәйгамбәр алардан газәлне бәтиләрен имезергә җибәрүләрен сорый һәм үзе тотык сыйфатында кяферләр кулында калырга риза була. Кяферләр газәлне иреккә җибәрәләр, ә үзләре Пәйгамбәрне һәлак итәргә чамалыйлар, газәл кайтып килер дип ышанмыйлар. Газәл чыннан да соңара, чөнки кире кайтканда тозакка эләккән була. Кяферләр Пәйгамбәргә соңгы тапкыр гыйбадәт кылырга рөхсәт итәләр... Шул чагында Аллаһы аңа ярдәмгә Җәбраил фәрештәне индерә. Моны күргәч, кяферләр шәһадәт китерәләр, ун мең йәһүд мөселманлыкка чыга.

Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның дүрт сәхабәсе турында татарда табышмак та чыгарганнар:

Бар икән, ди, дөньяда бер байтирәк,
Гәүһәрдән дүрт ботагы аңа терәк,
Табышмагым уйла да тап, уйна да тап,
Моны тапкан кешенең акылы зирәк.

Нурулла Мөфлихун Арыслани хәзрәт ("Тәфсир Ногмани"ның яңа басмасын әзерләгән зат) "Пәйгамбәргә иман" дигән самими шигырендә:

Кяфирләрдән курыкмады, өркеп
Бер карыш та артка чигенмәде.
Аллаһы юлында хаклык өчен
Көрәшүдән һич тә зирекмәде,—

дип яза.

Хак мөселманның күңелендә һәрчак Мөхәммәд пәйгамбәр булыр. Төрек шагыйре Юныс Әмрә үзенең бер шигырендә болай ди:

Эзли-эзли тапсам эзеңне,
Эзең тузанына куйсам йөземне,
Ходай насыйп әйләп, күрсәм үзеңне!
И Мөхәммәд! Күңелем шундый ашкына сиңа.

(Бикә Рәхимова тәрҗемәсендә.)

Билгеле булганча, Солтан Сәлим ибн Баязит заманында гарәп җирләре төрекләр кулына төшә. Ул вакытларда Мисыр хәлифәсендә Пәйгамбәрнең таягы, мисвәге (теш чистарткычы),башмагы, чәч һәм сакал бөртекләре әманәт булып сакланган була.Җиңүче төрекләр Пәйгамбәрнең бу мирасын ганимәт маллары сыйфатында Истанбулга алып кайтканнар һәм, көмеш сандыкларга салып, Солтан мәчетенең хәзинәләр бүлегенә куйганнар. Аларны тик Мәүлид бәйрәмендә генә халыкка күрсәтәләр. Бу истәлекләр "Мәэван Мөбәрак"дип йөртелә.

Төркия солтаны Габделхәмид II Рәсүлулланың төкләре балавызга утыртып катырылган һәм эче ефәктән, тышы фил сөягеннән гыйбарәт сандыктагы истәлекле бүләкне 1893 елда хаҗ сәфәре вакытында Истанбулга килгән мөфти хәзрәтләре Мөхәммәдьяр Солтанга Русия мөселманнарына дип тапшырырга боера. Бу тарихи ядкяр утта янмый торган сандыкка салына һәм бүгенге көнгәчә саклана. Мәүлид кичәсендә ул мөселманнарга күрсәтелә, салаватлар укыла.

Европа мәдәниятында Мөхәммәд пәйгамбәрне башта мәкерле булуда, аяусызлыкта, бәдәни ләззәтләргә бирелүдә гаепләргә тырышып карыйлар. Мәгърифәтчеләр исә аны шәхси рәхәтләр хакына динне файдаланучы алдакчы дип күрсәтергә тырышканнар.Аның хакында төрле әкияти риваятьләр таралган. Мәсәлән,

имештер, Мөхәммәднең табуты һавада эленеп тора икән дип сөйләгәннәр. Шул ук вакытта тамплиерлар (тәре яулары чорында католик рухани-рыцарь ордены әгъзалары—әһле салиблар, тәре йөртүчеләр) яшерен рәвештә Мөхәммәд пәйгамбәргә табынганнар.

Мөхәммәд пәйгамбәр укый-яза белмәгән дигән сүзләрне дә ишетергә һәм укырга туры килә (мәсәлән, Мәҗит Гафури Рәсүлулла турында:"Уку-язу өйрәнмәде,"—дип яза.) Гарәп галимнәре фикеренчә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Бәһрәйн әмире Мөнзир бин Сәүигә үз кулы белән язган хаты исән. Бу хатында Пәйгамбәр әмирне Ислам динен кабул итәргә өнди. Хатның күчермәсе Багъдадта чыга торган "Сумер" журналының 1974 елгы беренче санында басылган.

Гете үзенең "Көнбатыш-көнчыгыш диваны" дигән китабында Мөхәммәд пәйгамбәр турында: "(Мөхәммәд)... үзенең шагыйрь түгеллеген, бәлки пәйгамбәр икәнлеген һәм аның Коръәнен ләззәт алу өчен билгеләнгән адәми китап итеп түгел, бәлки илаһи канун итеп карарга тиешлеген кат-кат тәкърарлый, "—дип яза.

Бернард Шоу Мөхәммәд Пәйгамбәр турында мондый сүзләр әйткән:"Аны Кешелекне коткаручы дип атарга мөмкин. Әгәр аның кебек кеше хәзерге дөнья белән идарә итүне үз өстенә алса, дөнья алдында торган проблемаларны хәл итүдә уңышка ирешәчәгенә ышанам мин."

Ахырда сүзне "Британика" энциклопедиясенә бирик: "...беренчел чыганаклардагы аерым детальләр аның гадел һәм туры кеше булганлыгын, шундый ук гадел һәм туры кешеләрнең ихтирамын һәм ышанычын казанганлыгын раслыйлар,"—ди бу абруйлы белешмә.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлындагы вакыйгалар һәм фактларның җентекле хронологиясе Әбү-р-Рәйхан әл-Бирунинең "Кичкән буыннар ядкярләре"ндә китерелә.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең эпитеты—Иң соңгы пәйгамбәр (Хатәмен-нәбийин—"Пәйгамбәрләр мөһере", ягъни иң соңгы, тәмамлаучы пәйгамбәр).Безнең Әхмәдһади Максуди: "Мөхәммәд галәйһиссәлам ахырзаман пәйгамбәредер.Анардан соң дөньяга һич пәйгамбәр киләчәк түгелдер,"—дип яза.Мөхәммәд пәйгамбәр җир йөзенә элгәрге пәйгамбәрләр китергән вәхиләрне янә бер кат раслау һәм китап (Тәүрат, Зәбур, Инҗил) әһелләре, ягъни насранилар (христианнар) һәм йәһүдиләр тарафыннан бозылган илаһи текстларны һәм васыятьләрне төзәтү өчен җибәрелгән.

Җәбир ибн Габдулла сөйләвенә караганда, Пәйгамбәр үзе турында:"Элек һәр пәйгамбәр үз халкына җибәрелгән булса, мин барлык кешеләргә җибәрелдем,"—дигән.

Тагын бер мөһим нәрсәгә игътибар юнәлтмичә мөмкин түгел. Кайчагында дини матбугатта аерым авторлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең гади кеше түгеллегенә басым ясарга тырышалар, аны беренче чиратта кешелек вәкиле итеп күрүчеләрне Пәйгамбәргә ихтирамнары җитмәүдә гаепләргә телиләр. Юк, Мөхәммәд башкалар кебек үк кеше. Ул Аллаһының колы һәм Аның илчесе.Коръән Кәримдә болай диелә: "Әйт: "Мин сезнең кебек бер инсанмын, миңа Аллаһыдан вәхи булды, сезнең Илаһыгыз—барча вөҗүдкә бер генә Аллаһы дип. Әгәр берәү Раббысына яхшы хәлдә юлыкмакны теләсә, ул кеше яхшы эшләрне эшләсен, изге гамәлләрне кылсын, әмма Раббысына тиешле булган гыйбадәтенә һичкемне шәрик-тиңдәш кылмасын" ("Тау тишеге" сүрәсе: 110, "Коръән тәфсире" буенча). Рәсүлебез бу васыятьне һәрдаим һәм һәрнәрсәдә саклаган, тыйнак кеше булып калган, үзен кешеләрдән өстен күрергә рөхсәт итмәгән, шәхес культы, ягъни шәхесләргә табыну дигән нәрсә аның өчен ят булган. Имам Бохаридан килгән бер хәдистә Пәйгамбәр моны ачыктан-ачык әйтә: "Мине һич мактамагыз, нәсранилар Мәрьям углын мактагандай булмасын, чөнки дөреслектә мин бәндәмен, әйтегез: "Аллаһының колы һәм илчесе дип."

Пәйгамбәрнең түбәндәге сүзләре дә аның гадәттән тыш тыйнак кеше булуы турында сөйли: "Аллаһы тәгаләнең ахирәттә үз хакымда нинди мөгамәлә кылачагын белә алмыйм, мин башкалар кабиленнән адәм баласымын, аермам исә бары Алланың әмерләрен халыкларга ирештерү ноктасында гына булып, гаепләрне белергә кодрәтем юк,"—дигән ул.

*Әнвәр Давыдовның туууына 80 ел*

# АНЫҢ ШИГЪРИЯТЕ ОЗАК БАЛКЫР ӘЛЕ

*Йөрәге барның дәрте бар.*

Татар халык мәкале.

Әнвәр абый Давыдовның тыныч кына сөйләшкәнен һич хәтерләмим. Әңгәмәбез нәрсәдән генә башланмасын, әлбәттә, шигърияткә барып тоташа торган иде. Ә инде шигъри әсәрләрне Давыдов тыныч кына, салкын кан белән генә укый да, тыңлый да, яза да алмый иде. Миңа калса, ул һич тә "соцзаказ" дигән нәрсәне кабул итмәде, фәкать үзен борчыган яки дулкынландырган, көендергән яки сөендергән берәр вакыйга-күренешләрне күңеленә якын ала, шулар аның миенә кереп утыра, һич кенә дә тынгы бирми, көн-төн уйлана торгач, әлбәттә инде, шигъри образлар буларак гәүдәләнә. Шул рәвешле иҗат эше башлана. Ә инде иҗади илһам килгәндә шагыйрь бөтен дөньясын оныта—яшәвенең бөтен мәгънәсе әле яза торган әсәренә сыеп бетәдер шикелле иде.

Әнвәр абый өчен иҗат дигән ләззәтле вә татлы михнәт, язу өстәле янына утырып, авыз эченнән ботка пешереп, мыгырданып-сөйләнеп рифма эзләүдә түгел иде бугай. Өстәл янында шигъри юллар чигеп утыруны ул бик үк өнәп тә бетермәде кебек. Бүлмә эчендә йөренгәндәме, авыл яки шәһәр гизгәндәме, ул өзлексез рәвештә үз әсәрләре тәэсирендә булыр иде.

—Утырасың шулай диванда уйланып-онытылып... Каяндыр әллә кайдан ишетәсен битәрләү: "Син тагын эшләмисең! Үзең, эшем бар, дидең, кибеткә дә чыгып керергә авырыксындың..." Зиһененә тиз генә барып җитми әлеге сүзләр, чөнки һич тә ябышмый ул сүзләр синең уй-фикереңә. Рифмага да ябышмый, ритмга да сыешмый... Аңламагач, аңламыйлар бит халәтеңне. Әйтерсең лә, каләм тотып, өстәл артында утырып кына язып була. Иҗат ул һәммә җирдә иҗат, синең йөрәгеңдә, миеңдә, бөтен табигатеңдә бит ул иҗат,—дип өйдәгеләрдән зарланганы хәтердә Әнвәр абыйның.

Әллә яна берәр әсәр яза башлаганда, әллә инде торгынлыкны күңеле өнәмәгәнгә, кайчан карасаң да эш бүлмәсендәге шкаф-диван, өстәл-урындыкише нәрсәләр элеккеге урыннарыннан күчкән булыр иделәр. Синең гаҗәпләнүеңне күреп, шагыйрь елмая гына:

—Үзгәртергә булдым әле обстановканы. Бәлки, берәр уңай тәэсире булып, яхшырак языла башлар. Яхшырак язарга иде исәп...—диебрәк төшендереп бирер иде.

Университетны тәмамлаганнан соң бер-ике ел гына Сарман урта мәктәбендә укытып кайтып, нәшриятта яшьләр-балалар әдәбиятында эшләгәч, минем инде һәрдаим шәһәр мәктәпләре белән кызыксынуым-аралашуым табигый. Ничектер шулай, сүз иярә сүз чыгып, Әнвәр абыйга заманча бер нәрсә—повестьмы-фәләнме язып ятуымны чиштем дә бер уңайдан мәктәптәге хәлләрнең һәм программаларның әледән-әле үзгәреп торуыннан зарланып алдым. Җавап гаять кыска булды:

—Син бит мәктәп программасы язмыйсыңдыр, син бит кешеләрнең язмышын, аларның характерларын ачып язарга тиешсең.

Танылган шагыйрь үзе минем берәр төрле булышлык күрсәтүемә һич мохтаҗ түгел иде. Нәшриятта эшләп тә, әлләни файдам тимәде. Фәкать ике-өч китабын чыгарыштым да, Муса Җәлилнең каһарманлыгын укучыларыбыз сабый чактан ук белеп үссен өчен, проза әсәре язарга үгетләдем. Сүз тыңлап, башка эшләрен ташлап, "Муса абый" повестен язганына мең рәхмәт!

Без аның белән бер тирәдәрәк яшәгән идек. Урыслар әйтмешли, "весовая

категория"ләребез төрле булса да, аралаша торган идек, гаиләләребез белән йөрешә идек. Бервакыт шулай, Әнвәр абыйның өйдән чыга алмыйча, авырып яткан, тәмам гаҗиз булган чагында сугылдым. Авыруларының күп булуыннан, һич кенә дә сихәтләнә алмавыннан зарланды, еламсырап кына шаяртып алды, бер авырудан дәвалый башласалар—икенчесенә зыян китергәннәрен бәян итте дә, тәрәзәгә төбәлеп, ишегалдындагы кышкы манзарага сокланып, шактый гына уйланып торганнан соң:

—Их, һәйбәтләп атны җигеп аласы иде дә, дилбегәне учлап тотып, менеп басасы иде менә хәзер, мин сиңәйтим, үрәчәле саламлы чанага! Җилдерәсе иде! Һәйт!—дип әйтеп куйды, янәсе бер гайрәтләнеп алды, аннары һич икеләнми-нитми өстәр булды:—Бөтен данын-шөһрәтен бирер идем, мә, алыгыз дип, шул тазалыкны, сәламәтлекне әгәр кайтарып булса.

Алексей Толстойның язмаларында: таза-сау хәлеңдә өстәл янында язып-сызып утыруың дан түгел, менә син авыру чагыңда, чиреңне җиңеп эшләп кара, шунда булырсың кеше, дигәнрәк фикеренә тап булган идем. Әнвәр абый нәкъ әнә шундый кеше булды. Гәрчә саулыгын кире кайтарырга талпынып берни майтара алмаса да, гәрчә тешен кысып яшәүгә дучар ителсә дә, гәрчә үз хәлен үзе генә белсә дә—иҗатны ташламады. Кая ул ташлау! Әледән-әле гүзәл әсәрләр язудан, татар поэзиясен янадан-яңа шигырьләр, яхшыдан-яхшы поэмалар белән баетудан һич туктамады. Әйтик, поэзиябезгә зур яңалык алып килгән "Себер тракты" циклы да, искиткеч йөгерек "Ташу" поэмасы да олуг шагыйрьнең сәламәтлегә бик нык какшагач язылган гүзәл поэзия үрнәкләре иде.


*Әнвәр Давыдов*

"Ташу"ны автор үзе Матбугат йортының Тукай клубында трибунадан кычкырып укыды. Поэманың камиллегенә вә гүзәллегенә, шигъри юлларының, язгы ташу сыман, дәртләнеп агылуына, бер караганда гап-гади, тормышчан, ә инде икенче караганда тоташы белән сихри булуына, шул ук вакытта сине уйландыра да, ышандыра да алуына, авторның дәртләнеп, илаһи бер аһәң белән укуына, мөгаен, бер мин генә хәйран калмаганмындыр. Поэманың бик тә үзенчәлекле, гыйбрәтле вә тормышчан булуы да, гаҗәеп дәрәҗәдә музыкаль яңгыравы да тәмам сихерләде тыңлаучыларны.

Нәкъ шул көннәрдә Әнвәр абый, Хисам Камаловлар белән бергәләп Матбугат йортына якынрак ашханәгә төш вакытында тамак туйдырырга сугылдык. (Ул чагында бик арзан гына ашап чыгып була иде.) Өстәл тирәли утырышкач, мин кургашын кашыкны сөртеп-чистартып азапланган арада, ни күрим, Әнвәр абыебыз ашап та бетерә язган иде инде. Мине шаккатырганы аның кашыгын ялт-йолт йөртүе булмады, сул кулы белән ашавы булды.

—Әнвә-ә-әр абы-ы-ый, сез сулагаймыни?—дип кычкырып җибәргәнемне үзем дә сизми калдым.

Әнвәр абыебыз елмаеп куйды, ашаудан туктамыйча гына:

—Шулайрак шул,—диде.

Икенче соравым тагын да урынсызрак килеп чыкты:

—Нәрсә "Ташу"ны да шулай сул кулыгыз белән яздыгызмы?

—Әллә сизеләме?

Җавап урынына бирелгән әлеге тапкыр сорау шунда минем күземне ачты, шагыйрь белән безнең арада хәйран биек Зирәклек тавы ятканын исбатлады, яшь редакторны рәнҗетмичә генә урынына утыртты.

Гәрчә күбебез, матурлыктамыни хикмәт, ир-ат гомумән матурлык белән дан тотмый, дигән фикерне яклаunion да, үзебез һәрчак ир-атның холкына-фигыленә, талантына-сәләтенә генә түгел, бәлки әле кыяфәте күрекле яисә күрексез булуына да игътибар итәбез. Әнвәр абыйның мөлаем-күркәм кыяфәтен, аристократларга гына хас озын бармаклы нәфис кулларын, мәһабәт гәүдәсен, ашыгу-кабаланууның ни икәнен дә белмичә, салмак адымнар белән саллы гына атлап йөргәнен күреп, бу, һичшиксез,

морзалар нәселеннәндер, дип уйларлык иде. Хәер, аның үтә дә нәзакәтлелегенә хатын-кызлар сокланалар, бигрәк тә гүзәллек дөньясында яшәүче артиска һәм шагыйрә кебек асыл затлар чынлап торып гашыйк булалар, аларны шагыйрь үзе дә әлләни чит итми иде шикелле.

Әмма үзенең хатынын үләр дәрәҗәгә житеп көнләшер иде. Ул аны гомумән эшләтмәде. Нина ханым бичара, кая да булса эшкә урнашып, берәр атна эшләгәч тә, үзенең беркатлылыгы белән, иренең кызыксынуына, игътибарлы булуына, дикъкать биреп тыңлавына алданып, эшендә күргән-белгән хәлләрне түкми-чәчми сөйләп бирә. Әлбәттә инде, бүтәннәрнең гайбәтен дә сата. Аның сайраганын сабыр гына тыңлап утырган, сүз уңаенда сораулар да кыстыргалаган шагыйрьне чыгырыннан чыгарырга шул әңгәмә җитә кала:

—Бетте! Иртәгәдән эшкә бармыйсың!—Мондый ук хәлнең килеп чыгасын башына да китермәгән бичара хатын үзенә эш стажы кирәклеген, әлеге эш урынының бер-ике урам аша гына булуын, барып-кайтып йөрер өчен бигрәк җайлы икәнен исбатларга тырышып, ничек кенә балавыз сыкмасын—барыбер файдасы тими, катгый карар үз көчендә кала.

Ихтимал, нечкә күңелле шагыйрь әнә шул рәвешле гаиләсендәге иминлекне саклагандыр, хатынының көнләшүен күреп, үз күңелендә көнчелек кортын симертергә теләмәгәндер. Ни генә дисәң дә, гаилә аның өчен, Поэзия шикелле үк, изге нәрсә булып кала килде.

Иң зур аянычыбыз шунда булды: әллә мәҗлес эше нәрсәләрдән, гәпләшеп утырудан тәм тапты, әллә шигърияткә сихерләнеп, дөньясын ук онытып җибәргәләде, әллә инде түзеп булмаслык чирләреннән котылу юлын, һич югы онытылып тору чарасын эзләде—Әнвәр абыебыз эчү белән артыграк мавыгып китте, чама дигән нәрсәне бөтенләй онытып җибәргәләде. Шуның нәтиҗәсендә сәламәтлеге елдан-ел ныграк какшады. Йөрәк авыруы үзен аяктан еккач, шифаханәдә хөкем сөргән гаделсезлеккә (табибларның түрәләргә тәлинкә тотуына һәм чынлап торып авыручыларга игътибарсыз булуына) түзеп тора алмыйча, өенә кайта да сихәтләнгәнче беркая да чыкмыйча ята иде.

Аякка басарлык, чыгып йөрерлек хәлгә килгәч, бөтен зирәклеген өйдән чыгып качу әмәленә юнәлдерә. Көннәрдән бер көнне ул китап нәшриятына гонорар алырга барасын өйдәгеләргә хәбәр итә. Хатыны өйдә әле тагын бер атналык мая барын әйтә, янә берәр көн дәваланып ятуны кулайрак күрә. Тик инде Әнвәр абый ниятеннән кире кайта торган кеше түгел. Хатын-кыз күпме генә каршы тора ала соң? Ризалаша Нина ханым, әмма авыру хәлендә үзен генә өйдән чыгарып җибәрәсе килмичә (алган акчасын эчеп бетермәгәе, дип шикләнүе дә булгандыр инде), иренә тагылып юлга чыга. Трамвай белән шәһәрнең үзәгенә килеп җиткәч, китәләр болар Бауман урамы буйлап. Андагы кибетләргә алдана шул Нина ханым, алдана.

—Әйдә, кереп чыгыйк әле кибеткә, Алсуыбызга кирәкле әйбер шушында гына,—дип ишекне ача.

Әмма чүпрәк-чапрак сайлап йөрү һич тә керми шагыйрьнең планына. Юл буе түзеп килгәненә рәхмәт әйтсеннәр. Тавышына хәлсезлек чыгарып, диварга сөялә Әнвәр абый:

—Анда миңа һава җитмәс бит, үзең генә кереп чык, мин бераз ял итеп алам...

Нина ханым дүрт-биш минуттан әйләнеп чыкса, иреннән җилләр искән...

Нәшрияттагы эш бүлмәмнең ишеге тупсасына кадәр ачыла да, бусагамда ах-вах килеп Нина ханым күренә:

—Кыйям, Анвар югалды бит...—дип башлый да аһ-зарын бер-бер артлы тезә.

Хатыны ут йотып кайтып киткәннән соң озак та узмый, телефон чылтырый:

—Килдеме Нина? Шулайдыр дигән идем аны. Ярый, хәзер синең янга барып җитәм. Сәмән кирәк булыр миңа. Каян да булса табарсың әле. Бу арада гонорар-мазар аласым юк...

Әллә гипноз инде, әллә шагыйрь алдында карусызлык, нихәтле генә уңайсызлансам да, аның хәленә кермичә, буш кул белән җибәргәнем булмады бугай.

Ул арада, кесәгә сәмәнне җитез генә салгач, ниятен гамәлгә ашыруына шиге-шөбһәсе инде калмагач, Әнвәр абый көр тавыш белән сөйләп җибәрә:

—Акыл кирәк бит һәр эштә, хәйлә кирәк әнә шул кечкенә генә эштә дә. Нина ишектән кереп китү белән, элдертәм кирегә табан. Карап торам аркалы капка

бушлыгыннан хатынның ах-вах килеп нәшриятка йөгергәнен. Башына да керми бит ул хатын-кызның, артка бордырып алгандыр дип. Шуннан инде минем дүрт ягым кыйбла, китәм ашыкмыйча гына...

Хәтсез күп укый иде Әнвәр абый. Кайчан гына барып керсәң дә, өстәлендә йә кулында син бөтенләй белмәгән, төшенә дә кермәгән шигырь җыентыгы. Шундук үзен хәйран калдырган шигъри юлларны сиңа һәйбәтләп укып та күрсәтә. Аның шулай рухланып укуын күреп-ишетеп, мөгаен, артистың да көнләшер иде.

Әнвәр абый янында, бер генә уку йорты белән канәгатьләнмичә, икешәрне бетергән әдибең яки шагыйрең дә, зур гыйльми дәрәҗәләргә ирешкән агаең да югалып кала торган иде. Чөнки галәмне күзаллау, һәртөрле мәсьәләдә логик һәм аек фикер йөртү ягыннан, философ шагыйрь булу ягыннан Давыдов белән ярышырдай зат, мөгаен, булмагандыр. Образлы яза белү һәм образлы сөйли белү кодрәте һәркемгә дә бирелмәгән шул. Үзебезнең милләт вәкилләрен генә күздә тотып әйтүем түгел, бәлки зур укымышлы урыслар яисә яһүдләр дә аның белән аралашкан чагында телдән язалар, шагыйрьнең авызына карап торырга мәҗбүр булалар иде. Рәсми рәвештә урта мәктәпне яки техникумны тәмамламый торып та, үзенең замандашлары, иҗатияләре арасында иң белемле, иң зыялы, һәркем сокланырлык дәрәҗәдәге уникаль бер шәхес иде.

Татар әдәбиятына Әнвәр Давыдов зур яңалык, гаять үзенчәлекле шигърияте белән килеп керде. Шигърият күгендә шундый якты йолдыз булгач, Әнвәр абыйның илленче-алтмышынчы елларда киң мәйданда бәйге тотуы да, яшь шагыйрьләр өчен остазга әйләнеп китүе дә табигый бер күренеш иде. Яшьләр аның гыйбрәтле сүзләрен бик рәхәтләнеп тыңлыйлар, үзләренең шигырьләрен дә укыйлар, яңа сулышлы шигырьләрдә "беренче скрипкәне уйнаучы" шагыйрьдән мактау сүзе ишетергә өметләнәләр иде. Кордашларым сөйләгән мондый бер вакыйга хәтердә калган.

Яшь шагыйрьләр остазларын шулай бермәл ресторанга алып керәләр. Яхшы гына сыйланалар болар. Шигырь укыйлар. Һәркайсының үз иҗатына карата берәр җылырак сүз ишетәсе килә. Әмма Әнвәр абый акылын җуймый:

—Мине эчертеп кенә һич тә мактау сүзе ишетмәссез, егетләр. Әйе, мина күңелле сезнең белән болай утыру. Ләкин поэзия бөтенләй икенче нәрсә бит ул. Поэзия—изге нәрсә. Һәм сез аны берни белән дә бутамагыз!..—дигән кебегрәк сүзләр әйтә. (Кордашларым, зинһар, үпкәләмәсеннәр: сөйләгәннәре хәтеремә әнә шулайрак уелган).

Давыдов гаилә тормышында яман көнче булса да, иҗат мәсьәләсендә көнләшә белмәде бугай. Берәр шагыйрьнең яңа китабына карата көндәлек матбугатта мәкалә бастырамы, кульязмага эчке рецензия генә язамы, Тукай клубында чыгыш ясыймы, ул гаҗәеп зур дәрт белән язар яки сөйләр иде, үз фикерен һәркемне ышандырырлык итеп дәлилләр иде. Поэзия аның өчен һәрвакыт изге булды: фальшны, ясалмалыкны өнәмәде, каләмдәшләренә һәрчак теләктәшлек күрсәтте, үз иҗатына бигрәк таләпчән булды ул.

Мина калса, иҗат әһелләренә лаеклы бәяне үлгәннән соң илле еллар узгач кына бирәләр кебек. Иҗади уңыштан бигрәк шөһрәткә кызыгучы, үзе исән чакта һәйкәл куйдырттыручыларга да, рәсми тәстә уңышка ирешмәгән талантлы иҗат әһелләренә дә. Моның шулай икәненә ышандырырлык гыйбрәтле хәлләр булып тора.

Әнвәр абыйның вакытсыз дөнья куйганына, иллегә дә җитмәгән килеш арабыздан киткәненә утыз еллап вакыт узды. Авыр туфрагы җиңел булсын! Арабыздан киткән дусларыбыз яки остазларыбызны истән чыгармыйча, аларның иҗатларын,—үз әсәрләребезне ятканга караганда күп тапкырлар ныграк яратып!—укучыларга аңлату, җиткерү—һәркайсыбызның изге бурычы.

Әнвәр Давыдовның шәкертләре—санап бетергесез. Ә бит аларның шактые, бигрәк тә дөньяви дәрәҗәгә ирешкәннәре, остазлары кем икәнне исләреннән үк чыгардылар шикелле. Бик сирәге остазларына тугрылык саклый. Һәм әнә шундый иҗатчылар гына, хәсетлек ише яман чирдән арына алган талантлар гына халык күңеленә үтеп керә алырлар. Үзләренең шәкертләрен булдырып, алар хәтерендә калуга (берәү дә мәңгелек түгел) өмет багларга хаклы һәм әнә шулар гына остазлары дәрәҗәсенә күтәрелү бәхетенә ирешерләр.

Ә инде аларның остазлары Әнвәр Давыдов—шигъриятебез күгендә нурланып балкыган, һәм әле озак яначак якты йолдыз ул.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

# ШАГЫЙРЬ САЛГАН КҮПЕР

*Без аның белән Болак күперендә кара-каршы килеп очраштык.*
*- Юри шулай очраша алмассың. Гаҗәп, гаҗәп!—дидем мин.*
*Әнвәр абый суга бераз карап торды да:*
*- Гаҗәп түгел. Тормыш үзе күпер уртасында бер очрашу,—диде.*

*Шагыйрьнең якташы, иҗатта аның шәкерте*
*Рөстәм Мингалим хатирәсеннән.*

*..................*
*Мин бер көнне үзем күпер булып*
*Егылырмын шушы арага...*

Әнвәр Давыдов шигыреннән.

Шулай да гаҗәеп бу дөнья. Ул гомер иткән, тормыш тәҗрибәң күбәйгән саен сиңа яңа яклары белән ачыла бара. Дөньяның үзе кебек катлаулы шагыйрьләр иҗатын да гомер узган саен күбрәк, тирәнрәк аңлыйсың икән.

Әнвәр Давыдовның да укый-укый ятланган, күптән беләм дип йөргән әсәрләрен кабат караштыра башласам, әлегәчә күрелмәгән яңа мәгънәләре ачылып киткәндәй була, күңелдә бөтенләй башка, яңа хисләр кузгала.

Алмагач беренче яфрагын
Чыгара башлый сак кына,
Ни әйтсәң дә, кешегә язын
Ямансу була чак кына.

Күкнең зәңгәр бәрхете
Күңелгә йомшак кагыла.
Каршылап яңа бәхетне,
Кемнедер йөрәк сагына.

Әнвәр абыйның ошбу шигырен мин илленче еллар уртасында ук көндәлек дәфтәремә күчереп язып куйганмын. Күңелемдә язгы алмагачтагы сыман мәхәббәт бөреләнә башлаган яшүсмер буларак, күкнең зәңгәр бәрхетедәй зәңгәр күзле кызны сагынганда язып алган идем мин аны. Әле ул вакытта "яңа бәхетне каршылап, йөрәк сагынган ул кемдер" бик якында гына, үзем белән бер мәктәптә укып йөри иде ләбаса. Ә хәзер... Хәзер инде ул йөрәкне сагынудан сыкрарга мәҗбүр иткән кемнәр—узган көннәр, узган гомернең чуар сәхифәләре, гыйбрәтле үкенечләр, еракта-еракта калган яки инде якты дөньядан ук китеп барган кадерле кешеләрем сыйфатында күңелдә әрнүле-сагышлы хисләр кузгаталар. Әле илле яше дә тулмаган килеш дөнья куйган шагыйрь абый үзе дә сагындыра...

1965 елның язгы бер көнендә, Казан дәүләт университетының чыгарылыш курсы студенты буларак, "Әнвәр Давыдов шигърияте" дигән диплом эшемне, җитәкчем Зәет абый Мәҗитов юлламасы белән, шагыйрьнең үзенә укып, киңәшен тыңлау өчен өенә баруым, озак кына җылы әңгәмә корып утыруыбыз хәтердә яңара. Шушы тәүге танышуыбызда ук мин Әнвәр абыйның һәр җәһәттән гаять мәгълүматлы, зыялы кеше булуын абайлап алдым. Шуннан соң әдип белән һәр очрашу хәтта университетта төшенеп җитмәгән нәрсәләрне аңларга ярдәм итә, шигърият белеменнән үзе бер гаҗәеп дәрес-сабак сыман була торган иде.

Әнвәр Давыдов шигырьләре тыгыз фикерле, әлегәчә күнегелгән шәкелдән үзгә, яңа, үзенчәлекле образларга төренгән булуы белән күңелемне яулап алды. Аның иҗатында кызыклы ачышлар ясау мөмкинлеген күрдем.

Хәер, ул елларда Әнвәр Давыдов иҗаты әдәби җәмәгатьчелекнең дә, шигърияттне яратучыларның да игътибар үзәгендә булып, әдәбиятыбыз аксакалы Сибгат ага Хәким аның турында болай язган иде: "Яшь шагыйрь башта ук укучыларны колачының киңлеге, күтәргән проблемаларының актуальлеге, зурлыгы белән, фикерләренең үткенлеге белән тартты. Казанга ул өйрәнер өчен килгән авыл малае булып түгел, татар, рус, дөнья әдәбияты белән шактый таныш, бүгенге заман яшьләренең хәзерлекле, алдынгы вәкиле сыйфатында килеп керде..."

Шагыйрь үзе исә максатын түбәндәгечә бәян итә: "... бүгенге поэзияне дөнья әдәбияты, шул исәптән үзебезнең әдәбият казанышлары нигезендә эшләргә тырышу,

бертөрлелектән арынырга тырышу. Бәлки, әсәрләрем (зур мөстәкыйль әһәмияткә ия булмасалар да) әдәбиятыбызның, поэзиябезнең яңа буыннарына бер ярдәм, черновой бер эш була алыр." (Автобиографиясеннән).

Үз иҗатына бәя бирүдә шагыйрь тыйнаклык күрсәтсә дә, шигъри ачышларының киләчәк буын шагыйрьләренә өлге булачагын яхшы белгән ул.

Мәгълүм ки, имлябызны кат-кат алыштыру, әдәбиятыбызның алтын баганаларыннан кайсын "суфыйчылык бу!", кайсын "буржуаз бу!", кайсыларын "халык дошманы бу!" дип, арадагы күперләрне яндыру аркасында шигърият бакчабыз шактый ярлыланган, зәгыйфьләнгән еллар иде. Каләм ияләренә дә талантына, әсәрләренең сыйфат дәрәҗәләренә караудан битәр, аларның нинди идеяне яклау яки якламауларына нисбәтән бәя бирелгән заман. Мондый шартларда шигърият бакчасын чүп үләннәре басачагы, ихлас шигърияте назым-такмакчылык алыштырачагы табигый нәрсә. Шулай да әле, бәхеткә, күперләр бөтенләй үк янып бетмәгән, үзләренең яшьли үлемнәре аркасындамы "исән" калган Тукай бар, Такташ, Җәлилләр бар, аларны укып үскән өлкән буын әдипләр, кем әйтмешли, яңгыннан калган баганалар бар.

Әнә шундый шартларда Куйбышев өлкәсенең Камышлы дигән җыйнак кына татар авылында туган Әнвәр дигән малай шигъри авазын сала: Тукайга, Такташка ияреп язган беренче шигырьләрен район газетенә юллый башлый, Мәскәүдәге "Октябрь баласы" журналына кадәр барып, шунда эшләүче Муса Җәлилдән беренче әдәби дәресләр алуга ирешә...

Билгеле инде, тормышны ал да гөл итеп кенә күрсәтергә яраган заманда яшь талант та аны урап уза алмый. "Кызыл" шигырьләр дә язына. (Шунысын да әйтик, андый әсәрләр Давыдов иҗатында алга таба да булмады түгел, ләкин алар торган саен азая барып, соңыннан ул алардан бөтенләй арына алды. Хәер, талантлы әдипнең "кызыл" дигән шигырьләре дә җиңел кулдан шома гына язылган әсәрләр түгел, ә образлы итеп, сәнгать дәрәҗәсендә эшләнгән, ихлас булулары белән аерылып торалар.



*Рәсемдә: (сулдан уңга) татар әдипләре Нәби Дәүли, Баян Гыйззәт, Сәрвәр Әдһәмова, Хәсән Хәйри, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Әнвәр Давыдов. Матбугат йорты (Бауман ур., 19) балконында. Алтмышынчы еллар башы.*

Бу урында Сибгат ага Хәкимнең: "Шагыйрьнең иҗатын ил биографиясеннән аерып карарга мөмкин түгел. Шагыйрьнең гражданлык хисләрен мин үзе актив катнашкан зур вакыйгалардан эзлим, ул шулар эчендә үскән, формалашкан",— дигән фикерен китерү урынлы булыр. Әнвәр дигән яшүсмер авылдагы крәстияннәрне кайсын үгетләп, кайсын көчләп, раскулачивать итү белән өркетеп колхозга куып кертүне, анда бушка диярлек эшләтүне, әлбәттә, үз күзләре белән күргәндер. Ләкин, икенче яктан, бу гамәл бит ярлыларны яклау, авыл эшчәннәренә киләчәктә матур, мул тормыш вәгъдә итүләр, ялган оптимизм шартларында алып барыла. Тиздән Әнвәр Давыдов үзе дә шул "уенның" үзәгендә кайный башлый. Җидееллык мәктәпне тәмамлауга Камышлыдагы авыл хуҗалыгы техникумында уку, звено башлыгы булу, әтисе белән абыйсы бер-бер артлы диярлек вафат булганнан соң, колхоз бригадасында хисапчы

булып эшли башлау, үзешчән сәнгатьтә катнашу, аннары киномеханик буларак, халыкка совет крәстияннәренең бәхетле тормышын чагылдыручы фильмнар күрсәтү, комсомол активисты булу... Әнә шушы, чынбарлык белән хыял, матур ялганның капма-каршылыгы булачак шагыйрь күңелендә каршылыклы хисләр булып җыелган һәм соңыннан аның бөтен иҗатында чагылыш тапкан дияргә мөмкин.

Балачактан ук кулына каләм алса да, Әнвәр Давыдов шагыйрь буларак, Ватан сугышы кырларыннан кайтканнан соң гына мәйданга чыга. 1947 елда "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналында бер-бер артлы ике зур шигъри әсәре—"Коммунизм таңы" колхозында" һәм "Алтын көз" поэмалары дөнья күрә. Ул колачының киңлеге, көнүзәк мәсьәләләрне күтәрүе, образларының яңалыгы белән әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын бик тиз яулап ала. Ә 1950 елда шагыйрьнең "Беренче бөртек" дигән китабы дөнья күрә. Шигырьләре урысчага тәрҗемә ителеп, "Новый мир" кебек абруйлы журналларда басыла башлый. Шуннан башлап, һәр ике-өч ел саен бер китабы нәшер ителү шагыйрьнең никадәр актив иҗат итүе, киеренке тормыш белән яшәве турында сөйли. Игътибар итик: "Алгы сафтагылар"(Шигырьләр һәм поэмалар)—1952 елда дөнья күргән. "Сине сөюем" (Шигырьләр һәм поэмалар)—1953 ел. "Серле бөртекләр" (Поэма-әкият)—1954 ел. "Шигырьләр" (1954), "Ташу" (1956), "Тормыш лирикасы" (1959), "Ферма кызы" (1960), "Чорлар чатында" (1961), һ.б.—барысы өч дистәгә якын китап. Шуларның дистәгә якыны—урыс телендә. Вафатыннан соң да (әле аңа илле яшь тә тулмаган иде) архивыннан бик күп яңа шигырьләре, "Йокысыз төннән соң" дигән шигырь белән язылган роман-симфониясе табыла. Ул 1972 елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та басылып чыкты. Үзе үлгәннән соң шагыйрьнең иҗатын шактый тулы чагылдыручы "Дәверләр диалогы" (Сибгат Хәкимнең кереш мәкаләсе белән. 1969 елда) һәм Альберт Нарбеков төзегән "Кояшлы көн хакына" (Әхсән Баяновның кереш мәкаләсе белән. 1979 елда), "Түгәрәк бәхет" (төзүчеләре—Р. Мингалим һәм А. Нарбеков. 1984 елда) дигән шигъри һәм чәчмә әсәрләрен туплаган китаплары укучылар кулына барып ирешге.

Галәм киңлекләрендәге йолдызларның нуры үзләре сүнгәннән соң да Җиргә озак еллар килеп тора, диләр. Шигърият күгендәге йолдызларның нуры да кешеләр күңелен шулай яктыртуын, җылытуын дәвам итә, күрәсең...

Вакытлар уза, сәясәтләр алышына, идеаллар үзгәрә... Әдипләр иҗатын да галиҗәнап вакыт үзенең нечкә иләге аша иләп, йөрәк һәм акыл җимешләренең адәм баласы өчен һәр заманда да бик кирәк булганын, алтын бөртеге кебек искерми, тузмый, тутыкмый торганын гына үзе белән киләчәккә ала. Андый әсәрләр Әнвәр Давыдов иҗатында шактый. Һәм бүгенге көндә Әнвәр Давыдов дигән зур шагыйрьне әнә шундый—үз рухи халәтен чагылдырган лирик-фәлсәфи шигырьләрен аңлаган хәлдә бәяләү дөрес һәм гадел булыр. Аның бу кимәлдәге әсәрләре ихлас, моңлы, әрнүле. Аларда тормыш ачысын күп татыган, Волхов сазлыкларында туңган-күшеккән, мең үлемне җиңеп, туган туфрагына кайтып егылган, шунда яңадан тыныч, матур тормыш корырга ашкынып йөрүче солдат-шагыйрьнең каршылыклы уй-тойгылары мул итеп сибелгән.

Кипкән, диләр Волхов сазлыклары,
Нурлар балкый, диләр, суыннан.
Торган саен ләкин ныграк сызлый
Шул сазлыкта туңган буыннар.

Торган саен йөрәк авыр тибә,
Тамырлары ныграк шешәләр.
Үлем китереп, ядрә ярчыклары
Якынрак гүя төшәләр...

Әйе, сугыштан мең үлемне җиңеп кайтсалар да, фронтовикларны Әҗәл күз уңыннан ычкындырмады, берәм-берәм салкын кочагына ала торды. Әнвәр абый да Әҗәлнең салкын сулышын һәрдаим тоеп яшәде, ул авыру, чир-чорларга бирешергә теләмәде, отыры үҗәтләнеп иҗат итте, еш кына үлем белән бәхәскә дә керде. Үзенең "тормышны өзелеп яратуын әйтеп, аның кочагына ташланасын, шул сөю учагында янып, үлемгә фәкать көлен генә калдырачагын..." җырлады. Шул ук вакытта үзендә башкаларны юатырлык көч-көдрәт тә тапты ул:

Нигә башың салдың әле, туган,
Син авырудан дөнья җимерелмәс.
Тәрәзәгә күзең төшереп ал,
Күр, табигать бүген нинди яшь!
..................................................

Ике баштан икәү тоткыннар да
Карават алып кайта ике яшь.
Шулай булгач,
Бар да үз урынында!
Күтәр башың!
Дөнья җимерелмәс!

Әнвәр Давыдов лирик шигырьләрен нигездә традицион шәкелдә язса да, күп кенә очракларда аның киеренке вә каршылыклы уй-тойгылары көйле юлларга гына сыеша алмадылар, үзләренә киңрәк-иркенрәк мәйдан таләп иттеләр, ирекле шигырь галәменә күтәрелделәр, рухи ирекә омтылдылар. Бу хәл бигрәк тә аның публицистик ялкын белән сугарылган лирик-фәлсәфи шигырьләрендә чагылыш тапты. Ул сугыштан соңгы татар шигъриятендә яңа эчтәлеккә муафыйк яңа шәкел-формалар эзләүдә иң актив шагыйрьләрнең берсе булды. Бу юлда ул татар шигъриятенең бай мирасына таянган хәлдә, дөнья поэзиясенең алдынгы тәҗрибәсен өлге итте. Бу җәһәттән аның уңышлары белән беррәттән, уңышсызлыклары да булды, әлбәттә. Хәлбуки, публицистиканы, фәлсәфи фикерне йөрәк ялкыны, күңел җылысы аша үткәреп бирү генә уңышка китерәсен Әнвәр Давыдов бервакытта да исеннән чыгармады. "Күмер көйри" (шигъри повесть), "Чорлар чатында" (поэма), "Йокысыз төннән соң" (роман-симфония) кебек киң полотнолы әсәрләрендә шагыйрь аеруча зур уңышка ирешә. Бу әсәрләр татар шигъриятенең образлы тасвирлау мөмкинлекләрен яңа биеклеккә күтәрде. Болар һәм күпләгән башка шигырьләре, "Муса абый", "Урта Иделдә балачак", "Биографиямнең беренче юлы" повестьлары, хикәяләре—Әнвәр Давыдов дигән кабатланмас шәхес, зур шагыйрьнең йокысыз төннән соң халкыбызга биреп калдырган күңел җәүһәрләре, йөрәк җимешләре... Аларда үз халкыңның киләчәге, Җирнең иминлеге өчен борчылу, хәвефләнү белән бергә, йөрәк хисе белән җылытылган аек акылның җиңеп чыгасына ышаныч-өмет яктылыгы чагылыш тапкан:

Сугыш һәлакәте,
Халыклар хәрәкәте,
Җимерү,
Тәзү тетрәнүләре белән
Яши,
Сулышын ала бу Җир шары.
Сулышы киңәюеннән
өзелә,
тетелә бара
Күгәреп беткән коллык чылбырлары.
Җир әрнеше,
Җир хурлыгы—
коллык!
Сугыш—мең еллык!
Газап—мең еллык!
Бетсен ул кырылып!
..................
Кайгы җыерчыклары кими барган
Йөзе белән көлеп, уйланып,
Яңа кояш, яңа дөньяларга
Дуслык кулын суза безнең Җир,
Гакыл нуры белән нурланып!

Гомумән, Ватан сугышы ялкыннарында янып чыныгу татар әдипләрен дөньяга җитди, аек күз белән карарга өйрәтте, иҗатларына тирәнлек, фәлсәфилек иңдерде. Моңа дәлил—Муса Җәлилнең Моабит диварларын җимереп чыгып, туган илебезгә кайткан ялкынлы җырлары, илгә, халкына тугрылыгын каны белән раслаган Фатих Кәрим шигырьләре, Сибгат Хәким, Салих Баттал, Мөхәммәт Садри, Шәрәф Мөдәррис, Зыя Мансур, Нури Арсланов, Гали Хуҗи, Әдип Маликов, Хисам Камаловларның сугыштан соңгы иҗатлары. Алар Сталинның шәхес шөһрәте тәэсирендә тормышыбызны бизәкләп күрсәтүгә корылган шигъриятебез корабын кайчандыр Дәрдмәнд корабы йөзгән шаулы-давыллы тормыш диңгезенә таба юнәлттеләр. Тиздән бу кораб штурвалы илленче-алтмышынчы елларда күтәрелеп чыккан яңа—тагын да кыюрак, тагын да үзенчәлеклерәк, эзләнүчәнрәк шагыйрьләр кулына күчте. (Җәя эчендә генә әйтеп үтү урынлы булыр: нәкъ менә шушы эзләнүләре яшь талантларга иҗатта үз йөзләрен, үз алымнарын, үз язу стильләрен табарга ярдәм итте).

Билгеле ки, иҗаттагы бу кыюлык, яшәп килгән тәртипләргә карата метафорага төреп булса да әйтелгән кискен фикерләр, "кызыл" шигырьләргә каршы "ирекле, ак"

шигырьләрне кую, төнге күктә ялтырап алган яшен камчысыдай нюанслар, метаморфозалар—яшь шагыйрьләрнең "мөгез чыгарулары" дип бәяләнде, чөнки бу хикмәтләр талгын-рәхәт тормышка күнеккән идеология сагында торучыларга ошамады. Ул вакытта бит татарча түгәрәкләп сакал-мыек үстерү, кәләпүш яки тар балаклы чалбар кию, бизәкле галстук тагу кебек гөнаһсыз гамәлләр дә гаепкә санала, андыйларның "тәртибе" комсомол җыелышларына куеп тикшерелә иде. Янәсе, көнбатышка ияру, буржуа яшьләренә охшарга тырышу яшьләрнең күңелләрен дә шул тарафка борып куярга мөмкин. Әдәбият вә сәнгатьтәге форма эзләнүләре әнә шундый беркатлы-примитив бәяләнде, моңа каршы матбугат аша һөҗүмнәр оештырылды. Бу гамәлгә хәтта кайбер могътәбәр өлкән әдипләр дә тартылды. "Җилкәнен киргән корабка" юнәлтеп, "Юкны эзләргә түгел, барны үстерергә" кебек "торпедалар" җибәрелү әнә шуның аяныч нәтиҗәләре иде.

Әнә шундый кискен борылыш вакытларында "Язлар кебек күкрәп", "Безнең чорда (Яшь шагыйрьләргә)" дигән мәкалә һәм шигырь язып, Әнвәр Давыдов эзләнүчән яшь талантларны яклап чыкты.

Нәрсә ул "Бар"? Нәрсә ул "Юк"? Уйлачы, шагыйрь-бала!
Ни бар? Ни юк? Бармы чын "Бар", бармы чын "Юк" дөньяда.
.....................................................
Берни юк язгы түтәлдә. Әмма ни ләззәт тоя
Кулларың, йомшартсалар орлык өчен шунда оя.

Гәрчә бик күптән кызарып бакчада пешсә җиләк,
"Үстерәм",—дип барны син, су ташыма чиләк-чиләк.
.....................................................
Һич курыкма, "Юк!" дигәннән, "Юк"—вакытлы "Юк" әле ул.
Булма һич белмәүгә корбан, армый эзләү әһле бул!

Хәтта ки, халык күпме еллар "Бар Ул, бердәнбер Ул!" дип ышанган Алланы да инкяр иткән имансызлык шартларында әнә шулай, "Юк!" дигәнгә карамагыз, армый-талмый эзләнегез, югалганны табу өчен көрәшегез!..—дип оран салуы аның үзеннән соң килүче шагыйрьләргә, гомумән яшь буынга васыяте булып яңгырый. Ул, шигърияптебезнең узганы белән бүгенгесенә үзе салган күпер уртасына баскан хәлдә, әле дә безгә шулай дип аваз бирә, тормыш, бәхет турында уйлана һәм шул уйларын безнең белән дә уртаклаша сыман:

Беләсеңме, тормыш ул нәрсә?
Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?
Без барабыз икәү янәшә.
Безне күпме яңа юл дәшә.
Урманда—чык, далада—рәшә.
.....................
Шулай атла, шулай мең яшә!

Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?
Юлда битеңә талгын җил бәрсә!
Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?
Эштә күңелең җырлап җибәрсә!
Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?
Кеше сиңа рәхмәтен әйтсә!
Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?
Эзең калсын үлсәң дә гәрчә!

**Шамил МАННАПОВ**

*Фән*

# ТАРИХЧЫ ҮТКӘН ЮЛ

Шушы елның мартында киң җәмәгатьчелеккә үзенен "Урта Идел буе татарлары 1773-1775 елларда Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында" (Казан, 1973), "Каһарман бабайлар" (Казан, 1976), "Урта Идел буе халыкларынын XVI йөздә-XIX йөз башында тарихи язмышлары" (Мәскәү, 1990), "Казан һәм Мәскәү: XV-XVI йөзләрдә дәүләтара мөнәсәбәтләр" (Казан, 1995) кебек тарихи монографияләре, йөзләгән фәнни мәкаләләре белән мәгълүм тарихчы-галим, Татарстанның атказан фән эшлеклесе, тарих фәннәре докторы Сәлам Хатыйп улы Алишевка 70 яшь тулды.

Ул 1929 елның 20 мартында Аксубай районынын Шәрбән авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Бер елдан сон анын әти-әниләре үзләренең төп авыллары булган Яна Әлмәткә (хәзер Норлат районы) күчеп кайталар. Сәлам 10 классны бетергәнчегә кадәр шунда үсә. Әти-әниләре карт, хуҗалыкны алып бару малай өстенә төшә. Ун-унике яшеннән ул арба-чана тартып урманнан утын ташый, печән чаба. Колхозда җир тырмалый, лабогрейка белән урак урдыра. Ә 1945 елдан трактор бригадасы хисапчысы булып эшли башлый. Боларнын барысы да мәктәптә укулар белән бергә бара. Яна Әлмәттә укучылар аз булганлыктан алтынчы сыйныф ябылгач, ул өч чакрым ераклыктагы Кычытканлы авылына йөреп җиденче сыйныфны бетерә. 1947 елда Күлбай-Мораса урта мәктәбен тәмамлый.

Шул ук 1947 елда ул Казан педагогия институтының тарих факультетына укырга керә. Студент елларында институтнын тулай торагында яши. Иптәшләре белән бергә Идел буендагы пристаньга—"Усия"гә баржалар, вокзалга вагоннар бушатырга йөреп тамак туйдыра. Атна үткәч эшләгән өчен алтмыш сум хезмәт хакы бирелә. Аңа базардан ипи карточкасы сатып алалар. Ипинең үзләреннән артканын янәдән базарга чыгарып саталар. Ә укулар исә үз чиратында бара тора. Мәгълүм ки, яшь зиһен белемнәрне тиз үзләштерүчән була. Алар—фронтовиклар Салих Нәҗметдинов, Ә. Салихов, яшьтәшләре Марат Мөлеков, Азат Җәләлов, Тәлгать Еферов, Галиәскәр Хәмитов, Әнвәр Садыйков һәм Сәлам Алишев узара дуслашып, бер-берсеннән калышмаска тырышып, урыс телен дә яхшылап үзләштерергә теләп ярыша-ярыша укыйлар. Тулай торакта фәнни бәхәсләр кузгаталар, тарих кафедрасында һәм группада "түгәрәк өстәлләр", семинарлар уткәрәләр. Спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт табыла. Сәлам тиз йөгерә, яхшы сикерә. "Динамо" стадионында уздырылган җиңел атлетика ярышларында ул йөгергән вакытта дәрт биреп торучы иптәшләреннән, аптырап: "Нигә аны гел "сәлам" ("привет") дип сәламлисез?"—дип сорыйлар икән. Шулай йөгерә-сикерә торгач, ул Ленинградка, Бөтенроссия ярышларына да барып житә.

Өченче курста укыган вакытта Казаннын 80 нче мәктәбендә педагогик практика үткәч тә мәктәп белән араны өзми. Моны "комсоргнын яналыгы" дип атыйлар. Гомумән, студентлык еллары, тормыш ничек кенә авыр булмасын, Сәлам ага хәтерендә тормышнын иң матур, күнелле, кадерле бер мизгеле булып уелып кала. Хәзер дә әле үзенең ул чордагы күп иптәшләрен, укытучы-галимнәрдән М. Н. Бушмакинны, Е. И. Устюжанинны, Н. П. Муньковны һәм башкаларны җылы сүзләр белән искә ала.

Институтны бетерергә санаулы көннәр генә калып барган бер вакытта группага атна саен килеп йөрүче КГБ әһелләре яшьләрне үзләренә эшкә чакыралар. Шул ук вакытта аларны районнарга, мәктәпләргә бүлү-билгеләү дә бара. Инде дәүләт имтиханнары бирелгән, һәр студент үзенә билгеләнгән эш урынын белә диярлек. Ләкин тулай торактагы алты-җиде кешегә һаман да диплом бирмиләр. Аларны КГБга эшкә чакыру—өндәү дәвам итә. Институт җитәкчеләренә баргач, алар чырайларын сытып, башларын читкә боралар. Бер айга якын вакыт үткәч кенә алар, ниһаять, диплом алуга ирешәләр.

Җәйге айларны әнисе янында авылда үткәргәннән соң, Сәлам ага билгеләнү буенча Лаеш районының Татар Сараланы урта мәктәбенә эшкә килә. Бу районда бердәнбер татар урта мәктәбе була. Анa төбәкнең төрле авылларыннан килеп укыйлар. Мәктәп бинасы зур түгел, дәресләр ике сменада алып барыла. Озак та үтми авылда ыгы-зыгы башлана: Куйбышев сусаклагычы төзелү сәбәпле авылны югарырак урынга күчерәселәр икән. Һәрбер торакны, хуҗалыкны, шул исәптән мәктәпне дә яңа җирдә урнаштыру өчен күпме акча кирәклеге билгеләнә.

Сәлам җәйге каникулга Яңа Әлмәткә кайтып китә, әнисенә яңа өй җиткерә. Ялы беткәнче үк август башында РОНОдан хат аша приказ ала: "15 августтан мәктәпнең директоры итеп билгеләнәсез, килеп кабул итегез". Ул килгәндә яңа урындагы мәктәпнең түбәсен ябып яткан булалар. Монда аңа "вак-төяк" хуҗалык мәсьәләләре белән дә шөгыльләнеп, баштан ук җиң сызганып эшләргә туры килә. Нәтиҗәдә 1 сентябрьдән мәктәп тулы тәртиптә эшен башлап җибәрә.

Мәктәп директоры укытучылар, ата-аналар һәм укучылар коллективлары белән оста җитәкчелек итәргә бурычлы. Моны бик яхшы аңлаган яшь белгеч бөтен көчен, белемен, егәрлеген эшкә җигә. Укытучылар арасында үз һөнәрләрен белеп, яратып эшләүчеләре байтак булган кебек үк, араларында бернинди китап укымаучылары, үз хуҗалыгы белән генә мәшгуль булганнары да очрый. Ата-аналар арасында балаларына бик аз игътибар бирүчеләре дә табылып тора. Директор Сараланда гына түгел, төрле башка авылларда да ата-аналар җыелышлары, аерым сөйләшүләр үткәрергә тиеш була. Мәктәптәге хуҗалык эшләре дә аның ярдәменнән башка башкарылмый. Мәктәп биләмәсе яхшы койма белән әйләндереп алына. Анда җиләк-җимеш һәм яшелчә тәҗрибә участогы булдырыла. Мәктәпне тормыш белән тыгызрак бәйләү өчен остаханәләр салына, техника юнәтелә, төрле җиһазлар табыла. Куйбышев сусаклагычы буасын ябу алдыннан мәктәпләргә Чулман аръягындагы урман хуҗалыгы биналарын бүлеп бирәләр. Татар Сараланы урта мәктәбенә шул хуҗалыкның клуб, контора һәм ашханә биналары тәгаенләнә. Аларны сүтеп алып кайтып, зур гына остаханә һәм ике торак йорт салалар.

Илленче еллар ахырында мәктәптә балалар саны кими башлый. Сәлам Алишев авыл Советына кереп хуҗалык кенәгәләрен тикшерә һәм алдагы берничә елда укучыларның тагын да кимиячәген күрә. Байтак гаиләләр башка районнарга, шәһәрләргә күчеп китәләр икән. Мәктәп директоры да уйга кала. Аны мәктәпнең киләчәк язмышы борчый. Ул мәктәптән китәргә карар кыла. Министрлык аны Югары Ослан районына РОНО мөдире итеп җибәрә. Монда ул 1960—1962 елларда эшли һәм җае чыгу белән Казанда кооператив квартира төзеп, шәһәргә күченә.

1963 елның көзендә ул СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлеге аспирантурасында укый башлый. Яше утыз дүрттән узган булса да, гарәп графикасында яхшы укый, яза белүе аркасында (әтисе балачакта ук өйрәткән була) аны кабул итәләр. Фәнни җитәкчесе итеп зур гыйлем иясе Евгений Иванович Чернышевны билгелиләр. Ул аспирантка үзенең бай тәҗрибәсеннән байтак белем бирә. Борынгы рус язмаларын укырга өйрәтә. Ләкин 1964 елның азагында ул пенсиягә китә. 1966 елда Сәлам Алишев "Урта Идел буе татарлары 1773—1775 еллардагы Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында" темасына кандидатлык диссертациясен язып тәмамлый. Әллә үзен тикшерәләр, әллә... Шулай да бүлектә кече фәнни хезмәткәр итеп калдыралар. Ниһаять, 1968 елда ул кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. Шул ук елларда матбугатта аның мәкаләләре, очерклары чыга башлый. Татарларның Пугачев явында актив катнашуы җәмәгатьчелек өчен яңалык, ачыш була. Чөнки аңа кадәр татарларның бу сугыштагы роле ачык булмый. Язучылар, шагыйрьләр, сәнгатьчеләр татарларның андагы батырлыгы турында әсәрләр яза башлыйлар. Мостафа Ногман баллада иҗат итә. Берничә шагыйрь пугачевчы татар полковникларының исемнәрен үзләренең шигырьләрендә яңгырата. Һәм, ниһаять, Г. Камал театрында Туфан Миңнуллин пьесасы буенча "Канкай углы Бәхтияр" спектакле сәхнәгә куела. Билгеле булганча, Бәхтияр Канкаев Пугачевның баш полковнигы дәрәҗәсенә ирешкән гайрәтле сәргаскәр була. Ул татарлардан чыккан берничә дистә полковникның гомумиләштерелгән образын күзалларга мөмкинлек бирүче каһарман, халык бәхете өчен көрәшүчеләрнең алдынгы вәкиле. Аның турында С. Х. Алишев күп язды.

Тарих бүлегенең эш планнарын җиренә җиткереп үтәп бару белән бергә аңарда

яна темага күчәргә кирәклеге турында да фикер туплана. Бу фикер өлкән фәнни хезмәткәр итеп билгеләнгәч тагын да көчәя. Сәлам ага өчен 1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы темасы 1973 елда Оренбург, Уфа, Казан, Мәскәү шәһәрләрендә бу сугышның 200 еллык юбилеен үткәрү һәм аның "Татары Среднего Поволжья в пугачевском восстании" дигән, русча һәм татарча яңа китабы басылып чыгу белән тәмамлана бугай. Әмма галимнең 1976 елда татарча басылган "Каһарман бабайлар" дип исемләнгән китабын да билгеләп үтми булмый. Бу китапта пугачевчылар гына түгел, ә бәлки төрле чорларда татар халкының ирек, азатлык өчен хәрәкәтен әйдәп барган каһарман Хәсән Карачурин (Степан Разинның көрәштәше), Габдулла Галиев (Батырша) һәм башкалар да бәян ителә. Ул чордагы Институт директоры Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов һәм бүлек мөдире Җәмил Ибраһим улы Гыйльмановларның теләктәшлеге тапкан яңа, мөһим тема "Урта Идел буен Рус дәүләтенә кушу" ("Присоединение Среднего Поволжья к Русскому государству") дип атала. Тирән һәм газаплы уйланулар, эзләнүләр башлана. Темага каршы килүчеләр дә табыла. Бер Мәскәү профессоры: "Андый тема юк. Тегесе кушылган, бусы кушылган, ә Рәсәйнең үзенеке кайда кала?",—дип ачулана. Ләкин объектив дөреслекнең җинеп чыгуына өметен өзмәстән, Сәлам ага эшен дәвам иттерә. Ул барлык рус елъязмаларын, басылып чыккан чыганакларны кат-кат тикшерә, бик күп рус тарихчыларының китапларын укый, конспектлар төзи. Ничек хәл итәргә соң?.. Проблемалар күп һәм җинел түгелләр. Алар арасында төп мәсьәлә—Рәсәйнең Казанны яулавы, Урта Иделне басып алуы. Бу чынлыкта булган вакыйгага күз йому да, аны инкяр итү дә мөмкин түгел бит... Шундый газаплы уйлар кичерә, эшли торгач, ул 1987 елда үзенең әзер китап кулъязмасын Мәскәү Тарих институты тикшерүенә куя. Монда күп кенә гадел булмаган сүзләр ишетергә туры килә аңа. Өлкән бер профессор: "Кытайлар да безне яулап алучылар (завоеватели) дип атый, син дә монда шулай дип килгәнсең",—дип битәрли һәм: "Шулай булгач, нишләргә соң?",—дигән сөальгә, "бөтенләй язмаска, кирәк түгел бу", ди дә сүзен йомгаклый. Докторлык диссертациясе итеп каралырга тиешле бу монография "Казан феодал дәүләтенең оешуы һәм үсүе", "Мәскәү бөек кнэзьлегенең Казан патшалыгы өстеннән хакимлеге (протекторат)", "XVI гасырның беренче яртысында Рус дәүләте", "Казанны яулап алу һәм Урда Иделнең Рус дәүләтенә керүе", "Урта Идел буе халыклары Рус дәүләтендә" һәм "Урта Иделне Рус дәүләтенә кушуның тарихи әһәмияте" исемле алты бүлектән торган.



*Сәлам Алишев*

Кулъязмада Казан дәүләтенең оешуы, аның болгар җәмгыяте белән тарихи бәйләнеше, рус кенәзләренең һәм руханиларының көнчыгышка агрессия идеологиясе, Мәскәү дәүләтенең эчке хәле һәм үсеше, Казанны яулап алу күренешләре, җирле халыкларның рус изүенә дучар булуы һәм аңа каршы көрәше дәлилле тасвирланган була.

Бу мәсьәләләр фәнни тарихи дөреслекне чагылдырсалар да ул вакытта рәсми совет идеологиясен алга сөрүче түрәләр, тарихчылар "агымсуга каршы баручы" андый карашны кабул итә алмыйлар.

Әле аңа кадәр үк, 1975 елда, Сәлам ага Алишев "Татария в прошлом и настоящем" дигән китапта санап үтелгән тарихи мәсьәләләрнең кайберләрен чагылдырган мәкаләсен урнаштыра. Бу мәкалә унаеннан кайбер Мәскәү галимнәре "мондый яңа сүз әйтүче, мәсьәләгә тирән анализ бирүче юк иде әле",—дисәләр, икенчеләре эчтән сүгәләр, яки дәшмиләр. Ә АКШ тарихчысы E. Lazzerini (Е. И. Лаццерини) "Slavic Review" ("Славяннарны күзәтү") журналында хәтта "Советлар Союзында татарларны өйрәнү һәм яңа историография: татар-рус мөнәсәбәтләрен тикшерүне ревизияләү" дигән мәкалә белән дә чыга. Бу мәкаләдә автор С. Х. Алишевның хезмәтенә югары бәя биреп, аның төп нәтиҗәләренә туктала. Алар исә түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: 1. Казан ханлыгы халкының икътисади, мәдәни

үсеш дәрәҗәсе рус дәүләте халкыныкыннан калышмаган (ә бит ул вакытта рәсми совет тарих фәнендә "бары тик руслар гына алга киткәннәр, башка халыклар артта калган" дигән фикер хөкем сөрә. ) 2. Халыклар үзләре теләп (добровольно) Рус дәүләтенә кушылмаганнар, алар яулап алынганнар (аңарчы бу мәсьәләдә кешеләр аңына "барлык җирләр, барча халыклар Рус дәүләтенә ирекле рәвештә килеп кушылганнар" дигән фикер иңдерелә иде. ) 3. Татар халкы милли азатлыгын, дәүләтен югалтса да, тарихи киләчәк өчен яулап алуның прогрессив яклары да булган (рус совет тарихчылары бу яулап алуны башта "тулысынча явызлык" ("абсолютное зло") дип, 40 нчы еллардан башлап "кечкенә явызлык" ("наименьшее зло"), ә сонрак "тулысынча прогрессив күренеш" дип яздылар). С. Х. Алишев алгарышны үзенчә Казан ханлыгы Көнчыгышка йөз тоткан, анынча тормыш рәвеше белән яшәгән ил буларак алга таба торгынлык чорына кереп, хуҗалык, сәясәт өлкәләрендә артта калуга дучар иде, дип аңлата. Күргәнебезчә бу мәсьәләдә дә тарихчы яулап алуның "тулысынча прогрессив күренеш" булуын инкяр итеп, коммунистлар партиясе күрсәткән "олы юлдан" бераз читкә тайпыла.

Лаццерини да бу карашны хуплый. Шулай да Рус дәүләте уздырган басып алу, башка халыкларны буйсындырып тоту сәясәтенең агрессия икәнлегенә басым ясый һәм Рәсәйне империячел дәүләт дип саный.

Лаццерининең "тайпылышларын", "советча булмаган карашларын" Казан галиме М. И. Абдуллин үзенең "Батып баручы еланнарга таяна" дигән китабында тәнкыйть утына ала һәм Алишев белән Лаццерини карашларының "бик үк туры килеп бетмәгәнлеген"дә ачыклый.

1976 елда Аграр тарихны өйрәнү проблемасы берләшмәсенең Урта Идел буе бюросы оеша. Аның Йошкар-Олада булган беренче конгрессында С. Х. Алишев рус колонизациясе темасына доклад белән чыгып, "колонизацияне иң беренче булып крестьяннар тыныч юл белән башлаганнар, аннан соң гына хөкүмәт көчләре килгән" дигән уйдырмаларның ялган булуын дәлилле тасвирлый. Шуңа бәйләп милли азатлык хәрәкәте күренешләренә дә туктала. Нәтиҗәдә җыелышта катнашучы кайбер әһелләрнең каты тиргәвенә дучар була. Аны "мондый докладлар белән коммунизм төзеп булмый",—дип өйрәтәләр. Ә берәү хәтта Мәскәүгә шалтыратып, "Алишев докладын җыентыкка кертсәгез, партбилетсыз калуыгыз да мөмкин",—дип тә куркыта. Шунысын да искәртеп үтик—ул вакытта Мәскәү рөхсәтеннән башка (рецензияләү, йә редакцияләү рәвешендә) тарих китаплары, җыентыклар чыгарылмый иде. Шулай итеп, ул доклад-мәкалә тарихи җыентыкта басылмыйча кала. Кайда инде ул сүз, матбугат иреге! Ә бит алар макталган совет Конституциясендә кешенең аерылгысыз хокукы итеп игълан ителгән булалар. Янә бер мисал. 1977 елда тарих бүлегенең чираттагы җыентыгы төзелә. С. Х. Алишев анда "Газиз Гобәйдуллин—тарихчы" дигән мәкаләсен урнаштыра. Главлит (ул вакыттагы цензура) бу мәкалә төшереп калдырылмаса, яки анда тарихчыга тискәре бәя бирелмәсә, җыентыкның чыгарылмаячагын хәбәр итә. Авторга ул вакытта Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары булып эшләгән Мансур Хәсән улы Хәсәнов янына барырга туры килә. "Шундый зур татар тарихчысын, Сталин заманында атып үтерелгән, инде реабилитацияләнгән галимебезне халыктан качырып торабызмы?". М. Х. Хәсәнов главлит белән сөйләшә һәм мәкалә җыентыкта басылып чыга.

1978 елда "Молодость древнего города" дигән һәм Казанга багышланган тагын бер китап дөнья күрә. Анда "Урта гасырлардагы Казан" дип аталган беренче бүлекне С. Х. Алишев яза. Китапны партиянең өлкә комитетында тикшерү вакытында секретарь М. Ф. Вәлиев: "Менә Алишев Казандагы беренче рус гимназиясендә 1769 елда ук татарча да укытканнар, дип яза, кайдан алган, нигә ул аны яза", — дип тәнкыйтьли. Башкалар дәшми. Автор ул урынны төшереп калдырырга тиеш була. Ләкин бу хәбәр башка бер бүлектә урын ала һәм С. Х. Алишев мәкаләсе дә китапта басылып чыга. Әмма гадел булмаган сүзләр йөрәкне әрнетеп күңелдә кала. Мондый "тәнкыйтьләр", хәтта яла ягулар да ул вакытта күп була. Аның өстенә 1976 елда аның 23 ел бергә тормыш иткән хатыны да үлеп китә. Аларның Булат һәм Айрат исемле малайлары бу вакытта инде университет студентлары. 1979 елда ул янадан өйләнә, ә 1980 елда улы Самат туа (хәзер ул КДУ студенты).

80 елларны С. Х. Алишев үзе өчен иң киеренке, тыгыз һәм нәтиҗәле эш чоры дип исәпли. Ана Г. Ибраһимовның тарихи хезмәтләрдән торган томын матбугатка әзерләүне йөклиләр. Үзе шөгыльләнгән борынгырак чорлар тарихына язучының әллә

ни катнашы булмаганлыгын белсә дә, бу эшкә алына. Чөнки бүлектә аның гарәп графикасында язылган тарихи әсәрләрен кириллицага күчереп язу, гарәп, фарсы телләреннән алынма сүзләргә аңлатмалы сүзлек төзү, аерым төшенчәләргә искәрмәләр бирү эшенә бүтән алынучы булмый. Г. Ибраһимовның тарихи эшчәнлеген өйрәнү үзе генә дә байтак вакыт сорый. Мәскәүгә барып Г. Ибраһимов чыгарган "Чулпан" газетасы номерларыннан тарихи-публицистик материал җыю том төзүченең үзен дә гыйльми баета. Ә Г. Ибраһимовның язма мирасы аша татарларның 1905-1907, 1917 еллардагы инкыйлабларда катнашу тарихы, ул вакыттагы татар газеталары, язучының М. Вахитовка, башка эшлекләләргә карашы белән тагын да якыннанрак танышу, укучыларга да файдалы китап житештерә.

Шул вакытта галим 30 нчы елларда репрессияләнгән татар тарихчыларының әсәрләрен янадан халыкка кайтару уе белән яна башлый. Бу исә тарихчының фәнни иҗатында инде Каюм Насыйри, Гафур Колахметов хезмәтләрен өйрәнгәндә, дөньяга чыгарганда ук барлыкка килгән яңа юнәлешнең нигъп берегүе нәтиҗәсе була. Мона кадәр аның эшчәнлеге күбрәк татар халкы тарихын, XVI-XVIII йөзләрдә крестьяннарның милли-сыйнфый көрәшен өйрәнү юнәлешендә барса, хәзер инде ул бу тарихны өйрәнүнең ничек барганлыгы (историография) турында да уйлана.

Галимнең тарих фәнендәге төп иҗади юнәлеше татар халкының гомуми тарихын, аның аерым бер мизгелләрен, чорларын һәм проблемаларын гына түгел, ә бәлки милләт буларак оешу, үсеш баскычларын өйрәнүне дә үз эченә ала.

1970 елларда ул Казан шәһәренең борынгы тарихын өйрәнә башлый. 80 елларда тарих бүлеге алдында «Казан шәһәре тарихы» дигән 2 томлык хезмәт язу бурычы тора. Аның беренче томы С. Х. Алишев катнашында, аның җитәкчелегендә языла. Шуның белән бергә галим төрле чорларда, Казан тарихын өйрәнгән шәхесләр, аларның иҗади мираслары белән дә кызыксына. Андый тарихчылар ул вакытта галимнәргә, ә бигрәк тә җәмәгатьчелеккә аз мәгълүм була. Нәтиҗәдә "Үткәннәр эзеннән" дигән планнан тыш эшләнгән китап барлыкка килә. Казан тарихын өйрәнүнең гомуми торышы, аның беренче тарихчылары К. Ф. Фукс, М. С. Рыбушкин, Н. К. Баженов, И. А. Износков, Н. Я. Агафонов турындагы язмалар, татарларда тарих фәненең торышына, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм Мөхәммәтҗан Аитов, Газиз Гобәйдуллин, Гафур Колахметов һәм Г. Ибраһимовларның тарихи әсәрләренә, карашларына багышланган мәкаләләр күп кешеләрнең игътибарын җәлеп итә. Чөнки аңарчы бу кешеләр совет чоры энциклопедияләренә кертелмиләр диярлек, ә иске китап-газеталардагы мәгълүматлар ерак киштәләрдә булып, укучыларга анда барып ирешү авырга туры килә. Шунлыктан, "Үткәннәр эзеннән" китабы озак еллар вузларда, махсус уку йортларында, мәктәпләрдә туган як тарихын уку-укыту эшендә популяр кулланма-дәреслек булып хезмәт итә. "Казан тарихы" китабы исә үзе сонрак басылып чыга. Бу коллектив хезмәтнен I бүлеген алар тарихчы-археолог А. Х. Халиков белән бергә язалар, ә 2,3,4 бүлекләрне С. Х. Алишев эшли. Бүлекләрдә Казанның борынгы чорлардан алып шәһәр, һөнәр-сәүдә, хакимият үзәге буларак тарихи үсеше тасвирлана. Шулай итеп, галим иҗатында ике юнәлеш—шәхсән тарих үзе һәм аны өйрәнү тарихы бергә үрелеп баралар.

Әлбәттә, Сәлам ага чыганакларны өйрәнүгә дә зур әһәмият бирә, матбугатта аның татар тарихи кульязмаларына багышланган байтак мәкаләләре басылып чыга. Бу мәкаләләрдә ул татар язма чыганакларының тарихи әһәмияте, татар халкында мәгариф эшенең куелышы, аның грамоталылыгы мәсьәләләренә дә тукталды. Татар мәдрәсәләрендә уку-укыту процессы, бу уку йортларының XVIII йөздә үк дини мәктәпләр генә булмыйча, мәгърифәт учаклары да булуы турында ул совет чоры тарихчылары арасында беренчеләрдән булып язып чыкты.

Татар язма чыганакларын дөньяга чыгаруда ул А. Госманов белән дә бергәләп эшләп ала; алар "Казан утлары" журналында Пугачев хәрәкәте циклына керә торган татар документларын бастыралар. 1988 елда нигездә алар тарафыннан хәзерләнгән, 24 табак күләмле "Воззвания и переписка вожаков пугачевкского движения в Поволжье и Приуралье" дигән зур китап басылып чыга. Ул пугачевчыларга караган документларны, бигрәк тә Бәхтияр Канкаев канцеляриясендә татарча язылган материалларны русчага тәржемәләре белән бергә туплаган басма була. Чыганакларның мондый күләмле җыелмасы басылып чыгу сирәк була торган күренеш. Ул тарихчылар өчен генә түгел, телчеләр, фәлсәфәчеләр, фольклорчылар өчен дә файдалы, кирәкле хезмәт булды.

Үткән буын өлкән тарихчыларга булган ихтирамы аны бервакытта да ташламый. Онытыла башлаган тарихчыларыбызның әсәрләрен яңадан халыкка кайтармыйча, алар тарих фәнендә үз урыннарын ала алмаслар дигән фикердән чыгып һәм репрессияләнгән татар тарихчыларының истәлегенә тугры калып ул Г. Гобәйдуллинның сайланма әсәрләрен үз эченә алган "Тарих сәхифәләре ачылганда" китабын төзи. Кереш сүз, искәрмәләр яза, сүзлекләр төзи. 1989 елда Казанда татар телендә басылып чыккан бу китапка беренче татар тарих профессоры Газиз Гобәйдуллинның төп тарихи хезмәтләре, шул исәптән "Татар тарихы" да кертелә. Шул ук елда Ш. Мәрҗанинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" дигән тарихи әсәре дә, хәзерге телгә күчермәдә зур гына бер китап булып дөнья күрде. С. Х. Алишев аның редколлегия әгъзасы буларак китапны бастыруда актив катнаша.

1989 ел тарихчы өчен вакыйгаларга бай ел була. Ул елны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты оешуга 50 ел тула. Институтның 50 еллык эшләренә йомгак ясау йөзеннән аның тарихи үткәнен яктырту ихтыяҗы туа. Шул унайдан "Эзләнүләргә һәм ачышларга 50 ел" дип аталган китапны чыгаруда да С. Х. Алишев редколлегия әгъзасы, басманы оештыручы-җыештыручы буларак шактый файдалы хезмәт башкара. Китап вакытында чыга.

Тарихчы тырышлыгы белән 1993 һәм 1994 елларда Казанда "Источники по истории Татарстана" исемле китапның I һәм II кисәкләре дөнья күрә. Ул китаплар тиз арада укучылар, фәнни хезмәткәрләр, вуз укытучылары арасында таралып та бетә.

Анарчы галим тормышында күренекле бер вакыйга булып ала. 1987 елда ул 6 айлык түләүле иҗат ялы ала һәм үз вакытында якланмый калган докторлык диссертациясен яңадан үзгәртеп төзи. 1988 елның язында исә Мәскәүдә, СССР Фәннәр академиясенең Тарих институты гыйльми советында беренче зур тикшерү була. Анда галимгә Казан ханлыгы чорын төшереп калдыр, монда чагыштырулар Бөек Мәскәү кенәзлеге файдасына түгел",—диләр һ. б. Шул ук елның көзендә икенче тикшерү дә була. Диссертацияне кабул итәләр. "1989 елда якларсың"—диләр. Ләкин... күп тә үтми "1989 елда безнең үзебезнең кешеләр докторлык диссертациясен өлгертәләр икән, сез инде 1990 елга каласыз",—дигән хәбәр алына. Кая барсын, ул инде түзәргә дә, көтәргә дә күнеккән. Хәерле булсын, 1990 елда "Среднее Поволжье в XVI—первой половине XIX века" дип аталган диссертация уңышлы яклана.

Шул ук елда ул "Исторические судьбы народов Среднего Поволжья в XVI—начале XIX в. " исеме белән Мәскәүдә китап булып та басылып чыга. Китапка рецензиясендә Йошкар-Ола галиме Г. Н. Айплатов: "Бу китап бик файдалы, ул Урта Идел буе халыкларының элеккеге тормыш-көнкүрешен, рухи мәдәниятен белеп язылган",—дип бәяли. Ә менә Германиядә яшәүче немец галиме А. Каппелер болай ди: "Китаптагы каршылыклар татар тарихчысының ташламалар ясарга тиеш булганлыгын күрсәтәләр. Бу хәлнең 1989 елда, китап "Наука" нәшриятында яткан чагында да саклануы, Мәскәүдә традицион руссоцентризм стереотипларының никадәр тормышчан икәнлеген искәртәләр".

Тарих фәннәре докторы, профессор, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре Җәмил Ибраһим улы Гыйльманов , каты авыру сәбәпле, 1987 елдан башлап бүлек мөдире вазифаларын башкара алмый башлый. Аңа кадәр дә мөдирнең уң кулы булган С. Алишевны 1989 елда аны мөдир вазифаларын башкаручы итеп билгелиләр. 1990 елда исә мөдир итеп сайлыйлар.

С. Алишев Институтның, республиканың иҗтимагый, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Ул озак еллар буенча "Белем" җәмгыятенең институт оешмасы рәисе, республика идарәсе каршындагы тарихи-методик бюро әгъзасе булып тора. Районнарга, авылларга да чыгып, халык алдында бик күп лекцияләр укый.

1989 елның көзендә, аның бүлмәсенә бер яшь иптәш белән студентлык елларыннан ук курсташ дусты Марат Мөлеков килеп керә. Яшьтәше: "Сәлам, әйдә 1967 елда сөйләшенгән эшне башлыйбыз",—дип сүз ката. "Мин дә шундый уйларда",—дип җавап бирә С. Х. Алишев. Ә нинди сөйләшү соң 1967 елда? Берничә үзара дус, яшь галимнәр Марат Мөлеков, Индус Таһиров, Рафик Гарәфетдинев, Сәлам Алишев, Рәмзи Вәлиев җыелышалар да, бер өйгә кереп яшертен гәп куерталар. Байтак фикер алышу, зарланулар, халыкның хокуксызлыгы турында сөйләшүләр була. Автономия кысаларыннан чыгып, Татарстанны союздаш республика итү өчен көрәш юлына басарга, дигән фикергә киләләр. Аның өчен яшерен оешма төзеп, шул идеяны

тормышка ашыру өчен иҗтимагый хәрәкәт җәелдерергә, дигән тәкъдимнәр калыплаша.

Тавышлар икегә аерыла.

Бераүләр:—Фикеребезгә тугры калуга каныбыз белән имза куеп ант итик!..—диләр.

Икенчеләр:—Кирәкмәс, балалар уены уйнамыйк,—дигән караштa торалар.

Шулай итеп, яшерен оешма төзелми, пропаганда җәелдерелми кала. Шартлар әле тумаган була.

1989 елда инде "үзгәртеп корулар чоры" башланган була. Марат Мөлеков "Институттан кемнәрне тәкъдим итәсен?—дип, С. Алишевтан рекомендацияләр ала да, озакламый Казан дәүләт университетының зур бер аудиториясендә Татар иҗтимагый үзәгенең оештыру җыелышын уздыра. Оешманың идарә әгъзалары сайлана. Бу идарә советына тарих һәм аны пропагандалау бүлеге җитәкчесе итеп тәгаенләнгән С. Алишев та кертелә. Идарә советы иҗтимагый үзәкнең беренче корылтаена кадәр эшли. Анарчы оешманың рәисе булган М. Мөлеков исә корылтайда Татар иҗтимагый үзәгенең президенты итеп сайлана. С. Алишев алга таба да иҗтимагый хәрәкәттә республиканың сәяси тормышы куйган төрле мәсьәләләр буенча язылган мәкаләләр белән катнаша.

1989 елның май аенда филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллин С. Алишев янына кереп "Җир шарында иминлек һәм тереклек өчен көрәшүче рыцарьларның бөтендөнья конфедерациясе", дигән оешма бар. Үзем аның әгъзасы. Мина яна әгъзалар тәкъдим итү вәкаләте бирелгән. Менә документлар белән таныш. Риза булсаң анкетаны тутыр",—дип аны шул конфедерациягә өнди. Сәлам ага риза була. Бер елдан соң конфедерация аны "Асыл кош" ордены белән бүләкли, конфедерациянен бөек парламент Советына әгъза итеп кертә. Ә 1992 елда ул "Рыцарьларның күк тасмалы йолдызы" орденына лаек була. Ана гражданлыклык, Австралия конфедерациясендә яшәү хокукы бирелә. Бу соңгы хокук, бәлки, "Алишевны СССР да эзәрлекли торганнардыр", дигән уйдан да килеп чыккандыр. Ләкин андый эзәрлекләүләр чынлыкта булмый. 1990 еллар башы сәяси яктан катлаулы була. Иҗтимагый хәрәкәт иң югары ноктага күтәрелә. Шул ук вакытта республика кораллы агрессия куркынычы астында да кала. Галим тулы мөстәкыйльлек алу өчен шартларның әле һаман туып җитмәгәнлеген аңлый һәм шулай була да: 1995 еллардан республика яңадан элеккеге кебек бәйле, ярымколониаль дәүләт булып кала.

1990 елларда С. Х. Алишев тарих бүлегенең мөдире буларак оештыру эшендә актив хезмәт күрсәтә. Фән өлкәсендә үзенең күп кырлы эшчәнлеген дәвам иттерә.

Татар һәм рус вакытлы матбугат битләрендә күпсанлы фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләренә, җыентыкларда басылып чыккан язмаларына тукталмыйча, соңгы еллардагы зур күләмле хезмәтләре турында берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр. Иң башта ул электән килгән фәнни юнәлешен дәвам итеп, репрессия корбаны булган татар тарихчысы Һади Атласиның тарихи әсәрләрен кириллицага күчереп бастыру эшен башкара. Атласиның галим мөхәррирлегендәге "Себер тарихы", "Сөенбикә", "Казан ханлыгы" дигән тарихи рисаләләре 26 табак күләмле (448 бит) китапка җыйналып бастырыла. Шуның белән тарихчы Һ. Атласи да тарих фәнендә үзенең мөхтәрәм урынына утыртыла. Китап матбугатта унай бәя ала. С. Алишев үзе дә Академиянең бер җыелышында: "Мин атып үтерелгән татар тарихчыларының (Г. Ибраһимов, Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласи) әсәрләрен дөньяга чыгаруым белән үзем язган китаплар белән шикелле үк бертигез горурланам",—ди. Шул ук 1993 елда аның мөхәррирлегендә урта мәктәпнең 5-6 класслары өчен тәгаенләнгән "Татарстан тарихыннан хикәяләр" (авторлары: Г. Дәүләтшин, Ф. Хуҗин, И. Измайлов) дигән дәреслек тә басылып чыга. Ул фәнни нигездә эшләнгән һәм Мәгариф Министрлыгы тарафыннан расланган булса да, киң кулланылышка кертелми кала.

1994 елда шулай ук аның мөхәррирлегендә, галимнең кереш сүзе белән "Татар тарихы: онытылмас сәхифәләр" дигән (тарих дәресләренә өстәмә әдәбият буларак тәкъдим ителгән) уку китабы дөнья күрә. Алар бу басманы тарих фәннәре кандидаты (хәзер тарих фәннәре докторы) Равил Әмирханов, тарих, әдәбият белгече Әнвәр Хәйруллин белән берлектә әзерлиләр. Күренекле тарихчыларыбыз Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, Әхмәтзәки Вәлиди хезмәтләренең аерым өлешләреннән төзелгән бу җыентык татар халкы тарихының борынгыдан башлап XIX йөзгә кадәрге чорын үз эченә ала. Укучыларны халкыбыз тарихы, мәдәнияты, гореф-гадәте, дине һәм әдәп-әхлагына караган кыйммәтле чыганаклар белән таныштыра.

1995 елда С. Алишев "Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV-XVI вв. " дип аталган китап бастырып чыгара. Бу китап диссертация эшендә һәм "Исторические судьбы народов... "китабында әйтелмәгән яки төшереп калдырылган мәсьәләләрне кире кайтарып һәм өстәп языла. Ул Рус дәүләтенең тулысынча агрессив тышкы сәясәт үткәрүен, башка халык җирләрен яулап алу бу сәясәтнең төп максаты икәнлеген ачып бирә. Автор Казан ханлыгының оешуын, үсүен, аның җирле халкын күздән кичергәннән соңында ике дәүләт арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләргә, дипломатик хәйләкәр дошманлык, кўралмаучылыкларга туктала. Казанның мөстәкыйль дәүләт булып калу өчен көрәш-сугыш ысулларын, вакыйгаларның Казанның, ханлыкның яулап алынуы белән тәгәлләнүен күп төрле чыганаклар җирлегендә тасвирлый. Китап 10 табак кына булса да, бай эчтәлекле һәм бер утыруда укыла торган әсәр. Хезмәт матбугатта югары бәяләнә. Мәсәлән, китапка язган бәяләмәсендә Татарстан фәннәр академиясе академигы Әбрар Кәримуллин болай ди: "Бу хезмәтне мин болгар-татарларның бәйсезлек, азатлык өчен көрәшенең трагик эпопеясы, дип атар идем. Шуның өстенә ул—урыс империясенең талау, басып алу, геноцид сәясәтен тасвирлаучы гаепләү акты буларак та актуаль тикшерү".

Ә менә шул ук елда бастырылган "Материалы по истории татарского народа" дигән китап Татарстан фәннәр академиясе акчасына оештырылган вакытлы хезмәт коллективы тарафыннан эшләнә. Ул берничә ел дәвамында, озак төзелә, чөнки авторлар коллективын оештырырга, аерым каршылыкларны җиңәргә кирәк була. Бу эшләрдә дә башлап, әйдәп йөрүче С. Алишев була. 31 табак (496 бит) тәшкил иткән бу китапны язуда 15 галим катнаша. Ә Сәлам ага исә "Казан ханлыгы: барлыкка килүе һәм үсеше", "Татар халкының оешуы", "Татарларны Рус дәүләтенең яулап алуы", дигән өч зур әһәмиятле бүлекне яза.

Китап татар халкының этногенезы проблемалары, Болгар дәүләте, Алтын Урда тарихы, Рус патшасының милли, сыйнфый сәясәте, халкыбызның демографик үсеш, милләт булып оешу мәсьәләләре, Әстерхан татарлары һәм совет чоры тарихының кайбер өйрәнелмәгән яклары белән таныштыра.

1990 еллар уртасында фәнни тикшеренү эшләре планы нигезендә тарих бүлегенең төп юнәлеше итеп Татарстан һәм татар халкы тарихын өйрәнү билгеләнә. Аңарчы бүлек тә, Институт та бары тик Татарстан тарихы белән шөгыльләнергә тиеш иде. Чөнки шул чикләрдән чыгып тикшеренүләр тыелган була.

Хәзер инде Рәсәйдә генә түгел, бөтен җир шарына чәчелгән татар халкының тарихын язу бурычы килеп баса. Берүк вакытта элегрәк планлаштырылган, 4 томнан 3 томга калдырылган "Татарстан республикасы тарихын" да язып тәгәлләргә кирәк була. С. Алишевның 90 елларда кайгырткан һәм хезмәт куйган төп эше әнә шул "Татарстан Республикасы тарихы" һәм "Татар халкы тарихы" булды. Бу фундаменталь хезмәтләрдә ул күпьеллык тәҗрибәсеннән һәм тирән гыйльми белеменнән чыгып үзе өчен какшамас принципиаль мәсьәләләрне хәл итә. Мисал өчен берничәсенә тукталып үтик:

—Татарлар этнос буларак җирле төркиләрдән, болгар һәм кыпчак кабиләләреннән абориген халык булып оешканнар. Татар этнонимы аларга соңыннан тагылган. Бу фикерне ул инде 30 елдан артык үткәреп килә.

Урта гасырлар татар җәмгыяте тормышында феодаль монархия хакимлек иткән, ләкин крепостнойлык булмаган. Рус дәүләте кул астында калгач кына крепостнойлык тәртипләре урнаштырылган.

—Ислам дине һәм аның мәдәнияты яшәешнең барлык өлкәләрендә, халык булып оешу һәм үсеш процессында бик зур, уңай роль уйнаган.

—Казан яулап алынгач ук Рус дәүләтенең колониаль изү сәясәтенә каршы Урта Идел буе халыкларының, беренче чиратта татарларның, милли азатлык хәрәкәте башлана. Бу хәрәкәтнең төп күрсәткече булып төрле елларда хан сайлап кую тора. Тора-бара милли азатлык хәрәкәте сыйнфый көрәш белән тыгыз бәйләнеп үскән.

Шул рәвешчә, С. Х. Алишев электән килгән тарихи нәтиҗәләрне ныгыта. Соңгы (әлегә кульязма) китабында да ул шул нәтиҗәләрдән тайпылмый. Рус телендә аның бу китабы: "Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа во II пол. XVI-XIX вв." дип атала. Ул китап та басылып чыгар дип ышаныйк.

**Рәшит ГАЛЛӘМОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

*Beznen̡ kalendar'*

## Ƣabdraxman Səƣdinen̡ tuuьna 110 jьl

Jegermence jьllardaƣь ədəbi xərəkəttə aktiv qatnaşqan həm tatar ədəbi tənqite formalaşuƣa çitdi ɵleş kertkən kyrenekle tənqitce, ədəbiat ƣalime, filolog həm pedagog Ƣabdraxman Səƣdi (Ƣabdraxman Ƣajnan ulь Səƣdief) 1889 jьlnьn̡ 14 martьnda elekke Ufa gubernasь Zlatoust ɵjəze Tajmi awьlьnda mədərris ƣailəsendə tua. 1902-1906 jьllarda Troisk mədrəsəsendə uqьj, anda ƣərəp, farsь, tɵrek telləren ɵjrənə, kɵncьƣьş xalьqlarь tarixь, fəlsəfəse belən qьzьqsьna. Mədrəsəne təmamlaƣac, tuƣan jaqlarьnda ike jьl mɵƣəllimlek itə. 1908-1911 jьllarda Istanbul universitetьnda uqьp qajtqac, Fevral' inqilabьna qədər Urta Azia, Aqtybə, Alma-Ata, Jekaterinburg, Bɵgelmə həm başqa şəhərlərdə balalar uqьta. Ədəbi-pedagogik içat eşcənlegen də ul şul corda başlap çibərə: 1910 jьlda "Şura" žurnalьnda jəş ədip-mɵƣəllimnen̡ "Ədəbiatьbьznь mədrəsələrdə uqьtu" isemle berence metodik məqələse dɵnja kyrə. 1911 jьlda Ufada "Qawaƣide ədəbiat" ("Ədəbiat qaƣidələre"), 1912 jьlda Orenburgta "Ədəbiat ьsullarь" digən xezmətlərе ajьrьm kitaplar bulьp basьlьp cьƣa. Avtornьn̡ tatar telen ɵjrəny həm uqьtuƣa qaraƣan xezmətlərе həm 1912-1915 jьllar arasьnda "Şura" žurnalьnda basьlƣan məqələlərе də yz waqьtьnda zur qьzьqsьnu ujatalar.

1921-1925 jьllarda Ƣ. Səƣdi Taşkentta jəş həm Urta Azia dəylət universitetьnda tel-ədəbiat uqьta, gazeta-žurnallarda tɵrki ədəbiatlar tarixьna qaraƣan kypsanlь ədəbi-tənqit məqələləren bastьra.

1925 jьlnьn̡ kɵzendə Ƣ. Səƣdi Qazanƣa qajta. 1925-1930 jьllar arasьnda ul başta Tatar kommunistlar universitetьnda, annarь Kɵncьƣьş pedagogiə institutьnda tatar tele həm ədəbiatь uqьta, dotsent (1927), professor (1929) dərəçəsen ala. Şul jьllarda tənqitce-ƣalimnen̡ ədəbiat tarixьn həm ədəbi kyreneşlərne tikşergən "Tatar ədəbiatь tarixь" (1926), "Proletariat diktaturasь dəwerendə tatar ədəbiatь" (1930), "Simvolizm turьnda" (1932) isemle kitaplarь həm "Tatar teatr ədəbiatь həm anьn̡ ysy tarixь" (1926), "Ədəbiatnь çəmƣiət beleme belən baƣlau" (1926), "Ədəbiat uqьtu təçribəse" (1926), "Fatix Əmirxan" (1926), "Qandalьj turьnda" (1927), "Bezdə ədəbi tənqit" (1927), "Ƣalimçan Ibrahimof həm anьn̡ ədəbi içatь" (1928) həm başqa məqələlərе basьlьp cьƣa. Bu xezmətlər yzlərenen̡ baj faktik materialь, içtimaƣьj ədəbi protsesslarƣa, ajьrьm jazucьlarnьn̡ içatьna birelgən analizlarь nətiçələrе belən əle də əhəmiətləren juƣaltmaƣannar həm tatar ədəbiatь tarixcьlarь ɵcen qimmətle cьƣanaq rolen ytilər.

1930 jьlda Ƣ. Səƣdi janadan Yzbəkstanƣa kitə. Taşkenttaƣь, Səmərqandtaƣь universitetlarda professor bula.

"Nəwoi içatь—yzbək klassik ədəbiatьnьn̡ juƣarьƣь etabь" isemle xezmətе nigezendə doktorlьq dissertatsiəse jaqlьj.

Ƣabdraxman Səƣdi 1956 jьlnьn̡ 6 nojəbrendə Səmərqand şəhərendə wafat bula.

## Rinat Rəximofnьn̡ tuuьna 60 jьl

Şaƣir Rinat Rəxim ulь Rəximof 1939 jьlnьn̡ 17 martьnda Tatarstannьn̡ Arca rajonь Urta Sərdə awьlьnda kolxozcь ƣailəsendə tua. 1956 jьlda Biektau

rajonьndagь Mylmə urta məktəben təmamlagannan son, tugan awьlьnda ber jьl kolxozcь bulьp eşli. 1957-1962 jьllarda M. Gor'kij isemendəge Qazan awьl xuçalьgь institutьnьn agronomiə fakul'tetьnda uqьj. Anь təmamlagac, əc jьlga jaqьn Tatarstannьn Pitrəc rajonь Il'ic isemendəge kolxozda baş agronom, 1965 jьldan 1973 jьlga qədər xuçalьq rəise bula. 1973-1980 jьllarda R. Rəximof şul uq rajonnьn awьl xuçalьgь idarəsendə ølkən agronom-meliorator, annarь sugaru berləşməsenen baş agronomь həm sonьnnan çitəkcese bulьp eşli. 1980-1984 jьllarda janadan şul uq berləşmənen baş agronomь wazifalarьn başqara.

R. Rəximofnьn ədəbi içat julь urta məktəptə uqьganda başlana. Student jьllarьnda ul "Tatarstan jəşləre" gazetasь qarşьnda ədəbi tygərəkkə jөri həm şul uq gazetada berence şigerləren bastьra. Berence møstəqil kitabь—"Tormьş atomnarь" isemle şigerlər çьjьntьgь 1964 jьlda dønja kyrə. Annan son "Saban turgajь", "Tugan çirem" həm urьs telendə "Тепло земли" isemle şiger kitaplarь basьlьp cьga.

Awьlda tuьp-yskən, kendege belən awьlga berekkən R. Rəximof awьlnь, çir xezməte keşelərenen tormьşьn biş barmagьdaj jaxşь belə, awьlda bargan yzgəreşlərne həm əledən-əle bulьp tora torgan problemalarnь neckə sizemli ide. Anьn poeziəse də ənə şul yze qajnap jəşəgən tormьş materialьna nigezlənep, "tugan tufraqtan şьtqan çьrlar" bulьp jangьradь.

R. Rəximof 1984 jьlnьn 16 avgustьnda wafat buldь.

R. Rəximof 1972 jьldan SSSR jazucьlar berlege əgzasь ide.

---

# Зөлфәт Хәким

## Уйлар уйнавы...

* Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ясалмалылыгы гына ясалма түгел.

* Берәр тавыш ишетелсә як-ягыңа карарга ашыкма. Иң элек үзенә колак сал—синең үзеннән килми микән ул аваз.

* Күзгедәге сурәтемә ышанып өчен мин күзгегә ышанырга тиеш...
Нинди бәйлелек! Нинди әсирлек! Нинди көчсезлек!

* Кешене хаерчелек үзе түгел, ә бәлки башкаларның аңа: "Хаерче!"—диюләре куркыта.

* "Кешеләрне яратам!"—дигәннәрен еш ишетәм.

Гомумән алганда инсаният мәхәббәткә лаек түгел. Аерым алган кешеләрне генә ярату мөмкин. Аерым алган шәхес бөтен кешелек дөньясына караганда кызыграк.

Бөтен инсаниятькә мәдхия җырлаучы, минемчә, шәхесләрдән "качып" өчен, алардан үзе өстен булу нияте белән яки аерым алган кешегә ярдәм итәргә теләмәүдән (һәм көченнән килмәүдән) "халык", "кешелек дөньясы", "кешеләр" дигән һ. б. төшенчәләр белән сату-алу итә.

* Үткәннәре түгел, бүгенгесе бөек булса гына халык бөек санала.

* Өндәүчегә игътибар белән карасаң күрерсең: кешеләрдән үзендә житенкерәмәгән сыйфатларны таләп итә ул.

* Һәрбер сагыну—үзеңне сагыну.

# Укучы сүзе

"Казан утлары" журналының 1998 елгы 11 нче санында Әсрар Галинең "Лаеш шулпасы" дип аталган мәкаләсен (без аны нәкъ шулай кабул иттек, хикәя дәрәҗәсенә күтәрелгән матур әдәбият әсәре булудан шактый ерак) укып чыктык. Ул Сингел *(әсәрдә Тауширмә)* мәктәбенең 40 еллар буена алмашчысыз эшләгән директоры Хәйруллин Самат Хәйрулловичка *(әсәрдә Намат Каштанович)*, Лаеш райкомына, Лаеш роносына кара ягу ул.

Самат Хәйруллович Сингел авылына 1963 елны мәктәп директоры итеп билгеләнә. Ана хәзер 62 яшь, бөтен хезмәт һәм тормыш юлы шушы авыл белән бәйле. Бүген бу мәктәптә аның белән 35, 20, 15, 10 ар ел бергә эшләгән коллегалары, авылда ул тәрбия биргән йөзләрчә укучылары, күршеләре, авылдашлары исән бит. Аның намуслы хезмәтенең тере шаһитлары алар. Самат Хәйрулловичны төрле оешмалар тарафыннан бүләкләнгән медальләр, мактау кәгазьләре, мактаулы исемнәр бизи.

Ул—"Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы", хезмәт ветераны. Мактау кәгазьләре санап бетергесез: РСФСР Мәгариф министрлыгы, РСФСР "Белем" җәмгыятенең Татарстан Республикасы правлениесе, Татарстан Республикасы мәгариф министрлыгы, КПСС Лаеш райкомы һәм башкарма комитеты, Лаеш районы администрациясе башлыклары, Лаеш роносы һәм профсоюз тарафыннан тапшырылганнар алар, җәмгысе 2 дистәгә якын. Ә бит бу бүләкләр барысы да укыту-тәрбия эшендә ирешелгән уңышлар, партия һәм дәүләт органнарында актив эшчәнлек күрсәткән, тулы канлы пропагандистлык хезмәтләре өчен бирелгән. 1977 елда Лаеш районының иң эре "Комсомол" совхозы коммунистларының да зур ихтирамына лаек була: аны шушы хуҗалыкның партком секретаре итеп сайлыйлар. 4 ел буе бу хезмәтне дә намус белән башкара.

Гомумән, Самат Хәйрулловичны белгән, күргән, аның белән бергә эшләгән кешеләр аны хөрмәт итәләр, принципиаль җитәкче, оста педагог икәнлегенә иманнары камил. Яңа уку елына мәктәпне әзерләү буенча еллар дәвамында призлы урыннар алынуы, шушы авыр елларда укучыларны ашханәдә бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү дә иптәш Хәйруллин Самат Хәйрулловичның фидакарь хезмәтенең күркәм нәтиҗәсе ул.

Самат Хәйруллович—хатынының яраткан ире, балаларының сөекле әтисе. Сәкинә ханым белән өч бала тәрбияләп, ныклы белем биреп, ата-ана йортыннан фатиха белән олы тормыш юлына озаткан кешеләр. Оныкларының яраткан дәү әтиләре дә.

Журналда "...аның күңеле изгелектә, нияте яхшылыкта иде... Шушы сыйфатлары аның "Лаеш шулпасы" дигән хикәясендә дә ачык чагыла. Әсрар Гали бу әсәрен "Казан утлары" журналына үзенең ноябрь аенда булачак юбилее уңаеннан җибәргән иде" дигән юллар бар. Шунысы аяныч: Самат Хәйруллович әчкече, карак, шикаятьче булган икән, нигә соң бу ялган исемне Әсләм—Әсрар 32 ел дәвамында тишмичә торды икән? (Әсрар Гали бу мәктәптә 1967 елда 7 ай эшләп китә, дәресргә куыла). Әллә инде үләсен сизеп 1998 елның ноябрь аен көттеме? Мөгаен, үлгәннәр шикаять өчен җавап тота алмыйлар бит. Моны без эштән куылу сәбәпле үч алу дип аңлыйбыз.

Без Самат Хәйрулловичның намусына, эшчәнлегенә, тормышына кагылышлы кара ягуга каршылык белдерәбез, аның намуслы исеменә тап төшерелмәвен телибез.

Бергә эшләгән, эшләүче хезмәттәшләре, озак еллар дәвамында мәктәптә төрле вазифалар башкаручылар, укучылары, авылдашлары теләге ул.

Хөсәенова Р. М., Гайнетдинова С. М., Хөсәенова Г. Н.,
Шакирова Л. В., Сафина Р. Р., Хәйруллина С. З., Хәйруллина Д. Д.,
Ибраһимова М. Г., Гайнуллина М. Г., Галләмов Г. М., Сафина Ф. Г.

РЕДАКЦИЯДӘН:

*Лаеш районыннан алынган бу хатны без журналда бернинди үзгәрешсез бастырабыз. Хатка нинди дә булса аңлатма, комментарий бирү кирәк түгелдер. Әлеге хаттан китерелгән юллар язучының, гомумән, һәр калам иясенең үз хезмәтенә, әдәби иҗатка аеруча таләпчән булырга кирәклеген тагын бер кат искәртә. Ә редакция хезмәткәрләренә исә (гәрчә язма, ягъни хикәя, язучы фантазиясенә корылырга мөмкин булса да, бу очракта ул нәкъ шулай килеп чыккан да) мәрхүм Ә. Гали өчен гафу үтенергә генә кала.*

## РОССИЯ—ТАТАРСТАН: ШАРТНАМӘГӘ 5 ЕЛ

15 февральдә Татарстанның Федераль үзәк белән "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турында"гы Шартнамәгә кул куюына биш ел тулды. Шул уңайдан Казанда Татарстан Дәүләт Советы һәм ТР Фәннәр академиясе халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрде. Анын эшендә Россиянең милли сәясәт министры Р. Абдулатыйпов, РФ төбәк сәясәте министры В. Кирпичников, Россия Дәүләт Думасының Милләтләр эше комитеты рәисе В. Зорин, Россиянең төрле төбәкләреннән, БДБ илләреннән, чит илләрдән килгән сәясәтчеләр, галимнәр катнашты һәм чыгыш ясады.

ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин ТР Президенты М. Шәймиевнын конференциядә катнашучыларга котлавын игълан итте. ТР Фәннәр академиясе президенты, академик М. Хәсәнов "Татарстан Республикасы дәүләтчелеген торгызу этаплары һәм перспективалары", ТР Премьер-министры Р. Миннеханов "Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәне гамәлгә ашыру проблемалары" дигән темаларга докладлар белән чыктылар.

* * *

Мәскәүдә дә шартнамәгә кагылышлы байтак чаралар үткәрелде. Журналистларның үзәк йортында ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин Россия, Татарстан һәм чит ил журналистлары өчен "Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе һәм Россия федерализмы үсешендә анын әһәмияте" дигән темага матбугат конференциясе үткәрде.

Шул ук көнне Ак йортта бюджетара килешүне әзерләү буенча Россия-Татарстан хөкүмәтара комиссиясенең эшлекле очрашуы булды. Кичен исә Татарстанның Россиядәге даими вәкиллегендә Шартнамәгә кул куюга 5 ел тулу уңаеннан кабул итү оештырылды.

## М. ШӘЙМИЕВ—"ЕЛНЫҢ ИҢ ДИПЛОМАТИК ҖИТӘКЧЕСЕ"

"Ел профиле" дип аталган рейтинг нәтиҗәләре буенча (анда 200 тикшерүче катнашты) Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев "1998 елның иң дипломатик җитәкчесе" дигән махсус бүләккә лаек булды. Бу бәйгедә анын абруе, илдәге вәзгыятькә йогынты ясау сәләте, чит илләрдә билгеле булуы, эшмәкәрлектәге уңышлары, авыр хәлләрдә үз-үзен тота алу осталыгы һәм лидерлык сыйфатлары да искә алынды.

## ӘФГАНЛЫЛАР—ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

15 февральдә Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләрен чыгаруга 10 ел тулды. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты махсус карар кабул итте. Ул Әфганстандагы хәрби вакыйгаларда катнашучыларга һәм һәлак булганнарның гаиләләренә медицина ярдәме күрсәтүгә, аларны социаль яклауга юнәлдерелгән. Тиздән, шушы карар нигезендә, Әфганстан сугышында һәлак булганнарның "Хәтер китабы" да басылып чыгачак.

## ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫ ҖЫЕНЫ

11 февральдә Казанда, Г. Тукай музеенда татар зыялыларының чираттагы җыены булып үтте. Бөтентатар "Мәгариф" берлеге оештырган әлеге җыенда "Татар-башкорт мөнәсәбәтләре—бүгенгесе һәм киләчәге" дигән темага зур сөйләшү булды. Мәгълүм булганча, Башкортостан Республикасы парламентында "Телләр турында"гы Закон кабул ителеп тә, анда татар теленә "дәүләт теле" статусы бирелмәү татар җәмәгатьчелегендә зур борчылу тудырды. ( Билгеле булганча, бу статус башкорт һәм рус телләренә генә бирелгән иде). Шул уңайдан, җыенда катнашучылар татар-башкорт мөнәсәбәтләрен өйрәнү, анын тотрыклыгын саклау, бу юнәлештә эзлекле эш алып бару өчен Гыйльми-иҗтимагый үзәк булдыру турында карар кабул иттеләр һәм анын әгъзаларын

сайладылар. Бер үк вакытта Башкортостан Республикасы Президенты М. Рәхимовка "Телләр турында"гы Законны парламент кабул иткән эчтәлектә расламавын үтенеп, БР Президентын сайлау компаниясендә актив катнашкан Татарстан әдәбият һәм сәнгать әһелләренен мөрәҗәгате дә җибәрелде.

## МИЛЛИ МӘҖЛЕС ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим, Татар халкынын Милли Мәҗлесе эшләре буенча, сонгы вакытта байтак кына төбәкләрдә булып, татар-мөселман җәмәгатьчелеге белән очрашты. Әдип Сарытау мөфтие М. Бибарсов, Чувашстаннын халык язучысы, Чуваш мәдәният үзәге рәисе М. Юхма белән әнгәмәләште, Уфада Башкортостанда татар теле хокукларын яклауга багышланган митингта катнашты, татар милли хәрәкәте корылтаенда чыгыш ясады. Екатеринбургта ул Татарстаннын даими вәкиллегендә татар милли-мәдәни автономиясе активистлары белән очрашты, "Космос" мәдәният үзәгендә күренекле җырчыларыбыз И. Шакиров, З. Шәрифуллина концертында катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе 1999 ел өчен республикабызнын Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә күренекле язучылардан Әхсән Баяновнын "Урланган ай" һәм Зөфәр Фәтхетдиновнын "Афоризмы и максимы" китапларын тәкъдим итте.

* * *

ТР Язучылар берлегенен Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләгенә быел Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры—танылган язучы Рәфкать Кәраминен "Каргышлы этаплар" дигән романы лаек булды.

* * *

Идарә утырышында, Татарстан Язучылар берлегенә яна әгъзалар итеп, шагыйрә һәм публицист—Асия Юнысова ("Ватаным Татарстан" газетасы), прозаиклардан Фирдәвес Зариф ("Мирас" журналы) һәм Мансур Шаһимәрдән, публицистлардан—фәлсәфә фәннәре докторы Айдар Юзиев һәм Мәгъсүм Гәрәев ("Чаян" журналы) кабул ителде.

## ӘГЕРҖЕДӘ—ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

29-30 гыйнвар көннәрендә Әгерҗедә, район хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе башлангычы белән, "Татар әдәбияты көннәре" үткәрелде. Р. Мөхәммәдиев җитәкчелегендәге бер төркем әдәбият әһелләре (делегация составында Г. Ахунов, И. Юзеев, Ә. Гадел, Р. Низамиев, Н. Кәримова, Ш. Мостафин, К. Кәримов, М. Гәрәев һ. б. бар иде) ин элек район үзәгендә "Шигърият", "Проза, драматургия, публицистика" остаханәләренен берләштерелгән күчмә утырышын үткәреп, җирле авторлар иҗатына җентекле анализ ясадылар. Шулар арасыннан ике кеше—Чынгыз Мусин белән Габдулла Галиев, Татарстан Язучылары берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителделәр. Район мәдәният йортында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдән сон, кунаклар, төркемнәргә бүленеп, Тирсә авылында татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әнисә Кәримованын һәм Салагышта Чаллыда яшәп иҗат итүче Наилә Хөрмәтованын яна китапларын тәгъдир итү бәйрәмнәрендә катнаштылар, данлыклы Иж Бубый авылы мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән дә очраштылар.

Әгерҗедәге әдәбият бәйрәменә Удмуртиянен Мәгълүмат һәм матбугат министры урынбасары Н. Касыймова җитәкчелегендәге делегация дә килгән иде.

## ВЕТАКАДЕМИЯДӘ—ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Журналыбызнын даими авторы—Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенен 47 яшьлек профессоры, фәннәр докторы, Татарстаннын атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Рифат Җамал улы Корбанов гыйнвар аенын тәүге көннәреннән әлеге данлыклы уку йортынын ректоры вазифаларын башкаручы итеп билгеләнде.

## Р. ФӘХРЕТДИН ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетынын Лениногорск бүлекчәсе һәм бирeдәге "Заман сулышы" газетасы редакциясе мәшһүр әдип, тарихчы, педагог, галим, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге премия булдырган иде. Әлеге бүләк татар халкы тарихын, шул исәптән туган як тарихын өйрәнүче шәхесләргә һәм аерым коллективларга ике елга бер мәртәбә бирелә. Быел—Р. Фәхретдиннен тууына 140 ел тулган көннәрдә—әлеге мәртәбәле премия филология фәннәре докторы М. Әхмәтҗановка (Казан) һәм Лениногорск районынын Түбән Чыршылы мәктәбе коллективына (директоры—Р. Сафина) бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# РӘССАМ ҮТКӘН ЮЛ

Рәшит Имашев тумышы белән җырларда җырланган гүзәл Дим буйларыннан."Димдә туып, Димдә үсеп, Дим тугайларында җиләк җыеп" үскән Рәшит агай, Уфадагы интернат-мәктәпне тәмамлагач (хәзер ул башкорт гимназиясе), Казан сәнгать училищесына укырга керә. Биредә ул яхшы кулларга "эләгә", ләкин үзе дә кул кушырып ятмый—махсус хәзерлеге булмаган егет, Казан мәктәпләрен бетереп килгән "зубр"лар арасында югалып калмас өчен, рәсем сәнгатенең төрле өлкәләрендә көчен сынап карый: гипстан сыннар коя, акварель техникасын үзләштерә, карикатуралар иҗат итә. Беренче курста укыган вакытында ук, ягъни 1959 елда, "Чаян" журналында беренче рәсеме басылып чыга. Журналның баш рәссамы Павел Новичков шушы танышудан соң, аңа булачак карикатураның темасын үзе табышып, осталык буенча киңәшләрен биреп, юл күрсәтеп тора. Өченче курста укыганда инде ул училищеның иң сәләтле укучылары рәтенә баса. Шулай итеп, диплом яклар көннәр дә килеп җитә. Диплом җитәкчесе Рәшит Төхфәтуллин, танылган рәссам булу өстенә, гаҗәеп кайгыртучан остаз да буларак (адашлар да бит әле), Рәшитне тулаем үз канаты астына ала. Укучысына фатиха биреп, нефть чыккан якларга сәяхәткә җибәрә. Бу сәяхәт бушка китми, Рәшит Имашев аннан алган тәэсирләр нигезендә майлы буяу белән "Авыл укытучысы" дигән беренче зур картинасын яза. Училищены "бик яхшы" билгеләренә тәмамлаган яшь рәссам, нишләргә икән дип озак уйланып тормый, Мәскәүнең В. И. Суриков исемендәге сәнгать институтына укырга барып керә. Дейнека, Иогансон кебек данлыклы рәссамнар остаханәсендә осталыгын чарлаган егет зур сәнгатьтә үзенә урын даулый башлый.

"Детгиз" нәшриятының СССР халыклары әдәбияты редакциясе редакторы—якташ апасы Галия Рахманкол кызы Кәримова аны китап, әдәбият дөньясына алып керә, китапларын бизәгән чорда Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Давид Көгелтинов, Мостай Кәрим кебек күренекле шагыйрьләр белән таныштыра һәм шушы чорда Рәшит агай, рәссам буларак  таныласың килсә, кешеләр белән аралашып яшәргә кирәк икән, дигән хакыйкатьне үзләштерә.

Мәркәзи Казанга кайткач ул баштанаяк эшкә чума. Заман темасына язылган колоритлы картиналары белән күргәзмә арты күргәзмәләрдә катнаша. Аның эше утыздан артык күргәзмәгә куела. Әдәбият-сәнгать дөньясында кайнап яши. Ачык күңелле, җор телле Рәшит Имаш язучылар, журналистларның да, композитор, артистларның да үз кешесенә әйләнә. Абруй казана. Аңа "Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелә. Хәсән Туфан, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Нәҗип Җиһанов, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев, Заһид Хәбибуллин, Кайсын Кулиев портретлары галереясы татар рәсем сәнгатенең алтын фондында урын ала. Бүген дә ул остаханәсеннән чыкмыйча ике Равилнең—татар шагыйре Равил Фәйзуллин белән башкорт шагыйре Равил Бикбаевның портретларын яза.


**Наис ГАМБӘР**

**Тышлыкның беренче битендә:** Рәшит Имашевның "Рәссам кыз портреты" дигән картинасыннан фоторепродукция тәкъдим ителә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле язучы-фантаст Адлер Тимергалин.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Зиннур МАНСУРОВ. **Яшәү үзәне**.—Казан.—Татарстан китап нәшрияты.—1998.—320 бит. Тиражы—2000 данә.




Танылган шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зиннур Мансуровның бу китабында әдәби җәмәгатьчелектә унай бәя алган иң яхшы шигъри әсәрләр туплап бирелгән. Шулай ук, җыентыкта "Хозыр галәйһес-сәләмне эзләү", "Балкыш яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар", "Кылдан нечкә, кылычтан үткен" исемле поэмалар да урын алган. "Яшәү үзәне"—авторның моңа кадәр чыккан китаплары арасында иң күләмлесе һәм мәгънәви яктан да иң саллысы. Китап ахырында бирелгән мәкаләдә "Зиннур Мансуров өйрәнү һәм яшьлек чорларын үтеп, эзләнү аша үзенне раслау дигән олы бер иҗади дәверенә кереп бара" дип яза әдәбият галиме һәм язучы Тәлгат Галиуллин. Биш бүлектән торган бу китапның нәшрият мөхәррире—Ф. Зыятдинова, рәссамы—И. Азимов.

Фатих УРМАНЧЕ. **Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә**.—Казан.—Татарстан китап нәшрияты.—1998.—176 бит. Тиражы—5000 данә.




Төрле язма чыганаклардагы һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендәге мәгълүматларга нигезләнеп язылган бу китапта милләтебез тарихында тирән эз калдырган шәхесләр—Идегәй, Нурсолтан һәм Сөембикәнең данлы һәм шул ук вакытта фаҗигале язмышлары хакында сөйләнә. "Безнең көннәрдә халык тарихына, шул тарихта зур роль уйнаган шәхесләргә игътибар көннән-көн арта, кинәя һәм тирәнәя бара. Чорның әнә шул үзенчәлеген истә тотканда, хәзер халык иҗатына, аның дастаннарына, риваять-легендаларына, бәетләренә дә янача килү таләп ителә, ди автор—фольклор белгече, профессор Фатих Урманче—үзенең кереш сүзендә. Китап заманча полиграфик ысулда, матур итеп бизәп чыгарылган. Бу китап киң катлау укучылар, тарихчылар, студентлар, милләтебез һәм дәүләтчелегебез тарихы белән кызыксынучылар игътиба-рына тәкъдим ителә.

Китапларны соратып алучылар игътибарына:

*420111, Казан, Бауман ур. 19.*
*Татарстан китап нәшрияты.*
*☎ 92-27-62; 92-00-13*

Индекс 73210



Адлер Тимергалин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-худ
и общественно-политическ
(на татарском язы